ЯГЪСУФ
ШӘФЫЙКОВ

# БЕР ОЧРАШУ–
# БЕР ГОМЕР

КАЗАН • ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ • 2002

ББК 76.12
Ш 30

**Шәфыйков Я.Д.**

Ш 30 Бер очрашу — бер гомер. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002.— 208 бит

Киң катлам укучыларга үзенең гаять дәрәҗәдә мавыктыргыч һәм үзенчәлекле әсәрләре белән таныш булган күренекле язучы һәм публицист, Халыкара Мәгълүмат Академиясенең әгъза-корреспонденты Ягъсуф Шәфыйков бу хезмәтендә Россиянең төрле төбәкләрендә яшәп, хезмәт итүче мәшһүр татарларның гыйбрәтле язмышлары турында сөйли.

Минтимер Шәймиев, Мансур Хәсәнов, Фикрәт Табеев, Ренат һәм Рәсим Акчуриннар, Ренат Ибраһимов, Гази Заһитов, Тинчуриннар нәселенең вәкилләре, имам Шамил оныклары, татар морзалары...

Татар тормышында алар тирән эз калдырган шәхесләр, олы шәхесләрнең варислары — бу китапта үзләренең күп кенә яңа сыйфатлары белән ачылалар.

ISBN 5-85247-094-5

© Шәфыйков Я.Д., 2002
© Татарстан китап нәшрияты, 2002

# Кереш сүз

Хөрмәтле укучылар!

Сезнең кулыгызда танылган язучы һәм публицист, каләм остасы Ягъсуф Шәфыйковның өр-яңа китабы. Авторның үзе белән таныштыру кирәк түгел дип уйлыйм, чөнки аның күпсанлы мәкаләләре, җәмгыятьнең үткәне һәм бүгенгесе турында язылган репортажлары, интервью һәм очерклары республика матбугатында даими басыла, автор укучыларының һәрвакыт күз алдында. Ул сигез китап авторы.

Бу тынгысыз язучы һәм публицист, үткер күзле каләм иясе, үз халкының тарихы, мәдәнияте, рухи дөньясы белән күптәннән кызыксына. Ягъсуф Шәфыйковның рус телендә «Я знаю одно чудо» дигән китабы басылу республиканың иҗтимагый тормышында сизелерлек вакыйга һәм үзенә күрә бер яңалык булды. Автор бу хезмәтендә мөселманнарның изге китабы Коръән-Кәримнең татар, рус телләрендә басылып, дөнья күргән тәрҗемәләре һәм шулай ук аларны тәрҗемә итүчеләр турында бик мавыктыргыч итеп яза. Тиздән ул «Мин бер могҗиза беләм...» дигән исем белән татар телендә дә басылачак.

Кадерле укучылар! Сез укырга җыенган бу җыентык «Бер очрашу — бер гомер» дип атала. Ул нәрсә турында дисезме? Безнең данлы үткәнебез, һәм бүгенге көнебез, кыскасы, һәммәбезнең һәм, гомумән, җәмгыятебез тормышы турында. Җыр сүзләре белән әйтсәк, «Бу — синең һәм минем язмыш, бу —безнең биография». Бу китап шулай ук безнең соңгы 10—15 елдагы тормышыбыз, аның әлегә кадәр җавапсыз калган сораулары хакында. Мәсәлән, элек СССР дип аталган бөек державаның бүгенге көне тарихи закончалыкмы, әллә гади буталышмы? Теге яки бу шәхес республика тормышында нинди роль уйнаган һәм тарихта нинди эз калдырган? Җир шарының алтыдан бер өлешен биләп торган ил халкының бүгенге яшәеше, хәле милли үзаңның алга китүеме, үсүеме, әллә һәлакәтеме?

Китапның авторы шушы сораулар белән үзенең әңгәмәдәшләренә — Татарстан Республикасы Президенты М.Шәймиев һәм КПССның Татарстан өлкә комитетының элеккеге беренче секретаре Ф.Табеев, Башкортстан Президенты М.Рәхимов, замандашларыбыз Акчуриннар —генерал-полковник Рәсим Акчурин һәм кардиохирург Ренат Акчурин, танылган җырчы Ренат Ибраһимов, татар һәм мөселман дөньясында күренекле танылган шәхесләргә мөрәҗәгать итә.

Ни өчен Ягъсуф Шәфыйков үзенең әңгәмәдәшләре итеп шундый танылган шәхесләрне генә сайлый икән дигән сорау туарга мөмкин. Бу күренекле, тәҗрибәле язучы һәм публицист гомерендә бик күп һөнәр вәкилләре, гади кешеләр, эшче, колхозчы, табиб, укытучылар турында теләп язды. Бөек Ватан сугышы солдатлары каһарманлыгы, аларның гыйбрәтле язмышлары, катлаулы тормышы аның иҗатында зур урын алып тора. Рейхстаг түбәсенә

Җиңү Байрагын кадаган гади солдат-милләттәшебез Гази Заһитов һәм аның полкташлары турында хикәя үзе генә дә ни тора!

Бүген ул Шәймиев һәм Табеев кебек күренекле шәхесләргә мөрәҗәгать итә. Моның сәбәбе бик гади: автор иң кискен үзгәрешләр чорында җәмгыятькә дөрес юлны күрсәтә алучы көчле рухлы кешеләрне тасвирлый.

Җыентыкның кулъязмасын укып чыгуга мин дустыма мондый сорау бирдем:

— Ник син шундый төрле кешеләрне бер китапка тупларга булдың?

— Ышанасыңмы, шушы китабымның геройлары белән очрашудан алган тәэсирләр китап язарга нык этәргеч бирде,— диде ул. — Аларның һәркайсы үзенчәлекле кешеләр: бай тормыш һәм идарә итү тәҗрибәсе туплаганнар, һәрнәрсәгә фәлсәфи карашлары бар. Минем алардан алган хисләремне башкаларга да җиткерәсем килде. Ник дигәндә, мондый кешеләр белән аралашу —язмышның зур бүләге һәм ул, кызганычка каршы, бар кешегә дә эләкми. Шуңа күрә мин үземнең язучы һөнәремә һәм язмышыма бик рәхмәтле.

Бу сүзләрнең дөреслегенә китапны укып чыккач, син дә ышанырсың, хөрмәтле укучы.

Йомгаклап, шуны да әйтәсем килә: Ягъсуф Шәфыйков журналистларның иҗат бәйгесе «Бәллүр кәлам-99» лауреаты булды, Татарстанда елның иң яхшы журналисты исемен алды.

Ягъсуф Шәфыйков безне — үзенең укучыларын — киләчәктә дә кызыклы язмалары, яңа китаплары белән гел сөендереп торыр, дип ышанабыз.

***Шамил Мулаянов***

## М.Ш.ШӘЙМИЕВ:

# «Җиребез барчабызга бер генә...»

**Авторның кереш сүзе.** Балачактагы вакыйгалар күңелгә тирән үтеп керә һәм йөрәктә урнашып кала. Балачак хатирәләрен еллар үткәч тә, таулар кичкәч тә баштан чыгарып ташлап булмый.

Актаныш районындагы туган авылым Түбән Карачта күп дистә еллар булганым юк иде. Әмма һәр язда сабан тургайлары сайравын ишеткәндәй булам. Күңелем шуларны юксына, сагына. Күзләремне йомам да, балачагыма әйләнеп кайткандай булам... Түбән Донның һәм Кубаньның иксез-чиксез далаларында, Нева ярларында, ерак Германия елгалары — Одер һәм Рейн калкулыкларында, кайчандыр социалистик режимлы Венгриядә шул тургайлар сайравын тыңлап хозурланганым бар.

Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә йөргәндә дә 40 градуслы эсседә балачак тургайларымның тавышын ишеткәндәй булдым. Колакларым ишеткәндәй булса да, күзләремне ачып карасам, тургайларны һич кенә дә күрә алмыйм. Ком чүлләрендә дөядән башка тагын ни күрә аласың соң?

Күп дистә еллар узгач, хыялым гамәлгә ашты. Әкияттәгедәй матур Агыйдел ярларына якын гына урнашкан туган авылымның басу капкасы янында торам. Кинәт баш очымнан тургайлар очып үтте. Күңел кылларымны тибрәтеп, сайрыйлар да сайрыйлар. Исәнме, тургаем! Балачак дустым, саумы!

Басу капкасыннан Калмаш авылына кадәрге ара бер чакрымлап булыр. Күрше авыл ул безнең. 1941 елның июль иртәсендә әтиемне сугышка озаткан чаклар искә төште. Ир-атларның: «Хуш, туган җиркәебез!» — дип саубуллашып китүләрен әле дә хәтерлим. Әтиләр китте, ә тургай минем белән калды.

Ул вакытлардан бирле күп үзгәрешләр кичердек. Төрле реформалар үткәрелде, яңалыклар кертелде. Ә халыкны кара ипигә дә туендыра алмадылар. Күпләр читкә китеп акча эшләү ягын карады.

Менә мин яңадан туган җиремдә басып торам. Кемнеке син хәзер, туган җирем? Агыйдел һәм Ык буйларында йөргәндә шулар турында уйланам. Шәһәр халкының да күбесе тамырлары белән крестьян гаиләсенә килеп тоташа бит. Актанышта, Тукай районында булганда да, Башкортстанның Илеш һ.б. төбәкләрендә, Уфада, Ижауда, Мәскәүдә йөргәндә дә гади авыл эшчәннәре, сука тоткан кешеләр, авылдашларым һич кенә дә исемнән чыкмый.

Каты бәхәстә күпләрнең җир язмышы турында хәтта оныта да барулары сизелә. Шуңа борчылам. Соңгы елларда Татарстан Республикасының матбугат басмаларында үзхәбәрче булып эшләгәндә күп җирдә булырга туры килде. Уңдырышлы Краснодар краеның, Ростов өлкәсенең бәя биреп бетергесез кара туфраклы җирләре эшкәртелми калган чаклар да булды. Аларны чүп-чар, куаклыклар басты. Ә менә туган Татарстанымның иксез-чиксез кырлары буйлап йөргәндә күңел сөенә: анда бер генә карыш җирне дә кадерсезләмиләр.

«Җиргә кем хуҗа булырга тиеш?» — дигән бәхәсләр күптән бара инде. Бөтен кешене канәгатьләндерә торган җавап биреп булмый бу сорауга. Бүген без бөек үзгәрешләр алдында торабыз. Шушындый катлаулы чорда үз көнелемдә туган һәм гади булмаган сорауларга җавап эзләп, мин Татарстан Республикасы Җир ресурслары һәм җир реформасы дәүләт комитеты рәисе А.А.Ефремов һәм аның беренче урынбасары Ф.В.Бариев, яңа шартларда авыл хуҗалыгы производствосын тәҗрибәле оештыручы, элекке Балтач район хакимияте башлыгы, хәзер исә премьер-министр урынбасары, республикабызның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры М.Г.Әхмәтов белән очрашып сөйләштем. Аннары юл-сәфәрләр мине Президентыбыз Минтимер Шәрип улы Шәймиев янына китереп җиткерде. Ул бик төпле кеше, Җир-Ананың проблемаларын яхшы белә. Бүген ул — Татарстанда Җирнең язмышы өчен, димәк, кешеләребезнең язмышы өчен җавап бирүче иң баш шәхес. Халык үзе сайлап куйган Президент. Җир турында аннан да яхшырак, төплерәк сөйләп бирердәй тагын кем бар икән? Чынлап та, кем?

Журналист һәм публицист буларак, гомумән, сукадан чыккан кеше буларак, үземне борчыган күп кенә сорауларга үз Президентыбыздан җаваплар ишетүемә бик шатмын.

## ПРЕЗИДЕНТ СҮЗЕ

**— Минтимер Шәрипович, Сезнең өчен җир нәрсә ул? Бу төшенчәгә Сез нинди мәгънә саласыз?**

— Кыскача гына әйтсәк, җир — минем өчен бөтенесе дә. Җир — яшәешнең нигезе. Авылда туып-үскән, беренче адымнарны туган җирдә ясаган һәм анда эшләгән кешегә бигрәк тә шулай ул. Безнең балачак сугыштан соңгы авыр елларга туры килде. Кече яшьтән үк, әле мәктәптә укый башламас борын ук, әниләребезгә, абый һәм апаларыбызга җир эшкәртүдә, бәрәңге алуда һ.б. эшләрдә булыша идек. Мәктәптә укый башлагач та җиргә берегеп үстек, колхоз басуларында өлкәннәргә булыштык. «Җир — дөнья тоткасы», «җир исе», «җир тире» — минем өчен бик таныш төшенчәләр. Сугыштан соңгы елларда кечкенә генә җир кисәге дә күпләрне ач үлемнән коткарып калды. Җиргә җаныңтәнең белән бирелеп хезмәт итсәң, ул сиңа тиешлесен бирә, бераү дә ач булмый. Җәмгыятьнең иминлегенә һәрчак нәкъ менә авыл кешесенең эш нәтиҗәсенә карап бәя бирелеп килде. «Икмәк — барысына да баш», дип тикмәгә генә әйтмиләр бит. Җир, икмәк — тормышыбызның нигезе.

Минем карашымча, без беркайчан да ата-бабаларыбызның васыятен онытырга тиеш түгел. Без җиргә кешелек цивилизациясенең иң кадерле бүләге итеп, Аллаһының бәя биреп бетергесез бүләге итеп карарга бурычлы. Җир — кешелек җәмгыятенең әхлакый башлангычы, дип әйтсәм дә ялгышмамдыр.

Балачактан ук мин җиргә ихлас булдым. Өлкәннәр ярдәмендә җирне кайчан һәм ничек сөрергә, кайсы вакытта чәчәргә өйрәндем, үз басуларыңа гына хас хисләр аша арышны яки бодайны кайчанрак ура башларга кирәклегенә төшендем. Казан авыл хуҗалыгы институтына

укырга керүем дә әтинең теләге иде. Хәер, үземнең күңелем дә шуңа күбрәк тартылды, күрәсең. Гәрчә минем гадел прокурорларга кызыгып яшәгән көннәрем дә булды, һәм моның нигезле сәбәпләре дә бар иде шул.

1949 елда, ачлык чорында, минем әтиемне аз гына төрмәгә утыртмый калдылар. Эш шунда, язгы чәчү чорында кешеләр ачтан күбенә, шешенә башлады. Чөнки яз — ачлар өчен иң авыр вакыт. Иске запас беткән, яңасы өлгермәгән чак. Колхоз басуларында язгы чәчүне дә үткәрәсе бар. Ә бит бөтен эш шешенгән аякларын көч-хәл белән өстерәп йөрүче кешеләр өстендә. Шулчак әтием җәмәгать туклануына ике центнер тары бирергә була. Кемдер шундук донос та язып өлгерә. Вакыты шундый инде — колхоз байлыгын әрәм-шәрәм иткән өчен унар елга утырталар иде. Кыскасы, район прокуроры «эшкә тотына». Әтине караңгы көзгәчә прокуратурага чакыртып азапладылар. Ә үлемнән коткарып калынган кешеләрнең язгы чәчүне уңышлы башкарып чыгуларын искә алучы кеше дә юк. Көзен бөртеклеләрдән заманына күрә яхшы гына уңыш алуның ярдәме тиде.

Әтием өчен бөтен авыл кайгырды. Ул чагында миңа 12 яшь иде. «Әтинең үзе өчен түгел, ә кешеләр өчен тырышуын бу прокурор нигә аңламый икән?» — дип уйлап йөрдем. Күрәсең, шул чагындагы кичерешләр инде гадел прокурор булу теләген тудыргандыр. Шул чагында мин дөньяда иң мөһиме — гаделлек һәм кешеләр турында кайгырту икәнлегенә төшендем.

Мөслим районы «Сельхозтехника»сының баш инженеры итеп билгеләнгәндә миңа нибары 23 яшь иде. Яшермим, башта миңа бик куркыныч булды. Миңа чәчләренә чал кергән ир-атлар, кичәге фронтовиклар, тәҗрибәле механизаторлар, токарьлар, тимерчеләр белән эш итәргә туры килде. Яшь белгеч буларак, миңа карата «ышанмаучылык бозы» бик тиз эреде. Мин, яшь авыл инженеры, үземә әти булырдай тәҗрибәле кешеләр белән эшләүгә зур игътибар бирдем, алардан исә тормыш тәҗрибәсенә өйрәндем.

Хәтеремдә әле, ул чагында без көне-төне кукуруз белән шөгыльләндек. Күпләр моны көлке дип кабул иттеләр. Чөнки Хрущевка кадәр Татарстан җирендә «кырлар патшасы» турында беркем берни белми иде. Мин һәм минем хезмәттәшләрем — механизаторлар кукуруз игү технологиясендә иң мөһимен — кырда квадратлар белән эшләү кирәклеген бик тиз аңлап алдык. Ә моны эшләве җиңел түгел иде. Хәтердә әле, ул чагында мин шундый метод эшләдем ки, теләсә кайсы техника белән квадратлар килеп чыга башлады. Һәм без республикада кукуруздан иң югары уңыш алдык.

Мине ВЛКСМның XIV съездына делегат итеп сайлаулары очраклы булмаган, күрәсең.

«Кырлар патшасы»на килгәндә, хәзер аны Татарстан җирләрендә үстерүнең максатка ярашлы булуына беркем дә шикләнмидер.

Шуннан соңгы елларда да минем бөтен тормышым җир белән бәйле булды. Димәк, җир — минем өчен кичә дә, бүген дә яшәешнең нигезе.

Теләсә кайсы дәрәҗәдәге күп кенә җитәкчеләрнең эшлеклелек сыйфатларына җиргә булган мөнәсәбәттән чыгып бәя бирәм мин хәзер. Җир —минем шатлыгым, өмет-ышанычым. Яшермим, кайчагында җир — хәсрәтләнүем дә, пошынуым да.

**Автор хатирәләре.** Туган җиребезне саклау өчен барган Бөек Ватан сугышы Мәскәүдән көнбатышкарак һәм көньяккарак җәелде. Авылда калган карт-коры, аптырашып, Гитлер Урал тауларына кадәр килеп җитү белән яный икән, дип ләчтит сата. Картларның шикләнүе өчен урын да бар: алар әле «сәнәк сугышы» көннәрен, ягъни Гражданнар сугышын хәтерлиләр. Ул чагында кызыл эскадроннар аклар гаскәрен Минзәлә, Пучы аша, Чат авылы һәм безнең авыл аша Агыйделгә таба куалар. Авыл картлары безнең Түбән Карач авылына авыр пушкалардан атуларын хәтерлиләр. Аклар Әҗәкүл пристанена кадәр чигенәләр, аларның максаты — атаклы адмирал Старк җитәкчелегендәге хәрби корабльләрдә акгвардиячеләрнең зур төркеме белән бәрелешү.

Агыйделнең шушы борылмасында берләшеп, аклар елга буйлап югарыга таба китәләр. Уфа тирәсенә эләгеп, Көнчыгышка таба чигенүче Колчак гаскәрләренә килеп кушылырга тели алар.

Гражданнар сугышы минем туган ягым — Актаныш җирләренә дә утлы өермә китерде. Күпме кан-яшь түгелде, якташларыбыз җәберләнде. Ата-бабаларыбыз җире, үз җирләребез өчен сугыш «Үлемгә —үлем!» дигән лозунг астында барды.

## ПРЕЗИДЕНТ СҮЗЕ

— Тормышта яхшысы да, яманы да җир белән бәйләнгән. Барлык халыкларның тарихы һәм яңа тарихыбыз шуны раслый. Кызганычка каршы, сугышлар да бит җир аркасында килеп чыга. Тынычлык һәм иминлек җиргә бәйле. Әгәр нык алга киткән дәүләтләрдән АКШ, Германия, Канада һ.б. илләрне мисал итеп алсак, шуңа инанырбыз: аларда яхшы көйләнгән, гел законнар файдасына эшләп торучы җиргә кагылышлы мөнәсәбәтләр урнашкан, игенчелек культурасы югары, терлекчелек менә дигән итеп оештырылган. АКШ авыл хуҗалыгында халыкның нибары 4 проценты, ә сусыз, корылыклы Израильдә 5 проценты эшли. Ә бит бу илләр азыкны зур күләмдә экспортлыйлар. Яисә тюльпаннар иле Голландияне алыгыз: гасырлар буена җир кишәрлекләрен океаннан йолып алып, икмәк, бәрәңге, яшелчә, чәчәк плантацияләреннән менә дигән уңыш җыялар. Биредә ике төп моментны күрсәтеп үтәсем килә. Беренчесе —алга киткән илләрдә җирнең үз хуҗасы бар. Хосусый милек хокукына ия булган чын хуҗа. Моннан исә икенче нәрсә килеп чыга: авыл хуҗалыгы өлкәсендә дә, авыл белән шәһәр арасында товар мөнәсәбәтләре өлкәсендә дә яхшы көйләнгән базар мөнәсәбәтләре яши аларда.

Әле берничә дистә ел элек Россия авыл хуҗалыгында хезмәткә яраклы бөтен халыкның 50 проценты шөгыльләнә иде. Ил ул чагында да үзен теләгәнчә ашата алмады. Бүгенге көндә Россия авыл хуҗалыгында 30 миллион кеше эшли (бөтен халыкның 20 проценты), ә хәл әллә ни үзгәрмәде.

Европа һәм Төньяк Американың шул ук алга киткән илләрендә промышленностьны алсак, ул да алга китүе, өстенлеге белән аерылып

тора. Чөнки аларда җир мөнәсәбәтләре әйбәт җайга салынган. Җир продуктларыннан башка промышленностьның теләсә кайсы тармагы (ул файдалы казылмалар булмасын яки игенчелек һәм терлекчелек продуктлары булмасын) нуль ул! Шик юк, монда төп фактор — җир мөнәсәбәтләре, ягъни җирнең кем кулында булуы зур роль уйный.

Кызганычка каршы, тарихи яктан шулай килеп чыкты ки, Россиядә җиргә мөнәсәбәт һәрчак берникадәр читкә этәрелеп килде. Минем тирәнтен инануымча биредә төп сәбәп — кешеләрнең җирдә чын хуҗа була алмавы. Җирнең чын хуҗасын билгели торган ачык закон юк бездә. Җир турында цивилизацияле закон юк.

Әйдәгез, саннарга күз салыйк әле. РФ Җир ресурслары һәм җир реформасы дәүләт комитетының соңгы мәгълүматларына караганда, бүген Россиядә 30 миллион гектар җир ташландык хәлдә. Алар хуҗасыз, эшкәртелми, язмыш карамагына тапшырылган. Шуның 10 миллион гектары сөрү җире бит югыйсә. Безнең республикада барлыгы 3,5 миллион гектар сөрү җире бар. Менә чагыштырып карагыз инде. Россиядә бүгенге көндә Татарстанның өч сөрү җире тулысынча ташландык хәлдә, дигән сүз бит бу.

Шул ук вакытта РФ Дәүләт Думасында кайбер өлкәләрдә һәм крайларда, җирне хосусый милеккә бирергәме яки юкмы, дигән мәсьәлә һаман да шик астына куела.

Миллионнарча гектар сөрү җире эшкәртелмичә ятканда, төп мәсьәлә — җиргә милек турындагы мәсьәлә хәл ителмәгәндә, һәртөрле азык-төлек программалары турында сүз куертуны әхлаксызлык дип саныйм мин.

Шул ук вакытта әйтергә тиешмен, нинди генә кыенлыклар булса да, безнең Татарстанда файдаланмыйча ятучы бер генә кишәрлекне дә очрата алмассыз.

**Автор хатирәләре.** Фронттан өчпочмаклы хатлар һаман азрак килә башлый. Алар урынына күп кенә өйләргә үлем турында кара кәгазьләр килә. «Хәбәрсез югалды...» дигәннәре дә аз түгел. Әтиемнең бертуганы Фәткелбаян абзыйга, әтиемнең сеңлесенең ире Арслан җизнигә, күршебез Минзариф абыйга, соңрак Шәйхенур абыйга һ.б.ларга да кара кәгазьләр килә. Алар кайда күмелгән? Җир куенына керү бәхете эләктеме икән аларга? Бу сорауларга бүген дә җавап юк.

Ә туган җиребезгә аларның хатыннары, карт әти-әниләре, үсмерләр хезмәт күрсәтә. Ул елларда әле сугыш авырлыклары бик үк сизелми, ныклык запасы бетмәгән була. Атлар да, сбруйлар да, инвентарь да билгеле бер дәрәҗәдә төзек. Өмет көче сүнмәгән. Күп кенә гаиләләр «һәлак булды», «хәбәрсез югалды» дигән сүзләргә ышанмый, өмет белән яши. Ирләре һәм әтиләренең исән-имин өйләренә кайтуларын көтәләр.

## ПРЕЗИДЕНТ СҮЗЕ

— Җир турындагы мәсьәләне хәл итмичә торып, бернинди азык-төлек программасын хәл итеп булмый.

Менә шунлыктан без Татарстанда «Җиргә хосусый милек» төшенчәсен куерта башладык. Яшермим, бездә дә бу эшкә аяк чалучылар,

шикләнүчеләр булды. Бу аңлашыла да. Әмма без кешеләрне инандыра алдык, җирне хосусый милек итәргә омтылыш барлык үткән буыннарның күңел түрендәге хыялы иде, икътисади тупиктан чыгуның бердәнбер юлы шул, дидек.

1998 елда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарихи документ — Җир кодексы кабул итте, ә шул ук елның 10 июлендә мин аңа кул куйдым. Кайчан да булса миңа кул куярга туры килгән документларның, язмышыбызга бәйле законнарның берсе иде бу. Ә моңа килү җиңел дә, гади дә булмады.

Беренчедән, җир мөнәсәбәтләренә бәйле мәсьәләләрне тикшерү һәр коллективта, һәр авылда нигезләп үткәрелде. Кодексны республикабызның күп кенә ведомстволары белгечләре җентекләп, кат-кат тикшерделәр. Республиканың Җир ресурслары һәм җир реформасы дәүләт комитетының роле аеруча зур булды. Шунысы шатлыклы, республикабыз Дәүләт Советы депутатлары бу мәсьәләгә бик тә игътибарлы мөнәсәбәттә булдылар.

Икенчедән, минем тирәнтен инануымча, Татарстан Республикасының Җир кодексы безнең суверенитетка ия булуыбыз нәтиҗәсендә әзерләнде һәм кабул ителде. Ул җир мөнәсәбәтләренең төп мәсьәләләрен хәл итә һәм җиргә хосусый милекне билгели. Кодексның 2 нче статьясында болай дип язылган: «Татарстан Республикасының җир законнары Татарстан Республикасы Конституциясе, Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне үзара тапшырышу турында Шартнамәдә билгеләнгән чикләрдә Россия Федерациясе законнары тарафыннан билгеләнә һәм әлеге Җир кодексыннан, Татарстан Республикасының аның нигезендә кабул ителгән законнарыннан һәм Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган башка норматив-хокукый актлардан тора».

**Автор хатирәләре.** Сугыш бетте. Бәхет килмәде. Ирләрнең яртысыннан күбрәге сугыш кырыннан әйләнеп кайтмады. Гарипләнеп кайтканнар бер-бер артлы теге дөньяга китә бардылар. Хәер, алар үзенчә «бәхетле» булып санала, чөнки аларны якташлары кадерләп җирләде, каберләре бар. Салих абый, Минталип абый, Советлар иленең элекке фронтовиклары, Чапаев исемендәге колхоз әгъзалары әнә шулай үз җиребездә күмелде.

Сугыш бетүгә, атлар арасында үләт башланды. Аларның муеннары, ян-яклары, сыртлары череде, һәм үлемнән куркынулы гаять зур күзләрен акайтып, атлар барган килеш җиргә егылалар иде.

Чапаев исемендәге колхозда җирне эшкәртерлек көч калмады. Тол калган хатыннарның сыерлары эшкә җигелде. Алар да ач бит, буразнада йөриселәре килми. Шуны күреп, 5 — 6 шар хатын-кыз, дилбегәгә җигелеп, буразна сыза башлады. Сабаннарга исә яшьләрнең дә көче җитә, чират-чират җигеләләр. Җирне көрәк белән казыган чаклар да булды. Ә тәҗрибәле картлар, муеннарына капчык асып, сөялле куллары белән орлык чәчәләр. Көзен исә үзләренә җитәр-җитмәс ашлыкны дәүләткә озаталар. Язгы чәчүгә орлык та калмый иде, анысын читтән ташыдылар...

## ПРЕЗИДЕНТ СҮЗЕ

— Җир кодексының 46 нчы статьясында әйтелгәнчә, Татарстан Республикасында җир кишәрлекләре хосусый һәм дәүләт милкендә, җирле үзидарә милкендә һәм башка милек формаларында була ала.

50 нче статьяда: «Дәүләт җирләре һәм җирле үзидарә милкендәге (коммуналь милектәге), шәхси милектәге, мөлкәт гомерлек мирас итеп калдырырлык һәм даими (чикләнмәгән вакытка) файдалануга тапшырылган җирләрдәге җир кишәрлекләре арендага бирелергә мөмкин».

Миңа калса, күп кенә гражданнарыбыз «җирне сату-алу, бүләк итеп бирү» кебек сүзләрнең тирән мәгънәсенә төшенеп җитмиләр әле. Бөтен республика масштабларында социаль-икътисади үсешнең барышын үзгәртү мөмкинлеген тулысынча аңлап җиткермиләр. Кайда һәм кайсы гасырда безнең кешеләр үз өендә Җир-ана белән иректе рәвештә, үз милке кебек эш итә алды соң?!

Республика агропромышленность комплексын үзгәртеп кору барышында авылда яшәүче 464 меңнән артык кеше үзенә тигән җир өлешенә хуҗа булды. Алар карамагына өлешләп, барлыгы 2,6 миллион гектар җир тапшырылды. Бөтен авыл хуҗалыгы җиренең 64 проценты бу. 300 меңнән артык милекче, үзләренең конституцион хокукыннан файдаланып, үз җирләрен арендага бирү турында договорлар төзеде һ.б.

Шактый күпсанлы гражданнар җир кишәрлекләренә хуҗа булдылар. Хәзерге вакытта 584 мең граждан фермер хуҗалыгын, шәхси ярдәмче хуҗалыкны алып бару өчен, индивидуаль торак һәм гараж төзелеше, коллектив бакчачылык өчен үз милекләрендә 137 мең гектар җиргә ия.

1991 елдан бирле коллектив бакчалар мәйданы 17,4 меңнән 28 мең гектарга киңәйде. Шул нигездә шәһәр халкын бакча кишәрлекләре белән тәэмин итү проблемасы хәл ителде.

Җир реформасы җир мөнәсәбәтләренең характерына зур үзгәрешләр кертте, авылда хуҗалык итүнең яңа формалары барлыкка килде һәм алар үсә бара. Мәсәлән, 1999 елның 1 гыйнварына республикада 118,8 мең гектар мәйданда 1761 фермер хуҗалыгы исәпләнде, шуның меңнән артыгы соңгы ике елга туры килә. Бер фермер хуҗалыгының уртача зурлыгы 67,4 гектар тәшкил итә.

Бер миллион гектардан артык сөрү җире резерв фондына бүлеп бирелде. Резервтагы җирләр һәр хуҗалыкта булырга тиеш. Үсеп килүче буын турында кайгыртуның тагын бер мисалы бу. Армиягә киткәннәр яңадан үз туган җирләренә әйләнеп кайтачаклар бит.

Хәзер авыл халкы эшкә кыю алына. Күптән түгел Лаеш районы хуҗалыкларында булган идем. Күргәннәремнән бик канәгать калдым. Районда колхоз һәм совхозларның 77 проценты яңача хуҗалык итүгә күчкән — җирнең бер өлешен шәхси кулларга тапшырган. Биредә «Победа» колхозының дуңгызчылык комплексы әле ике генә ел элек зыянга эшли иде. Дуңгызларның баш саны 2 меңгә кимегән. Колхозның баш икътисадчысы М.Каюмова үзенең өч хезмәттәше — Ф.Гари-

пова, А.Зарипова һәм А.Вәлиев белән бергәләп «Каюмова һәм аның компаниясе» дигән ширкәт төзегән. Дуңгызчылык комплексы бүген инде табышлы эшли.

Яки менә башка мисал: элекке колхоз базасында агроном Рәшит Галиевнең «Таң» дип аталган фермер хуҗалыгы эшләп ята. 1997 елда фермер һәр гектардан 38 центнер, ә корылыклы 1998 елда 17 центнер ашлык алган. Җир һәм милек арендасы өчен пайчылар белән тулысынча исәп-хисап ясаганнар.

«Лаеш МТСы» җәмгыятенең һәм хосусый эшмәкәр Д.Гайнуллинның авыл хуҗалыгы техникасына диагноз кую һәм урып-җыю чорында хуҗалыкларга ярдәм күрсәтү буенча эш тәҗрибәсе игътибарга лаек. Шунысы характерлы, минем белән очрашу вакытында Д.Гайнуллин һәм МТС учредителе А.Харитонов совхоз һәм колхозлар белән эшләүгә карaганда фермерлар белән эшләве ышанычлырак булуын әйттеләр.

Шушы коллективларның эшчәнлеге, башка районнардагы фермерларның эше мисалында шуны әйтергә телим: бүген республикада җирнең чын хуҗалары җитлегеп килә. Авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүчеләрнең яңа буыны кемнәрнеңдер көндәлек кайгыртуына мохтаҗ түгел. Базар мөнәсәбәтләренең барлык таләпләрен исәпкә алып эш итүче агропромышленность комплексында дөрес юнәлешле сәясәт кенә булсын аларга. Калганын үзләре белеп эшлиләр.

**Автор хатирәләре.** Яшәеш орлыклары. Колхоз басуына чәчеләсе орлыклар. Кышкы җил коллективлашуның беренче елларында төзелгән һәм инде искереп беткән колхоз амбарларына сызгырып үтеп керә. Шыгырдавыклы колхоз амбарларында хәтта тычканнарны да очратып булмый иде. Бөтен уңыш кырып-себереп дәүләт амбарларына озатылды. Колхозчыларга ышаныч юк. Аларга дәүләткә дигән орлык фондын саклауны да ышанып тапшырмадылар. Апрель җитүгә, Әҗәкүл пристанендә ашлык складларыннан колхозчылар, иңнәренә күтәреп, чәчүлек орлык ташыйлар иде. Күп кенә тол хатыннар ачтан, талчыгудан һушы китеп егыла, әмма авызына бер уч бодай каба алмый. Үлчәнгән! Тимә! Синеке түгел! Дәүләтнеке! Иртәгә ул колхозныкы була, ә көзен яңадан дәүләтнекенә әверелә.

Илленче ел язына кадәр апрельдә иңнәре сөякләренә ябышып беткән хатын-кызлар Әҗәкүлдән Актаныш, Мөслим районнары хуҗалыкларына күтәреп орлык ташыдылар.

## ПРЕЗИДЕНТ СҮЗЕ

— Иксез-чиксез Россиянең күп кенә төбәкләрендә бөтен җәмгыятебез үзгәрә барган шартларда җирнең язмышы турында бәхәсләр барганда, Җир турында төрле федераль закон проектлары ун еллап инде Мәскәүдә бәхәс темасына әверелгән бер вакытта Татарстанда биш закон инде тулы көченә эшли. Менә алар:

а) Җир кодексы;
б) Җир реформасы турында закон;
в) Җир өчен түләү турында закон;
г) Крестьян һәм фермер хуҗалыгы турында закон;

д) Җиргә кагылышлы законнарны бозган өчен административ җаваплылык турында закон.

Якын арада тагын дүрт закон чыгачак. Болар:

а) Җирне бәяләү турында закон;

б) Җир кишәрлекләрен сату-алу турында закон;

в) Авыл хуҗалыгы җирләрен залогка бирү (ипотека) турында закон;

г) Туфракның уңдырышы турында закон.

Дәүләт җир кадастры, җир төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык турында закон проектлары эшләнә.

**Автор хатирәләре.** Әгәр 1945 — 1946 елларны, бигрәк тә 47 нче елны искә төшерсәк, минем якташларымның хәтерендә коточкыч ачлык янаса, кешеләр ачлыктан шешенсә, 48 нче елда хәтерегездәниләр калды? Уйлагыз, уйлагыз! Төрмәгә утыртулар ул. Бер башак арыш өчен утырттылар кешеләрне.

Минем туган авылыма күршедә генә зур Татар Суыксуы авылы бар. Анда минем кардәшем — Мәрхәбә апам яши. Яше инде күптән 80 нән артты. 1948 елның көзендә хатын-кызларның, уракларын иңбашларына элеп, урактан өйгә кайтып барышлары. Авыл читендәге зират янындарак кына урында партия райкомы тарафыннан җибәрелгән энкэвэдычылар уратып ала боларны. Әйе, һәркайсының ыштан балагыннан 2,5 —3әр килограмм башактан уылган бодай табып алалар. Өйдә балалар ачтан шешенә бит!

Акт төзиләр дә уракчыларны, халык дошманнары сыйфатында, дәүләт милкен урлаучылар дип атыйлар һәм башта Актаныш КПЗысына, аннары Минзәлә төрмәсенә озаталар. Кайсына биш, кайсына алты ел срок бирелә. Билгеләнгән срокны утырып чыкканнан соң Мәрхәбә апа барысын да сөйләп бирде. «Иң куркынычы резин капчык булды, — дип сөйләде ул елый-елый. — Кешене зур резин капчыкка кертәләр дә, капчыкның башын бәйләп, таяклар белән кыйныйлар. Аңны югалтасың, авыздан, борыннан, колаклардан кан китә!»

Минем әтиемне, элекке фронтовик һәм колхоз рәисен, 1948 елның сентябрь азагында алып китәләр һәм ун елга Колымага җибәрәләр. Ни өчен диген?! Колхозчыларга һәр хезмәт көненә 200 әр грамм ашлык өләшкән өчен. Партия райкомыннан һәм НКВДдан рөхсәт сорарга кирәк булган икән ләбаса...

## ПРЕЗИДЕНТ СҮЗЕ

— Авыл кешеләре тормышында шәхси ярдәмче хуҗалык турындагы законның да әһәмияте, һичшиксез, зур булачак. Дөрес, бу закон проекты әле Россия Җир хокукы үзәгендә өйрәнелә. Мин ышанам, бу мәсьәлә крестьян файдасына хәл ителер. Башкача була алмый!

Бүген Татарстанда 356 мең шәхси ярдәмче хуҗалык бар. Аларның җире — иң уңдырышлы кишәрлекләр. Чөнки безнең бабаларыбызның һәм әбиләребезнең бабалары аларны даими ашлап торганнар, кадерләп тотканнар, үзләренеке итеп санаганнар. Югыйсә юридик яктан ул беркайчан да милек хокукында булмаган.

Чагыштыру өчен баштагы санга — 3,5 миллион гектарга әйләнеп кайтыйк. Татарстанда шулкадәр сөрү җире бар. Шәхси ярдәмче хуҗалыклар исә нибары 94 мең гектарны били. Моның гомуми сөрү

җирләреннән нибары 3 процент тәшкил итүен хисаплап чыгару кыен түгел. Ә бит бу шәхси ярдәмче хуҗалыклар республикада бүген бәрәңгенең 80 — 90 процентын, сөт һәм итнең 25—30 процентын, йон, терлек тиресенең шактый өлешен бирәләр. Байтак кешенең умарталары бар. Һичшиксез, аларга азыкның күмәк хуҗалык кырларыннан бүлеп бирелүен исәпкә алырга кирәк.

Ләкин беркемдә дә шул шик тудырмый: үсеп килүче буынны тәрбияләүнең беренче үсентеләре нәкъ менә шәхси ярдәмче хуҗалыкта барлыкка килә. Нәкъ менә шәхси ишегалды һәм ата-ана йорты авылда төп рухи һәм матди нигезе булып тора. Әгәр безнең кичәге һәм бүгенге фәндәге, сәнгатьтәге, мәдәнияттәге, мәгарифтәге, производстводагы һәртөрле ихтирамга лаеклы күренекле кешеләрнең нәкъ менә авыл йортларында туган булуларын исәпкә алсак, авыл ишегалдының безнең күп әхлакый башлангычларыбыз, әхлакый нигезләребезнең нигезе булганлыгы һәм булачагы ачык булып әверелер.

Авыл һәрвакыт җәмгыятебезнең рухи башлангычы булып торды. Мин ышанам, җиргә хосусый милек турында законнар кабул итү, шул исәптән шәхси ярдәмче хуҗалыклар турында законнар кабул итү авыл тормышының бөтен рәвешен яхшы якка җитди үзгәртер, чөнки яңа законнар буенча шәхси ярдәмче хуҗалык иясенең җир бүлемтеге зурлыгын бер гектарга кадәр зурайтырга, шул исәптән авыл эчендә ярты гектарга кадәр зурайтырга хакы бар. Җир пайлары булган авыл кешеләре хәзер үзләренең шәхси ярдәмче хуҗалыкларын үз өлешләре зурлыгында киңәйтә алалар. Республикада бу уртача 5,2 гектар тәшкил итә. Элекке замандагы кебек, хәзер терлек саны чикләнелми. Шәхси хуҗалыкларга бүген салымнар әллә ни зур түгел. Алар киметү ягына яңадан каралыр, дип уйлыйм.

Җирле үзидарә органнарының бурычы бүген терлекчелек һәм игенчелек продуктларын эшкәртү буенча кече предприятиеләр оештырудан, әзерләү оешмаларын бөтенләй башка дәрәҗәдә булдырудан, ихтимал, техниканы, инвентарьны, хәтта көнкүреш техникасын һәм мебельне сатуның лизинг формасын файдаланудан гыйбарәттер.

Мин, авыл йортында туып үскән кеше һәм Татарстан Республикасы Конституциясе гаранты буларак, авыл кешеләренең җиргә чын хуҗа булу турындагы гасырлар буена килгән хыялын тормышка ашыру өчен бөтен көчемне куячакмын.

**Автор хатирәләре.** Артык тыйнаклык күрсәтмичә шуны әйтеп узыйм, журналистлык эшчәнлегем чорында миңа Бөек Ватан сугышында катнашкан бик күп кешеләр белән очрашырга туры килде, алар турында, аларның батырлыклары турында күп яздым. Узган сугышның моңа хәтле билгесез, гади генә әйткәндә, хакимият һәм безнең тарафтан онытылган күп геройлары турында язарга туры килде.

Һәр җирдә — туган Татарстаныбызда да, Уралда да, Мәскәүдә дә, Ленинградта да, Ростовта да һәм Майкопта да элекке фронтовиклар миңа шаккаткыч бер вакыйганы сөйләделәр. Җир турында...

Совет гаскәрләре Германия җиренә аяк баскач, андагы төзек авыл-шәһәрләрдә,

бистәләрдә һәм бөтенләй аерым хуторларда немец бюргерларының хуҗалыкларын күреп, безнең ир-атлар телсез калалар диярлек. Советның эчкәреге авылларында өметсез хәерчелектә яшәп, аларның моңа хәтле беркайчан да авыл хуҗалыгының шулай рациональ алып барылуын, авыл җирендәге көнкүрешнең шулай оештырылуын күргәннәре булмаган.

Үзара гәпләшеп алгач, кичәге җирсез совет крестьяннары бердәм фикергә киләләр: «Бөтенесе җирдә, бөтен хикмәт аның кемнеке булуында». Германиядә, әйтергә кирәк, Польшада һәм башка Көнчыгыш Европа илләрендә, Көнбатыш илләрен инде әйтеп тә тормастан, җиргә аны эшкәрткән кешеләр хуҗа булып торганнар.

Совет гаскәрләре арасында, бигрәк тә авылдан чыкканнары арасында, Гитлер гаскәрләре белән инде Германиянең үз территориясендә хәлиткеч сугышка керү алдыннан бер «агитка» йөри башлаган: янәсе, әгәр сугышны җиңү белән тәгалләсәк, Сталин колхозларны таратырга, ә җирне авыл кешеләренә, беренче чиратта, янәсе, җиңүче сугышчыларга бирергә вәгъдә иткән.

Берәүләр бу «агитка»ны Совет Армиясе агитпромы тараткан дип уйлый: янәсе, хәлиткеч сугышлар алдыннан сугышчыларның рухын күтәрер өчен «алдавыч» тараткаңнар. Башкалары моны солдат сөйләүләре дип кабул итә. Ничек кенә булмасын, кан коюлы сугыштан талчыккан безнең ир-атлар, кичәге җирсез крестьяннар, туган җирләрен, гаиләләрен сагынып, татлы хыялларга чумганнар: «Менә өйгә кайтырмын да җир алырмын һәм шушы рациональ немец бюргерлары кебек үк хуҗалык итәрмен».

Кызганычка каршы, сугыштан соңгы бөтен ярты гасыр буена бу хыяллар барыбер шул чынга ашмаслык хыяллар булып кына калды. Ихтимал, бүген туган Татарстан җирендә шул токымның берән-сәрән исән калган кешеләренә әҗәл җитәр алдыннан кыска вакытка гына булса да үзләрен җирнең чын хуҗалары итеп тоеп карау һәм бу кыйммәтләрне инде улларына һәм кызларына түгел, ә оныкларына, оныкларының балаларына тапшыру бәхете туры килер.

## ПРЕЗИДЕНТ СҮЗЕ

— Без барыбыз да күп кенә Россия сәясәтчеләренең шау-шулы бәхәсләрдә ни өчен чит ил фирмалары һәм компанияләренең Россия икътисадына акча салмаулары сәбәпләрен, гаеплеләрне эзләүләренә шаһит булып торабыз. Бөтен дөньяда инвестицияләрне рәсмиләштергәндә, кредиторлар беренче чиратта җир мөнәсәбәтләренә карыйлар. Әгәр завод һәм фабрикалар урнашкан җир бу предприятиеләрнеке булмаса, инвесторлар капиталны урнаштыру турында сөйләшеп тә тормыйлар. Кәсәбәчелек дөньясында биналар, үзләренең эчендәге әйберләр белән бергә, җирдән башка гына әллә ни ымсындырмый. Җир-ана белән бәйле менә тагын бер бик җитди проблема.

Нигә әле бөтен Россиядә Татарстан инвестицияләр өчен аеруча уңайлы төбәк дип санала? Чөнки республикада җиргә милек хокукы эш итә башлады. Мин инде Татарстанда сәяси, социаль-икътисади тотрыклылык хакимлек итүен әйтеп тә тормыйм.

Бүген республика промышленность предприятиеләре 95,5 мең гектар җирне биләп торалар. Күпме бу, азмы? Шәхси ярдәмче хуҗалык-

лардагы 94 мең гектарны исегезгә төшерегез. Алар бертигез диярлек.

Промышленность предприятиеләренең үзенчәлекләре бар, акционерлык предприятиеләре биналар, корылмалар, ишегаллары һәм юллар биләгән җирләрне хосусыйлаштыралар һәм аның бәясен устав фондына кертәләр. Бу шул турыда сөйли: җир турындагы барлык законнар эш иткән шартларда әлеге бүлемтекләр инде товар булып торалар, ягъни җир эш итә.

Шуны да әйтергә кирәк, шәһәр һәм бистәләрдә, промышленность үзәкләрендә, йомшак кына итеп әйткәндә, законнар кабул ителгәнчә җир әллә ни ихтирам ителми иде әле. Бу өлкәдәге җирләр файдасыз ятты. Республиканың Җир ресурслары һәм җир реформасы дәүләт комитеты әлеге өлкәдә җирдән файдалануны тәртипкә салу буенча зур эш башкарды. Республикадагы җиргә тулысынча инвентарьлаштыру үткәрелде. Җирнең һәр квадрат метрының үз статусы билгеләнде. Бу, беренчедән, җиргә салым салуның төгәл базасын бирә. Икенчедән, монысы да бик кызык, инвентарьлаштыру барышында элек җирнең исәпкә алынмаган 52 мең очрагы ачыкланды.

Хәзер күбесе артык җирдән баш тарта. Чөнки аның өчен түләргә кирәк. Менә шуңа күрә күбәүләр җирнең кадерен белә, җирдән файдалану белән бәйле законнарны ихтирам итә башлады.

**Автор хатирәләре.** Илленче еллар башына кадәр диярлек Актаныш авылларында шактый кызыклы бер традиция — «уракка чыгу» традициясе яшәп килде. Арыш урылып беткәч (әлбәттә, урак белән, кулдан), күп хатын-кызлар, җирле хакимият рөхсәте белән кулларына үзләренең ураклары тотып, бер-ике атнага Пермь өлкәсенең Барда, Удмуртиянең Сарапул һәм Каракул районнарына, Башкортстанның Агыйдел аръягы авылларына китәләр иде. Кем моңа ирешә, — гаилә, бигрәк тә күп балалы гаилә, бөтен кыш буена өйдә пешкән ипи белән тәэмин ителә дигән сүз, чөнки туган колхоз җиреннән берни дә эләкми иде бит кулга.

Минем әбиемнең кыз туганы Агәби (аның чын исемен без белмәдек тә) сугышка хәтле үк инде күп еллар буена «уракка», ягъни Башкортстанның Актаныш районы чигеннән ерак түгел урнашкан Илеш районындагы немец авылларына игенне кулдан урырга йөргән. Илеш һәм Иске Куктай авыллары арасында урнашкан үзләренең төзек утарларында бу якларга әле «Әби патша», ягъни Екатерина II китергән немецлар яшиләр иде. Акыллы немец-патшабикә немецларның рациональлеге, җыйнаклыгы үрнәгендә җирле крестьяннарны культуралы игенчелеккә, традиция буенча «җилгә чыгып утырмасын» өчен җирле халыкны кешегә хас көнкүрешкә күнектерергә теләгән. Җирле крестьяннар педант немецлардан файдалы күп нәрсә алганнар.

Ул елларда без барыбыз да, совет нормаларыннан чыгып караганда, бары тик гарәп алфавиты буенча гына укый белә торган гади Агәбинең немецча шактый иркен «сыптыруына» гаҗәпләнә идек. Ә ул немецчаны немец хуҗалыкларында эшләгән шул кыска гына атналар эчендә өйрәнгән икән. Аннары инде ул безгә немецларның рациональ тормышы турында, аларның җиргә акыллы мөнәсәбәте, көнкүрешне нормаль оештырулары турында сокланып сөйли иде.

Мин быел кайчандыр немец авыллары урнашкан шул җирләргә барып кайттым. Аларны инде мыеклы юлбашчы заманында ук бөлгенлеккә төшергәннәр. Юк инде хәзер монда

немецлар. Элекке төзек бистәләр урынында биек тирәкләр, тупыллар һәм башка агачлар шаулап утыра. Элекке немец авыллары урынында хәзер Илеш колхозының хуҗасыз 4 нче һәм 5 нче бригадалары гомер кичерә.

Заманында киләчәк турында уйлап эш итүче Екатерина II немец крестьяннарын Иделгә һәм Кубаньга, Одесса якларына кешеләр алардан җирне белеп файдаланырга өйрәнсеннәр өчен китергән.

Кайда бүген ул немецлар?! Дөресрәге, кайда аларның токымнары? Әлбәттә, Германиядә. Билгеле, Сталин лагерьларыннан һәм махсус яшәү урыннарыннан исән калганнары турында бара сүз.

Туган җиребездә без хәтта үҗәт немецлар алып килгән нәрсәләрне дә саклап кала алмадык. Җирнең чын хуҗалары, үз хезмәтенең хуҗасы булырга өйрәнмәгән кешеләр чын хезмәт кешесенең җанын аңлый, гасырлар буена чит ил кешеләре һәм үзләренең ата-бабалары калдырган кыйммәтле нәрсәләрне кабул итеп ала алмый.

## ПРЕЗИДЕНТ СҮЗЕ

— Җирне милеккә алып, аның формаль хуҗасы булу гына аз әле ул. Җирне яратырга, кадерләргә, аны тере организмны тәрбияләгән кебек тәрбияләргә кирәк.

Менә без әңгәмәбезнең башында республикага байтак бәрәңге, яшелчә бирә торган шәхси ярдәмче хуҗалыклар турында сүз алып бардык. Бөтен хикмәт шунда, безнең бабаларыбыз, монда гасырлар буена яшәп, җиргә даими рәвештә ашлама кертеп килгәннәр. Шуны исәпкә алырга кирәк, авыл хуҗалыгы җирләрендә аларның төрлечә деградацияләнүе аркасында туфракның уңдырышы киму дәвам итә. Ел саен бер гектарда гумус микъдары бер тоннага кими һәм ул хәтта органик ашламалар, сидератлар кертеп тә тиешле күләмдә капланмый.

Җиргә ашламалар кертмичә, үсемлекләрне саклау чараларын кулланмыйча эшләүне мин әхлаксызлык дип саныйм. Әгәр кеше җиргә шушы компонентларны кертмичә эшли һәм, әйтик, гектардан 12 — 15 центнер бөртекле ашлык ала икән, моны нәрсә дип атыйсың инде? Бу бит сугыштан соңгы еллардагы шул ук хезмәт көннәренә бәрабәр. Хәерчелеккә алып бара торган бушлай хезмәт бу. Бернинди шартларда да болай булырга тиеш түгел. Соңгы болгавыр елларда күп республикаларда, край һәм өлкәләрдә авыл хуҗалыгы химиясенең җайга салынган системасын тулысынча таркатуга һәм юк итүгә ирештеләр. Бәхеткә каршы, безнең республикада бу системаны саклап кала алдык. Нәкъ менә республика «Сельхозхимия»се һәм аның урыннардагы бүлекчәләренең квалификацияле эшләве аркасында күп хуҗалыклар кайбер елларда гектардан 50 центнер һәм аннан да күбрәк яхшы сыйфатлы бөртекле ашлык алалар.

Узган ел һәр гектарга 120 килограмм минераль ашлама кертелгән. Күпме соң бу? Башка күп төбәкләр белән чагыштырганда, начар түгел бу. Әмма безнең өчен аз әле. Үзегез уйлап карагыз, мәсәлән, Голландиядә бер гектар җиргә 300 килограмм һәм аннан

да күбрәк минераль ашлама кертәләр. Бүген җирне интенсивлаштырмый, экология-икътисади яктан нигезләнгән агротехника чаралары үткәрми торып, туфракта туклыклы матдәләр балансын яхшыртучы химияләштерү чараларын кулланмый торып, планлаштырылган югары уңыш алу мөмкин түгел. Чөнки соңгы унъеллыкларда сөрү җирләре мәйданы күзгә күренеп кимеде бит: әгәр алтмышынчы елларда республикада бер кешегә 139 сутый җир туры килгән булса, хәзер нибары 95 сутый җир туры килә.

Ләкин шушы көнгә хәтле минераль ашламаларны, зур акча тотып, Татарстанга читтән кертергә туры килә. Үз аммиагыбыз булмавы республикада төзелгән Яңа Менделеев минераль ашламалар җитештерү заводының проект куәтләрен тулысынча үзләштерү мөмкинлеге бирми. Ә бу — елга 450 мең тонна. Безнең ихтыяҗыбызга бу төр ашламаның яртысы да җитәрлек. Зур инвестицияләр, аерым алганда, «Газпром» акционерлык җәмгыяте инвестицияләрен җәлеп итеп, без бу проблеманы хәл итәргә ниятләнәбез.

**Автор хатирәләре.** Минем туган авылда һәм аның тирә-ягында җиргә беркем дә хуҗа булып тормады, дип расласак, бөтенләй үк дөрес булып бетмәс иде. Дөрес, утызынчы елларга хәтле җир кисәкләренә генә булса да хуҗа булдылар — кем күбрәккә, кем азракка. Хуҗа булу ничектер чамалы иде — әллә ул синеке, әллә патшаныкы, әллә дәүләтнеке. Бүгенге көннәр биеклегеннән чыгып фикер йөртсәң, аның юридик нигезе турында аңлатма бирү кыен. Әмма утызынчы еллар башында тоташ күмәкләштерү башлану белән шушы бүлемтекләргә хуҗа булуга да чик куелды: әгәр кемдер башкалардан зуррак җиргә хуҗа булган булса, димәк, ул кулак, байгура. Андыйларны Себергә, Төньякка озаттылар. Менә шушы кечтеки генә зуррак җир кисәге өчен Гыйльфан бабай Дәүләтбаевның әйберләрен тартып алдылар һәм Магнитканы төзергә җибәрделәр. Туган җиренә әйләнеп кайтмады ул шуннан. Атаклы Магнит тавы янында башын салган.

Утызынчы елларда җир ызаннарын сукалап юкка чыгару белән генә чикләнмәделәр, сыерларны да яңа төзелгән Василий Иванович Чапаев исемендәге колхозның гомуми ишегалдына җыеп алдылар. Менә шунда туган җиргә кеше яше тагын бер тапкыр мул коелды да инде. Нәкъ менә шул чагында крестьян күңеле белән җирдән файдалануның социалистик рәвеше арасына ызан салып, дөресрәге, упкын казып куелды да инде.

Хәтәр 1937 елда «халык дошманнары»н эзләү безнең авылны да читләтеп узмады. Колхоз тимерчесе ярдәмчесе, инде өлкән яшьтәге бөтенләй укый-яза белми торган Шәрифулла Хамматуллин авыл халкы арасында бер такмак җырлап куя:

Каһәр төшсен Николайга —
Җиде сыер саудырды,
Рәхмәт инде Сталинга —
Бер кәҗәгә калдырды.

Һәр заманда һәр халыкның сатлык җаннары булган. Әләкченең милләте юк. Авылдан бер абзый кая кирәк шунда җиткергән теге такмакны. Ике көннән соң тимерче ярдәмчесен НКВД кешеләре төнлә район үзәгенә алып китәләр. Ике атнадан соң (команда җыелганчы) «халык дошманы»н, тагын башка авыллардан шундый ук өч дистәләп ир-атны, рәткә икешәр кеше тезеп, НКВДның Актаныш бүлегеннән безнең авыл аша Минзәлә төрмәсенә

алып китәләр. Режим дошманына Сталин җәлладлары үзенең туган авылында 7 яшьлек улын кулга алып сөяргә, башыннан сыйпарга һәм бер тустаган авыл суын эчәргә, инде аңа ят булып, колхозныкы булып, бәлки, бөтенләй хуҗасыз булып әверелгән туган җиренә соңгы караш ташларга рөхсәт итәләр.

Тиздән Шәрифулла Хамматуллинны «халык дошманы» буларак атып үтерәләр.

Куян, Уразай, Такталачык, Чалманарат, Түбән Карач, Урьяды, Куҗәкә һәм башка авылларның урамнары «төрмә юлы» дип аталды. Чөнки ике атнага бер тапкыр бу авылларның урамнары аша җәлладлар «халык дошманнары»н — Актаныш авыллары ир-атларын Минзәлә төрмәсенә алып китәләр иде.

Инде 1948 елда бу тәмуг юлын нигәдер үзгәрттеләр. Актаныш яклары ир-атларын Шәрип, Теләкәй, Чынык авыллары аша алып китә башладылар. Әмма юл бер генә — тәмугка, Минзәлә төрмәсенә иде.

## ПРЕЗИДЕНТ СҮЗЕ

— Менә без сезнең белән соңгы унъеллыкларда сөрү җирләре мәйданнарының сизелерлек кимүе турында сөйләштек. Бу безнең күңелсез хакыйкатебез. Моның сәбәпләре күп. Шуларның берсе, һичшиксез, шул: яңа шәһәрләр, яңа промышленность предприятиеләре, яңа юллар төзелешенә җир юмарт бүлеп бирелде. Шуны да онытырга ярамый, күптән түгел Татарстан илгә төп нефть бирүчеләрдән берсе иде. Үзегез беләсез, бу күп кенә җирләрне башка максатларда файдалануга китерә.

Соңгы биш елда гына да промышленность предприятиеләре төзүгә, юллар салуга, нефтьчеләр һәм энергетикларга 9600 гектар җир, шул исәптән 4600 гектар сөрү җире бүлеп бирелде.

Кем әйтмешли, монда да бөтенесе өметсез түгел. Җиргә милек турындагы законнар һәм аның өчен түләүне кертү күп кенә хуҗалыкчыларны бу мәсьәләгә башкача карарга мәҗбүр итте. Хәзер инде күбәүләр «артык бүлемтекләр»дән баш тарталар. Кирәкле күләмнәрдә калган бүлемтекләрне алар рациональ файдаланырга омтыла.

Безнең нефтьчеләр, нефть-газ үткәрүчеләр, бүлеп бирелгән җирләрне акыл белән файдаланып, соңгы елларда җирләрне рекультивацияләү һәм аларны республика фондына кире кайтару буенча күп эш башкаралар. Бүген инде бу юнәлештә уңай тенденция барлыкка килде. Әгәр 1994 елда, мәсәлән, нибары 3,5 гектар җир кире кайтарылган булса, инде 1997 елда 700 гектар җир кире кайтарылды. Шулай итеп, Татарстанга «Марс ландшафты» янамый. Әлбәттә инде, туган Җиранага киләчәктә тә кадерле мөнәсәбәттә булсак.

**Автор хатирәләре.** Крепостной хокук 1861 елда юкка чыгарылган, дип раслау бик үк дөрес түгел. Крепостной хокук иң рәхимсез, ерткычларча, нигездә, кичәге көнгә хәтле яшәп килде дип санарга мөмкин. 1956 елга хәтле колхозчыларның паспорт алуга хокукы булмады. Абзардагы сыер белән өйдәге кеше бер иде. Авылдан чыгарга җөрьәт итмә. Хезмәт көне хисабына җир эшкәрт.

Тәвәккәлләр берәмләп тә, ата-анасы корган ояларны, бабалары җирен ташлап, бер сынык ипи эзләп, гаиләләре белән дә чит җирләргә чыгып киттеләр. Безнең актанышныкы-

лар күрше Ижау, Сарапул, Пермьгә һәм Уралның башка шәһәрләренә качтылар. Шулай килеп чыкты ки, алтмышынчы елларда авылларда тракторлар, комбайннар инде җитәрлек санда иде, хәтта ут белән радио да уздырдылар, паспорт алырга рөхсәт иттеләр. Шуңа карамастан авыллар бушап калды. Туган җирдә, колхоз җирендә эшләргә кеше юк иде инде. Туган җир булса да, бу җир чынлыкта хуҗасыз, күп кешеләр өчен чит җир булып калды.

## ПРЕЗИДЕНТ СҮЗЕ

— Һичшиксез, җир мөнәсәбәтләрендә реформалар уздыру елларында техника хәлиткеч роль уйный. Яшереп торасы юк, тракторлар, комбайннар һәм башка авыл хуҗалыгы техникасы соңгы елларда шактый какшады. Монда инде халык хуҗалыгындагы һәм Россия җәмгыятендәге иҗтимагый-сәяси строй алмашуга, шулай ук икътисадны реформалаштырудагы мәгълүм ялгышларга бәйле гомуми кризис чагылмый кала алмады.

Җир реформасын ныклык белән дәвам иттереп, без авыл товар җитештерүчеләрен техник коралландыру белән бик җитди шөгыльләнергә ниятләнәбез. Бу яктан алганда, һичшиксез, республика бюджетыннан кире кайтару нигезендә акча бүлеп биреләчәк. Мин шуңа ышанам, фермер һәм күмәк хуҗалыкларда ресурс мөмкинлекләре иң беренче чиратта хәзерге заман югары җитештерүчән тракторларны, комбайннарны, машиналар һәм агрегатларны сатып алуга, аларны барлык чаралар белән торгызуга, республика авыл хуҗалыгы техникасы һәм промышленносте предприятиеләрендә шуларны әзерләүгә юнәлдерелергә тиеш. Без әле авыл хуҗалыгы техникасы белән тәэмин итүнең сыналган һәм агропромышленность ягыннан нык үскән илләрдә үзенең тормышчанлыгын исбатлаган чын лизинг һәм башка рәвешләренә килеп җитмәдек дип уйлыйм.

Күп республикаларда, крайларда һәм өлкәләрдә авыл хуҗалыгы техникасы хезмәтләре таркалды һәм базар стихиясендә эреп юкка чыкты. Кем әйтмешли, җимерү — төзү түгел ул. Реформаларның асылы уңга-сулга җимерүдән гыйбарәт түгел бит. Безгә монда да сиземләү хыянәт итмәде. Без шушы өлкәдәге иң яхшы нәрсәләрне саклап кала һәм яңа шартларга җайлаштыра алдык. Безнең «Сельхозтехника», холдинг компаниясе рәвешендә мөстәкыйльлек алып, үзенең горизонталь һәм вертикаль элемтәләрен саклап калды, куәтле җитештерүчән көчкә әверелде. Аның механикалаштырылган урып-җыю отрядлары бөртекле ашлыкның төп өлешен урып-җыялар, терлек азыгы хәзерләү гомуми күләменең 25 процентын үтиләр. Безнең ремонтчыларның осталыгына, зирәклегенә килсәк, алар мактауга лаек. Мәсәлән, Украинадан көч агрегатлары сатып алуга бәйле кыенлыклар аркасында кайбер комбайннар һәм тракторлар тик торырга мәҗбүр иде. Ә менә без аларга «КамАЗ» двигательләрен көйләдек һәм машиналар эшли башлады!

Кырларда тулы күчергечле «КамАЗ»лар нигезендә әзерләнгән сөрү агрегатлары сынауларны уңышлы узды. Республика заводларында иң яхшы бөтендөнья үрнәкләренә охшаш тигез чәчә торган шикәр чөгендере һәм кукуруз чәчкечләрен җитештерү җайга салынды.

Без сезнең белән Россиянең күп төбәкләрендә җирне эшкәртүдән, аның нигъмәтләреннән файдаланудан туктаганлыкларын әйткән идек инде. Мондый «сукачыларга» җирнең кирәк булмавы ап-ачык. Димәк, тракторлар да, комбайннар да, элита орлыклар һәм ашламалар да кирәкми. Кем җирдә эшләми — аның бернинди мәшәкате юк. Әмма нәтиҗә бик аяныч: өстәл буш, хәерчелек. Татарстан игенчеләренең хәле киресенчә — мәшәкатьләрнең иге-чиге юк. Алар бүген муафыйк шартлардагы паритет бәяләр нигезендә техника, ашламалар белән тәэмин итүне таләп итәләр. Без Россия Федерациясе хөкүмәтенә авылга авыл хуҗалыгы техникасын лизинг нигезендә сатуны оештыру тәкъдиме белән чыктык. Федераль хөкүмәттә бу эштә безнең инициативалар күп позицияләр буенча яклау тапты. Мин ышанам, якын арада инде таушалган авыл хуҗалыгы техникасын без заманчарак, җитештерүчәнрәк техника белән алмаштырырбыз.

**Автор хатирәләре.** Планлы социалистик икътисад, соңга таба мәгълүм ГОЭЛРО планы да Татарстан җиренә төзәтеп булмаслык зыян салды. Меңнәрчә гектар иң уңдырышлы кара туфраклы мәйданнар Куйбышев сусаклагычы астында калды. Куйбышев ГЭСы сулары астында җир генә түгел, безнең тарихи кыйммәтләребез, шул исәптән, борынгы Болгар дәүләте җирләре дә калды.

Түбән Кама ГЭСы файдалануга тапшырылгач, җитмешенче еллар ахырында Татарстанны икенче тапкыр су басты. Дуга биеклегендә игеннәр шаулап үсә торган меңнәрчә гектар менә дигән җирләр, меңнәрчә гектар болыннар су астына кереп чумды. Зур су килүенә тулы программа буенча әзерләнеп, ягъни башлангыч проектны исәпкә алып, минем туган Актаныш районындагы мең ел тарихлы гаять зур авыллар, Зур Дербышка бистәсе җир йөзеннән юкка чыгарылды. Тарихчылар исбатлавынча, нәкъ менә шушы урыннарда әкияти зур Көләгеш күле буенда булачак маҗар мәдәнияте туган.

Су астында калган авыллардагы якташларым әлеге хәлдән үпкәләп хәтта Татарстаннан да китеп бардылар. Сарапулга, шушы шәһәр янындагы «Удмуртский» совхозына киттеләр. Мин шундый искиткеч вакыйгага шаһитмын: сабантуй көннәрендә шушы элекке авылларның кешеләре үзләренең элекке нигезләренә киләләр дә, күзләрендәге яшьне яшермичә, бәйрәмнәр уздыралар. Бүген Актаныш районындагы якташларым шөбһәләнеп фараз кылалар: су проект билгесенә хәтле күтәрелерме, юкмы? Калган җирләр су астына китәрме, юкмы?

## ПРЕЗИДЕНТ СҮЗЕ

— Күптән түгел бер киңәшмәдә бер кәсәбәче болай диде: «Электр энергиясе җитми. Ә шул ук вакытта «яшелләр» хәрәкәте Актаныш, Әгерҗе һәм Минзәлә районнарындагы җир кишәрлекләренә, нинди-дер бака күле — Көләгеш күленә чатыр ябышты. ГЭС агрегатлары тулы көчкә эшләсен өчен Түбән Кама сусаклагычы суы биеклеген

һичкичекми беренче билгегә хәтле күтәрергә кирәк». Без ашык-пошык карарлар кабул итүгә оста. Ә үзләреннән без бәрәңге үстерүнең прогрессив технологиясен ала торган голландлар гасырлар буена су стихиясеннән кишәрлек артыннан кишәрлек җир яулап алганнар. Без исә, ахыргы нәтиҗәләре турында аз гына да уйлап тормастан, Куйбышев һәм Түбән Кама ГЭСларының гаять зур сусаклагычлары астында 456,2 мең гектар җирне, ягъни республика җир фондының 6,7 процентын калдырдык. Җирләре су астында бигрәк тә күп калган берничә районны атап узам: Лаеш районында — 68223 гектар, Актаныш районында — 59245 гектар, Спас районында — 55804 гектар, Минзәлә районында — 54175 гектар, Алексеевск районында — 41186 гектар һ.б. Республиканың 22 районы кеше кулы белән ясалган туфаннан зыян күрде. Әйдәгез, шулай килешик, бу эштә гаепле кешеләрне эзләмик. Беренчедән, элекке СССРның бөтен территориясендә сусаклагычлар гидроэлектростанцияләр төзүнең бердәм планы буенча төзелде, ә Кама һәм Иделдәге ГЭСлар әле Совет хакимиятенең беренче елларында ук төзелгән ГОЭЛРО планы буенча корылды. Бу грандиоз объектлар бөтен халык хуҗалыгын, бөтен тормыш укладын катгый планлы алып бару елларында төзелде. Илгә электр энергиясе кирәк иде. Су сай булганлыктан, суднолар йөртү проблемаларын, шиверлар, елгаларның аерым бүлемтекләрендәге бусагалар мәсьәләсен хәл итәргә кирәк иде.

Икенчедән, Идел һәм Камадагы гидроэлектростанцияләр каскадындагы барлык ГЭСларны төзеп, Түбән Кама ГЭСын гына төземи калып булмый иде бит инде.

Җир саклау турында тирәнтен уйланырга кирәк иде — монысы башка мәсьәлә. Әйдәгез, шуны онытмыйк, ул елларда халык «Давай-давай!» дип атаган сан күрсәткечләре системасы өстенлек итте.

Хәзер инде йодрык күрсәтергә соң. Мөмкин булганын сакларга кирәк. Татарстанның Актаныш, Минзәлә, Әгерҗе районнарында, Башкортстанның Николо-Березов, Бөре, Каракул районнарында, Удмуртиянең Сарапул районында яшәүче күп кенә кешеләр Чаллыдагы Түбән Кама ГЭСы ягына шөбһәләнеп карый: су тулы проект билгесенә хәтле күтәрелерме, әллә юкмы? Тулы нигезле борчылу бу. Мин болай уйлыйм: Түбән Кама ГЭСы агрегатлары куәтен акрынлап арттыра барырга, димәк, сусаклагыч күләмен дә арттырырга кирәк. Ләкин моны, ГЭСның башлангыч куәтен исәпкә алып, төзелешнең беренче елларында төзелгән барлык инженерлык корылмаларын тулысынча торгызганнан соң гына эшләргә кирәк. Алар бит инде бүген җимерелгән яки җимереләләр. Өстәмә суны да, киләчәктә бер генә гектар җир дә су астына китмәсен өчен, өстәмә саклану дамбаларын һәм корылмаларын коргач кына җыярга кирәк.

Төшенәсездер инде, бу бик күп акча таләп итәчәк, ә мондый акча бүген федераль казнада да, республика казнасында да юк. Киләчәктә бу проблеманы барыбер хәл итәргә, һичшиксез, табигать өчен, халык өчен минималь югалтулар белән хәл итәргә кирәк булачак.

**Автор хатирәләре.** Авылда яшәүчеләр колхоз җирен Чаллы, Түбән Кама, Алабуга шәһәрләрен төзү дәверендә ташлап киттеләр. Шушы шәһәрләрдә, башкалабыз Казанның үзендә дә, кемнең дә булса җиңеннән тотсаң, йә Актаныш, йә Мамадыш, йә Тәкәнеш кешесенә юлыгырсың. Хуҗасыз колхоз җиренә берегеп торган кешеләр күп калмады. Хезмәткә түләү дә көлке дәрәҗәдә кала килде. Ә эшнең нормасы, үлчәме юк.

Бүген эшсез калган, кызганычка каршы, еш кына исерек ир-атларга карыйм да үпкә белән якташларым турында уйлап куям: кемнәр болар? Шәһәрнекеләрме? Шикле. Һәр ял көнне алар туган авылларына җир казырга, утыртырга, утарга, җыярга кайталар. «Бәрәңге алырга». Кем ата-анасы бакчасында көрәк белән ала, аны кем үзенең картларыннан капчык белән алып китә?!

Бәлки, болар авыл кешеләредер? Кайберләре, мөгаен, җаны белән авыл кешеседер. Ә чынлыкта — юк. Алар крестьян хезмәтеннән бизде инде. Чит җирдә, колхоз җирендә эшләүдән тиз бизәләр. Әгәр сине тупас бригадир, кулы озын рәис даими кимсетеп торса, бигрәк тә. Ә бит ташланган туган җир өчен күп кешенең җанын сагыш кыра.

## ПРЕЗИДЕНТ СҮЗЕ

Сезнең белән безнең әңгәмәдә күтәрелгән мәсьәләләр шулкадәр катлаулы һәм актуаль ки, кем әйтмешли, бер утыруда гына бөтенесен колачлап бетереп булмый. Яшәешнең бөтен мәсьәләләре, һәр кешенең барлык өметләре җиргә бәйләнгән. Җир ул — туйдыручы анабыз, җир — тормыш синонимы. Ул — өмет һәм таяныч.

Аеруча шуны күрсәтеп узарга кирәк, җир — мөгаен, аны хосусыйлаштыру бездә социаль гаделлек нигезендә үткәрелгән бердәнбер җитештерү чарасыдыр. Колхоз рәисе дә, тракторчы да, пенсионер да, авыл укытучысы да җирне тигез өлештә алды. Берәүләр шул җирдә эшләүләре өчен, башкалары — шул җирдә кайчандыр эшләгән өчен.

Табигый ки, җир һәркемгә дә кирәкми. Ул акрынлап җирне төшенгән, анда эшли белгән, эшне тиешенчә оештыра белүче кешеләр кулында тупланачак. Әмма аларга җир өлеше хуҗалары белән сөйләшергә, килешергә туры киләчәк. Йә аренда, йә сатып алу шартларында тупланыр ул җир — моны тормыш күрсәтер. Иң әһәмиятлесе шул — җирне беренче тапкыр бүлгәндә читләтеп узылган, кыерсытылган кешеләр булмаска тиеш.

Бүген без җәмгыять үсешенең кайчандагыдан да җитдирәк тарихи күчешендә торабыз. Тарихның бөтен барышы белән безгә бүген үз тормышыбызны тамырдан үзгәртү мөмкинлеге бирелде. Без барыбыз да шуны фикерләргә һәм төшенергә тиешбез: республикада уздырыла торган Җир реформасы җирне эшкәртүчеләрнең тормышын яхшыртуга, авыл тормышының инде урнашкан укладын тамырдан үзгәртүгә, барлык кешеләр өчен туклану продуктлары муллыгын булдыруга юнәлдерелә. Җир законнары шәһәрдә дә актив эш итәргә, табыш китерергә, безнең кыйммәтләребезне арттырырга тиеш. Безнең бүгенге һәм озак вакытлы программаларга кагылсак, алар барысы да җир законнарын исәпкә алып, җирдә яшәүче һәм эшләүчеләрнең мәнфәгатьләрен исәпкә алып тормышка ашырылачак. Әңгәмәбез ахы-

рында тагын бер сан китерәм: 10 процент. Авыл хуҗалыгына булышлык күрсәтүгә республика бюджетының чыгым өлешеннән кире кайтарып бирү шарты белән менә шул хәтле акча бүлеп бирелә.

Авыл халкының тормыш дәрәҗәсен күтәрүгә ярдәм итүче инфраструктура объектлары өстенлекле булып кала. Әйтик, авылларны газлаштыру проблемасын алыйк. Авылларның газлаштырылуын 2001 елда төгәлләүне планлаштыра торган программа бар. 1995 елда республика районнарын газлаштыру буенча дәүләтнең бюджеттан тыш фонды булдырылды. Республика авыл йортларын һәм квартираларын челтәрле газ белән газлаштыру дәрәҗәсе 60 процентка якынлашып килә. Бездә хәзер торак 100 процент диярлек газлаштырылган районнар бар. Моның кешеләр тормышын ничек җиңеләйтүен әйтеп тору артык булыр дип уйлыйм.

Соңгы 5-6 елда 900 урынлы 200 гә якын яңа мәктәп, яңа поликлиникалар, 700 дән артык урынлы хастаханәләр төзелде, уңайлы күп йортлар корылды. Мөгаен, моңа хәтле бөтен йөз ел буена республикада шушы кадәр мәчет һәм чиркәүләр төзелмәгәндер.

Россиядә авыл хуҗалыгы дәүләт хакимияте сәясәтенең шундый өстенлекле юнәлешенә әверелгән башка бүтән төбәкне табу кыен дип уйлыйм.

...Без сезнең белән әңгәмә корган арада республиканың байтак районнарында күптән көтелгән июнь-июль яңгырлары явып узды. Кәефемнең ничек күтәрелгәнлеген, шушы яңгыр турында ничек хыялланганлыгымны сүзләр белән әйтеп бирә алмыйм. Моны төшенеп булмый, моны җаның һәм тәнең белән тоемларга кирәк. Син инде барысын да эшләгәч, уңыш үстерү өчен тиреңне койгач, вакытында яңгыр яумаса, тасвирлап биреп булмый торган җан ачысы туа. Менә шуңа күрә җирдә эшләүче кеше кодрәткә күбрәк ышанучанрак була дип уйлыйм. Чөнки алар күккә өмет белән ешрак карыйлар. Әгәр өмет акланса, ул бөек серле көчнең яшәвенә ышана башлый.

**Автор хатирәләре.** Шушы язманы матбугатта бастырырга әзерләгәч, мин яңадан туган якларымда булып кайттым. Туганнарым, якын кешеләр, якташлар белән очраштым. Кем белән очрашсам да, сүз, һичшиксез, җиргә, җәмгыятьтә җир реформасы белән бәйле соңгы үзгәрешләргә кагылды. Күпләр әле яңалыкларны төшенергә, җан һәм күңел белән тулысынча кабул итәргә өлгермәгәннәр. Күбесе инде шуны төшенә: җир мөнәсәбәтләрен, җиргә үз мөнәсәбәтеңне тамырдан үзгәртми торып, якын арада тормышта уңай үзгәрешләр булачагын көтәргә кирәкми.

Актаныштан Чаллыга алып бара торган юл безнең Президентның туган авылы яныннан уза. Аның ничек аталуын барысы да беләдер дип уйлыйм. Бу юлы мин махсус рәвештә Әнәккә сугылдым.

Өйгә кайткач, мин кулыма «Хәтер» дигән китапны алдым һәм Минтимер Шәриповичның сугышта һәлак булган авылдашларын санап чыктым. Әнәк авылыннан менә дигән 30 ир-ат Бөек Ватан сугышы кырларыннан әйләнеп кайтмаган. Алар үз башларын Ватан өчен, үзләренең җире өчен салганнар. Әмма бу ачы хакыйкатьнең бер өлеше генә. Безнең игътибарсызлыгыбыз аркасында әлеге сатышлы китапка, барлык авылларныкы кебек

үк, безнең Президентның да һәлак булган барлык якташларының исемнәре кереп бетмәгән. Кемнедер Пучыныкы дип язганнар, кемнедер бөтенләй онытканнар. Ә бит шушы Әнәк авылыннан сугышта үз җирләре өчен һәлак булган бөтен бер гаиләләр бар. Мәсәлән, Әнәккә дүрт бертуган Дәминовлар кире әйләнеп кайтмаган: Камил Дәминович — 1909 елгы, Миргалим Дәминович — 1911 елгы, Кәндел Дәминович — 1914 елгы, Хәниф Дәминович — 1918 елгы.

Вакытны кире кайтарып булмый. Әгәр безнең туган җирне сакларга киткән һәм кече Ватаннан, үзләренең авылларыннан еракта башларын салган бабаларыбыз, әтиләребез бүген үзләренең гаиләләренә кайта алсалар, үзләренең балаларының, оныкларының җиргә чын хуҗалар булып әверелүләрен күрә алсалар, алар чиктән тыш бәхетле булыр иде дип ышанам.

Үлем сугышының җиңүле тәмамлануына карамастан, без аларны озак көттек. Ләкин көтеп ала алмадык. Алар бүген безнең янга төшебездә генә кайталар. Яшь, сәламәт, көчле, җирдә эшләргә атлыгып торучылар булып төшкә керәләр.

Табигать законнары — какшамас законнар. Тормыш дәвам итә. Бүген үзләренең иректе җирендәге лаеклы тормышны теге чакта бер кишәрлек үз җире турында хыялланган шәһит солдатларның токымнары дәвам иттерә.

*Июль, 1999 ел.*

## МОРТАЗА РӘХИМОВ:

## Без бергә һәм дус яшибез...

*Башкортстанны хаклы рәвештә Русиянең энҗе бөртеге дип атыйлар. Бездә табигать бай, җир асты байлыклары Менделеевның бөтен серен үз эченә сыйдырган өчен генә дә түгел. Республика куәтле икътисади һәм рухи потенциалга ия, ә аның төп байлыгы — искиткеч хезмәт сөючән халкы ул — төрле милләтләрнең һәм үзенчәлекле мәдәниятләрнең гүзәл гөлләмәсе. Һәм республикада иң кадерлесен — тынычлыкны, милләтләр арасында татулыкны, халыклар дуслыгын саклап калуыбыз белән горурланабыз.*

М.Г.РӘХИМОВ,
Башкортстан Республикасы Президенты

### БЕРЕНЧЕ ПРЕЗИДЕНТ

Бу әкияттәгедәй матур төбәк турында сүзне нәрсәдән башларга? Татарстан белән күрше булган тугандаш республиканың матурлыгын һәм куәтен нинди сүзләр һәм саннар белән белдерергә мөмкин?!

Башкортстанның мәйданы 143,6 мең квадрат километр тәшкил итә. Ул Татарстан территориясеннән ике тапкырдан артыгракка зур һәм Русия Федерациясе мәйданының бер проценты чамасын тәшкил итә. Территориянең озынлыгы төньяктан көньякка — 550 километр, көнбатыштан көнчыгышка 450 километрдан артыграк.

Башкортстанда 4,1 миллион кеше яши. Бу Русия Федерациясе халкының 2,7 проценты. Башкортстан Республикасы Русия Федерациясе субъектлары арасында халык саны буенча җиденче урында тора. Аның географик урыны да уңайлы. Республика территориясе буйлап мөһим тимер юл, торба үткәргеч һәм автомобиль магистральләре үтә. Биредә файдалы казылмаларның Менделеев таблицасындагы бөтен элементлары да бар. Республикада 30 дан артык милләт тыныч һәм тату яши. Аның башкаласы Уфада — 1 миллион 100 мең кеше яши.

Башкортстанга төрле вакытта төрле кешеләр җитәкчелек итте. Әмма өлкә комитетларының беренче секретарьлары халык хәтерендә зур эз калдырды. Моңа кадәр республикага президентлар җитәкчелек итмәде. Мортаза Гобәйдулла улы Рәхимов — 1993 елның декабреннән Башкортстанның беренче Президенты.

Ул 1934 елның 7 февралендә Башкортстанның Күгәрчен районы Тәвәкән авылында крестьян гаиләсендә туган. Нефть техникумын тәмамлагач, Уфа нефть эшкәртү заводында оператор булып эшли башлый. Бер үк вакытта нефть институтында кичке бүлектә укый. Җайланма начальнигы вазифасына кадәр күтәрелә. СССРдагы иң зур заводның цех начальнигы урынбасары, баш инженер урынбасары, баш химигы, баш инженеры һәм генеральный директоры була. СССР халык депутаты, аннары Башкортстан Республикасы Югары Советы Рәисе итеп сайлана.

Безнең әңгәмәбезне Мортаза Гобәйдулла улы беренчеләрдән булып үзе башлады һәм болай диде:

— Мин безнең халыкларыбызның тормышына профессиональ кызыксыну күрсәткән өчен, әңгәмәбезне оештырган өчен сезгә һәм җитәкчеләрегезгә рәхмәтлемен. Безнең республикаларыбыз халыклары меңнәрчә еллар бу урыннарда дус һәм тату яшәгән. Без бер үк суны эчеп үскәнбез. Татарлар һәм башкортлар бер үк телдә диярлек сөйләшәләр. Җыр-моңнарыбыз да уртак. Бер үк гореф-гадәтләрне һәм традицияләрне саклыйбыз. Мөстәкыйльлек алсак та, безнең республикаларыбызга аерым яшәү килешми. Форсаттан файдаланып, Татарстанның барлык халыкларына туганлык сәламнәремне юллыйм, барсына да сәламәтлек, иминлек һәм мул тормыш телим.

**— Мортаза Гобәйдуллович, Башкортстан Конституциясе республиканы демократик җәмгыять буларак үстерү өчен нинди әһәмияткә ия?**

— Башкортстанның Совет власте чорында да үз Конституциясе булды. Безнең хәзерге Конституциябез Русия Федерациясе Конституциясеннән аерылып тора. Анда Башкортстанның дәүләт булуы турында анык язылган. Конституция нигезен безнең республикабыз белән Русия Федерациясе арасында кул куелган Федератив договор тәшкил итә. Федератив договорга кушымтасы белән кул куелды. Анда, җир, җир асты байлыклары һәм дәүләтебезнең башка табигый ресурслары Башкортстан халыкларыныкы, тышкы икътисади эшчәнлек, суд системасы, прокуратура һәм адвокатура безнең республикабыз карамагында тора, дип ачык язылган. Финанс буенча гына без Үзәк белән договор төзергә тиешбез.

**— Башкортстан Республикасы территориясендә урнашкан хәрби сәнәгать комплексы предприятиеләре һәм югары уку йортлары —федераль властьларның хәстәрлегедер, мөгаен?**

— Алай ук түгел. Федератив договор нигезендә без вузларны да, хәрби сәнәгать комплексының күп кенә программаларын да финанслыйбыз.

Үзебезнең Конституциябезгә кире кайтыйк әле. Анда законнар чыгару, башкарма һәм суд властьларының роле һәм урыны анык билгеләнгән. Әйтеп үтүемчә, безнең Конституциябез Русия Федерациясе Конституциясеннән берникадәр аерылып тора. Минемчә, бу нормаль күренеш. Биредә бернинди фаҗига да юк. Аларның кайбер статьялары туры килми, кайберәүләре теге яки бу конституциядә бөтенләй юк.

Ни өчен әле барлык конституцияләр дә нәкъ Русия Федерациясе Конституциясенә ярашлы булырга тиеш? Русиянең Төп Законы барлык конституцияләр өчен нигез булырга тиеш. Аның Конституциясендә татарларның, башкортларның, бурятларның ничек яшәргә тиешлеге турында язылмаган бит. Ничек кенә булмасын, безнең тарихларыбыз, гореф-гадәтләребез, традицияләребез, мәдәниятебез төрле. Икътисади тормышыбыз, климат шартлары да төрле. Безнең Конституциябез парламентыбыз тарафыннан кабул ителде һәм, нигездә, Русия Федерациясе Конституциясе рухына туры килә.

Бүген нәрсә хакында бәхәс бара? Кайбер Русия губерналарында ул нәрсәдән башланып китте? Әллә без берәрсенең ризыгына керәбезме? Һич алай түгел! Безнең республика Русиянең иң куәтле донор субъектлары арасында исәпләнә. Киресенчә, без үзебез күпләрне ашатабыз.

Янә игътибарыгызны юнәлтүегезне үтенәм: Башкортстан Республикасының мөстәкыйльлеге турында сүзләр астында минем имзам янәшәсендә Русия Федерациясе Президенты Б.Н.Ельцинның имзасы да тора.

**— Шулай да югарыда искә алынган ике Конституциядә каршылыклар бардыр?**

— Бар. Әмма алар бәхәс алып барырлык, теге яки бу Конституциянең гамәлдә булуын туктатып торырлык, Конституцион судка тапшырырлык дәрәҗәдә кискен түгел. Кем әйтмешли, түземлелек белән, ашыкмыйча бер-беребезгә таба барырга кирәк.

**— Башкортстан Республикасының дәүләт корылышын якындагы 5—10 елда, аннары 50 елда ничек күзаллыйсыз?**

— Безгә Башкортстанның мөстәкыйльлеген тирәнәйтергә һәм киңәйтергә, Үзәк белән федератив мөнәсәбәтләрне сыйфат ягыннан яңа дәрәҗәгә күтәрергә кирәк. Без Русия Федерациясе составыннан чыгабыз, дип беркайчан да белдермәдек бит. Безнең юлыбыз, күрше Татарстан юлы кебек үк — Русия Федерациясенең бөтенлеген саклау өчен бердәнбер дөрес юл ул. Аннары XXI гасырга аяк басканда кая чыгасың? Айга гына булмаса? Күреп торасыз, икътисади җәһәттән бөтен дөнья берләшә. Аннары нәрсә тел чарлап торырга? Башкортстан үзенең тарихы дәверендә Русия белән договор мөнәсәбәтләрендә яшәде. Хәзер федератив мөнәсәбәтләрне һичшиксез тирәнәйтәчәкбез һәм киңәйтәчәкбез. Биредә иң мөһиме — республикабыз һәм тоташ Русия Федерациясе икътисадын күтәрү. Калганы җайланыр. Безнең барлык бәлаләребез, комплексларыбыз һәм амбицияләребез акылсызлыктан түгел, хәерчелектән.

**— Ә Русиянең дәүләт корылышын якындагы елларда ничек күзаллыйсыз — Федерация кәгазьдә генә калырмы? Тулы хокуклы федерация булырмы? Конфедерацияме?**

— Бары тик федерализм гына. Яңартылган демократик Русиядә чын федерализм. Бернинди губерналаштыру кирәкми. Әгәр милли берләшмәләрне, бигрәк тә бәйсез республикаларны губерналаштыруга барсак, бәлане көт тә тор. Ул Русиянең бетүенә китерәчәк. Безгә тыныч һәм тату яшәү ошамыймыни?

Ахыр чиктә халкыбыз аңлый: кемнең патша яки Президент булуы — Ельцинмы, Иванов, Петров яки Сидоровмы — аның өчен әһәмиятле түгел. Икътисад кына яхшы үссен, халыкның тормыш дәрәҗәсе генә күтәрелсен, туган теле һәм үз мәдәнияте генә үссен, гореф-гадәтләр һәм традицияләр генә саклансын. Кайбер кызу башларның «тегендә китәбез, монда китәбез» дип кычкырынулары көлке генә тудыра. Кая китик инде без? Никахларның өчтән бере дә бездә катнаш никахлар бит.

Конфедерациягә килгәндә исә, безнең җәмгыятебез андый дәрәҗәгә килеп җитмәде әле.

**— Шулай да Башкортстанда судьяларны кем тәгаенли һәм кирәк булган очракта кем бушата?**

— Без үзебез тәгаенлибез. Үзебез үк бушатабыз да. Әйткәнемчә, безнең республикада судьялар турында үзебезнең законыбыз бар. Судьялар турында федераль законны кабул иткәндә хаталарга юл куелган. Бәлки, күбесе белмәүдәндер. Федерация советында без М.Ш.Шәймиев белән катгый каршы чыккан идек. Кызганычка каршы, безне якламадылар. Хәзер Русия Федерациясе Конституцион судына судьялар турындагы законның Конституциягә ярашлы булмавы турында мөрәҗәгать иттек. Үзегез уйлап карагыз, Русия Президенты, судьяларны тәгаенләгәндә, аның эшлекле, кешелек сыйфатлары турында беләмени? Хәтерегездәдер, хәтта Совет власте чорында да судьяларны сайлап куялар иде. Бүген исә демократик федерализм турында сөйлибез, ә эштә киресенчә килеп чыга.

Без бу мәсьәләне цивилизацияле хәл итү өчен көрәшәчәкбез. Аннары без Минтимер Шәрип улы белән судьялар турындагы законның билгеләнгән регламентны бозып, ягъни турыдан-туры тавыш бирү түгел, ә сорау алу юлы белән кабул ителүенә игътибарны юнәлттек.

**— Яңа Салым кодексы проектына ничек карыйсыз? Тәкъдим ителгән проект федерация субъектларын Үзәккә бәйләгән кебек түгелме?**

— Без Башкортстанда Салым кодексының мондый проектына катгый каршыбыз. Әгәр ул шушы килеш кабул ителсә, безгә «федерализм» сүзен бөтенләй онытырга кирәк булачак. Яңа проект регионнарны Үзәккә бәйли, унитар дәүләт тудыра. Дәүләт думасы аны кабул итмичә дөрес эшләде. Бу мәсьәлә астына нокта куярга иртәрәк әле. Федерация Советы да бу җәһәттән үзенең сүзен әйтер, дип ышанам. Федерализм турында сөйлибез икән, бюджет федерализмының аның өлешен тәшкил итүе турында онытырга ярамый.

## СӘНӘГАТЬ ПОТЕНЦИАЛЫ — ГАЯТЬ ЗУР

**— Бүген республиканың сәнәгать-икътисад потенциалы нинди? Хосусыйлаштыру нинди нәтиҗәләр бирде? Эш хакын түләү тоткарланамы?**

— Башкортстанның сәнәгать потенциалы, һичшиксез, гаять зур. Федерациянең 89 субъекты арасында сәнәгать продукциясе күләме

буенча без 36 нчы урында торабыз. Табыш күләме буенча — өченче урында. Авыл хуҗалыгы продукциясе күләме буенча да өченче урында. Ә салым җыю буенча җиденче урында торабыз. Шуңа күрә дә Башкортстан белән Татарстанның Русия Федерациясенең иң куәтле донорлары булуы очраклы түгел.

Дөресен әйтергә кирәк, республика сәнәгате әлеге көндә авыр хәлдә тора. Без надан кешеләр булган яки начар эшләгән өчен түгел. Бүген бөтен фаҗига шунда, без Советлар Союзы чорында үткәрелгән сәясәт җимешләрен җыябыз. Социалистик планлы хуҗалыкның төп күрсәткече булып тулай продукция тора иде.

СССР таркалгач барлык бәйләнешләр дә өзелде. Шул сәбәпле күп кенә производстволар туктап калды. Менә шул сәнәгать производствосының кимүенә китерде дә инде.

Хәрби-сәнәгать комплексы предприятиеләре белән эш итүдә тупас хатага юл куелды. Дөньяда коралсызлану бара имеш, барлык оборона производстволары да туктап калды. Теге яки бу корал төренә ихтыяҗ бар икән, ни өчен аны җитештереп сатуны дәвам итмәскә? Алынган валютага яңа сәнәгать технологияләре сатып алырга һәм халык хуҗалыгы продукциясен җитештерүгә, халык ихтыяҗына җибәрергә кирәк иде. Өстәвенә элегрәк тә югары сыйфатлы көнкүреш товарлары оборона предприятиеләрендә эшләнә иде. Чөнки иң яхшы станоклар һәм җиһазлар, югары класслы белгечләр аларда эшли иде. Хәзер исә корал базарын яңадан яулап алу бик кыен булачак. Аннары үзебез өчен шулкадәр танк һәм башка кораллар нәрсәгә кирәк булгандыр. Ә Русиядә авыл хуҗалыгы машиналары җитештерү буенча производствоның артта калуын искә дә төшермәделәр. Кеше тормышының бу өлкәсендә бүген дә бернәрсә дә эшләмибез бит.

Хосусыйлаштыруга килгәндә исә, без аны үзебезнең Башкортстан законнары буенча үткәрдек. Ваучерларны 10 мең сум түгел, ә 40 мең сум итеп билгеләдек.

Нәрсә ул хосусыйлаштыру? Ул намуслы һәм вөҗданлы кешеләргә исәпләнгән. Кызганычка каршы, бу эштә бездә намуссызлар күбрәк булып чыкты. Һәм шунысы кызыклы, бу кешеләр барсы да әлеге яки элеккеге коммунистлар, партия җитәкчеләре. Менә сиңа чорыбызның акылы, намусы һәм вөҗданы!

Башта әзерлек эшләре үткәрергә кирәк иде. Хосусыйлаштыруны сәүдәдән, көнкүрештән, җирле сәнәгатьтән башларга кирәк булган. Республиканың, илнең икътисадын билгеләүче төп предприятиеләрне дәүләткә калдырырга һәм әкренләп хосусыйлаштырырга кирәк иде. Ә без бер көндә, исерек сәүдәгәр кебек, барысын да сатып, туздырып, таратып бетердек. Нәтиҗәдә күп байлыгыбыз чеп-чи караклар кулына калды.

**— Ә республикада эш хакы түләү ничек тора?**

— Әлбәттә, хәл бөтен федерациядәге кебек. Хәзерге вакытта бюджет хезмәткәрләренә бурыч республика буенча 140 миллиард сум тәшкил итә. Ә предприятиеләрдә 1 триллион 741 миллиард сум. Болар барсы да бартер нәтиҗәләре. Гомумән, шушы яманаты чыккан бартер карак-

лар, мафиоз структуралар өчен уйлап табылган. Шушы бартер аркасында акча булмау шундый фаҗигагә китерде. Минемчә, дөньяда хезмәт хакын бирмәгән бер генә дәүләт тә юктыр һәм булырга да тиеш түгел. Безнең очракта кем төп рэкетир? Дәүләт, әлбәттә! Бу хәлне бөтенләйгә бетерергә кирәк. Сәнәгать икътисадын үстерү перспективаларына килгәндә исә, бездә, Татарстандагы кебек үк, бар алар. Һәм Башкортстан икътисады якын киләчәктә аякка басар, дип ышанам.

## БЕЗ АВЫЛНЫҢ ТАРКАЛУЫНА ЮЛ КУЙМАДЫК

**— Авылда социаль-икътисади хәл нинди? Колхозлар, совхозлар, кулланучылар кооперациясе, «Сельхозтехника» сакландымы?**

— Без колхозларны һәм совхозларны, шулай ук кулланучылар кооперациясен таркатуга юл куймадык. Безнең кооператорларыбыз соңгы биш елда Русия буенча беренче урында тора. Белмим, Русиядә бу кооперация күптән бетерелгәндер, бәлки. Әгәр без кулланучылар кооперациясен саклап калмаган булсак, авылларның бетүенә булышлык итәр идек.

Шул ук вакытта безнең кулланучылар кооперациясе кебек эшләргә ярамый, дияр идем. Алар үзләренә зыян китереп яши. Һәр предприятие табыш алып эшләргә тиеш. Сәүдә бигрәк тә. Хәтта кечкенә авылларда булса да. Кооператорларның идарә итү аппараты структурасы бик зур бит. Шуңа күрә дә чыгымнары да бик зур. Анализлый башласак, таң каласың. Шул ук итекне генә алыйк. Башта аны базага, аннары районара базага, аннары райпотребсоюзларга, сельполарга ташыйлар. Шуннан соң гына кибетләргә барып җитә. «Хәзерләүче — кибет» схемасы буенча турыдан-туры эшләргә кирәк. Шул чакта товар да сыйфатлы булачак. Табыш та алыначак.

Колхозларга һәм совхозларга килгәндә исә, без аларны саклап калдык. Фермер хәрәкәте башланганда бездә дүрт меңнән артык фермер исәпләнә иде. Тора-бара аларның саны шактый кимеде. Бүгенге көнгә өч меңгә якын гына тәшкил итә. Алар 81 мең гектар җир эшкәртә, әмма канәгатьләнерлек файда алалмый. Начар эшләгән өчен түгел. Без аларга тиешле шартлар тудыра алмадык әлегә. Аларның хезмәт коралы да юк. Бүгенге көндә фермер бер миллиард сумлык «Дон» комбайнын сатып алырлык хәлдә түгел.

Аннары гаилә, кардәшлек төркемнәре ныклы булган фермерлар хуҗалыклары яшәүчән. Алар кечкенә колхозлар кебек. Тик шунысын әйтергә кирәк, алар таңнан-таңга кадәр һәм ялсыз 12 — 14 әр сәгать эшли.

Бүген Башкортстанның авыл хуҗалыгы чәчәк ата, дип әйтә алмыйм. Ләкин без авылны саклап калдык. Чөнки авылларда колхозчыларның да, пенсионерларның да, интеллигенциянең дә өчтән бере яши. Республика үткән елда гына да авыл хуҗалыгына ярдәм итү өчен 2 триллион сум акча тотты. Ә бернинди файда да булмады. Арытаба болай дәвам итә алмый. Шуңа күрә дә авыл хуҗалыгына реформа үткәрү бурычын куябыз. Шул ук колхозларны саклап, хуҗалык эчендә

реформа үткәрергә кирәк. Шушы мөһим мәсьәләгә эчтән карарга кирәк. Кайвакыт кызык хәлләр була. Колхоз рәисе итнең үзкыйммәте турында да белми. Башкортстан базарларында ит 12 — 13 мең сум тора икән, ә колхоз итенең үзкыйммәте 25 мең сум икән, мондый ферманың нәрсәгә кирәге бар?

Русиядә юньле генә авыл хуҗалыгы техникасы да юк. Безнең «Сельхозтехника» системасын саклап калуыбыз берникадәр ярдәм итте. Дөрес, формасын, берникадәр үзгәрттек, әмма саклап калдык.

Бүген авылда халык саны да арта. Авыл яшьләре шәһәргә омтылып бармый инде, хәтта шәһәр кешеләре дә үзләренең авылларына кайта. Авылларда юллар төзүне дәвам итәбез, газ үткәрәбез. Якындагы өч-дүрт елда авыл юлларына асфальт җәюне һәм газ үткәрүне тулысынча тәмамларбыз, дип уйлыйбыз. Авылда торак та күп төзелә. Безнең авылларда күбрәк урыс телле булмаган халык — башкортлар, татарлар, марилар, мордвалар, удмуртлар, чувашлар яши. Аларның тамырлары авылда береккән һәм шәһәрләргә омтылып бармый. Шуңа күрә шәһәрләрдә, нигездә, урыс телле, ә авылларда башка милләт халкы яши. Үзебезнең дәүләт сәясәтендә моны исәпкә алырга туры килә.

Авылларны тулысынча тергезергә кирәк. Чөнки бөтен башлангычларыбыз шуннан килә. Республиканың киң танылган, талантлы кешеләре — язучылар, шагыйрьләр, артистлар, композиторлар каян килгән дисез? Алар барсы да авылдан чыккан.

**— Ишеткәнсездер инде, Татарстанда яңа нигездәге МТСлар оештырыла.**

— Ишеттем. Мондый башлангычны, ихлас яклыйм. Без дә МТСлар оештырачакбыз, әлбәттә, яңа нигездә. Мәләвездә шундый МТС булдырдык инде. Аларга Америка тракторлары, комбайннары сатып алырга ярдәм иттек. Колхозлар бүгенге көндә миллиардлар түләп авыл хуҗалыгы техникасы сатып алалмый. Шулай булгач, МТС хезмәтеннән файдалансыннар инде.

**— Бәлки, безгә, гомумән, Америкадан авыл хуҗалыгы техникасы сатып алуга күчәргәдер?**

— Әгәр Русиядә авыл хуҗалыгы машиналары җитештерү буенча хәл үзгәрмәсә, шулай эшләргә туры киләчәк. Русиянең яраксыз техникасы өчен гадәттән тыш зур акчалар түләгәнче, бәясе дә күтәрерлек һәм техникасы да авыл эшчәннәре таләпләренә җавап бирерлек булган җирдән алачакбыз.

## ҖИРГӘ КЕМ ХУҖА?

**— Җиргә милек турында нәрсә әйтерсез?**

— Җиргә милек турында сөйләшүләр башлангач, без республикада 1995 елда референдум үткәрдек. Тавыш бирүдә катнашучыларның 85 проценты җирне милек итеп сатарга ярамый, диде.

Әлбәттә, җирне сәнәгать предприятиеләренә тапшырырга ярамый. Шул ук вакытта мин авыл хуҗалыгы җирләрен таратуга да каршы-

мын. Байлар килеп, бөтенләйгә сатып алачак. Без җирсез булдык, җирсез калачакбыз.

Шул ук вакытта җирдә хуҗа булырга тиеш. Җирдә реформалар үткәрелергә тиешлеген дә аңлыйбыз. Мин указ чыгарган идем. Аңа ярашлы рәвештә, дача участоклары, предприятиеләр, йортлар һәм муниципиаль учреждениеләр мәйданнары, гараж участоклары сатылырга һәм сатып алынырга тиеш.

Җир — безнең байлыгыбыз. Җир — безнең милкебез. Без аңа бик сакчыл караячакбыз.

## ЭЧӘРГӘМЕ, ЮКМЫ?

**— Республикада, аерым алганда Уфада, экологик хәл нинди? Татарстанлыларны нефть үткәргечләрдәге аварияләр, нефть эшкәртү һәм нефть химиясе заводларында чыгарылган зарарлы газлар һәм сулар һәм шул сәбәпле Агыйдел, Кама елгаларының пычрануы борчый. Чөнки татарстанлыларның зур өлеше шушы елгалар ярларында яши, шуннан су эчә. Бүген, бу суны эчәргәме, юкмы дигән сорау тора.**

— Башкортстанда экологик хәлне яхшыртасы бар. 90 нчы еллар башында демократия дулкынына бирелеп «яшелләр» хәрәкәтенең таләп итүе буенча без күп кенә производстволарны япкан идек. Минемчә, тупас хата ясадык. Шул ук вакытта Башкортстан өстенә гаять зур экологик йөк төшә. Әйтерең бармы, ел саен 65 миллион тонна нефть эшкәртәбез бит.

Бүген без, экологик хәлне тамырыннан яхшыртуны исәпкә алып, нефть эшкәртү һәм нефть химиясе сәнәгате предприятиеләрен реконструкцияләүгә зур чыгымнар тотабыз. Мин республикада нефть чималын эшкәртү күләмен киметү ягында торам. Без аны елына 25 миллион тоннага кадәр киметәчәкбез. Гомумән, Башкортстанның экологик хәлендә сыналыш чоры җитте. Федераль хөкүмәт бу мәсьәләдә, кем әйтмешли, «кулын юды». Барысын да безнең үзебезгә һәм үзебезнең средстволарыбыз исәбенә эшләргә туры киләчәк. Һәм эшләячәкбез. Экологик хәлне яхшырту мәсьәләләрендә безгә Татарстан Республикасы белән тырышлыкларыбызны берләштерергә кирәк. Кызганычка каршы, химия һәм нефть химиясе мәсьәләләрендә күрше республика җитәкчеләре ягыннан яклау табалмыйм. Хәзерге вакытта нефть химиясенең 72 төрле ярымфабрикатын Татарстанга бирәбез. Һәм сездән 18 төрле ярымфабрикат алабыз. Шуңа күрә бер генә производствоны япсак та, сездә бөтен нефть химиясе туктап калачак. Шуңа күрә берләшеп, бер зур нефть химиясе холдинг компаниясен төзергә кирәк. Менә шул чакта экологик хәлне яхшырту мәсьәләләрен хәл итү дә җиңелрәк булачак.

**— Татарлар турында сөйләшик. Һәм алар турында гына да түгел. Тарихи шулай килгән, Башкортстан Республикасында бик күп татар яши. Республиканың иҗтимагый-сәяси һәм икътисади тормышында татарлар нинди роль уйный?**

— Бездә барсы да шулай буталып бетте ки, хәтта кемнең татар, кемнең башкорт булуын да билгеләве кыен. Алар тугандаш халыклар бит. Аннары катнаш никахлар да күп. Гомумән, соңгы халык исәбен алу мәгълүматлары буенча, Башкортстанда 21,9 процент башкортлар, 28,4 процент татарлар, 39,3 процент урыслар яши. Әлбәттә, шундый заманнар да булды. Өлкә комитетының беренче секретаре башкорт булса, барысын да башкорт дип яздырырга, татар булса, барысын да татар дип яздырырга кирәк, дип белдерә иде. Болар барсы да юләрлек, әлбәттә. Без бер ана балалары булуыбыз турында онытырга тиеш түгелбез. Бер-беребезне ихтирам итәргә тиешбез. Кеше кем булып туган, шул милләтен язарга кирәк.

Хәзерге вакытта Башкортстанда туган телне торгызу, мәдәниятне үстерү буенча күп эш башкарыла. Мин, мәсәлән, татар баласының — татар мәктәбендә, башкорт баласының башкорт мәктәбендә укуы яклымын. Бездә милли мәктәпләрдә укыту кискен артты. Байтак милли балалар бакчалары ачылды. Гомумән, Башкортстанда укыту 14 телдә алып барыла. Бу бик дөрес. Балалар ана телен белергә тиеш. Әгәр бала үзенең туган телен белә икән, ул рухи һәм әхлакый яктан бөтенләй башка кеше булачак. Республикабызның күпмилләтле булуын аның өстенлеге дип карарга кирәк.

**— Милли укытучы кадрлар белән үзегезне ничек тәэмин итәсез?**

— Безнең республикада милли педагогик училищелар җитәрлек. Югары уку йортлары каршында да факультетлар һәм бүлекләр бар. Бу мәсьәләдә бездә проблемалар юк. Моннан тыш, шәһәрләрдә якшәмбе мәктәпләре эшли.

Безнең республикада ике татар театры бар. Хәзерге вакытта Уфада яңа татар драма театры төзелә. Моннан тыш, халык театрлары, үзешчән сәнгать коллективлары да бик күп. Милли мәдәният үзәкләре эшләп килә. Без Башкортстанның барлык төр халыкларының корылтайларын үткәрдек. Хәтта украиннар һәм греклар корылтайлары да булды. 1998 елда Башкортстанның барлык халыклары конгрессын үткәрәчәкбез.

**— Информация белән тәэмин итү җәһәтеннән республика халыклары ничек канәгатьләндерелгән?**

— Барлык милли районнарда да халыкның туган телендә гәзитләр чыга. Радио һәм телевидение аша милли телләрдә тапшырулар алып барыла.

Әгәр татарларны тәгаен алып карасак, Уфада татар телендә «Кызыл таң» республика гәзите чыга. Һәм һәр татар районында үзенең гәзите нәшер ителә. Республика радиосы һәм телевидениесендә дә татарлар өчен вакыт бирелә. Татар китап нәшрияты эшли.

**— Республика, аерым алганда Уфа халкы арасында шундый фикер яши. Имеш, республиканы мөстәкыйльләштерү сәбәпле, җитәкче вазифаларга татарларны үткәрмиләр, аларны вазифаларыннан алалар. Бу дөресме?**

— Бу ялган сүз, әлбәттә. Хөкүмәт, дәүләт учреждениеләрендә, киресенчә, башкортларны табуы кыен. Республика Министрлар кабинетында бер Ишморатов кына башкортча сөйли белә. Калганнары барысы да татарлар (башка милләтләрне исәпкә алмаганда, әлбәттә). Президент аппаратында берничә башкорт бар, әлбәттә. Республика Фәннәр академиясе президенты академик Нигъмәтуллин дә татар. Гомумән, татарлар искиткеч иптәшләр, җаваплы хезмәткәрләр, әдәпле кешеләр алар. Аларны кысуның һич кенә дә кирәге юк. Алар безнең туганнарыбыз бит. Бер дин кешеләре.

## БИШЕНЧЕ ГРАФА ТУРЫНДА

**— Мортаза Гобәйдуллович, яңа паспортка мөнәсәбәтегез нинди? Безгә милләт графасы да булмаган паспорт бирә башладылар бит.**

— Мин милләт графасын гамәлдән чыгаруга катгый каршымын. Әгәр федераль властьлар бу мәсьәләдә үзләренең юләрлек эшләвен аңлап, яңа паспортны үзгәртмәсә, без милләт күрсәтелгән битне үзебез кертәчәкбез. Безнең күпмилләтле республикабызда бу мәсьәлә белән шаярырга ярамый. Яңа паспортта милләтнең күрсәтелүе өчен нык тырышачакбыз.

## МӘЧЕТЛӘР, ЧИРКӘҮЛӘР, СИНАГОГАЛАР ҺӘМ ХАҖ ТУРЫНДА

**— Мортаза Гобәйдуллович, Башкортстанда конфессияләр арасында татулыкка ничек ирешелә?**

— Бу минем өчен бик четерекле мәсьәлә. Кешене көчләп чиркәүгә дә, мәчеткә дә кертеп булмый. Җиде дистә еллар буена котырынган атеизм чорында кешеләр бөтенләй үзгәрде. Башка карашлы кешеләр үсеп чыкты. Барысы да әкренләп, иректе нигездә кешеләрнең теләге буенча эшләнергә тиеш.

Миңа КПСС райкомнарының кичәге беренче секретарьлары муллаларга, имамнарга әйләнүе ошамый. Бездә андый очраклар булды. Элекке секретарьдан нинди мулла булсын? Кичә генә дингә бирелгән өчен КПСС сафларыннан чыгарылган кеше, бүген Алла исеме белән азан укый. Яки кичә КПСС Өлкә комитетының беренче секретаре булган, ә бүген шәм тотып, елар чиккә җитеп, чиркәүдә тора. Болар миңа һич кенә дә ошамый.

Без элек тартып алынган мәчетләрне, чиркәүләрне мәхәллә кешеләренә кайтарып бирү буенча күп эшлибез. Үзем дә мөмкин булганда Корбан бәйрәмендә, Ураза бәйрәмендә Русия мөселманнарының Диния нәзарәте каршындагы Җәмигъ мәчетендә булгалыйм. Минем белән Президент аппараты һәм Министрлар кабинеты хезмәткәрләре дә баргалый.

1994 елда Русия мөселманнарының Диния нәзарәте җитәкчесе

мөфти хәзрәт Тәлгать Таҗетдин белән хаҗ кылдым. Әйткәндәй, анда Татарстанның да күп кенә җитәкчеләре булды. Кешеләр Аллага ышансын, ул әшәкелектән арындыра.

## КЕЧКЕНӘ КОММУНИЗМ, ТАТАРЛАР КОНГРЕССЫ ҺӘМ НУРЛЫ КАЗАН ТУРЫНДА

**— Мортаза Гобәйдуллович, Уфага һәм Башкортстанның башка шәһәрләренә килгәндә мине автобусларда, трамвайларда һәм троллейбусларда халыкның түләүсез йөрүе гаҗәпләндерә. Нәрсә бу — кечкенә коммунизм төреме?**

— Бу кечкенә коммунизм да, зур популизм да түгел. Чарасызлыктан шулай ул. Килеп туган хәл-шартларны исәпкә алып, биш ел элек без шундый чарага барырга мәҗбүр булдык һәм шәһәр транспортын бюджет исәбенә тотабыз. Бу безгә зур гына суммага — елына 200 миллиард сумга төшә.

Үзегез уйлап карагыз, күпләр айлар буена эш хакы алалмый. Пенсияләр түләү белән дә тоткарлыклар булды. Кайвакыт авыру кеше поликлиникага да барып җитә алмый иде. Менә шуңа күрә дә әлегә шундый юлдан барырга карар иттек.

Әмма бу вакытлы чара. «Коммунистларча» йөрү кешеләрне боза. Тормышта һәрнәрсәнең бәясе бар. Әкренләп бу «коммунизмнан» арыначакбыз. Ә 1998 елда транспортта йөрү түләүсез калыр, мөгаен.

**— Сез икенче Бөтендөнья татар конгрессы эшендә катнашкан идегез. Тәэссоратларыгыз нинди?**

— Конгресс югары дәрәҗәдә оештырылган иде. Бар яктан да шәп әзерләнгәннәр. Конгресс рәисе академик Индус Таһировның докладды бик уйланылган иде. Әйткәнчә, ул саф татар телендә яңгырады.

Татарстан Президенты Минтимер Шәрип улы Шәймиевнең тирән эчтәлекле чыгышы да зур тәэсир калдырды. Ул да үзенең докладын саф татар телендә ясады. Чит ил кунакларының чыгышлары да бик ошады. Кыскасы, конгресс шәп килеп чыкты.

**— Татарстан башкаласы Казан турында тәэссоратларыгыз нинди?**

— Соңгы елларда Казан күз алдында яхшы якка үзгәрде. Бөтендөнья конгрессы көннәренә ул тагын да матурланган иде.

Конгресстан кайткач та Уфа һәм Башкортстан Министрлар кабинеты җитәкчеләренең зур делегациясен шәһәр төзелешен яхшыртуга, иске районнарны реконструкцияләүгә өйрәнсеннәр өчен Казанга җибәрдем. Киләчәктә дә казанлыларның алдынгы тәҗрибәсен өйрәнәчәкбез.

## ҮЗАРА ХЕЗМӘТТӘШЛЕК ТУРЫНДА

**— Мортаза Гобәйдуллович, сезнең республиканың Русия Федерациясенең башка субъектлары һәм Татарстан арасындагы договорларында аерма бармы? Бар икән, нәрсәдән гыйбарәт?**

— Әлбәттә, аерма бар. Беренчедән, без якын кардәшләр. Икенчедән, без күршеләр. Сәнәгатебез дә үзара тирән бәйләнгән. Сәяси яктан да бер планда булдык һәм шулай булып калачакбыз.

Без бер-беребезне якларга тиешбез. Бигрәк тә Русиядә милли мәсьәләләргә бәйле хәлләр, кызганычка каршы, яхшы якка үзгәрмәгән вакытта. Әгәр без бер-беребезгә ярдәм итмәсәк, безнең киләчәгебез шикле. Чөнки хәзерге вакытта халыкларны урыслаштыру линиясе буенча көчле басым сизелә.

Ике республиканың авыл хуҗалыгын таркатуга юл куймавы, күп кенә тармакларда башкаларны узып китүебез, милләтләр һәм конфессияләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең тотрыклы булуы барысына да ошамый. Сез моны матбугат һәм телевидение аша да үзегез күреп торасыз.

Мин сезнең Президентыгыз Минтимер Шәрип улы Шәймиевне ихтирам итәм, безнең бер-беребезгә ышануыбыз кешеләргә дә күчә. Гади кешеләр югары дәрәҗәдәге мөнәсәбәтләрне бик тиз сизә. Аллага шөкер, ике дус республикада да югары һәм түбән дәрәҗәләрдәге мөнәсәбәтләр бүген дә яхшы булып кала.

## СОҢГЫ СҮЗ

Башкортстан Республикасының беренче Президенты белән әңгәмә өч сәгатькә якын дәвам итте. Мортаза Гобәйдулла улы тугандаш Татарстан вәкилен әңгәмә барышында вакыт буенча чикләмәде. Шуның өчен автор чын күңелдән аңа рәхмәт белдерә.

*Декабрь, 1997 ел*

**Ф.Ә.ТАБЕЕВ:**

## «Үткән елларым — байлыгым минем»

Фикрәт Әхмәтҗан улы Табеев — чын мәгънәсендә легендар фигура. Утыз бер яшендә ул Татарстан партия өлкә комитетының беренче секретаре булды һәм унтугыз ел буена шул вазифаны башкарды. Тиңдәше булмаган очрак бу! Өстәвенә, Татарстанга ул бөек үзгәрешләр (бернинди арттырусыз) чорында җитәкчелек итте. Ул чагында әле автономияле өлкә булган Татарстанның көньяк-көнчыгышында нефть эшкәртү промышленносте көчле үсеш алган, шәһәрләр һәм матур-матур эшчеләр бистәләре кызу темпта төзелгән, ә Кама буенда Европада иң эре нефть комплексы һәм автомобиль гиганты корылган чор. Яңа шәһәрләргә Советлар Союзының төрле якларыннан яшьләр агыла...

Ф.Ә.Табеевны бик лаеклы рәвештә, яңа Татарстанны иҗат итүче, дип атадылар. Татарстанның социаль-икътисади куәте нәкъ менә шул елларда булдырылды. Артта калган аграр төбәктән ул куәтле промышленность-индустриаль республикага, авыл хуҗалыгын интенсив юл белән алып бару краена әверелде. Менә боларның һәммәсе республиканың суверенлашуында, һичшиксез, төп факторга әверелде.

Егерме ел буена Ф.Ә.Табеев КПСС Үзәк Комитеты әгъзасы булды, күпләгән чакырылышта СССР Югары Советы депутаты, СССР халык депутаты итеп сайланды. Күп орденнарга, шул исәптән биш Ленин орденына ия кеше ул!

1979 елда Ф.Ә.Табеевны дөньяның иң кайнар зонасы булган Әфганстанга Советлар Союзы илчесе итеп җибәрәләр. 1986 елда РСФСР Министрлар Советы Рәисенең беренче урынбасары була. Һәм шул вакытлардан алып аның тормышы Мәскәү белән бәйле. Әмма ул Казанда һәм Татарстанның башка шәһәрләрендә, шулай ук авылларда еш була. Үзе нигез салган КамАЗ автогигантының Директорлар советы әгъзасы да ул.

Бүгенге көндә Фикрәт Әхмәтҗан улы Табеев Россиядәге «Нефтехолдинг» компаниясенең баш киңәшчесе, бу компаниянең офисы борынгы Мәскәү урамнарының берсендә — Олимпия спорт комплексына якын гына Мещан урамында урнашкан.

Соңгы вакытта мин Фикрәт Әхмәтҗанович белән еш очрашам. Турысын әйтим: үткән еллар чәчләрен шактый көмешләндерсә дә, ул әле егетләрчә кыяфәттә: пөхтә, җыйнак. Ә әңгәмәдәш буларак, кабатланмас шәхес. Турыдан-туры бирелгән бер генә сорауны да җавапсыз калдырмый, дөресен әйтә дә бирә. Ачыклыгы, турылыгы белән әсир итә. Киң белемле, эрудицияле булуына, җәмгыятьтә аерым урын алып торуына карамастан, тәкәбберлек, мин-минлек юк.

## СУГЫШ ЕЛЛАРЫ БАЛАСЫ

**— Фикрәт Әхмәтҗанович, Сезнең балачак, әти-әниегез, гомумән, тамырларыгыз турында беләсе килә...**

— Мин 1928 елда Рязань өлкәсе, Ермишин районының татарлар яши торган Азеево авылында туганмын. Үз вакытында анда 7 мәчет бар иде. Крестьяннарның шәхси хуҗалыклары нык. Татарлар арасыннан галимнәр, хәрби начальниклар, дин әһелләре үстереп чыгарган авыл бу. Бай яшәде ул. Болгар дәүләтенең көнбатыш чикләрен саклаучы булды. Нишләптер, безнең авылда халык бик таза, нык бәдәнле иде. Ир-егетләрнең буе 2 метрга җитә. 1812 елгы Ватан сугышында азеевомылар актив катнашкан, махсус Азеево эскадроны булган.

Әнием Сабира Мәҗип кызы гомере буе колхозда эшләде. Әтием һәм аның ике ир туганы да крестьяннар иде. Әтием гражданнар сугышында катнашкан, кызыл командир иде. Урта Азиядә басмачыларга каршы сугыша, Фрунзеның элемтәчесе була. Минем әтием — гасыр яшьтәше. Бөек Ватан сугышы башлануга фронтка китә һәм 1943 елда Калинин фронтында һәлак була. 1925 елда туган абыем Җәүдәтне дә фронтка алалар. Өйдә әнием белән икәү генә калдык. Без, сугыш балалары, бер үк вакытта мәктәптә дә укыдык, колхозда да эшләдек. 1945 елда урта белем турындагы аттестатым белән Баку югары хәрби-диңгез училищесына укырга кердем, аннары мине курсант иттеләр. Әниемне бик сагына идем. Әйткәнемчә, әтием һәлак булды, ә Җәүдәт абыйның озак вакыт кайдалыгын да белмәдек. Аннары шул ачыкланды: ул Прага төркеменә эләккән һәм үзе турында хәбәр сала алмаган. Хәзер ул Мәскәүдә яши.

Бервакыт училище командиры, контр-адмирал Голубев-Манаткин мине оборона министры приказы белән таныштырды (мине чакыртып, аңа хат язарга киңәш бирергә булганнар икән): «Әтиең һәлак булган, абыең хәбәрсез югалган, безнең сине монда тотарга хакыбыз юк, әниең ялгыз бит», — диде ул. Шулай итеп, авылыма кайтып киттем һәм гади колхозчы булып эшли башладым. Казан дәүләт университетына кергәнче әнием янында булдым.

## КАЗАНГА, УКЫРГА!

**— Фикрәт Әхмәтҗанович, ни өчен нәкъ менә КДУны сайладыгыз?**

— Әтиемнең энесе Габдрахман абый Табеев фронттан кайтты. Бөтен җирендә яра эзләре. Сугышка кадәр ул Тимирязев исемендәге авыл хуҗалыгы академиясен тәмамлап чыккан иде. КДУга керергә шушы абзыем акыл бирде. Тарих-филология факультетына кердем, тулай торакта яшәдем. Барлык фәннәрдән «5»легә генә укыдым һәм Сталин стипендиаты булдым. 780 сум стипендия ала идем. Җәмәгать эшендә актив катнаштым: тулай торак старостасы, факультетның комсомол оешмасы секретаре булдым. Тора-бара бөтен университетның профкомы рәисе иттеләр. Дүртенче курста факультет парткомы сек-

ретаре һәм КДУ парткомы секретаре урынбасары итеп сайладылар. Студентлык еллары тиз үтә. Диплом яклар чак та җитте. Мине политэкономия кафедрасында ассистент итеп калдырдылар. Шул чакта ук студентларны укыта башладым, бер үк вакытта диссертация дә яздым. Бер ел ассистент булып эшләдем. 1952 елның азагында мине Мәскәү дәүләт университеты аспирантурасына җибәрделәр. Хезмәтем инде язылып беткән иде, һәм мин өч ел урынына ел ярым гына укыдым. Диссертациямнең темасы: «Промышленностьта эш хакы структурасы». Шуны яклаганнан соң КДУга әйләнеп кайттым һәм доцент булдым. Мине яңадан университетның партком әгъзасы итеп сайладылар.

## ХАКИМИЯТКӘ ЮЛ

**— Сезнең хакимияткә юлыгыз ниндирәк булды?**

— Ул елларда Татарстан партия өлкә комитетының беренче секретаре Семен Денисович Игнатьев иде. Сталин министры, элекке КГБ җитәкчесе. 1957 елда мине партия өлкә комитетына фән, мәдәният һәм мәгариф бүлеге мөдире итеп алдылар. Мәктәпләрдә белем реформасы башланган чак бу. Фәлсәфә фәннәре докторы Фасеев идеология секретаре иде. 1958 елда аны Татарстан Югары Советы Президиумы Рәисе итеп, ә мине өлкә комитетның идеология буенча секретаре итеп сайладылар. Ә 1960 елда инде КПССның Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре булдым.

**— Фикрәт Әхмәтҗанович, Сезне беренче секретарь итеп кем инициативасы белән куйдылар? Хрущев күрсәтмәсе буенчамы?**

— Юк. Шулай килеп чыкты инде. Хрущев һәркайда яшь кадрларны күтәрә башлады. Сүз дә юк, минем кандидатурам аның белән килешенгән булган.

**— Республикада, аерым алганда Казанда, яшь беренче секретарьны киң күңел белән каршыладылар бугай.**

— Каршылавын каршыладылар... Әмма С.Д.Игнатьев кебек сәяси шәхестән соң беренче чорда эшләве җиңел булмады. Оборона предприятиеләрен зур тәҗрибәле кешеләр җитәкли, алар артында — Союз масштабындагы күпне күргән министрлар, күп меңле коллективлар... Алар алдында мин малай гына кебек. ВЛКСМ өлкә комитетының беренче секретаре Фәхретдинов миннән яшь ярымга олырак иде.

**— Хрущев белән еш очраша идегезме?**

— Бик еш. Рухым буенча мин революционер. «Правда», «Известия» газеталарында мөһим темаларга зур-зур мәкаләләр яза идем. Өлкә һәм крайларның реформатор-җитәкчеләрендә яклау таптым. Хрущев мине бик яратты. Мин моны һәрчак белеп-сизеп тордым.

**— Сез бит Татарстанда кукуруз эпопеясын да якладыгыз.**

— Әйе. Моңа уңайсызланмыйм да. Киресенчә, горурланам: Кукуруз — Татарстан авыл хуҗалыгында — бөтен бер революция ул. Бүген Татарстанны кукуруз чәчәргә кем мәҗбүр итә соң? Хрущев та юк бит. Авылларда һаман да әле кукуруз «экспансиясе»нең җимешләрен җыялар.

1964 елда Н.С.Хрущев Татарстанга безнең кукурузны карарга килде. Мин аны Азнакай районына алып бардым. Никита Сергеевич бик канәгать булып калды. Татарстан басуларын күрсәм, әле дә күңелем сөенә. Карап туймассың! Кубаньлылар һәм украиннар көнләшерлек.

**— Инде күп дистә еллар үткәч тә Хрущев турында төрлечә фикер йөртүләр бар. Сезнең моңа карашыгыз нинди?**

— Тумыштан талантлы кеше иде ул. Гаять зур илебезгә, партиягә ул күп файда китерде. КПССның егерменче съездын гына алыйк. Үз чолганышындагыларның нык каршы торуларына карамастан, ул Сталинның шәхес культы турында дөреслекне әйтә алды. Авыл хуҗалыгы алдында хезмәте бик зур. Гади авыл эшчәненең абруен күтәрде ул. Бригадирлар, көтүчеләр, терлекчеләр, колхоз рәисләренең гаять зур зона киңәшмәләрен үткәрүче дә Хрущев иде бит. Дөрес, аның сәер яклары да булмады түгел. Авыл кешеләренең сыерларын җәмәгатьләштерү, шул ук кукурузны Ерак Төньякта да игә башлау кебек әкәмәт кыланышларын да беләбез.

...Ул чагында без шәхси секторда сыерлар санын бер генә башка да кыскартмадык.

**— «Русча никадәр тизрәк сөйләшергә өйрәнсәк, коммунизмны шулкадәр тизрәк төзербез», дип оран салып, милли мәктәпләрне, шул исәптән татар мәктәпләрен яптылар. Нәтиҗәдә коммунизм да төземәдек, туган телебезне дә оныттык...**

— Сезнең белән килешәсем килми. Семен Денисович Игнатьев вакытында булды бит бу. Татарлар үз балаларын татар телендә укытырга теләмиләр, дип ул белдерде һәм шуның белән «сыртын да сындырды». Ә без, киресенчә, Казанда, район үзәкләрендә күп милли мәктәпләр ачтык. Биләргә татар мәктәбен ачарга барганым әле дә хәтеремдә. Кайбер ата-аналарның «Татар мәктәбен тәмамлаган бала кайда урысча укый алсын соң?» дип фикер йөртүләре, әлбәттә, кайбер мәктәпләрнең ябылуына түгел, ә таркалуына китерде. Мәсьәлә бик катлаулы итеп куелган иде шул. Классларга 3 — 5 әр бала гына йөри башлады. Менә Сезнең сорауга җавап.

## БИЧАРА АВЫЛ ТУРЫНДА БЕРНИЧӘ СҮЗ

**— Сез идарә иткән елларда «перспективасыз авыллар» дигән термин бар иде. Меңнәрчә еллык тарихлы авылларны урыннарыннан күчерделәр, кешеләрне туганнары һәм якыннары каберләреннән аердылар.**

— Бу фикер белән килешеп бетмим. Татарлар яши торган авыллар беркайда да кечкенә түгел, шунлыктан алар исән-имин калды. Ә менә рус авыллары белән эш башкачарак. Минзәлә районының болынлы өлешен генә алыйк. Анда 5—6 йорттан гына торучы рус авыллары бар иде. Ни кибете, ни мәктәбе, ни юлы юк. Газ да үткәреп булмый. Андыйларны бер үзәккә туплауның ни зыяны бар? Моны дөрес карар дип саныйм мин.

## НЕФТЬ ЕЛГАСЫ ТУРЫНДА

**— Фикрәт Әхмәтҗанович, Сезнең ике дистә ел буена республика җитәкчесе сыйфатында эшләвегез Татарстан нефте белән бик нык бәйләнгән бит. Бер чагыштыру башымнан һич чыкмый. Татарстан һәм Кувейт нефтьне бер үк вакытта һәм бер үк күләмдә чыгара башладылар. Татарстан елына 100 миллион тоннадан артыкны да бирде бит. Әменә кувейтлылар бай, ә без ярлы. Шуның өстенә әле җирнең бөтен җелеген суырттылар...**

— Кем сөйләсә — шуныкы дөрес, диләрме әле? Татар акылы төштән соң, дип тә әйтәләр. Әмма шунысын онытмыйк, ул чагында социалистик хуҗалык системасы, хезмәтнең халыкара бүленеше, үзәкләштерелгән планлаштыру һ.б. шуның кебек төшенчәләр алга сөрелде. Кувейт үрнәге буенча эшләргә миңа кем рөхсәт итәр иде икән?

Нефтьнең тоннасын 8 сумга сата идек, ә «Дуслык» үткәргече аша башка илләргә 15 сумнан җибәрдек. «Татнефть» җитәкчесе Мингәрәевнең сүзләре әле дә колагымда яңгырап торган кебек: «Бер стакан Татарстан нефте бер стакан сиропсыз газлы судан да арзанрак бит», — дия торган иде ул. Менә сиңа Кувейт: Мөстәкыйль рәвештә берни дә эшли алмадык ул чагында. Татарстанда нефтьне вәхшиләрчә суырттылар. Гасыр талавы булды ул.

**— Данлы «Дуслык» нефтьүткәргече дә Сезнең чорда төзелде бит...**

— Бу «елга»ны удар темплар белән ике ел эчендә (1959—1960) төзеделәр. Политбюрода ясаган чыгышларымда нефть өлкәсендә америкалылар үрнәгендә эшләргә кирәклеге турында күп тапкырлар сүз кузгатканым булды. Миннән көлделәр генә: «Нинди акыллы баш табылган. Илгә нефть кирәк. Держава валютага мохтаҗ. Дус илләргә социализм төзүдә ярдәм итәргә кирәк, ә Табеев скважиналарны ябарга тәкъдим кертә», — диделәр.

...Һәм Брежнев кашларын селкетеп куйды

**— Инде нефтьне эшкәртүгә күчик. Түбән Камада нефть химиясе комплексын төзү һәм шәһәр салу идеясе кемнеке иде?**

— Билгеле булганча, Татарстанда нефтьне 1946 елда чыгара башладылар. Партия өлкә комитетының беренче секретаре булып Моратов эшләгән чакта Союз хөкүмәте Казан янындагы Матюшино төбәгендә нефть эшкәртү комплексын төзергә тәкъдим итә. Моратов исә моңа каршы төшә, завод шәһәрне харап итәчәк, ди. Шуннан соң аны Рязаньда төзеделәр.

Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре булып сайланганнан соң берничә тапкыр Хрущев янында, аннары Брежнев янында булдым һәм Татарстан өчен нефть эшкәртү заводы кирәклеген кузгаттым. СССР Госпланы Рәисе Байбаков һәм аның урынбасары Рябенко янында да булдым. Брежневка киләм дә әйтәм: «Леонид Ильич! Госпланда Рябенко кебекләрне ник тотасыз? Аның белән берни дә хәл итеп

булмый бит», дип. Брежнев куе кара кашларын сикертеп кенә куйды. Баксаң, Рябенко аның үз командасыннан икән. Менә шундый хәл.

Нефть эшкәртү заводын никадәр сорасам да, йөрүем бушка гына китте. «Татарстанга завод нигә кирәк? «Дуслык» нефтьүткәргече аша кудырыгыз да кудырыгыз. Нигә башыгызны авырттырып йөрисез?» — дип кенә җавап бирәләр иде. Вакыты шундый булгандыр инде.

Берникадәр вакыттан соң Байбаков: «Фикрәт, син нефть эшкәртү заводы сала алмадың инде, заманча нефтехимия комплексы төзерсең»,—ди. «Ярый!» — дидем һәм куллар кысыштык. Башлангыч проект 100 мең тонна нефть продукты эшкәртүгә көйләнгән иде. Ә ул чагында республикада 5 миллиард кубка кадәр иярчен газ яндырыла иде. Аны файдалансаң, ифрат зур акча алып була, шуңа торбалар сатып алырга мөмкин. Менә шунлыктан булачак заводка иярчен газ өчен торбалар сузылды. Бер үк вакытта Миңнебай газ эшкәртү заводын салуны тизләттек.

Ләкин Түбән Камада нефтехимия комплексын төзүгә нефть химиясе промышленносте министры Федоров каршы чыкты. Аны аңлап та була, моңа бик күп акча кирәк бит. Ә финанслау министрлык аша бара... Мин тагын кабинеттан кабинетка йөри башладым. Ниһаять, Түбән Кама нефтехимия комплексын төзү һәм шәһәр салу турында КПСС Үзәк Комитеты һәм СССР Министрлар Советының уртак карары чыкты. Карарда: «Бу документ Татарстан партия өлкә комитетының беренче секретаре җаваплылыгына кабул ителә»,— дип язылган. Комплекс таләп итәсең икән — җавап та бир!

Вакыт бу тарихи карарның дөреслеген раслады. Нефть эшкәртү комплексы да төзелде, шәһәре дә салынды. Ул чагында күпләр моңа ышанмады, безне хыялыйлар дип санаучылар да булды.

## СУ, ҺӘРКАЙДА СУ

**— Фикрәт Әхмәтҗанович, Сез идарә иткән чорда Түбән Кама ГЭСын төзү башланды. Хата түгел идеме бу? Карагыз әле, ничә мең гектар кара туфраклы җир, менә дигән болыннар су астында калды бит. Зуп-зур авылларны юк иттеләр, күпләр ачудан Татарстанны ташлап китте.**

— Бүгенге күзлектән чыгып каравы җиңел ул. Шуны әйтим: Куйбышев плотинасы һәм ГЭСы төзелгәч, Татарстанның 700 мең гектардан артык иң уңдырышлы җирләре, һәйбәт болыннары, борынгы Болгар җирләре су астында калды. Күңелем сыкрана.

**— Бу вакыйгаларны күпләр Табеев исеме белән бәйлиләр.**

— Ул чагында кем кемнән нәрсә сорап торган соң?! СССРны электрлаштыру буенча бердәм перспектив план, гидроэлектростанцияләр кору буенча бердәм план эшләнде һәм расланды. АКШта шулай ич, димәк, бездә дә шулай булырга тиеш, янәсе. Түбән Кама гидроузелын төзү турындагы карар мин беренче секретарь булып килгәнгә кадәр кабул ителгән иде инде. Ә секретарь булгач, мин аңа актив каршы төштем. Хәтерлим әле, Башкортстан партия өлкә комитетының секретаре З.Нуриев белән

без Политбюро утырышларында берничә тапкыр чыгыш ясадык. Түбән Камада гидроэлектростанция коруның зарарлы булуын исбатларга тырыштык. Йөзләрчә мең гектар менә дигән җир су астында калачак, мең еллык тарихы булган авылларны алып ташларга туры киләчәк, дидек. Ахыр чиктә безгә ишекләрнең ачык булуына төртеп күрсәттеләр һәм тупас кына итеп: «Әгәр сез каршы икән, Түбән Кама гидроузелын башка беренче секретарьлар төзер», — диделәр. Бу мәсьәләне хәл итүдә Табеев һәм Нуриевның роле турында менә шуны гына әйтә алам.

Ул чагында Кремльдәгеләр дә башкача уйлый иде бит, хәзергә гидроэлектростанцияләрне корыйк, аннары тулысынча кояш энергиясенә, атом станцияләренә күчәрбез, коммунизм төзербез, ГЭСларны шартлатырбыз, янәсе. Бөтенесе гади генә булып күренгән. Ул чагындагы «гөнаһлар»ны күп еллар үткәч кенә аңлый башладык. Җылылык станцияләре электр энергиясе гидроэлектростанцияләренекенә караганда кыйммәтрәк, дип уйланды. Әрәм-шәрәм ителгән җирләрне исәпкә алсаң, әлбәттә инде, гидроузелларда җитештерелгән электр энергиясенең күпкә кыйммәтрәк икәнен аңлавы кыен түгел.

**— Зәйдә дә бит гаять зур җылылык электр станциясе төзеделәр.**

— Әйе! Зәй ГРЭСы да минем чорда төзелде. Мин монысын бөтен яктан дөрес дип табам.

## КАМАЗ ИДЕЯСЕ ВАГОНДА ТУДЫ

**— Фикрәт Әхмәтҗанович, әйдәгез, хәзер КамАЗ турында сөйләшик әле.**

— Зур йөк автомобильләре заводын башта Красноярск краенда төзү планлаштырылган иде. Бу хакта А.Н.Косыгин имзасы белән СССР Министрлар Советының карары да кабул ителде... Ул елны Белоруссия Совет Социалистик Республикасының 40 еллыгын билгеләп үттек. Бәйрәм тантаналарында катнашу өчен Минскига барачак хөкүмәт делегациясенең җитәкчесе Леонид Ильич Брежнев үзе иде. Делегация составына мине дә керттеләр. Бу аңлашыла да. Сугыш вакытында һәм сугыштан соңгы торгызу елларында Татарстан Белоруссиягә шефлык ярдәме күрсәтә — туклану продуктлары, җылы киемнәр һ.б. җибәреп тора. Өстәвенә, Белоруссия җирендә гитлерчылар кулыннан Татарстанның күпме улы һәм кызы һәлак булды!

Менә шулай, мин Леонид Ильич белән бер вагонга туры килдем. Кичен берәр рюмка җибәрдек тә домино уйнарга утырдык. Кинәт минем башка шундый уй килде: Леонид Ильич, әйдәгез, автомобиль заводын Татарстанда салыйк, дим. Красноярскига салкын крайга барып-кайтып йөрүе дә ни тора бит. Меңнәрчә километрга никадәр җиһаз, материал ташырга кирәк... Брежнев һич игътибар итми, ах-ух килә, уйнавын дәвам итә, кашларын селкеткәләп куя. Мин тагын сүз кушам: Татарстан — СССРның үзәге ул, дим. Заводның беренче чиратын Красноярскида билгеләнгәнчә, 10 елда түгел, ә 5 елда, икенче

чиратын да 5 елда төзеп бетерергә сүз бирәм, дим. Брежнев дәшми. Йокларга таралыштык. Минскида тантана бик әйбәт үтте. Шәһәр үзәгендәге фоторәсемнәрдә һәм башка материалларда Татарстан вәкилләре турында, безнең республиканың Белоруссиягә күрсәткән ярдәме турында да сөйләнә. Аны күрүгә, күзләремә яшьләр килде.

Мәскәүгә кайтканда Брежнев белән тагын бергә туры килдек. Тагын домино уйнадык та урыннарыбызга таралыштык.

Икенче көнне поезд Мәскәүгә якынлашканда минем янга Брежневның ярдәмчесе килде һәм, бүген фәлән сәгатьтә Сезгә Политбюро утырышында катнашырга кирәк, ди. Килдем. Утырышны М.А.Суслов ачты:

— Иптәшләр, шундый фикер туды: автомобиль заводын Татарстанда төзергә кирәк, — диде ул. Шаклар катып утырганда:

— Шушы уңайдан сүз иптәш Табеевка бирелә, — дигән сүзләрне ишеттем. Трибунага чыгып, үз фикерләремне булдыра алганча тулысынча аңлаттым кебек һәм, әгәр партия һәм хөкүмәт безгә бу эшне ышанып тапшыра икән, без заводны һәм шәһәрне кору срокларын ике тапкыр кыскартачакбыз, дип ышандырдым...

Автозавод һәм шәһәр төзелешенә мин ахырына кадәр үзем җитәкчелек иттем. Һәм моның белән горурланам. Андый заводлар илебездә генә түгел, ә бөтен дөньяда да аз. Ә Чаллы кебек шәһәр Россиядә генә түгел, бөтен элекке СССРда да юк.

## МӘСКӘҮДӘН КАРАШ

**— Мәскәүдә яшәп ятып, Татарстанда ниләр эшләнүенә ничек карыйсыз?**

— Чын күңелемнән әйтәм, республиканың уңышларына бик сөенәм, җитешсезлекләренә көенәм. Суверенитетка килгәндә, башта мин аңа сагаеп караган идем, ә хәзер барысы да әйбәт булганга куанам. Татарстанда ярымэтник һәм ярымконфессиональ җәмгыять төзү күңелемә хуш килә.

**— Әйтегез әле, Татарстан үзеннән читтә яшәүче татарлар белән мөнәсәбәтләрне ничек корырга тиеш?**

— Кабиләдәшләрнең һәркайсы үзе яши торган төбәкнең салым түләүчесе булып тора. Ләкин Татарстан кабиләдәшләр яши торган өлкәләр һәм республикаларга билгеле дәрәҗәдә ярдәм итәргә тиеш. Әйтик, татар телендәге дәреслекләр һәм китаплар белән, милли кадрлар белән.

## «РОССИЯНЕ АКЫЛ БЕЛӘН АҢЛАП БУЛМЫЙ»

**— Фикрәт Әхмәтҗанович, Россия эшләре, базар мөнәсәбәтләренә күчү турында да сөйләшик әле.**

— Без үзенә бертөрле ярымазия-ярымевропа илендә яшибез. Әгәр акыл белән эш итсәң, реформаларыбыз цивилизацияле характерда булыр иде. Ә бездә һәрвакыттагыча «Россияне акыл белән аңлап булмый». Шок терапиясе нәрсә соң ул? Шуны ишетсәм, югары көчәнешле токка эләккәндәй булам. Безне шокка дучар итүче бандитлардан саклану өчен кулга таяк

аласы килә. Ватандашларымны Гайдар реформаларыннан әле дә айнып җитә алмыйлар кебек сизәм. Шул ук вакытта озын куллар чек «прихватизациясе» аша миллиардларны урладылар. Җитештерүнең ни икәнен дә белмәгән бай банкирларның кесәсенә акылга сыймаслык акчалар каян килә?

**— Сез фермерлыкка ничек карыйсыз?**

— Төрлечә. Ә еш кына тискәре карыйм. АКШта, Канадада, Австралиядә фермерлар һәм авыл хуҗалыгы җитәкчеләре белән очрашканым бар. Алар бездән көләләр: «Безне беркайчан да фермер ашатмады, буш сүз генә бу!» диләр. Ә күмәк хуҗалыкларга караш башкача. Бөтен эш шунда. Хуҗалык нинди принципта төзелгән бит. Россиянең ярымкустарь фермер кырларына карагыз сез һәм Татарстан кырларына күз салыгыз. Капма-каршы күренеш бит! Татарстан кырлары — авыл хуҗалыгын алып баруның менә дигән үрнәге. Валлаһи, дип әйтәм, чын күңелемнән сөенәм мин моңа. Фермер беркайчан да шулай эшли алмый. Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев авыл хуҗалыгын яхшы аңлый, авыл малае бит. Элек тә игенгә бай җир булган Оренбург өлкәсенә генә күз салыгыз сез. Татарстанга күрше генә диярлек бит югыйсә. Ә авыл хуҗалыгы бөлгенлектә, мал-туарны суеп бетерделәр, җир ташландык хәлдә. Россиянең күп төбәкләренә хас нәрсә бу. Менә сезгә «реформаторлар».

**— Җиргә хосусый милек мәсьәләсенә ничек карыйсыз?**

— Хуҗалыкны үрнәк төстә алып бара белүче генә җиргә хуҗа була ала. Әйтегез әле, бүген кемгә кирәк ул җир? Акчасыз, техникасыз, ашламасыз кеше ни эшли алсын аның белән? Хәтта ерак Австралиядә дә хосусый милкендә җир бүлемтекләре булган кешеләр кооперативларга, күмәк хуҗалыкларга берләшәләр. Тагын Татарстан турында әйтәм. Анда карарлар чынбарлыктан чыгып кабул ителә. Бер хуҗага 5—6 гектар җир бүлеп бирү, аннары аларны күмәк хуҗалыкларга берләштерү акыллы адым булыр иде. МТСларны да яңа нигездә төзү кирәк.

**— Тагын менә нәрсә. Предприятиеләр, оешмалар, акционерлар җәмгыятьләре һ.б. начар эшли, кешеләр айлар буена акча ала алмый, ә җитәкчеләр гаиләләре белән бергәләп чит илләрне гизеп кайталар, сарай кебек зур-зур йортлар салалар, кыйммәтле машиналары бар. Моңа мөнәсәбәтегез нинди?**

— Мөнәсәбәтем бик тискәре. Элек эш хакын алуда нинди дә булса проблема бар идеме соң? Юк иде. Мондый хәл җитәкчеләрнең намуссызлыгыннан килеп чыга.

## ӘФГАНСТАН — МИНЕМ СЫЗЛАНУЫМ УЛ

**— СССР илчесе сыйфатында Әфганстандагы эшегез турында беләсе килә. Ничектер бөтенесе көтелмәгәндәй килеп чыкты...**

— Дәүләтебез тарихында бу чор нинди генә авыр һәм фаҗигале булмасын, үз тормышымның бу өлешен мин иң күренекле чор дип исәплим. Алай гына да түгел, ул катлаулы чорда мине Әфганстанга илче итеп билгеләүне зур дәрәҗәгә санадым.

Мине КПСС Үзәк Комитеты Секретариатына чакыртып алдылар. Утырышны Михаил Андреевич Суслов алып барды. «Безгә Әфганстанда илче постына зур сәяси эшлекле кирәк, бүгенге көндә иң кулай кандидатура — Ф.Ә.Табеев, — дип башлады ул сүзен. — Зур обкомның беренче секретаре. Мөселман кеше. СССР Югары Советы депутаты һәм СССР Югары Советы Президиумы әгъзасы, шулай ук КПСС ҮК әгъзасы, Азия һәм Африканың күп кенә халыкара оешмалары составына керә һ.б.».

Мин риза булдым. Суслов белән бергәләп Брежнев янына кердек. «Молодец, Фикрәт, сиңа үземнең фатихамны бирәм. Синең риза булачагыңа шигем булмады», — диде дә кулымны кысты. Бер атнадан мин Кабулда идем инде.

**— Ул чагында совет гаскәрләре Әфганстанда идеме инде?**

— Әйе! Аларны 1979 елның ноябрендә керттеләр. Ә мине илче итеп декабрьдә җибәрделәр.

**— Хафизулла Әмин идарә иткән вакыт идеме?**

— Әйе, ул чагында әле Әмин иде. Аннары аны бәреп төшерделәр.

**— Яшь идеме ул?**

— Миннән бераз яшьрәк иде, 40 тан аз гына узган булгандыр.

**— Ә сез Әфганстанда ничә ел илче булдыгыз?**

— Җиде ел...

**— Сез ничек саныйсыз, Фикрәт Әхмәтҗанович, Әфганстанга совет гаскәрләрен кертү совет җитәкчелегенең ялгышлыгы булдымы?**

— Юк! Нәкъ менә ул чагында гаскәрләрне кертергә кирәк иде. Әфганстан белән безнең илнең уртак чиге өч мең километрга сузыла. Әфганнар безгә патша заманнарыннан бирле хәер хаһлы мөнәсәбәттә булып килделәр. Әгәр без гаскәр кертмәсәк, аны башкалар кисәкләргә бүлгәләп бетерерләр иде. Безгә этник төркемнәр арасындагы канлы бәрелештә буталырга кирәкмәс иде. Үз гаскәрләребезне кертеп һәм әфган халкының дошманнарын яхшылап кисәтеп, безгә аннан өч ай эчендә чыгарга кирәк булган. Американлылар андый хәлләрдә нәкъ менә шулай эшлиләр. Әгәр без гаскәрләребезне тиз генә чыгарган булсак, әфган территорияләрен үзләренә кушарга теләгән күрше илләр Әфганстанга якында гына куәтле күрше торуын күңелләренә сеңдерерләр иде. Ә чынлыкта нәрсә килеп чыкты...

Ләкин, ничек кенә булмасын, совет сугышчылары үзләренең интернациональ бурычын үтәделәр. Сәясәтчеләрнең ялгышлыгы кече офицерлар һәм солдатлар өстенә авыр йөк булып төште.

**— Андый хәлдә Әфганстан җитәкчеләренең, әфган халкының СССР илчесенә мөнәсәбәте нинди булды?**

— Әйбәт. Бу илгә килүгә, мин бөтен илне аркылыга-буйга йөреп чыктым. Мине кешеләр яхшы каршы алды. Бернинди басымсыз партияләр төзедек, губернаторлар билгеләдек, яшьләр оешмалары булдырдык. Сугыш нәтиҗәсендә боларның бөтенесе сызып ташланды, әлбәттә.

**— Сез Әфганстанда үзегез генә яшәдегезме?**

— Юк. Хатыным Динә Мөхәммәдовна һәрвакыт минем янда бул-

ды. Минем карамакта самолетлар бар иде. Кабул аэропортыннан Динәне теләсә кайсы вакытта СССРга утыртып җибәрә ала идем. Үзем дә кварталга бер тапкыр Мәскәүдә була идем. КПСС Үзәк Комитеты Политбюросында отчет бирәсе бар иде.

**— Балаларыгыз Казанда калдымы?**

— Юк. Мәскәүдә. Минем үземә һәм ике улыма Мәскәүдә аерым фатирлар бирделәр. Илче акчасыннан тыш, Үзәк Комитетта миңа 400 сум эш хакы түләп тордылар, бу акча саклык кенәгәсенә күчә барды.

**— КПСС ҮК Политбюросы алдында гаскәрләрне ашыгыч тәртиптә чыгарырга кирәклекне аңлата алмадыгызмыни?**

— Мәсьәләне күп тапкырлар кабыргасы белән куйдым. Проблема бик катлаулы иде бит. Бу илгә безнең хәрбиләр тау-тау заманча корал алып килделәр. Сугыш инде инерция буенча барды. Ничек китәсең? Бу хәтле коралны кемгә калдырасың? Төрле проектлар булды. Ул чагында инде Бабрак Кармаль авыру иде. Бездән соң хуҗа булып кем калыр? Ашыгыч рәвештә Бабракка алмашка кандидатура эзли башладык һәм Нәҗибуллага тукталдык.

**— Сәләтле дипломат сыйфатында түгел, гади кеше буларак үзегезне ничек хис иттегез?**

— Бик авыр булды. Мин анда 30 килограммга ябыктым һәм шуннан соң үз авырлыгымны җыя да алмадым... Илче вазифасыннан бушану белән беренче эшем итеп Казанга очтым. Мине бик яхшы кабул иттеләр. Ул чагында КПСС өлкә комитетының секретаре М.Ш.Шәймиев, республика Югары Советы Рәисе Ф.Х.Мөхәммәтшин, Премьер-министр М.Г.Сабиров белән бергәләп бөтен республиканы әйләнеп чыктык. Тәэсирләр бик зур. Мин аларга бик рәхмәтлемен.

**— Сүз уңаеннан, М.Ш.Шәймиев шәхесенә ничек карыйсыз?**

— Сүз дә юк, зур ихтирам белән карыйм. Әлбәттә, идеаль кеше булмый. Барысын да исәпкә алып эш итүче сәясәтче ул. Россиянең күренекле сәясәтчеләреннән берсе. Милләтебезнең дәрәҗәсен лаеклы күтәрү өчен рәхмәт аңа. Алла сәламәтлеген бирсен дә республика белән җитәкчелек итә генә күрсен. Үз тирәсенә яхшы команда, акыллы кешеләр тупласын.

## ХАСБУЛАТОВ, ЧУБАЙС ҺӘМ БАШКАЛАР

**— Әфганстаннан соң Сезне Россия Министрлар Советы Рәисенең беренче урынбасары итеп билгеләделәр. Сез нинди тармак өчен җаваплы идегез?**

— Асылда барысы өчен дә. Чөнки беренче урынбасар идем бит мин. Ә нигездә промышленность һәм финанс өчен җавап бирдем.

**— Ельцин Югары Совет Рәисе булганда аның белән очраша идегезме?**

— Даими рәвештә. Ул чагында бөтенесе нормаль иде. Ельцин эшне төгәл алып барды.

**— Ә Хасбулатов белән кулга-кул тотынып эшләдегезме?**

— Мин 1990 елдан пенсиядә идем инде, ә 1992 елда мине Хасбулатов Ак йортка чакырып алды да: «Мин Сезгә федераль мөлкәт фонды рәисе постын тәкъдим итәм»,— диде. Ризалаштым. Аның күп мәсьәләләрне дөрес аңлавын югары бәяли идем. Аннары ул ду китерә башлады, мине Ельцин белән бәрелештерде... Шуннан соң күп эшләмәдем, киттем дә бардым.

**— Ә Чубайс нинди кеше?**

— Бик әзерлекле, оешкан, көчле ихтыярлы кеше. Әмма ул билгеле бер максатка юнәлешле программаны үти.

**— Ельцин КПССны тыю турында Указ чыгаргач, үзегезне ничек хис иттегез?**

— Эшнең хөрти икәнлеген сиздем. Чөнки мин беркайчан да үз принципларыма хыянәт итмәдем. Партияне тоталитар дәүләт кенә тыя ала. Ә бит алар үзләрен демократик дәүләт төзүчеләр дип саслыйлар. Партияне тыю беркемгә дә дәрәҗә өстәми.

**— Сез хәзер КПРФ әгъзасы түгелме?**

— Юк! Ләкин алар минем белән киңәшәләр...

**— Зюгановка карашыгыз нинди?**

— Нигездә, уңай. Сәләте һәм мөмкинлеге ягыннан уртача кеше. Әмма бик гадел. Кыен чорда авыр йөкне үз өстенә алды.

**— Л.И.Брежнев шәхесенә ничек карыйсыз? Сез бит аны бик якыннан белгән кеше.**

— Мөнәсәбәтем каршылыклы. Җитешсезлекләре күп булса да, объектив иде. Әмма аның күп нәрсәне күрми калуы аркасында социализмның абруе төште.

**— М.С.Горбачев белән очрашканыгыз булдымы?**

— Әлбәттә. Ул КПССның Ставрополь край комитетының беренче секретаре, ә мин Татарстанда беренче секретарь булганда без хәтта дуслар идек.

**— Сез ничек уйлыйсыз: Россиядә Швеция тибындагы дәүләт төзеп булыр идеме?**

— Булыр иде. Бүген бөтенесе бездәгедәй казарма социализмы турында оран сала. Шуны аңлагыз: без бит коточкыч Гражданнар сугышы кичердек, тулы индустрияләштерүне уздык, фашистлар Германиясенә каршы кан коюлы сугыштан җиңүчеләр булып чыктык. Хәрабә хәлендә калган илне торгыздык. Мин, Россия коммунистлары кебек коммунистлар бөтен дөньяда да юктыр, дип саныйм. Менә мине генә алыгыз инде. Чабаталы крестьян улы буларак, буй җитә алмаслык үрләргә ирештем дип саныйм мин үземне.

## ДИН ТУРЫНДА БЕРНИЧӘ СҮЗ

**— Фикрәт Әхмәтҗанович, Рязань өлкәсендә үзегезнең туган авылыгызда булгалыйсызмы?**

— Һәр җәйдә булам. Кардәшләр кими бара инде. Авылда руслар да күбәя.

**— Сезнең авылда мәчет бармы?**

— Бер мәчет бар. Элек җидәү иде.

**— Дингә карашыгыз нинди?**

— Әйбәт. Мөселман дине — игелекле дин. Реакцион түгел. Ислам дине әһелләре бик гыйлемле кешеләр, халыкка зур файда китерүчеләр. Мөфти Тәлгать хәзрәт Таҗетдингә ихтирамым зур.

**— Гаиләгез ишлеме?**

— Өчәү без. Хатыным һәм аның әнисе белән бергә яшибез. Улларым аерым яши. Өч оныгыбыз бар. Фатирыбыз Мәскәүнең үзәгендә. Арбатта. Өч бүлмәле.

**— Сез баймы?**

— Нәрсә инде ул байлык? Минем өчен рухи байлык кадерлерәк. Бу яктан алганда, мин бик бай кеше. Үткән юлым, яшәгән елларым, дусларым һәм, ниһаять, балаларым һәм оныкларым белән баймын. Җәмгыятьтә нинди генә буталчыклар булса да, мине бер генә дустым да ташлаганы юк. Матди яктан да ярлы түгелмен. Мин дә, медицина фәннәре докторы булган хатыным да аена 330 ар сум пенсия алдык, хатынымның әнисенең пенсиясе дә шулкадәр булды. Яшәп була, әмма оят. Бөтен аңлы тормышымда мин зур җитәкче, ҮК һәм хөкүмәт әгъзасы булдым.

Без, РСФСР Министрлар Советы Рәисенең элекке урынбасарлары, ел ярым элек Б.Н.Ельцин исеменә хат яздык. Хат барып җиткән, күрәсең. Безнең барыбызга да Россия Хөкүмәте персональ пенсия билгеләде.

**— Хәзер мемуарлар язу модада...**

— Әлегә аның белән шөгыльләнмим. Күбесе яза: мин дә мин... Чиркану хисе туа. Үткәнеңә яисә шефыңа пычрак атуны егетлеккә санамыйм.

**— Татарстан белән элемтәләрегез нинди?**

— Бик яхшы. Миндә Татарстаннан берәр кеше булмаган көн юктыр. Барысына да киңәшләрем белән ярдәм итәм.

* * *

Без Фикрәт Әхмәтҗанович белән гел очрашып, телефоннан сөйләшеп торабыз. Мин аның кеше белән аралашучан, шат күңелле, оптимист булуына сокланам. Турылыгы, әдәплелеге белән үзенә тартып тора. Аннан беркайчан да үзенең элекке көрәштәшләрен, хезмәттәшләрен хурлаганын ишеткәнем юк, беркемгә дә кимсетүле бәя бирми. Фикрәт Әхмәтҗанович: «Начары онытыла — яхшысы кала»,— дип кабатларга ярата.

Шушы болганчык заманда шундый югары сыйфатларга ия булу бик зур байлык ул.

*Август, 1997 ел.*

## Чишмәләр һәм урманнар дөньясы

### БЕЗНЕҢ ШВЕЙЦАРИЯ

Удмуртия Россиядәге башка республикалар белән чагыштырганда зур түгел. Аның мәйданы барлыгы 42 мең квадрат километрлап тәшкил итә. Татарстан белән чагыштырганда аның мәйданы 1,5 тапкырга кимрәк. Ә Башкортстанга караганда бу сан 3,4 мәртәбә артык.

Халык саны буенча да ул күрше республикалардан күпкә калыша. Биредә 1,5 миллионнан аз гына артыграк кеше яши.

Ә менә промышленностька, алдынгы технологиягә килгәндә — республика Россиягә кергән күп кенә республикалардан һәм өлкәләрдән күпкә өстен тора. Чөнки Удмуртиядәге заводларның 90 процентка якыны хәрби комплекска эшләде. Шуңа күрә дә, бу өлкә социализм чорында чәчәк атты, ә менә базар мөнәсәбәтләренә күчкәч, югалып калды.

Миңа, озак еллар Удмуртиядә яшәгән һәм эшләгән кешегә, аның матур табигатенә сокланмый калу мөмкин түгел. Ә монда яшәгән төрле милләт вәкилләренең гасырлар дәвамында туганнарча гомер итүләре шатландырмыйммыни?

Дөрестән дә, йөзәрләгән чишмәләре, җиләк-җимешкә бай тау битләре, ылыслы урманнары беренче мәртәбә аяк баскан кешегә әкияттә генә сурәтләнә торган гүзәл дөньяны хәтерләтә. Шуңа күрә дә, аны «Швейцария», «безнең Швейцария» дип урынлы атыйлар...

Удмуртиянең төньяк-көнчыгышыннан, кечкенә генә елгадан, мул сулы Кама башлана. Безнең милләткә килгәндә, безнең бабаларыбыз аны Чулман дип йөрткәннәр.

Чынбарлыкта, Урал таулары итәкләрендә 1200 чакрым юл үтеп, Кама-Чулман мул сулы, киңлеге кайбер урыннарда бер километрга җиткән «эш аты» булып, тагы Удмуртиягә әйләнеп кайта. Аның матурлыгын, бай табигатен тасвирлау өчен Каракулино, Камбарка, Сарапулга юл тотарга кирәктер, минемчә.

Кама-Чулман Казанның берничә дистә чакрымда Идел елгасы белән кушыла. Кама-Чулманга Удмуртия җирләрен үтеп Татарстанда Вятка (Нократ), Иж елгалары да кушыла. Менә шушы урыннарда, бик борынгыдан алып, башкаларга үрнәк күрсәтеп, төрле милләт вәкилләре гомер иткәннәр. Шунысына шатланып туя алмыйм, бу дуслык җепләре бүгенге көндә дә һаман ныгый баралар.

...Менә минем алда Удмурт халкының тугрылыклы улы, үлмәс шагыйрь Флор Васильевның «Край мой родниковый» дигән шигырьләр җыентыгы. Мин бу китап авторы белән якыннан таныш идем. 60 нчы еллар уртасында бу күренекле шагыйрь «Комсомолец Удмуртии» газетасын җитәкләде. Минем язмаларым бу газетада еш кына дөнья күрә иделәр.

...Удмурт халкына көтелмәгән кайгы килде. Күренекле шагыйрь автомобиль фаҗигасенә эләгеп, вакытсыз вафат булды.

Шушы кайгылы көннәрдән 30 елга якын вакыт үтеп тә киткән. Мин Ижауда тагы Васильевны, бу юлы Флорның үзенә охшаган улын — Сергейны очратам. Сергей Флорович Удмурт дәүләт университетын тәмамлаган, аспирантурада Санкт-Петербургта укыган. Хәзер ул Дәүләт Советы рәисенең пресса хезмәте җитәкчесе. Без аның әтисен искә алабыз. Сарапулда эшләгән чорлар турында әңгәмә корабыз.

Билгеләнгән вакыт җиткәч, Александр Александрович Волковның эш кабинетына әңгәмә кору өчен үтәбез...

## ЯЛ ИТКӘНДӘ ГАРМОНИСТ

Удмуртиядә 70 ел дәверендә КПСС Өлкә комитетының беренче секретарьлары җитәкчелек иттеләр. Аларның төрлесе булды. Менә Удмуртия хезмәткәрләре 20 елдан артык беренче секретарь булып эшләгән В.К.Марисов турында бик яхшы фикердә. Ул дөрестән дә Удмуртия халкы өчен күп эшләде. Шуңа күрә дә, республиканың күпчелек халкы үткәннәрне яхшы яктан искә ала. Биредә, һичшиксез, инде вафат булган В.К.Марисовның да роле зур.

Бүгенге республика башында Дәүләт Советы рәисе А.А.Волков тора. Яшь булуга карамастан, ул зур тәҗрибә мәктәбе узган кеше.

А.А.Волков 1951 елның 25 декабрендә Брянск шәһәрендә эшче гаиләсендә дөньяга килә. Үз йортында, күп балалы гаиләдә гомер кичерә.

**— Алай булгач, кулыгызга балта тота беләсез инде, — дип, ярым шаяртып сорау бирәм.**

— Минем кулдан төрле эш килә. Печәнен дә чаптым, утынын да кистем, кадагын да кактым. Шуңа күрәдер инде, Брянскидагы төзү техникумына укырга кердем. Техникумны тәмамлагач, 18 яшендә Глазов шәһәренә юллама алдым.

Менә дигән Глазов шәһәре мине үз кешесе итеп кабул итте. Башта мастер, аннан прораб, участок башлыгы, соңыннан зур төзү-монтаж идарәсендә җитәкчелек иттем. Читтән торып политехника институтын тәмамладым. Төзелештә 17 ел эшләгәннән соң, Глазов шәһәр башкарма комитеты рәисе итеп сайландым.

Нәкъ менә Глазов шәһәрендә тормыш иптәшемне очраттым. Бер ул һәм кыз тәрбияләп үстерәбез. Улыбызга 23 яшь тулды, югары уку йортын тәмамлады. Кызыбыз югары уку йортында укый. Гомумән, гадәти гаилә.

1989 елны А.А.Волковны Удмуртия республикасының Дәүләт планы ведомствосы рәисе итеп билгелиләр. Ул шулай ук Удмуртия Республикасы дәүләтенең рәисе урынбасары, ике ел дәверендә дәүләт җитәкчесе вазифасын үти. Менә 2,5 ел инде Удмуртия Дәүләт Советы рәисе — иң җаваплы эштә. 1996 елның мартында «Дуслык» орденына лаек була. Минем әңгәмәдәшем музыканы ярата, бик матур итеп баянда уйный, көчле матур тавыш белән җырлый. Яраткан язучылары —Куприн, Шишков, Шолохов.

## УДМУРТИЯ ДӘҮЛӘТЕ ТӨЗЕЛЕШЕ ТУРЫНДА

Тормыш һәрчак үз таләпләрен куя. Шулай да аңа куелган сораулар да төрлечә булырга мөмкин. Дәүләт эшлеклеләре, милли республикалар җитәкчеләренә мин бер үк сорауларны бирергә яратам. А.А.Волковка да шундыйрак сорау бирдем.

**— Александр Александрович! Удмуртия Республикасының дәүләт төзелеше нидән гыйбарәт? Якын арада яңалыклар кертелерме?**

— Бүгенге көндә Удмуртия — парламент республикасы. Югары органы булып парламент исәпләнә. Аның белән Дәүләт Советы Рәисе җитәкчелек итә. Мондый республикалар Россия җирлегендә ике генә — Дагстан һәм Удмуртия. Шуңа күрә дә безгә Татарстан үрнәгендә эш итәргә кирәктер, дип уйлыйм. Дөрес, без әле төпле фикергә килә алмадык. Кемдер администрация башлыгы җитәкләргә тиеш, дип исәпли. Бу мәсьәләне республика Дәүләт Советы яки референдум хәл итәргә бурычлы. Миңа килгәндә, Удмуртия җирлегендә бөтен халык тарафыннан сайланган җитәкче, хөкүмәт һәм парламент булырга тиеш.

**— Киләчәктә Россия җирлегендә дәүләт структурасы нинди булырга тиеш?**

— Мин бүген Россиянең дәүләт структурасына ныклап үзгәрешләр кертү ягында түгел. Тик субъектлар белән шартнамәләр төзергә генә кирәк. Минем карашка, Россияне демократик федерализм гына киләчәктә коткарып калачак. Төрле конфедерацияләргә күчү упкынга төшү белән бер.

**— Бүген Россия җирлегендә яңа паспорт турында күп сүз бара. Сезнең моңа карашыгыз ничек?**

— Безнең совет чиновнигы һаман да яши әле. Шулай озак яшәячәк тә ул. Уйлап карыйк, кемгә кирәк булган ул «милләте» дигән графаны алу. Элеккеге совет паспортында удмурт телендә бөтен мәгълүматлар язылды. Әгәр сез рус кешесе икән, «рус» дип язылды, татар икән, «татар» дип язылды. Кемгә комачаулаган бу? Кыскасы, яңа паспортларда милли битләрне кире кайтару бик кирәк. Бу фикерем белән мин Удмуртия җирлегендә яшәүче төрле милләт вәкилләренең уй-фикерләрен чагылдырам.

## ХӘРБИ ЗАВОДЛАРНЫҢ БҮГЕНГЕ ХӘЛЕ

**— Александр Александрович! Хәрби кораллар җитештерүче заводлар нинди хәлдә бүген?**

— Билгеле булганча, безнең республика элек ябык республика иде. Заводларыбыз хәрби заказга эшләде. Базар мөнәсәбәтләренә күчкәч, иң югары технология, иң квалификацияле эшчеләр, технологлар, инженерлар эшсез калды.

Шушы авырлыкларга карамастан, без үзебезнең тоткан технологиябезне, югары квалификацияле кадрларны саклап кала алдык. Димәк,

илебезнең куәтен ныгытырлык чит илләргә сатарлык корал ясарга бүген безнең кулдан килә. Аннан тыш, без бүген яңа технология белән эшләнгән җиңел автомашиналар, мотоциклляр, станоклар, нефть җиһазлары чыгара башладык. Шунысын да ассызыклап әйтеп үтим, бездә нефть чыгару яхшы темплар белән бара. Республиканың төньягында Глазов шәһәрендә цирконий һәм уран эшкәртәбез. Менә шушы ике позиция буенча без дөнья күләмендә өченче урында торабыз. Шунысы шатлыклы, 1997 елда промышленностьта артка тәгәрәү бетерелде. Яңа елда яңа үрләр яуларбыз, дип әйтә алам.

Без үзебезне авыл хуҗалыгы продуктлары белән тәэмин итәбез.

**— Александр Александрович, авыл хуҗалыгы турында фикер йөртсәгез иде?**

— Республикабызда 167 колхоз, 22 совхоз һәм биш кошчылык фабрикасы бар. Бездә авыл хуҗалыгы берләшмәләре дә күп кенә. Шул исәптән, 3,6 мең фермерлар хуҗалыгы бар. Быел без бер миллион тоннадан артык иген җыеп алдык.

Авыл хуҗалыгына соңгы вакытта игътибар көчәйде. Иң мөһиме, безгә авыл хуҗалыгы продуктларын эшкәртүне яхшыртырга кирәк.

**— Җирне сату мәсьәләсенә ничек карыйсыз?**

— Бу турыда ашыгырга кирәкми. Алдагы 10 ел эчендә аны арендага бирергә генә мөмкин. Безнең Конституциядә шулай язылган. Ләкин тормыш бер урында гына тормый. Башка республика, өлкәләр, шул исәптән Татарстан үрнәгендә башкача да эшләп куярбыз.

## КАМБАРКА ҺӘМ КИЗНЕР. ФАҖИГА КӨТЕЛМИМЕ?

**— Александр Александрович! Удмуртиядә экология хәле ничек тора? Татарстан халкын Камбарка һәм Кизнерда коточкыч химия кораллары складлары булуы бик борчый. Камбарка шулай ук Башкортстан белән дә чикләшә.**

— Республикабызда экология хәле, нигездә, канәгатьләндерерлек, дип әйтер идем. Шулай да Камбарка һәм Кизнердагы агулы матдәләрнең озак еллар саклануы бик борчый. Шунысын гына әйтеп узыйм, шушы ике районда Россиядәге запасның 30 проценты тупланган.

Алдагы еллар эчендә бу агулы матдәләр юк ителәчәк. Бу мәсьәлә Россиянең Дәүләт Думасында да каралды. Россия хөкүмәте карар да кабул итте. Камбаркада агулы матдәләр беренче Бөтендөнья сугышы чорыннан ук саклануын да истән чыгармыйк. Якын арада Камбаркада аны юк итү өчен инфраструктура төзелә башланачак.

## ТАТАРЛАР АРАСЫНДА МИНЕМ ДУСЛАРЫМ КҮП

**— Удмуртиядә меңләгән татарлар яши. Милләтебез республикада нинди роль тота?**

— Татарлар бик эш сөючән, тыйнак халык. Сезнең милләт вәкилләре менә дигән эшкуарлар, оста җитәкчеләр.

Бүген Удмуртиядә 110 мең татар кешесе яши. Икенче сүз белән әйткәндә, сан ягыннан өченче урында тора (Удмуртиядә яшәүче бөтен халыкның 7 процентын тәшкил итә). Соңгы елларда татар халкының мәгърифәтен, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен торгызу өчен күп эшләнә.

Татарлар депутатлар арасында да байтак. Дәүләт органнарында да күп эшлиләр алар. Табиблар, укытучылар, инженерлар арасында алар санап бетергесез. Республикабыздагы күп кенә оешмаларны, предприятиеләрне алар җитәклиләр. Мәсәлән, республиканың милли банкын татар кешесе җитәкли. Шунысы шатлыклы, Удмуртиядә 70 тән артык милләт вәкилләре тату һәм дус яшиләр.

**— Республикада милли политика нәрсәгә нигезләнгән?**

— Без хөкүмәтебез каршында милләтләр эше буенча комитет оештырдык. Республикабызда төрле милләтләрнең иҗтимагый, мәдәни оешмалары эшләп килә. Бу татарларга да кагыла. Аларның шундый өч — ҮТИҮ, «Иман» татар яшьләре берлеге, «Йолдыз» исемен йөртүче мәдәният үзәкләре бар.

**— Ижауда сугыштан соңгы елларда ике татар мәктәбе эшләп килде. Ә бүгенге көндә?**

— Әйе, андый факт булган. Ләкин 60 нчы елларда милли мәктәпләр, шул исәптән татар мәктәпләре дә, ябылды. Бүген шул ялгышлыкларны төзәтү өстендә эшлибез. Татарлар күмәк яшәгән районнардагы мәктәпләрдә татар сыйныфлары ачабыз. Якын арада Ижау шәһәренең Ленин районында татар урта мәктәбе эшли башлаячак. Ихтыяҗ зур була икән, тагы да ачарбыз.

Удмурт Дәүләт университетында татар теле һәм әдәбияты укытучылары хәзерләү буенча бүлек эшли. Ижау педагогик училищесында да татар бүлеге ачылды.

Шәһәрләрдә, район үзәкләрендә үзешчән сәнгать коллективлары яхшы гына эш алып баралар. Удмуртиядә Татарстан һәм Башкортстанның танылган артистлары да еш кунаклар.

**— Татарлар өчен информация чаралары да булдырылгандыр?**

— Бу юнәлештә безнең борчылырлык урын юк. Татар телендә 8 битле атналык «Яңарыш» газетасы чыга. Телевидение һәм радиода да татар телендә тапшырулар алып барыла.

Автордан: Миңа «Яңарыш» газетасында булып, аларның хезмәткәрләре белән танышырга туры килде. «Яңарыш»та изге җаннар, югары квалификацияле журналистлар эшли. Газета көн кадагына суга торган язмаларга бик бай. «Яңарыш»ның халык арасында абруе зур. Шуңа күрә дә, аны алдыручылар саны елдан-ел үсә. Шунысы шатлыклы, «Яңарыш»ны Әгерҗедә дә үз итәләр. Быел аны 300 дән артык гаилә алдыра. Алдагы елда аның саны күпкә артуына шикләнмим.

## МАНСУР ХӘСӘНОВ:

## «Без яңарыш чорында яшибез»

Егерменче гасырның икенче яртысында Татарстан Республикасы үсешенә эре галимнәр һәм җәмәгать эшлеклеләренең йогынтысы зур булды. Алар арасында Мансур Хәсәнович Хәсәнов аерым урын тота. Казан университетында, дәүләт органнарында һәм Фәннәр Академиясендә эшләгән чорында аның мәгариф, фән һәм мәдәният үсешенә керткән хезмәтен бик югары бәяләргә мөмкин.

Бу очерк минем М.Х.Хәсәнов белән шәхси очрашуларым һәм әңгәмәләрем нигезендә язылды. Ниятем — героемның тормышындагы кызыклы сәхифәләрне сезгә җиткерү.

Шулай ук М.Х.Хәсәновның 70 яшьлек юбилеена багышланган тантанада Президентыбыз М.Ш.Шәймиевнең котлавын да сезнең игътибарга тәкъдим итүне кирәкле дип таптым.

### ПРЕЗИДЕНТ СҮЗЕ

Егерменче гасыр тарихта калды. Аңа һәркем үзенчә нәтиҗә ясый. Мин бернинди икеләнүләрсез шуны әйтә алам: узган йөзьеллыкта Татарстан тарихына зур йогынты ясаган шәхесләр исемлегендә дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, галим, оештыручы Мансур Хәсәнович Хәсәнов та лаеклы урын алыр.

Теге яки бу кешенең күңелен күрәбез дип, аның эшчәнлеген арттырып, тагын да калкурак итеп күрсәтү гадәте бар. Аеруча юбилейларда һәм башка тантаналарда нык сизелә ул. Әмма Сезнең хакта сөйләгәндә, хөрмәтле Мансур Хәсәнович, чыннан да, күпкырлы эшчәнлегегезгә гадәти сүзләр белән генә бәя бирү мөмкин түгел. Егерме елга якын республика Министрлар Советы урынбасары һәм беренче урынбасары булып эшләдегез. Сезнең тормыш позициягез һәм күпкырлы эшчәнлегегез нәтиҗәсендә, дистә еллар буе Татарстан халкының рухи яшәешен югары дәрәҗәдә тота алдык. Сез бик катлаулы һәм аеруча җаваплы өлкәдә — тормышның һәм халыкның төрле мәнфәгатьләрен үзендә туплаган социаль өлкәдә эшләдегез.

Хөкүмәт еш кына яхшы карарлар кабул итә, әмма аларны тормышка ашыру гади кеше җилкәсенә төшә, аның сәләтенә һәм мөмкинлекләренә кайтып кала. Сез үзегезнең фидакарь хезмәтегез белән мәгариф, фән, сәнгать, мәдәният өлкәсендә Татарстанның данын күтәрдегез. Болары өчен ихлас күңелдән зур рәхмәт.

Танылган галимнәребез күп. Әмма алар арасында фәнне оештыру-

чылар аз. Сез гыйлем һәм оештыру сәләтен табигый рәвештә үзендә туплаган талантлы шәхес. Әгәр дә Татарстан Фәннәр Академиясен оештыру мәсьәләсендә Сезнең төптән уйланылган нигезле позициягез булмаса, Академия дә оештырылмас иде. Оештырылган очракта да, мондый ук югары дәрәҗәдә булмас иде, мөгаен.

Татарстан Фәннәр Академиясе бик тиз арада барлыкка килде. Ун ел гомер — фән үсешендә бер мизгел генә ул. Шул чорда күпме эш башкарылды! Татарстан Фәннәр Академиясе үзебездәге һәм чит илләрдәге башка фәнни оешмалар белән тыгыз элемтәдә тора. Иң мөһиме, без республика галимнәренең тырышлыгын Татарстан үсешенең иң актуаль проблемаларына юнәлтә алдык. Татарстан Республикасының Фәннәр Академиясен оештырган елларда уңышка ирешүебезгә шикләнүчеләр дә күп иде. Әмма узган унъеллык бик нәтиҗәле булды. Монда, Мансур Хәсәнович, сезнең шәхси өлешегез бик зур. Моның өчен киләчәк буыннар да Сезнең алда баш иярләр.

Сездән башка Татар Энциклопедиясе институты да булмас иде. «Безнең үз Энциклопедиябез булырга тиеш!» дигән фикерне иң беренче Сез әйттегез. Энциклопедия сүзлеге нәшер ителеп, үз укучыларын тапты. Хәзер күптомлы энциклопедия язу өстендә эш бара. Бу аеруча җитди фәнни хезмәт дәүләт һәм халкыбыз тарихында тирән эз калдырачак.

Тормышыгызның иң матур сәхифәләренә бераз гына аерым тукталасым килә. Алар хакында юбилей кичәгездә дә күп әйтерләр әле. Республика тормышында гаять авыр булган 1970 — 1980 елларда бергә эшләгән хезмәттәшләрегез Сезнең халкыбыз мәнфәгатьләрен аңлап, аларны оста яклый белүегезне сокланып сөйлиләр. Ул чордагы режимда бу бер дә җиңел булмагандыр. Республика җитәкчелеге өчен дә шактый авыр заман иде. Әмма шул чакта да милләт өчен аеруча мөһим булган рухи даирә хасил итүче дәүләт институтлары тотрыклы эшләде. Ә бу тотрыклылыкка без Сезнең көндәлек аяусыз тырыш хезмәтегез нәтиҗәсендә ирештек. Үзгәртеп кору чоры башлангач, мин, еш кына үз-үземә мөрәҗәгать итеп, мондый сорау бирә идем: Мансур Хәсәнович хәзер нәрсә эшләр, илдә барган үзгәртеп коруларга бәйле рәвештә нинди адым ясар икән?

Милли һәм иҗтимагый тормыш, фикер тамырыннан үзгәргән ул заманда Мансур Хәсәновичның позициясен белеп тору бик мөһим иде. Чөнки, бөтен Татарстан интеллигенциясенең ышанычын яулаган хөрмәтле шәхес буларак, Мансур Хәсәновичның фикердәшләре һәрвакыт күп була иде. Мансур Хәсәнович беркайчан да бер ярдан икенче ярга ташланмады, һәрвакыт яңалыкка илтүче иң дөрес эшчәнлек формасын таба белде. Без еш кына күпмилләтле республикабызда халыкларның үзара дус, аңлашып һәм килешеп яши белүләрен иң зур байлыгыбызга тиңлибез. Бу байлыкта Мансур Хәсәновичның өлешен сүз белән әйтеп бетерү дә мөмкин түгел. Аеруча шәхси мәсьәләләргә дә тукталасым килә. Мансур Хәсәнович шундый кеше, аның янына тиктомалдан гына килеп, сүз башлап булмый. Башта уйлыйсың: бу кешегә кайсы яктан, ничегрәк итеп якынайсаң кулай булыр икән? Бу

хис бер миңа гына түгел, аның белән бергә эшләүче танылган галимнәргә дә, интеллигенция вәкилләренә дә яхшы таныштыр, дип уйлыйм.

Миңа Мансур Хәсәнович белән бик якыннан эшләргә туры килмәде. Республика хөкүмәтендә ул фән, мәгариф һәм мәдәният өлкәсен җитәкләде. Мин мелиорация һәм су хуҗалыгы министры булып эшләдем. Мансур Хәсәновичның минем үземә — ул чактагы яшь җитәкчегә, карашын, фикерләрен һәм мөнәсәбәтен бик беләсем килә иде. Бу табигый хәл. Аның 50 яшьлек юбилеен бәйрәм иткәндә аңладым: Мансур Хәсәнович минем кешелек сыйфатларымны һәм эшчәнлегемне профессионал буларак бик хөрмәт итә, тиешле дәрәҗәдә бәяли икән. Еллар дәвамында шушы дустанә мөнәсәбәтләрне саклап кала алуыбыз белән горурланам мин.

Мансур Хәсәнович, хөрмәтлем, республикабыз халкын сөендереп, иҗатыгыздан тәм табып, матур итеп яшәргә язсын Сезгә.

Россия Федерациясе Президенты Владимир Владимирович Путин М.Х.Хәсәновны Ватан алдындагы хезмәтләре өчен IV дәрәҗә Орден белән бүләкләү турында Указга кул куйды. Россия Президенты үз исеменнән юбилярны котлап, аңа югары бүләкне тапшыру миссиясен миңа йөкләде. (Татарстан Республикасы Президентының М.Х.Хәсәновның 70 еллыгына багышланган тантаналы утырышта ясаган чыгышыннан.)

## МЕНӘ ШУНДЫЙ БИГЕШ АЭРОПОРТЫ

КамАЗ автогигантын һәм Яр Чаллы шәһәрен төзи башлагач та, беренче нәүбәттә һава юлларын ачу, заманча аэропорт булдыру проблемасы килеп туды. Әмма КПССның Яр Чаллы шәһәр комитетының беренче секретаре Р.К.Беляев һәм Түбән Каманың беренче секретаре И.Х.Садыйков аэропортка исем куя алмый бик озак бәхәсләштеләр. «Яр Чаллы» исеменә Илдус Харисович риза булмаса, Рәис Кыямовичның «Түбән Кама» дигәнне ишетәсе дә килми иде.

КПССның Татарстан Өлкә комитетының беренче секретаре Ф.Ә.-Табеев үз янына культура, фән һәм уку йортлары бүлеге мөдире, КДУда бергә укыган дусты М.Х.Хәсәновны чакыра. «Беренче» сүзне кыска тота:

— Мансур, Кама аръягындагы аэропортны ничек атарга соң инде? Бәлки син берәр матур исем әйтерсең? Беляев белән Садыйковны берничек тә уртак фикергә китертеп булмый, һәркайсы үзенекен тәкрарлый...

— Соң бу бит минем эш түгел, Фикрәт Әхмәтҗанович,— дип җавап бирә аңа каршы Мансур Хәсәнович,— бу мәсьәләнең «хуҗасы» — транспорт һәм элемтә бүлеге мөдире Сергей Николаевич Зайцев бит.

— Юк шул, ул да бернәрсә дә тәкъдим итә алмады. Икәүләшеп уйлагыз әле, Мансур Хәсәнович.

Өлкә комитетының бер бүлмәсендә Хәсәнов белән Зайцев Татарстан картасыннан яңа аэропорт янындагы авыл исемнәрен өйрәнәләр.

Менә Бакчасарай авылы. Аэропорт өчен бик бармый бу. Кырымда Бакчасарай шәһәре бар бит. Куян авылы... «Куян» аэропорты. Гел ятышсыз исем, бусы да булмый.

Карандашын карта буйлап йөртә торгач, Зайцев шатлыгыннан кычкырып җибәрә: «Эврика! Бигеш авылы! Исеме бик матур. Бигеш аэропорты дип атыйк!»

Хәсәнов елмаеп куя.

— Ник көләсең? Әллә ошамыймы?

— Көлмим лә. Бу исем бик ошый. Әйдә, Табеевка керик булмаса...

— Ну, аэропортка исем таптыгызмы, егетләр? — дип каршы ала аларны Ф.Ә.Табеев.

— Таптык шикелле,— ди Хәсәнов.— Аэропортка якын-тирәдән берәр авыл исемен куярга кирәк.

Фикрәт Әхмәтҗанович, гадәтенчә:

— Тәк-тәк. Кызык бит әле бу, — ди.

Зайцев тиз генә:

— Бигеш,— дип әйтеп сала.

— Тәк-тәк,— Фикрәт Әхмәтҗанович картадан күзен дә күтәрми. — Бигеш дисез инде алайса. Матур исем. «Бигеш аэропорты», диярбез. Әниемнең кыз фамилиясе дә «Бегишева» булган...

Шулай итеп, җитмешенче еллар башында Кама аръягының промышленность үзәгендә Бигеш аэропорты барлыкка килә.

## ТУГАН АВЫЛЫМ — БИГЕШ

Теге чакта, аэропортка исем сайлап тапканда Хәсәновның ник елмайганын Зайцев соңрак белде. Бигеш — Мансур Хәсәновның туган авылы ул. Кама аръягында, урман куенына сыенып утырган бу авылда аның ата-бабалары гомер иткән. Эшчәнлеге һәм гыйлемлелеге белән аерылып торган бу нәселнең дәвамчысы булып, 1930 елның 25 нче июнендә киләчәктә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясен оештыручы һәм аның булачак беренче Президенты Мансур Хәсәнов дөньяга килә.

Мансурның холык-фигылендә бабасы Хәйрулла чалымнары күп. Курку белмәс, нык ихтыярлы Хәйрулла авылдашлары арасында белемле булуы белән аерылып тора. Юкка гына аны староста итеп сайламаганнардыр инде! Өстәвенә, бик оста умартачы да булган ул. Күп итеп умарта тоткан. Коллективлаштыру башлангач, утызынчы еллар башында умарталыгын колхозга биреп, үзе колхоз умартачысы булып эшли башлый. Бабасы, кая гына бармасын, оныгын үзеннән калдырмый. Алар бергәләп урманнарга, аланнарга йөриләр. Табигатькә һәм хезмәткә мәхәббәтне Мансур Хәйрулла бабасыннан мирас итеп ала. Мансур Хәсәнович хәзер дә ялгызы гына урманнарда йөреп йөзьяшәр агачлар белән сөйләшергә, кошлар сайравын тыңларга ярата.

— Табигать, урман белән аралашу җанны чистарта,— ди ул.— Урманда яңа фикерләр туа.

Әтисе, Хәсән абый, тирә-юньдә танылган тегүче була. Авыл халкы, яше-карты ул теккән киемнәрне кия. Шуның өстенә, хуҗалыгын да тәртиптә тота, колхоз эшенә дә өлгерә.

Мансурны язмыш иртә сыный башлый. Аңа өч, абыйсы Фатыйхка биш яшь тулганда, әнисе дөнья белән бәхилләшә. Әнисенең якты истәлеген, томанлы гына хәтерләгән йөз сызыкларын Мансур Хәсәнович гомере буе йөрәк түрендә йөртә.

Бераздан әтиләре яшь хатын ала һәм гаилә тагын да ишәеп, берcharacteristics бер артлы дүрт бала туа.

Хәсән ага да яктылыкка, гыйлемгә омтылучанлыгы белән аерылып тора. Коръәнне бер дә үзеннән калдырмый. Мунча кереп, чиста күлмәкыштан киеп чыккан Хәсән абый сәкегә кырын ятып, Коръән сүрәләрен укый, ә өйдәгеләр тын алырга да кыймыйча изге китапның могҗизалы сүзләрен тыңлыйлар. Мансур күңелендә мәгърифәткә, китапка мәхәббәт, мөгаен, шул елларда ук тугандыр.

Бервакыт әтисе Мансурга гаиләнең бөек серен ача. Улын чормага алып менеп, гарәпчә язылган китаплар төргәген күрсәтә. Фатыйх белән Мансурга бу китапларны карарга рөхсәт бирә. Әмма чардактан алып төшәргә һәм бу китаплар турында башкаларга сөйләргә кушмый. Бу — утызынчы елларда гарәп графикасыннан латинга күчкән чор була. Күп нәрсәләр тыелган заман. Шушы китапларны саклаган өчен генә дә Сталин лагерьларына илтеп тыгарга мөмкиннәр.

Мансур бу китапларны, әлбәттә, укый алмый. Әмма аларның сихри тарту көче шулкадәр көчле була ки, чормага менеп, китапларны бер күреп төшсәң дә, җан каядыр еракка, биеккә ашкына башлый. Минемчә, Мансур Хәсәнович һәм аның абыйсы Фатыйх Хәсәновичта Ватан тарихына, гомуми тарихка һәм китапларга мәхәббәт нәкъ менә шушы чормада туган да инде. Монда Риза Фәхретдинов, Шиһабетдин Мәрҗани һәм башка татар мәгърифәтчеләренең китаплары саклана. Алгарак китеп шунысын да әйтергә кирәк, Фатыйх Хәсәнов та китап җанлы кеше булып үсә. КДУны тәмамлап, журналист һөнәре ала, соңыннан татарча-русча сүзлек төзи.

Хәсәновлар гаиләсе ишегенә кайгы көтмәгәндә кагыла. 1938 нче елның җәй башында Мансур беренче сыйныфны бетереп, иркенләп укый башлаган чорда Бигештә зур янгын чыга. Хәсәновларның йортын, бар хуҗалыгын ут ялмап ала. Иң үкенече, чормадагы китаплардан да көл өеме генә кала.

Йортны һәм хуҗалыкны яңадан торгызып кына бетерәләр — сугыш башлана. Барлык ир-егетләрне фронтка алалар. Мансурның әтисе хезмәт армиясенә эләгә. 1947 елга кадәр ул Свердловскидагы хәрби заводта эшли.

Мансур мәктәптә укуын дәвам итә. Бигештә ул вакытта зур урта мәктәп булып, анда якын-тирәдәге тугыз авыл балалары йөреп укый. Бишенче класстан соң һәр елны җәйге каникул чорында колхозда эшли. Аны да өлкәннәр белән бергә атлы эшкә куялар.

1945 ел Мансур хәтеренә тирән уела. 9 Май аның өчен ике яңалык алып килә — берсе сөенечле, икенчесе — көенечле.

Мансур сигезенче классны гел биш билгеләренә генә тәмамлый. Шушы ук елны Бигештә унъеллык мәктәп бетерелә. Ул колхозда эшли һәм шул ук вакытта укуын дәвам итү турында уйлана. Ә егеттә уку теләге бик көчле була. Иң якын мәктәп — Зәйдә, анда 20 километр барасы. Мансур сыйныфташларын Алабуга педагогия училищесына керергә өнди. Аркасына киндер капчык асып, Бигештән Чулман елга аркылы Алабугага барган яшүсмер егетнең башына чирек гасырдан монда бер дигән аэропорт булыр, Түбән Кама һәм Яр Чаллы шәһәрләре калкып чыгар дигән уй килдеме икән?

## АЛАБУГА — СУГЫШТАН СОҢГЫ ЯШЬЛЕК ШӘҺӘРЕ

Алабуга педагогия училищесына керү имтиханнарына Мансур бөтен класслашларын ияртеп килә. Әмма педучилище студенты булу бәхете бары аңа гына эләгә. Китапханәчеләр техникумында имтиханнар бераз соңрак калып башлана икән, башка класслашлары документларын алып тизрәк шунда йөгерәләр. Мансур исә яңа коллективта япа-ялгызы кала. Моңа кадәр туган авылыннан беркая чыкмаган Мансур бу ялгызлыкны шулкадәр авыр кичерә ки, документларын алып китапханәчеләр техникумына күчәргә мәҗбүр була.

— Педучилищены ташлау бик кызганыч булды инде ул,— дип искә ала Мансур Хәсәнович. — Шундый матур, биек бина. Күтәрелеп карасаң, бүрегең төшеп китә. Хәзер анда Алабуга педагогия институты урнашкан. Бу бинаны сәүдәгәр Стахеевлар нәселе вәкиле Глафира төзеткән була. Гомумән, Алабугада күп нәрсә сәүдәгәр-меценат Стахеевлар ярдәме белән төзелгән. Алабуга халкы юкка гына Стахеевларның берсе —Дмитрий Иванович яшәгән йортка «Бу йортта сәүдәгәр, әдәбиятчы, күренекле шәхес Д.И.Стахеев яшәде», дип язылган мемориаль такта куймагандыр инде. Ул еллардагы идеология басымы нәтиҗәсендә Стахеевның китаплары халыкка чыгарылмады — революциягә кадәр яшәгән сәүдәгәрләр токымы китабын ничек чыгармак кирәк ди инде?

Бүген Алабуга педагогия институты ректоры булып фәннәр докторы, профессор Наил Мансурович Вәлиев эшли. Ул — Мансур Хәсәновичның укучысы. Вәлиев моннан берничә ел элек Мәскәүдә докторлык диссертациясен яклады. Аның фәнни эше Стахеев иҗатына багышлана. Наил Вәлиевич аны Салтыков-Щедрин белән бер баскычка куя.

Диссертация яклау шома гына үтми. Аттестация комиссиясе председателе Алабуга галименең диссертациясе белән танышып чыккач, ризасызлыгын сиздереп куя: «Сез Д.И.Стахеевны артык югары күтәргәнсез. Моның белән Салтыков-Щедринның ролен киметәсез». Комиссия председателе Салтыков-Щедрин иҗаты буенча белгеч икән. Наил Вәлиев Казанга килүгә Мансур Хәсәновичка бу вакыйганы түкмичәчми сөйләп бирә.

— Комиссия председателе мине дә, Стахеевны да өнәп бетерми. Инде нишләргә? —ди.

Мансур Хәсәнович яшь галимне тынычландыра.

— Ә сез комиссия председателен канәгатьләндерү өчен Салтыков-Щедрин исемен күбрәк кулланыгыз. «Салтыков-Щедрин үрнәгендә», «Салтыков-Щедрин шикелле», «Щедринга ияреп» кебек сүзтезмәләрне кызганмыйча, ешрак куегыз.

Наил Вәлиев нәкъ шулай эшли дә. Д.И.Стахеевның роле һич тә кимеми. Ә үз шәхесенә һәм фикеренә мөкиббән киткән һәм дан-шөһрәт яратучы комиссия председателе бик канәгать кала.

Соңыннан банкетта бераз чеметеп, телләре ачылган Мәскәү галимнәре ачыктан-ачык болай диләр: «Менә нәрсә кирәк безгә. Яшь татар галиме рус сәүдәгәре, язучының исемен билгесезлектән тартып алды. Аның иҗатын тирәнтен өйрәнеп, Стахеевның талантлы шәхес булуын һәммәбезгә исбатлап бирде».

— Укучыларым күп минем, — ди Мансур Хәсәнович. — Мин алардан бик канәгать. Иҗади һәм фәнни эштә максатчан булулары ошый миңа. Наил Вәлиевкә килсәк, ул үз шәһәренең һәм туган Татарстанының рухи һәм әдәби мирасына тугрылыклы галим булып чыкты. Илебез мәдәниятенә тиңсез өлеш кертүчеләрне үзебезнекеләргә һәм читләргә бүлеп буламыни? Стахеевның мемориаль тактасына сүзләрне кем язгандыр — анысын белмим. Шунысы бәхәссез: алдагы «шәхес» сүзе бу кешенең иҗатын һәм тарихи урынын бик яхшы аңлата.

Китапханәчеләр техникумында Мансур Хәсәнов бишлегә генә укый. Аеруча математиканы ярата ул. Ул фәнне республиканың танылган математигы Хәсән Яруллин укыта. Өстәвенә, ул техникумның завучы да була. Ул Мансурдан яхшы математик чыгачагына һич икеләнми. Группадан гына түгел, курстан берәү дә чишә алмаган катлаулы мәсьәләләрне дә Мансур «эһ» тә итми чишеп куя.

Алабугада өч ел сизелмичә дә үтеп китә. 1948 елда Мансур техникумны кызыл дипломга тәмамлап чыга. Аңа һөнәре буенча институтка имтиханнарсыз гына керү хокукы бирелә. Мансур Хәсәновны Мәскәү библиотека институтына тәкъдим итәләр. Егет алдына «Инде нишләргә?» дигән сорау килеп баса. Сугыштан соңгы авыр еллар... Гаиләнең матди хәле әйбәт түгел. Әтиләре хезмәт армиясеннән яңа гына кайткан. Сугыш чорында авыл халкы бераз яхшырак яшәде. Ә менә сугыштан соңгы ачлык халыкны кырды гына! Шушы заманда институтка керү мөмкин булмас эш иде. «Мәскәү көтәр әле», дип, Мансур Зәйгә, эшкә урнашырга килә. Район мәдәният бүлеге аны керәшен авылы Поповкага китапханә мөдире итеп җибәрә. Алабугада укыган һәм Поповкада эшләгән чорда Мансур башка диндәге кешеләр белән очраша. Бу очрашулар егеттә керәшен кардәшләргә, башка халыкларга, аларның гореф-гадәтләренә ихтирам тәрбияли, дөньяның күпкырлы булуын һәм теләге булган һәркемнең камиллеккә ирешә алуын аңлата.

Үсемлекләр кояшка ничек сузылса, кешеләр Мансурга шулай тартылалар. Ул чакларда халык китап, журналларның кадерен бик белә. Әмма укуны дәвам итү хыялы Мансурның күңеленә тынгы бирми. Аның иң зур хыялы — Мәскәү университеты студенты булу.

## КАЗАНГА — УНИВЕРСИТЕТКА

1950 елның җәендә Зәй комсомоллары Мансурны комсомолның республика конференциясенә делегат итеп сайлыйлар. Конференция югары уку йортларында кабул итү имтиханнары белән бер вакытка туры килә. Мансур моннан файдаланып, документларын Казан университетына илтеп тапшыра. Егет тарих-филология факультетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген сайлый. Мансурның университетта уку хыялы тормышка аша.

Мәскәү үк түгел-түгелен, әмма Казан университеты да дан-шөһрәт казанган мәшһүр уку йорты. Бу фән мәгарәсендә кемнәр генә укымаган да, кемнәр генә укытмаган!

Хәсәновка университетта уку да бик җиңел бирелә.

Табигатьнең гадәти булмаган шәхесләрне берләштерә торган бер сихри көче бар. Беренче курста укыганда Мансур бишенче курс студенты Фикрәт Табеев белән таныша. Фикрәт Мансурдан ике генә яшькә зур булып чыга. Алар КДУ парткомында, КПСС сафларына кабул ителгән көнне танышалар (Мансур Поповкада ук партиягә кандидат булып теркәлгән иде). Шушы очрашудан соң ике егетнең язмышы янәшә юлдан китә.

Фикрәт Табеев КДУда беренчеләрдән булып Сталин стипендиясе ала, Мансурга да соңрак шул ук стипендияне бирәләр. Ул чорда Сталин стипендиясе аспирант стипендиясеннән һәм ассистентның хезмәт хакыннан да артыграк була.

Сталин стипендиатлары бар факультетта да булмый, бөтен КДУда нибары шундый биш студент укый.

Мансурны КДУга алып килгән төп сәбәп — абыйсы Фатыйхның монда укуы. Кече туганнар, гадәттә, өлкәннәре сукмагыннан китә бит. Фатыйх Табеев белән бер курста укый. Өч дус еш кына Бауман урамына «Пирожковая»га төшәләр. Шул кайнар пирожкиларның тәме, хуш исе Мансур Хәсәновның хәтерендә хәзер дә саклана.

Укуны бетергәч, Ф.Ә.Табеев ассистент була. Соңрак Мансур да бу юлдан китә. Фикрәт факультетның партбюро секретаре урынбасары вазифасын башкара. Аны партком секретаре урынбасары итеп алгач, бу урынга Мансур тәкъдим ителә. Еллар үткәч. Фикрәт Әхмәтҗанович КПССның Татарстан өлкә комитетында фән, культура һәм уку йортлары бүлеген җитәкли. Берничә елдан бу урынга Мансур Хәсәнович раслана. Фикрәт Әхмәтҗанович бүген дә Мансур Хәсәновичка шаяртып: «Мин үз урынымны һәрвакыт бары сиңа гына калдыра идем», — ди.

Егетләрнең җәмәгать эше генә түгел, уку һәм фәнни эшчәнлекләре дә яхшы бара. Табеевны аспирантурага җибәргәндә, Мансур КДУны тәмамлый. Башта егетне аспирантурага профессор Галина Борисовна Курляндская чакыра. Ул Иван Сергеевич Тургенев иҗаты буенча СССРда иң зур белгеч санала иде. Аның Тургенев иҗаты буенча лекцияләре яхшы хатирә булып күңелдә калган. Гомумән, ул «алтын гасыр», ягъни унтугызынчы йөз әдәбияты буенча тирән белемле галимә иде.

Дүртенче курста укыганда, бер имтиханда Мансурга Иван Тургенев иҗаты турында билет эләгә. Ә Тургенев иҗатына Мансур чын күңеленнән гашыйк. Билеттагы сорауларга чатнатып җавап бирә. Тургеневның ак шигырьләре, табигатьне тасвирлау үзенчәлекләре турында илһамланып сөйли. Җавап профессор Курляндскаяга бик ошый һәм ул, кем әйтмешли, талантлы студентка «күз ташлый». Бишенче курста Галина Борисовна Хәсәновка аспирантурага керергә тәкъдим ясый. Тема бирергә вәгъдә итә. Егет тирән уйга кала. Чөнки моңа кадәр кафедра мөдире Хатыйп Госманович Госманов та аспирантурага керергә тәкъдим иткән була. Ул да танылган әдәбиятчы һәм язучы, университетның хөрмәтле укытучысы, Көнбатыш Европа әдәбияты белгече. Мансур Хатыйп Госманович тәкъдименнән баш тартырга кыймый һәм аның кафедрасында калырга була. Курляндская белән дә араны өзми. Иван Тургеневның иҗатына чын күңеленнән гашыйк булган Галина Борисовна тиздән аның туган җиренә — Орелга күчеп китә.

— Тургенев һәм Лев Толстой— минем иң яраткан язучыларым, — ди Мансур Хәсәнович. — Соңрак Галимҗан Ибраһимовны өйрәнә башлагач та, бу язучыларның иҗатын тирәнтен белүемнең файдасы тиде. Галимҗан Ибраһимовның, язучы буларак, бу ике талант иясе белән уртаклыгы күп.

Фикрәт Табеев Мәскәүгә аспирантурага киткәнче алар еш кына Мансур белән Ленин урамы буенча йөриләр, шул чорның вакыйгалары турында кызу бәхәсләшәләр. Бу — Хрущев идарә итә башлаган беренче еллар иде. КПССның XX съездыннан соң, Сталинның шәхес культы каты тәнкыйтьләнгәч, үткәннәргә һәм киләчәккә караш үзгәрә. Менә шуңа күрә дә инде Фикрәт Әхмәтҗанович Табеев һәм Мансур Хәсәнович Хәсәнов кебек большевиклар партиясенә фидакарь хезмәт иткән шәхесләр болай диләр:

— Безнең буын коммунистлары бөтенләй башка төр кешеләр. Без — партиядә шәхес культыннан соң демократик үзгәртүләр ясаган буын. Безнең репрессияләргә дә, төрле террорларга да бернинди катнашыбыз юк. Без яңа буын реформатор-коммунистлар токымы. Безнең буын —Сталинның шәхес культын, җәмгыятьтәге башка тискәре күренешләрне тәнкыйть итә алырлык көчле буын ул.

Бу язма авторы буларак, шуны әйтәсем килә: үзем дә алтмышынчы еллардагы демократик үзгәртүләр шаһиты мин. Әңгәмәдәшләрем белән тулысынча килешәм.

Мансур Хәсәнов һәм Фикрәт Табеев төрле курсларда укысалар да, аларның шәхес булып формалашуы бер чорга — Хрущев заманына, КПССның XX съезды карарлары белән рухланып яшәгән вакытка туры килә. Аларның тормышка карашында укыган вакытта аралашкан кешеләрнең роле зур була.

КДУ һәрвакыт фән дөньясының иң талантлы укытучылары белән дан тотты. Хәзер дә Фикрәт Әхмәтҗанович һәм Мансур Хәсәнович профессор Дмитрий Георгиевич Морозовның философия буенча лекцияләрен сагынып искә алалар.

Ул чакта тарих-филология факультетының деканы булып легендар кеше — Мансур ИбраһимовичАбдрахманов эшли. Бөек Ватан сугышы ветераны, ил азатлыгы өчен яуларда аягын калдырып кайткан. Протез белән генә йөри иде ул. Сугыштан соң кандидатлык диссертациясен яклаган.

Соңыннан Мәскәү университетында докторантура тәмамлап, философия фәннәре докторы була.

Мансур Абдрахманов татар телендә философия буенча дәреслек язган кеше. Бөек шәхесләрнең тормышлары янәшә юлдан бара дигән фикернең дөреслеген Абдрахманов белән Табеев мисалында да күрергә мөмкин.

Фикрәт Табеев та бу чорда Мәскәү университетында аспирантурада укый. Алар Абдрахманов белән икесе бер бүлмәдә яшиләр. Табеев үзенең өлкән дустына һәрвакыт ярдәм итә.

Фикрәт Табеев Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре булып эшләгән чорда Мансур Ибраһимовичны ТАССР Югары Советы Рәисе итеп куялар. Ул монда 1963 — 1967 елларда эшли. Шушы ук чорда Мансур Хәсәнович Хәсәнов та өлкә комитетының фән һәм уку йортлары бүлеген җитәкли. Ләкин бу бераз соңрак була. Аңа кадәр аспирантура тәмамлаган яшь галим Мансур Хәсәновны факультет деканы урынбасары итеп куялар. Бу вазифаны ул өч ел башкара. Шушы чорда кандидатлык диссертациясен яклый.

Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре булып С.Д.Игнатьев эшләгән заманда штаттан тыш инструкторлар институты булдырыла. Алар турыдан-туры өлкә комитеты секретарьларына буйсыналар. Идеология буенча секретарь булып Фикрәт Табеев эшли. Мансур Хәсәновны партия өлкә комитетының штаттан тыш инструкторы итеп билгелиләр.

— Мин Игнатьев белән аралашып калырга өлгердем әле,— дип искә ала Мансур Хәсәнович. — Көчле шәхес иде ул, дәрәҗәле хөкүмәт эшлеклесе. Аның иң төп сыйфаты — кадрлар сайлый белү, сизгерлек. Җитәкче булырлык кешеләрне әллә каян күреп ала иде ул.

Әле КДУ парткомында чакта ук Фикрәт Табеевны шунда тотуларына гел исем китә иде. Сукыр кешегә дә күренеп тора бит: бу егеттә әллә нинди җаваплы урыннарда эшләрлек көч-дәрт бар. Һәм 1957 елда Фикрәт Табеевны обкомга алгач, моңа һич тә гаҗәпләнмәдем. 1959 елда аны КПСС өлкә комитетына идеология буенча секретарь итеп куйдылар. Игнатьев булмаса, Табеев та булмас иде, — дип төгәлли үзенең фикерен Мансур Хәсәнович.

Бервакыт иртән эшкә барганда, КДУ каршында Хәсәнов Табеевны очрата.

— Хәлләр ничек, эшләр барамы, Фикрәт Әхмәтҗанович? — дип сорый Хәсәнов.

— Әй, Мансур, эш бик авыр әле.

— Ничего, бу бит сезнең өчен баскыч кына. Кем әйтмешли, переходный период.

Табеев Хәсәновка җитди генә итеп:

— Куй әле, Мансур, шаяртма, — ди. Мансур Хәсәновичның күрәзәсе дөрес булып чыга. Озак та үтми, Мәскәүдән танылган сәясәтче, СССР Фәннәр Академиясе академигы, КПСС ҮК секретаре, Президиум әгъзалыгына кандидат Петр Николаевич Поспелов килеп төшә. 1960 елның 30 октябрендә КПССның Татарстан өлкә комитеты пленумы була. Семен Денисовичны, шәхси гаризасы нигезендә, эшеннән азат итәләр, ә аның урынына беренче итеп Фикрәт Табеевны куялар. Бу вакытта аңа 32 яшь була.

Тиздән Мансур Хәсәнов та КПСС өлкә комитетының фән, культура, уку йортлары буенча бүлек мөдире булып эшли башлый. Бу бүлекне 10 ел җитәкли. 28 ел ТАССР Югары Советы депутаты булып сайлана.

Мансур Хәсәнович, бүлек мөдире буларак, Татарстан мәгариф эшенең бар нечкәлекләрен белә, югары уку йортларын, техникумнарны, һөнәри белем һәм гомуми урта белем системасын күзәтү астында тота. Бер генә югары уку йорты ректоры да аннан башка сайланмый. Минемчә, ул чорда Мансур Хәсәнович студентларның милли составы белән шөгыльләнеп, ватандашларыбыз каршындагы зур тарихи миссияне намус белән үтәде. Өлкә комитетының бүлек мөдире Хәсәнов авыллардан килгән татар яшьләренә нык игътибар бирде.

Ул чорда татар мәктәпләрен бетерүчеләргә республика югары уку йортларына керү имтиханнарын татарча бирү рөхсәт ителә. Ул елларда авыл җирендә туып-үскән күп кенә егет-кызлар югары уку йортларында уку бәхетенә ия булдылар. Бу, һичшиксез, Мансур Хәсәновичның тырышлыгы нәтиҗәсе. Ышанам ки, бүген безнең республика башка төбәкләргә караганда милли кадрларга бай. Бу — үткән еллардагы җитәкчелекнең тырышлыгы нәтиҗәсе.

Кайбер «акыллы башлар» Табеев һәм Хәсәнов эшләгән чорда милли мәктәпләр ябылды, татар программалары бетерелде дияргә яраталар. Ләкин бу — сафсата. 1958 елның маенда КПССның Татарстан өлкә комитеты пленумын искә төшерү дә җитә. Ул чакта беренче секретарь Семен Денисович Игнатьев татар халкына чын күңеленнән бүләк эшләргә уйлый. Ул идеология секретаре К.Ф.Фасеевка һәм бүлек мөдире Ф.Ә.Табеевка милли мәктәпләрнең хәлен яхшыртуга багышланган махсус пленум хәзерләргә куша. Фасеев та, Табеев та бу өлкәдә зур эш башкаралар.

Әмма тиздән КПСС Үзәк Комитетына «Татарстан өлкә комитеты милләтчелек белән шөгыльләнә»,— дип шикаять хатлары килә башлый.Татар мәктәпләре мәсьәләсе пленумда карала икән, димәк, бу — милләтчелек, дип уйлыйлар шикаять язучылар. Шуңа барып җитә ки, КПССның ҮК Татарстан өлкә комитеты карарын юкка чыгара. Көчле җитәкче, Сталин кадры С.Д.Игнатьев та берни дә эшли алмый бу очракта.

Соңрак өлкә комитетының бүлек мөдире итеп Мансур Хәсәновичны куйгач, аның янына еш кына ТАССР мәгариф министры М.И.Мәхмүтов кереп зарлана торган була:

— Менә Россия мәгариф министрлыгы дәресләр вакытын ике сәгатькә кыскартырга куша. Укучыларга нагрузка зур, — диләр.

— Нәрсә эшләргә уйлыйсың инде? — дип сорый Мансур Хәсәнович.

— Әлегә берни дә эшләмәдем. Рус телен кыскартырга ярамый, математика, физика, химияне дә... Хезмәт белән физкультурага тияргә кушмыйлар.

— Нәрсә тәкъдим итәсең?

— Мин берни дә тәкъдим итмим, Мәскәү татар теле сәгатьләрен кыскартырга куша.

— Соң, син бит Мәскәүдә яшәмисең,— дип кыза Хәсәнов,— фамилияң дә Иванов түгел, Мәхмүтов.

Мәгариф министры Табеев янына керми.

Менә шулай әйләндереп-тулгандырып дигәндәй, мәктәпләрдә татар телен кыскартмыйча калдыралар.

Бүгенге демократлар без туган телне торгыздык дип күкрәк сугып шапырынырга яраталар. Сүз дә юк, бу эштә янып-көеп йөрүчеләр даншөһрәткә лаек. Әмма туган телне саклау өчен көрәш беркайчан да — Хрущев заманында да, милли мәктәпләрне кысрыклаган чорларда да тукталмады. Митинглардан тәнкыйть уты яудыру гына эш кыру түгел әле ул.

Ул елларда Мәскәүнең Татарстанны кысуының сәбәбе гади, туган телдә тулы программа нигезендә урта мәктәпләр бары Татарстанда гына калган иде. Бездән соң Башкортстан бара. Башка барлык республикаларда, аерым алганда Мордовиядә, Чувашиядә 4 нче класстан соң русча укытуга күчтеләр. Республикада иң авыр заманнарда да татар теленә милли культураны саклаучы төп терәк итеп карадылар. Милләтне тармар итәсең килсә, башта аны туган теленнән генә мәхрүм итәсе.

Идеологик күрсәтмәләрне үтәү чорында, башкала чиновниклары белән үзара дуслыкны саклап калу авыр хәл иде. Ул елларда Мансур Хәсәнович РСФСР мәгариф министры А.И.Данилов белән бик дус була. Бу дуслыкның башы Казан университетына — Мансур Хәсәнович декан урынбасары булып эшләгән чорга барып тоташа. А.И.Данилов һәм Н.А.-Гуляев Казан университетына вакантлы вазифаларга киләләр. Мансур Хәсәнович өлкә комитетының бүлек мөдире булып эшли башлагач, Данилов РСФСР мәгариф министры була. Аның чиновникларыннан туган телне кыскарту турында күрсәтмәләр алгач, Хәсәнов Данилов алдына милли телне укытуга сәгать күләмен билгеләү һәм балаларны татар телендә кайсы сыйныфка кадәр укыту мәсьәләсе —КПССның Татарстан өлкә комитеты һәм республика Министрлыгы Советы вәкаләте икәнлеген кабыргасы белән куя. Моңа каршы Даниловның бернинди дә дәлиле булмый. Ул авыз ачып якламый да, кырт кистереп каршы да килми. Бары аның күзләре генә: «Мансур, кадерлем, үзең ничек уйлыйсың, шулай эшлә инде», — ди иде.

Хәсәнов Табеевка кереп, бу мәсьәләдә өлкә комитетының махсус карары кирәк булуын әйтә. Табеев Мансур Хәсәновичка текәлеп карап тора да:

— Юк, Мансур. Син бик акыллы тәкъдим әйтәсең, әмма, әйдә әле, бу эшне кәгазьсез генә эшлик.

Хәсәнов үзенең җитәкчесен бик яхшы аңлый. Өлкә комитетының һәр карары КПСС Үзәк Комитетына җибәрелә. Ә анда аны энә күзеннән үткәргәндәй тикшерәләр.

## ТАТАР РЕНЕССАНСЫ

Мансур Хәсәновичның университет дипломында «филолог» дип язылган. Әмма бу белгечлектән беркайчан да тарих фәнен аерып карарга ярамый. Мансур Хәсәновичның гомерлек мавыгуы да татар иҗтимагый фикере үсешенең тарихын өйрәнү булды. Үзенең эшчәнлеге һәм иҗаты белән ул соңгы елларда милли яңарышның алгы сафында барды. Мансур Хәсәнович болай ди:

— Тарихи һәм рухи үсешендә һәр милләт, һәр халык яңарыш, ягъни ренессанс чоры кичерә. Европа яңарышы, ислам яңарышы бар, япон һәм кытай яңарышларын да беләбез. Кайбер сәбәпләр аркасында соңга калып булса да, татар милләте дә шушы чорны кичерә. Минемчә, бездә бу процесс XIX гасырның икенче яртысында башланып, XX гасыр буе төрле борылышлар белән дәвам итте. Хәзерге яңа тарихи шартларда яңарыш тагын да активлашты.

М.Х.Хәсәновның төп фәнни хезмәтләре, кыскача әйткәндә, Россия чынбарлыгының үзенчәлекле шартларында татар милләтенең яңарышына багышлана.

Татар ренессансына нигез салучылар булып Шиһабетдин Мәрҗани һәм Исмәгыйль Гаспринский тора.

XIX гасырда танылган галим, мәгърифәтче Ш.Мәрҗани, иң беренче булып, татар халкының объектив тарихын яза башлый. Ул мөселман дөньясының дини тәгълимат үсешенә дә бәяләп бетергесез зур өлеш кертә.

XIX гасырның икенче яртысында Исмәгыйль Гаспринский шәхесе калкып чыга. Татар һәм рус культураларының бар нечкәлекләрен яхшы белгән, тирән белемле соклангыч интеллектуал була ул. Совет чорында аңа «пантюркист» дигән ярлык тагалар. Бу — аның шәхесен объектив бәяләргә нык комачаулый. И.Гаспринский карашлары нигезендә төрки халыкларның Россия составында үсешен билгели.

Гәбдрәшит Ибраһимов та үзеннән тирән эз калдырган шәхесләребезнең берсе. XIX гасырның соңгы чирегендә ул Европа һәм Көнчыгыш илләре буйлап күп сәяхәт итә. Галимҗан Ибраһимов юкка гына аны «тарих кыңгырауы», ягъни тарихның чаң кагучысы дип атамаган. Бу бик дөрес, образлы чагыштыру. Гәбдрәшит кайда гына булмасын, үз чыгышларын һәрвакыт кисәтү белән төгәлли: «татар милләте бетүгә бара!» Г.Ибраһимов фикерләренә Гаяз Исхакый фикерләре авааздаш. Аның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» дигән әсәре тарихка кереп калды һәм аны татарларга атап язылган сәяси манифест дияргә мөмкин. Аның әсәрләре, сәяси яктан караганда, шул чорда иҗтимагый фикерне формалаштыру-

да зур роль уйнады. Исхакый болай язган: «Татарлар, уяныгыз! Киләчәктә дә шулай яшәсәк, ике йөз елдан соң тәмам бетәчәкбез».

Әйтергә кирәк, Россия империясендә яшәүче халыклар арасында татарлар көчле иҗтимагый фикергә ия милләт буларак аерылып торганнар. Властьны большевиклар яулап алгач, беренче эш итеп халыкны Мәрҗани, Бигиев, Исхакый һәм башка фикер ияләренең, язучыларның иҗади мирасыннан мәхрүм итәләр. Совет чорында бу мирас берьяклап кына күрсәтелде. Хәтта аларга тәнкыйтьне дә өстән-өстән генә бирделәр. Бүген исә үзгә карашлар, үзгә бәя кирәк. Яңа фәнни методология нигезендә бик күп тарихи фактларны һәм вакыйгаларны яңабаштан карар вакыт җитте.

Татар милләте егерменче гасырга җәмәгать эшлеклеләренең көчле тәэсире белән аяк баса. Бу үзенчәлекле шәхесләр сәяси партияләр һәм иҗтимагый оешмалар төзиләр. Россия составындагы милли дәүләтнең нигезләрен эшлиләр. Тагын ассызыклап әйтәсем килә: бездәге иң радикаль сәясәтчеләрдә дә тулаем Россиядән аерылып чыгу уе булмады. Радикаллар бертавыштан унитар дәүләтне инкарь иттеләр. Фикерләр төрлелегенә нинди автономия булдыру мәсьәләсе китерде. Берләре милли-мәдәни бүленешне якласа, икенчеләре милли-территориаль бүленешне хуп күрде. Һәр төркем үзен хаклы санап, киләчәкне үзенчә күзаллады. Шунлыктан кызу бәхәсләр купты.

Мин 1920 елгы вакыйгаларны да татар яңарылышының бер этабы дип уйлыйм.

Мансур Хәсәнович шул мизгелдә үк фикеремне «эләктереп ала»:

— Сүз дә юк, В.И.Ленин декреты нигезендә автономияле республика төзү милли дәүләтчелек үсешенең мөһим баскычы булды. 1920 елда территориаль яктан өзеп-ертып дигәндәй, Татарстан Автономияле Республикасы төзелде. Татарлар яшәгән күп кенә төбәкләр төрле сәбәпләр аркасында күрше өлкә һәм республикаларда, мәсәлән, Башкортстан, Самара һәм башкаларда калды. Бердәм дәүләт составында автономия формасында яшәгән очракта да милли республикалар зур үсеш алыр иде дигән фикер белән кайчак килешеп тә куям. Әмма бу бүленеш, кызганычка каршы, бөтенләй башкача тәмамлана. Озак та үтми, хакимиятнең чын йөзе һәм уйлары ачыла. 1922 елда илнең милли мәсьәләләр буенча төп идеологы саналган Сталин Ленинга мондый хат җибәрә: «Кайбер милли лидерлар партия политикасын аңлап бетермиләр. Алар безнең программа документлары нигезендә чынбарлык төземәкчеләр. Аңлап бетермиләр: болар (ягъни документлар.— *Авт.*) партия лозунглары гына бит! Бүген бер лозунг булса, иртәгә икенчеләре язылыр. Күп бәхәсләр шуннан туа...» Сталинның авыру Ленинга язган юллары бу.

Ул елларда илнең сәяси җитәкчеләре арасында төрле карашлар хөкем сөрә. Мәсәлән, партиянең «сөеклесе» Бухарин, милли мәсьәләләрне бөтенләй кире кага. Экономик мәсьәләләрдә бер Бухарин булса, ул милли сәясәттә бөтенләй башка, капма-каршы кешегә әйләнә. Ул катгый итеп: «Нинди милли мәсьәләләр ди ул? Россиядә бердәм милләт булырга тиеш!» — дип белдерә. Егерменче елның ав-

тономиясен тоталитар система тәмам үзенчә үзгәртә. Союздаш республикалар автономия хәлендә кала, автономияләрнең исә бар хокуклары югалып, кем әйтмешли, автономия кәгазьдә генә кала. «Автономия» дип әйтү бер нәрсә, ә менә аңа мәгънә салу — бөтенләй икенче эш.

90 нчы еллар башында СССР Югары Советында булган бер дискуссия хәтеремә уелды. Ул чакта демократик җәмәгатьчелекнең сөеклесе Дмитрий Волкогонов «Татарстанга нинди суверенитет ди ул? Бөек, бердәм Россия дәүләте генә бар!» — дигән иде. Никадәр таныш сүзләр! Ике стандартлы сәясәт һәм мораль шушы була инде.

**— Ничек уйлыйсыз, 1927 елда гарәп графикасыннан латинга күчү татар милләтенең яңарыштан баш тартуы булмадымы?** — дип сорыйм әңгәмәдәшемнән.

— Графиканы, ягъни язуны алыштыруны милли яңарыштан баш тарту дип карау дөреслеккә туры килеп бетми. Бу — үсешнең аерым бер этабы. Изге Коръән телен чагылдыручы гарәп язуы зур хөрмәткә ия. Әмма, минемчә, латинга күчү дә прогрессив адым иде. Билгеле булганча, коммунистлар доктринасы җәмгыятьтәге милли аерымлыкларны бетереп, рус телле совет халкын булдыру максатын куя. Шуңа күрә, 1939 елда рус булмаган халыкларның язуларын кириллицага күчерүләренә бер дә шаккатасы түгел. Чын изү, көчләү мисалы бу. Бер мәлдә милли телләр мәҗбүри рәвештә үз язуларыннан мәхрүм ителделәр. Хәзер күпләр бу адымны халыкларны милли мәдәниятләреннән ваз кичтерү өчен эшләнгән эш дип бәялиләр. Мин кистереп, нәкъ шулай дип әйтмәс идем. Үз җитәкчеләребез арасында да милли үсешне юк итеп, руслаштыру сәясәтен алга сөрүчеләр аз булмады.

ТФА Президенты итеп сайланганга кадәр Мансур Хәсәновичның фәнгә чын күңеленнән бирелеп, «чумып» эшләргә әллә ни вакыты да калмый иде. Хөкүмәт эше алгы планга чыга. Әмма ул беркайчан да фәнни эшчәнлеген һәм, университет профессоры буларак, укытуын ташламый.

1971 елда М.Х.Хәсәнов СССР ФА Көнчыгышны өйрәнү институтында «Г.Ибраһимов иҗатының Совет чорында эволюциясе» дигән темага диссертация яклый. Ә эволюция исә бик җитди була. Г.Ибраһимов үзенең бар талантын, иҗатын һәм сәяси эшчәнлеген татар халкына багышлый. Ул, зур җәмәгать эшлеклесе буларак, башка милли лидерлар белән Татарстан Автономиясе Республикасын төзүгә зур өлеш кертә. Шул чорның башка бик күп җәмәгать эшлеклеләре кебек үк, Г.Ибраһимов та трагик шәхес. Ул 1938 елда хакимлек итүче системаның таш капчыгында вафат була.

— Г.Ибраһимов иҗаты искиткеч зур эволюция кичерә, — дип дәвам итә Мансур Хәсәнович. — Мин аны милли әдәбиятыбызда социалистик реализм методына нигез салучыларның берсе дип саныйм. Совет чорында бу иҗат методы идеологиянең каты кысаларында яшәде. Тоталитар җәмгыятьтә иҗат шәхесенең трагедиясенә китергән төп сәбәп бу. Нәкъ шуңа күрә 50 нче еллар ахырында, 60 нчы еллар башында

Хрущев чоры, 80 нче елларда Горбачевның үзгәртеп кору һәм хәбәрдарлык чоры күренмәгәнчә зур энтузиазм тудырды. Ул дәвер күп өметләрне чынбарлык итте.

90 нчы еллар зур үзгәртүләрдән башланды. Советлар Союзы таркалды. Татарстан суверенитет игълан итте. Җәмгыять, шул исәптән татар милләте дә, рухи тормышта зур үзгәреш кичерде. Татар мәдәнияте яңарышын моның нәтиҗәсе дип карарга мөмкин.

Дөнья тарихы күрсәткәнчә, һәр яңарыш процессының ахыры дәүләтчелек булдыру белән төгәлләнә.

Дәүләт органнарында эшләгән чорында, Мансур Хәсәнович, элеккеге СССРда татар культурасын пропагандалауга зур өлеш кертә. Ул Урта Азия һәм Кавказ республикаларында берничә тапкыр булып, аларның җитәкчеләре Д.Кунаев, Ш.Рәшидов, Г.Алиев белән очраша. Аның Союзлар йортының Колонналы залында һәм Әдәбият йортында фәнни һәм юбилей кичәләрендә, конференцияләрдә ясаган күпсанлы чыгышлары тыңлаучыларның татар әдәбияты, сәнгате һәм мәдәниятенә булган мөнәсәбәтен үзгәртте. Тыңлаучылары арасында һәрвакыт Мәскәүдә яшәүче татар интеллигенциясе вәкилләре дә була. Залдагыларның чыгышны ана телләрендә ишетәсе килгән очраклар да була. Мондый чакта Мансур Хәсәнович рус теленнән татарчага күчә-күчә рәхәтләнеп сөйли.

Соңгы елларда Фәннәр Академиясендә эшләгән чорында Хәсәнов Татарстан тарихы һәм мәдәнияте, республикада фән үсешенә багышланган докладлар белән Төркия җәмәгатьчелеге каршында еш чыгыш ясый. Мансур Хәсәновичны Америка Кушма Штатларына да еш чакыралар. Ул Филадельфия, Бостон, Төньяк Каролина штаты университетларында чыгыш ясый.

Татар милләтләренең яңарышы турында сөйләгәндә, бөек музыкантлар Салих Сәйдәшев, Рөстәм Яхин, Нәҗип Җиһановны да искә алырга кирәк. XX гасырның икенче яртысында милли культура үсешен аларның халыкчан музыкаль әсәрләреннән башка күз алдына китерү дә авыр. М.Х.Хәсәнов үзенең күп кенә язмаларын һәм хезмәтләрен әлеге композиторларның иҗатына багышлады.

60—70 нче елларда республика музыка үсешенә Натан Рахлин йогынтысы көчле була.

— Узган йөзьеллыкның соңгы ун елы милли үзаң яңарышына зур этәргеч ясады, — ди Мансур Хәсәнович. Без яңа формациянең яңача фикер йөртүче сәясәтчеләре һәм дәүләт эшлеклеләре белән таныштык. Бу чор алдынгы карашлы сәнгать ияләренә, мәгариф хезмәткәрләренә, талантлы язучыларга, публицистларга һәм журналистларга ачылырга ярдәм итте. Ул шәхесләр берсүзсез татар яңарышына үзләреннән зур өлеш керттеләр.

Бу урында сүземне йомгаклап, язма авторы буларак, сезгә кечкенә генә бер серне ачарга телим. Мансур Хәсәнович татар милләтенең яңарышы турында китап язды. Ул тиздән дөнья күреп, үз укучыларын табар, дип ышанам.

## ТФАның ОЕШТЫРЫЛУЫ

Бауман урамында Кремльгә үк терәлеп урнашкан социализмның үзенчәлекле архитектурасы нигезендә төзелгән бу бинада элек партия өлкә комитетының политик мәгариф йорты урнашкан була. Туксанынчы еллар башында ул яңа гына оешкан Фәннәр академиясенә тапшырыла.

Китап язу мәшәкатьләре белән йөргәндә, миңа еш кына бу йортта кунак булырга туры килде. Бүген биредә Татарстан Фәннәр Академиясенең Президиумы урнашкан. М.Х.Хәсәнов — Президиум җитәкчесе.

Әлбәттә, фәнни, тарихи, күпкырлы тормышның бихисап проблемаларына багышлап язучы, публицист буларак, мине Татарстан Фәннәр Академиясен оештыру тарихы кызыксындырды.

— Академия оештыру мәсьәләсе 1990 елда гына килеп туган проблема түгел иде, әлбәттә,— дип башлады сүзен Мансур Хәсәнович.— Математика, химия, астрономия, физика, медицина, лингвистика буенча гыйльми мәктәпләре белән Казан һәрвакыт дан тотты. Бик күп галимнәребезнең исемнәре дөнья фәне тарихына алтын хәрефләр белән язылган. Аларны санап тору да кирәкми. XIX гасырда һәм XX йөз башында Казан Көнчыгыш Европаның иң алдынгы фәнни үзәкләреннән саналган, ә 1917 елда Мәскәү һәм Петербургтан кала Россиядә өченче фәнни үзәк була.

Совет чорында да фән үсеше үз динамикасын югалтмый, 20 нче еллар башында милли академия прообразы булып, Татарстан Республикасының мәгариф наркомы каршында Академия үзәге оеша. Кыска гына вакыт эчендә әлеге үзәк аякка басып, республика галимнәренең координацион оешмасына әверелә. Әмма, автономияле өлкәнең үз милли академиясен булдырырга хокукы юк дигән сәбәп табып, тоталитар режим бу структураны юкка чыгара.

Икенче бөтендөнья сугышы елларында Казанга СССР Фәннәр Академиясенең күп кенә институтлары күчеп килү республикада фән үсешенә көчле этәргеч ясый. Ул чорда илнең куәтле фәнни-эзләнү базасы һәм фәнни көчләре нәкъ менә Казанда туплана. Хәрби-промышленность комплексы лабораторияләре һәм заводлары да безгә эвакуацияләнә.

1945 елда Казанда СССР ФА филиалын оештыру да очраклы хәл түгел. Бу беренче чиратта зур үсеш алган республика ихтыяҗы белән бәйле. Казанда төрле өлкәләргә караган фәнни оешмалар саны арткannan-арта. Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк, Совет чорында фәнни эзләнүләрне тулысынча координацияләү бик авыр иде. Академия, югары уку йортлары һәм төрле фәнни оешмалар, нигездә, аерым-аерым көн күрделәр.

Чама хисен югалту дигән сыйфат та үзенең тискәре эшен эшләми калмады. Мәсәлән, Хрущев дәверендә СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалын бөтенләй юк итәләр. Хрущев отставкага китеп, ике ай үтүгә, филиал яңадан эшли башлый. Әлбәттә, монда өлкә комитетының фән һәм уку йортлары бүлеге мөдире Мансур Хәсәновның роле зур була. Ул чакта М.Хәсәнов Табеевка:

— Филиалны югарырак дәрәҗәдә итеп яңадан оештырасы иде, — дип мөрәҗәгать итә.

Табеев:

— Нинди тәкъдимең бар соң? — ди.

Хәсәнов:

— Әгәр дә Казанда СССР Фәннәр Академиясенең Себер бүлеге кебек итеп, Идел буе бүлеген төзүне тәкъдим итеп карасак?

«Әлбәттә ул чорда мондый идеяне тормышка ашыру мөмкин түгел иде шул», — дип искә ала хәзер М.Х.Хәсәнов.

Туксанынчы еллар башында демократик үзгәрешләр дип аталган заманда Казанда Фәннәр Академиясен булдыру мәсьәләсе турында фикерләр ныграк ишетелә башлый. Моның өчен Татарстанда җитди нигез дә була.

Мансур Хәсәнович, беренче эш итеп, СССР Фәннәр Академиясе Президенты Гурий Иванович Марчукка мөрәҗәгать итә. Моның өчен Татарстан Министрлар Советы Рәисенең беренче урынбасары М.Х.Хәсәновның вәкаләтләре җитәрлек була. Үз заманында Марчук белән Хәсәновны КПСС ҮК фән һәм уку йортлары бүлеге мөдире, СССР Фәннәр Академиясенең член-корреспонденты В.А.Григорьев таныштыра. «80 нче елларның икенче яртысында Союз хөкүмәтенә һәм партия аппаратына эшкә СССР Фәннәр Академиясеннән танылган галимнәр килгән иде», — дип сөйли М.Хәсәнов.

Ул чакта Республика Югары Советын М.Ш.Шәймиев җитәкли. Татарстан суверенитетын игълан итәргә бер көн алдан Минтимер Шәрипович Мансур Хәсәновичны үзенә чакыртып ала да болай ди:

— Сезгә иртәгә Мәскәүгә, Президент Советының киңәйтелгән утырышына барырга туры киләчәк. Аны СССР Президенты М.С.Горбачев үзе үткәрә. Мин Казанда калырга тиеш. Аңлыйсыздыр: иртәгә Татарстан Югары Советының мөһим утырышы булачак.

Президент Советы утырышы Советлар чорындагы КПСС ҮК Политбюросы утырышына тиң чара. Әйтергә кирәк, Мансур Хәсәнович өчен анда катнашу тәкъдиме көтелмәгәндә була. Татарстан Югары Советының суверенитет игълан итәсе тарихи утырышында катнашмаячагын белгәч, бераз күңеле дә төшә. Суверенитет мәсьәләсендә күпме көч сарыф итте ул! КПСС өлкә комитеты Пленумында суверенитет хакында ясаган ялкынлы чыгышын искә төшерү дә җитә.

Мәскәү Кремлендә үткәрелгән Президент Советы утырышында Хәсәнов белән Марчукның урыннары янәшә туры килә. Хәл-әхвәл сорашканнан соң, Мансур Хәсәнович Марчукка җаен туры китереп, күңеленә тынгы бирмәгән сорауны бирә:

— Гурий Иванович, республикабызда Фәннәр Академиясе оештыру теләге бар. Бу фикергә сезнең мөнәсәбәтне беләсе килгән иде...

Г.И.Марчук ике дә уйлап тормый, болай ди:

— Академик яктан чыгып фикер йөрткәндә, берсүзсез оештырырга мөмкин!

Бераз сүзсез торгач:

— Дәүләт мәсьәләсенә килгәндә, үзегез карыйсыз инде. Элек бу мәсьәләләрне хәл итү бары тик КПСС ҮК Политбюросы вәкаләтендә иде. Академияләр дә союздаш республикаларда гына оештырылды, — дип куя.

Бу минутларда Казанда Республика Югары Советының тарихи утырышы баруын Марчук белми әле. Мөгаен, анда суверенитет игълан ителгәндер инде. Ә Мансур Хәсәнович Мәскәү Кремлендә Марчук янәшәсендә уйларына чумып утыра. «Без суверенитетны ни өчен яулап алырга омтылабыз? Суверенитет Татарстанның статусын үзгәртеп, союздаш республика дәрәҗәсенә күтәрергә ярдәм итәчәк. Әнә бит, СССР Фәннәр Академиясе Президенты Казанда Академия булдыруга каршы түгел, бары тик дәүләт мәсьәләсен генә үзегез хәл итегез», ди. Казанга кайтуга, Мансур Хәсәнович СССР Фәннәр Академиясенең союздаш республикаларның Академияләре эшчәнлеген координацияләү комиссиясенең җаваплы секретаре Н.С.Пшерковка шалтырата. Мансур Хәсәнович аның белән электән үк яхшы мөгамәләдә, Пшерков еш кына Казанга килә торган була.

— Николай Сергеевич! Сез СССРда Академияләр оештыру буенча профессорга тиң белгеч. Бу мәсьәләдә азау теш ярган кеше сез. Татарстанда үз Академиябезне булдырасыбыз килә иде. Ничек уйлыйсыз, хокукый яктан дөресме бу?

— Соңгы тапкыр 1961 елда Молдавия Республикасының Фәнни Академиясен төзедем. Бу — СССРдагы иң яшь Академия. Молдавиянең территориясеннән чыгып караганда, Татарстанда ике Академия төзергә дә мөмкин...

Бу урында шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: СССР Конституциясенең җәмгыятьтә КПССның җитәкчелек роле турындагы 6 нчы статьясы бетерелгән чак бу.

Академия төзү мәсьәләсен М.Ш.Шәймиев шәхси күзәтүдә тота.

Марчук һәм Пшерков белән сөйләшүләре турында Мансур Хәсәнович Минтимер Шәриповичка җиткерә һәм зур эшкә аның фатыйхасын ала.

М.Х.Хәсәнов Фәннәр Академиясенең оештыру комитетын төзү турындагы карарның проектын әзерли. Аңа республиканың 27 танылган галиме керә: Б.А.Арбузов, В.Е.Алемасов, И.А.Тарчевский, А.И.Коновалов, С.Р.Дьяконов, М.И.Мәхмүтов, М.К.Михайлов һәм башкалар. М.Ш.Шәймиев тәкъдиме белән оештыру комитеты рәисе итеп М.Х.Хәсәнов билгеләнә.

Бер үк вакытта Татарстан Фәннәр Академиясен оештыру концепциясе дә эшләнә. Ул көннәрдә төрле бәхәсләрнең иге-чиге булмый. Тел, әдәбият һәм тарих институты җитәкчеләре, татар тарихын һәм мәдәниятен өйрәнүче гуманитар Академия булдырырга тәкъдим итәләр. М.Хәсәнов һәм аның фикердәшләре бу карарның ялгышлыгын исбатлыйлар.

Татарстанның дәүләт нигезендә полиэтник һәм поликонфессиональ җәмгыять ята. Башка милләтләрнең мәнфәгатьләре белән

нишләргә? Цивилизациянең гомумкешелек дигән кысаларын да, Татарстанның тормышның бар даирәләрендә алга киткән республика икәнен дә истән чыгармаска кирәк.

Барлык әзерлек эшләре бетүгә 1991 елның 30 сентябрендә ТР Президенты Татарстан Фәннәр Академиясе турындагы Указга кул куя. Академия 1992 елның февраленә төзелеп бетә.

Фәннәр Академиясен төзегәндә Мансур Хәсәновичның девизы бер: «Бернәрсәне дә җимермәскә, юкка чыгармаска! Ирешелгәннәрне үстерү, тагын да камилләштерү юлы белән алга барырга!»

Чынбарлыкта нәкъ шулай була да. Яңа академия Казан Фәнни үзәгенең бинасына урнашып, башкалар туплаган мөлкәтне үзләштерер диючеләр нык ялгышалар.

М.Х.Хәсәнов академияне оештырганда да, соңыннан аның Президенты булгач та, читләрнең сыңар кадагына да тимәде.

Ул Политмәгариф йортын академия карамагына тапшыруны сорап ТР Президенты М.Ш.Шәймиевкә үзе мөрәҗәгать итә. Бүген ТФА составында җиде институт бар. Иң беренчеләрдән булып академиягә ортопедия хирургиясе һәм информатика проблемалары институты керә. Соңрак социаль, хокукый фәннәр, экология, тарих институтлары булдырыла. Шулай ук ике «хуҗага» буйсынучы институтлар да бар. Мәсәлән, казылма байлыкларга бәя бирү белән шөгыльләнүче геолнеруд институты, углеводород институты һ.б. Бөгелмә нефть институтының даны Татарстаннан читкә таралган.

ТФАда җиде бүлек булып, аларның һәркайсы берничә фәнни юнәлештә эшли.

Татарстан Фәннәр Академиясендә Татар Энциклопедиясе институты аерым урын алып тора. 1999 елда рус телендә беренче Татар Энциклопедия сүзлеге нәшер ителде. Бу үзенчәлекле басманың фәнни редакция коллегиясе рәисе һәм баш редакторы да М.Х.Хәсәнов.

Шундый ук сүзлек тиздән татар телендә дә басылып чыгачак. Киләчәктә биш томлык Зур татар энциклопедиясен язу күздә тотыла. Әле кайчан гына бу хакта татарлар һәм республика халкы бары хыяллана гына алалар иде. Ирексездән хәтеремә Мансур Хәсәновичның сүзләре килеп төшә: «Егерменче гасырның соңгы унъеллыгы татар милләте яңарышында иң якты чор булды».

Күптән түгел Татарстан Фәннәр Академиясе составында Ульяновск региональ бүлеге эшли башлады. Ульяновск өлкәсе губернаторы чакыруы буенча Мансур Хәсәнович анда презентациягә дә барып кайтты.

Минем гаҗәпләнеп: «Шулай да буламыни? Ульяновск өлкәсе — федерациянең аерым субъекты ич?» — дигән соравыма Мансур Хәсәнович болай җавап бирде:

— Элек Татарстан Фәннәр Академиясен дә күз алдына китерү авыр иде бит...

Ул әлеге вакыйганың тарихын сөйләп бирде. Башта Ульяновск губернаторы Президентыбыз М.Ш.Шәймиевкә мөрәҗәгать итә. Минтимер Шәрипович губернатор тәкъдимен хуплый һәм ТФА Пре-

зиденты М.Х.Хәсәнов белән киңәшләшергә куша. Мансур Хәсәнович күрше өлкә губернаторын игътибар белән тыңлагач, дипломатларча сорап куя:

— Сез ни өчен Россия Фәннәр Академиясенә мөрәҗәгать итмисез соң?

— Без аларга берничә тапкыр мөрәҗәгать итеп карадык. Тик алар озын-озакка суздылар. Соңгы баруда кистереп әйттеләр: «Безгә Россиядә яңа академияләр булдыру түгел, булганнарын тоту да бик авыр хәзер», — диделәр.

Бүген ТФА составында 100 әгъза һәм әгъза-корреспондент. Болар илдә танылган галимнәр. Алар академия, югары уку йортлар галимнәре һәм гамәли фәннәрне өйрәнүчеләр.

Әйе, бүген Татарстан Республикасы тормышында Фәннәр Академиясенең роле бик зур. Россия һәм Татарстан арасында үзара вәкаләтләр турында Шартнамәгә 1994 елның 15 февралендә кул куелды. Ә ТФА һәм РФА арасында үзара хезмәттәшлек турында килешү 1993 елның җәендә төзелде. Бу өлкәдә фәннең үз сүзен әйтә алуы яхшы аңлашыла.

— ТФА булдыруда Президентыбыз М.Ш.Шәймиевнең өлеше зур, — ди М.Х.Хәсәнов. — Ул Татарстанда фән тормышын яхшы белә иде. Безнең беренче адымнарыбыздан ук һәрнәрсәдән хәбәрдар булды. Фән үсеше өчен тиешле мохит булдырылуга тәмам ышангач кына Минтимер Шәрипович Указга кул куйды. Президент бу мәсьәләдә дә үзенең фикерләү сәясәтенең киңлеген исбатлады.

Татарстанда академия төзү тормыш басымы белән эшләнде. Оештыру ягыннан караганда, академиягә тел-теш тигезерлек түгел. Ул шулкадәр яхшы оештырылган ки, моны Мәскәү дә, Казан да раслый.

РФА президенты академик Ю.С.Осипов гомуми җыелышларда башка республикаларны тәнкыйтьләп, болай ди:

— Сез нәрсә анда велосипед уйлап табу белән шөгыльләнәсез. Әнә ТФАсеннән үрнәк алыгыз. Һәммәгез өчен дә классик үрнәк бит. Әллә нәрсәләр уйларга да кирәкми. Тотыгыз да күчерегез!..

Мәскәүдә М.Х.Хәсәнов Гурий Иванович Марчук белән еш очраша. Марчук канәгать елмаю белән:

— Мансур Хәсәнович, туксанынчы еллар башында ТФА оештырып без бик дөрес эшләдек, — ди.

## НУРЛЫ КАЗАН ТУРЫНДА

Бу язмамны бастырырга әзерләнеп йөргәндә, мин Мансур Хәсәновичтан булачак зур бәйрәм — Казанның меңъеллыгы турында сорашмыйча кала алмадым. Мине башкалабызның төгәл яшен билгеләүдә галимнәрнең эше кызыксындырды.

— Бик зур тарихи мәсьәлә, — ди Мансур Хәсәнович. — Академия

галимнәре кыска гына вакыт эчендә зур тикшеренү һәм археология эшләре башкардылар да мәсьәләне хәл иттеләр дип әйтү дөреслеккә туры килми. Казанның төгәл яшен билгеләү өчен фәнни тикшеренүләр соңгы 200 ел буена туктап тормады. Башкалабызның төгәл яшен үзебез бик яхшы белсәк тә, СССР Фәннәр Академиясен һәм Союз җитәкче оешмаларын моңа ышандырып булмады.

Ни өчен соң моны исбатлау бары тик егерменче гасыр азагында гына мөмкин булды? Беренчедән, борынгы шәһәрләрнең яшен билгеләүнең яңа методларын тәкъдим иттек. Икенчедән, Казан галимнәренең соңгы тикшеренү нәтиҗәләрен Россия Фәннәр Академиясе дөрес дип тапты. Өченчедән, бу эшкә Казан һәм Татарстан дәүләт җитәкчеләре ныклап керештеләр.

1999 елның 30 августында Мәскәүдә Президент Б.Н.Ельцин указы һәм Казанда Президент М.Ш.Шәймиев указы дөнья күрде. Ике документ та Казанның меңъеллыгын рәсми рәвештә таныды. Россия һәм Татарстан Фәннәр Академиясенең бер кулдан эшләве нәтиҗәсе булды бу.

2000 елның июнь ахырында республиканың күренекле хөкүмәт һәм җәмәгать эшлеклесе, танылган галим, Татарстан Фәннәр Академиясе Президенты, академик Мансур Хәсәнович Хәсәнов 70 еллык юбилеен билгеләп үтте. Бу бер кешенең юбилее гына түгел, бу — киң җәмәгатьчелекнең дә уртак бәйрәме булды.

## БЛИЦ-ӘҢГӘМӘ

**— Яраткан фильмыгыз?**

— «Тын Дон».

**— Газеталар укыйсызмы, яңалыклар карыйсызмы?**

— Яңалыклар карыйм, газеталар укыйм, караштырып кына чыкмыйм.

**— Яраткан язучыгыз?**

— Алар күп, аерып кына әйтүе кыен. Л.Толстой, И.Тургенев, И.Бунин. Татар язучыларыннан Галимҗан Ибраһимов, Фатыйх Хөсни. Мемуарлар укырга яратам.

**— Акчага мөнәсәбәтегез ничек?**

— Исем китми.

**— Кешеләрдә нинди сыйфатларны яратмыйсыз?**

— Алдакчы, сатлыкҗаннарны, миһербансызларны яратмыйм.

**— Ә нинди сыйфатларны хөрмәт итәсез?**

— Игелекле, гадел, яхшы күңелле кешеләрне хөрмәт итәм.

**— Яраткан ризыгыгыз?**

— Өчпочмак.

**— Яраткан эчемлегегез?**

— Чәй, кызыл шәраб.

**— Буш вакытта яраткан шөгылегез?**

— Урманда ялгызым гына уйланып йөрергә яратам.

## СҮЗ АХЫРЫ

Татарстан Республикасы XXI гасырга узган гасырның соңгы унъеллыгында нигез салынган сәяси һәм икътисади мирас белән керде. Үзенең бай традицияләре булган халык бу чорда яңа дәүләт төзүгә ирешті. Шул ук вакытта демократик үсеш юлына баскан күпмилләтле Россия Федерациясендә дә яңа мөнәсәбәтләр урнашты.

Россия җәмгыятенең үсешендә иң төп шартларның берсе — федератив мөнәсәбәтләр урнаштыру. Чын федерация төзү озак һәм четерекле процесс ул.

Советлар Союзы унификацияләнгән идеология нигезендә төзелде. Ул федератив формалы унитар дәүләт иде.

Туксанынчы еллар кырыс сәяси шартларда башланды. Килеп туган хәлдән чыгу юлы бер генә иде — яңа федератив мөнәсәбәтләр урнаштыру. Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе арасында 1994 елда төзелгән Шартнамә яңа мөнәсәбәтләр урнаштыруда төп нигез булды. Ул — Үзәк һәм Федерация субъектлары арасында мондый килешүләрнең беренче тәҗрибәсе дә иде. Сүз дә юк, Шартнамә Россия Федерациясенең абруен күтәрде. Үзара хезмәттәшлек тәҗрибәсе Федерациянең башка субъектлары өчен дә тирән мәгънәгә ия. Ул халыкара планда да зур кызыксыну тудырды. Шартнамәгә таркату, ягъни дезинтеграция чарасы дип караучыларның өметләре акланмады. Киресенчә, ул яңа федератив төзелеш моделенең башлангычы булды. Татарстан исә бу процессның пионеры. Республикабыз узган юл бик әһәмиятле һәм тыныч булуы белән тарихи кыйммәткә ия.

Көчле федерацияләре булмаган федератив дәүләт тә, көчле үзәге булмаган дәүләт тә яшәргә сәләтсез. Минемчә, Үзәк регионнар белән төрле мөнәсәбәттә яшәргә мөмкин, әмма ул мөнәсәбәттә халыкларның, милләтләрнең хокуклары сакланырга тиеш.

Татарстанны Үзәк Шартнамә төзүгә этәргән сәбәпләр борынгы дәүләт традицияләрен яңарту, демократик сәяси система төзү, икътисадны мөстәкыйль үстерү теләге генә булмады, билгеле. Монда тагын бик мөһим бер моментны — культура һәм татар цивилизациясе мәсьәләләрен дә онытмаска кирәк. Татарлар меңнәрчә еллар дәвамында бөек ислам цивилизациясендә яшиләр. Соңгы дүрт гасырда нәкъ менә ислам халыкка Россия империясенең көчләп руслаштыру, милләтләрне кушу сәясәтенә каршы торырга ярдәм итте. Россия Федерациясендәге Татарстан дәүләте — Балтыйк диңгезеннән Тын Океанга кадәр сузылган Евразиячел тормыш мисалы ул. Монда ике цивилизация —христиан дине һәм ислам бергә яши. Бүгенге көндә бу аеруча зур әһәмияткә ия.

Исламны өйрәнүдә соңгы унъеллыкта яңа тенденцияләр барлыкка килде. Бу — 80 нче еллар ахыры — 90 нчы еллар башында Россия һәм БДБ илләрендә башланып киткән мөселман яңарышының якты мисалы. Ләкин Совет власте чорындагы стереотипларга каршы торырлык яңа методология эшләнде дияргә бераз иртәрәк әле. Көнчы-

гышны өйрәнү, ягъни ориенталистика өлкәсендә ислам ике юнәлештә карала. Беренчедән, ислам галимнәрнең игътибарын халыкара һәм эчке сәясәттәге күп процесслар үсешендә җитди роль уйнавы белән үзенә тартты. Бу күзлектән чыгып караганда, галимнәрнең һәм сәясәтчеләрнең мөселман дөньясы, андагы вакыйгалар белән кызыксынуы нык аңлашыла. Исламны тирәннән өйрәнми торып, теге яки бу җирлектә акыллы, максатлы сәясәт алып бару мөмкин түгел.

Икенчедән, бу азлап кына булса да Европа һәм илебездә ислам тәгълиматы дөнья күрә башлады. Әмма белгечләр, нигездә, классик ислам белән генә чикләнәләр. Аның заман сәясәте белән бәйләнеше ничектер игътибардан читтә кала. Төрки дөнья мөселман цивилизациясенең бер кырында гына урнашканга күрә, әллә ни зур кызыксыну тудырмый дигән хаталы караш яши.

Россия исламы, аеруча Идел буе исламы классик ислам буларак та, сәяси фактор буларак та бөтенләй өйрәнелмәгән. Элеккеге Советлар Союзында ислам башка мөселман дәүләтләр белән чиктәш булган Урта Азия, Кавказда өйрәнелгән. Россиянең иң күп мөселманнары — татарлар яшәгән Үзәк регионнар ислам белгечләренең фәнни эзләнүләреннән ничектер мәхрүм калганнар.

Соңгы елларда бу мәсьәләдә гаять кызыклы тенденцияләр туды. Шуларның берсе — классик ислам тәгълиматының соңгы эзләнүләр һәм ачышлар белән синтезы, динне төрле, шул исәптән сәяси тәэсирләрдән азат булган үзгә феномен итеп караудан баш тарту. Россиядә ислам белән кызыксыну күзгә күренеп артты. Әмма ислам тәгълиматының методологик стереотиплары бетерелмәгән әле. Монысы бик кызганыч.

Россия исламы, эчке һәм тышкы сәясәтнең аеруча әһәмиятле факторы буларак, нигездә политологлар тарафыннан өйрәнелә. Шунлыктан ул этноконфессиональ һәм мәдәни феномен булудан бигрәк, теге яки бу регионның, яисә дәүләтнең иҗтимагый-сәяси тормышында мөселман факторы буларак карала.

Һәр дин кебек, исламның да иҗтимагый-сәяси процессларга катнашын инкарь итеп булмый. Әмма аны абсолют дәрәҗәгә куеп, теге яки бу сәяси вакыйганы ислам белән бәйләргә һич ярамый.

XXI гасыр башында бу проблема аеруча җитди төсмер алды. 2001 елның 11 августында Америкада булган хәлләрдән соң ислам конъюнктурасы тагын да актуальләште. Бу һәм башка факторлар исламны өйрәнүгә тискәре тәэсир ясыйлар.

Фәнни җәмәгатьчелек алдында татар халкы пландагы катлаулы сорауларны хәл итүнең комплекслы юлын булдыру тарихта киң урын алып, безнең көннәрдә аеруча көчәйгән идеологик һәм психологик ышанулардан котылу мәсьәләсе тора. Бу эштә шунысы ачык: моның өчен методологияне яңабаштан карап чыгарга, кайберләрен исә бөтенләй үзгәртергә кирәк.

## АЛЬБЕРТ БИКМУЛЛИН, ХАЛЫКАРА МӘГЪЛҮМАТЛАШТЫРУ АКАДЕМИЯСЕ ПРЕЗИДЕНТЫ:

### «Мәгълүмат кем кулында — дөньяга шул хуҗа»

**— Альберт Лотфуллович, Халыкара мәгълүматлаштыру академиясенең тарихы белән таныштырып үтсәгез иде. Ул ничек оештырылды: Россия Фәннәр академиясенә альтернатив буларакмы, яисә башка принцип буенчамы?**

— Халыкара мәгълүматлаштыру академиясе 1993 елда оештырылды. Моңа кадәр СССРда, шулай ук советлардан соңгы чордагы Россиядә, халыкара академияләр юк иде. Россия Фәннәр академиясе һәм элеккеге союздаш республикалар академияләре фән өлкәсендә бары тик Россия һәм төбәк проблемалары белән генә шөгыльләнделәр. Фәннәр академиясенең фәнни тикшеренүләр, эшләнмәләр, фәнни мәгълүмат өлкәсендә дөньякүләм бәйләнешләре булмады.

СССР Фәннәр академиясе академигы исеме алган күренекле галимнәребез бары тик Советлар Союзы чикләрендә, ә советлардан соңгы чорда Россия Федерациясендә генә академик булып калдылар. Тегe яки бу фәнни уңышларга ирешүләренә карамастан, аларны академик буларак башка илдә танымадылар. Чит илләрдә соңгы вакытларга кадәр безнең югары уку йорты биргән дипломнарны санга сукмаганны, Милли академия турында бу хакта ни әйтәсең?! Кайсыбер университет һәм академияләр Европа союзы аккредитациясен әле күптән түгел генә ала башладылар. Бездәге югары уку йортларын тәмамлаучыларга, квалификациясен өстәмә рәвештә расламыйча торып, чит илләрдә үз белгечлеге буенча эшләү мөмкинлеге булмады. СССР һәм советлардан соңгы чордагы Россия югары уку йортлары биргән дипломнар гамәлдә түгел дип саналды. Җәмгыятьтә үзгәртеп корулар, дөньяда интеграция процессы башлангач, дөньякүләм дәрәҗәдәге академия оештыру ихтыяҗы туды. Мәсәлән, Халыкара мәгълүматлаштыру академиясе академигы бүгенге көндә Россия яисә Украина академигы гына түгел инде. Ул АКШ яисә Канаданыкы да. Димәк, халыкара академик статусына ия!

Халыкара мәгълүматлаштыру академиясе (алга таба ХМА) оештырылуына кадәр һәрбер академия үз галимнәрен Милли академиягә почетлы әгъза итеп сайлый иде. Мәсәлән, СССР академигы АКШ академиясенең почетлы әгъзасы итеп (яисә киресенчә) сайланды. Бер сүз белән генә әйткәндә, дөньякүләм масштабта бердәм исем булмады.

Моннан тыш, базар икътисадына күчү шартларында дөньякүләм киңлектә тиз генә дөрес мәгълүмат кабул итә алу мөмкинлеге бул-

ган фәнни берләшмә төзү зарурлыгы туды. Илебез базар икътисадына күчә башлауга ук фәнни тикшеренүләр, эшләнмәләр өлкәсендә тиешле мәгълүматлар алу һәм гомумиләштерү кыенлашты. Шулай ук тикшеренүләрне финанслау да авырлашты.

Шуңа күрә дә бүгенге көндә Халыкара мәгълүматлаштыру академиясе кебек халыкара берләшмә генә, тулаем алганда, икътисадны һәм башка барлык инфраструктураны базар рельсларына күчерү өчен нигез булдыра.

Россия Федерациясенең Фәннәр академиясеннән аермалы буларак, ХМА шулай ук коллектив әгъзалыкны да күз уңында тота. Болар алдынгы технологияләр өлкәсендә, фәнни кадрлар әзерләүдә, информатикада фәнни кайгыртуга ихтыяҗы булган предприятиеләр төркеме, оешмалар, банклар, фәнни һәм уку учреждениеләре булырга мөмкин. Берләшкән Милләтләр Оешмасына, Европа Советына һәм башка халыкара учреждениеләргә чыгуны таләп итә. ХМА БМОның ассоциация әгъзасы булып торганлыктан, ул коллектив әгъзаларына үзенең киңәш-тәкъдимнәрен бирә.

Мәсәлән, бүгенге көндә «Татнефть» һәм Түбән Кама «Нефтехим» акционерлык җәмгыятьләре Халыкара мәгълүматлаштыру академиясенең коллектив әгъасы булып торалар.

**— ХМАнең төп максаты һәм аның эшчәнлек системалары нинди соң?**

— ХМАнең максаты галимнәр идеяләрен дөнья киңлегенә чыгарудан гыйбарәт. Без мәгълүматлаштыру теге яки бу дәүләтнең үсеш дәрәҗәсе интеграль күрсәткече булуына ирешергә тиеш. Фән һәм тәҗрибә раслаганча, мәгълүматлаштыру дәрәҗәсе югары булса, цивилизациянең дә шулкадәр үк югары булуын билгели иде. Соңгы вакытларда «Мәгълүмат кем кулында — дөньяга һәм Римга шул хуҗа» дигән әйтемнең киң таралуы да юкка гына түгел.

Куәтле дөньякүләм мәгълүмат киңлеге оештырудан без нәрсә отабыз соң? Беренчедән, кеше эшчәнлегенең теләсә нинди өлкәсе хакында да тиешле мәгълүматны тиз арада тапшыруга сәләтле «Интернет» дигән могҗиза пәйда булды. Икенчедән, галимнәребезгә махсус фәнни-тикшеренү институтларыннан башка гына, зур күләмдә бюджет акчалары сарыф итмичә, бер үк вакытта дөнья киңлегенең ачыш һәм эшләнмәләреннән файдаланып, үзләренең тикшеренү һәм эзләнүләрен сынап карау мөмкинлеге туды.

**— Мәгълүматлаштыру төшенчәсе хакында гади укучыларыбызга да аңлаешлы итеп сөйләп үтсәгез иде. Мәгълүматлаштыру һәм информатика дигән төшенчәләрне күп кеше бутап сөйли.**

— Әйе, болар икесе дә бер үк нәрсә дигән сүз түгел. Информатика ул теләсә нинди мәгълүматны — эшлекле, фәнни, техник мәгълүматны хисаплау техникасы ярдәмендә эшкәртү белән бәйләнешле барлык нәрсәне үз эченә ала. Мәгълүматлаштыру исә киңрәк төшенчә. Аның белән кеше эшчәнлегенең барлык өлкәсенә кагылышлы мәгълүмат алу бәйләнгән. Моңа информатика үзе, фән, авыл хуҗалы-

гы һәм промышленность җитештерүе, шәһәр хуҗалыгы, экология мәсьәләләре, хәтта спорт, туризм һ.б. керә. Халыкара мәгълүматлаштыру академиясенең төп үзенчәлекле билгесе — ул барлык фәннәр тоташкан җирдә урнашкан. Мәсьәләләрнең күпчелеге бергәлектә чишелеш таба.

Бүгенге көндә безнең промышленностьта һәм шулай ук авыл хуҗалыгында җитди проблемалар булу беркемгә дә сер түгел. Хәл ителмәгән мәсьәләләрнең берсе булып җир милекчәсен билгеләү тора. Мәгарифтә, фәнни эзләнүләр өлкәсендә һ.б. проблемалар күп.

Телибезме без — юкмы, әмма бу проблемалар барлык фәнни эзләнүләр һәм ачышлар тоташкан урында хәл ителәчәк.

Тагын бер мисал китереп үтәм. Татарстан республикасы нефть битумының бай ятмасына ия. Анык итеп әйткәндә, бүгенге көндә Татарстанда 9 млрд. тоннадан артык нефть битумы бар. Соңгы вакыткача бу табигать байлыгын чыгару һәм аны эшкәртү бик акрын барды. Нефть битумы бездә шактый тирәндә ята. Моннан тыш анда файдалы казылмаларның күп кенә элементлары да бар. Нефть битумын эшкәрткәндә бу элементлар юкка чыга.

Эшләр нишләп болай начар бара соң? Чөнки бу өлкәдә без артта калган технологияләр белән эш йөртәбез. Элек чит илләрдән безгә һәрвакыт искергән технологияләр биреп килделәр.

Халыкара мәгълүматлаштыру академиясе, күп кенә халыкара оешма һәм учреждениеләр белән күпсанлы горизонталь бәйләнешләрдә тору нәтиҗәсендә нефть битумы чыгару һәм аны эшкәртү өлкәсенә караган иң алдынгы технологияләр алуга иреште.

Күп кенә алга киткән илләр хәзерге көндә шушы юлны сайлап алдылар. Моңа иң ачык мисал итеп технологияләр ягыннан гаять нык алга киткән Японияне мисал итеп китерергә мөмкин.

**— ХМАнең структурасы белән дә таныштырып үтсәгез иде. Россия Фәннәр академиясеннән аның аермалыгы нидә?**

— ХМА структурасы — идарәнең мәгълүмати-кәрәз системасы ул. Һәм Россия Фәннәр академиясе структурасыннан тамырдан аерылып тора.

ХМАдә вертикаль юк. Аның структурасы киселештә бал кортлары ясаган кәрәзне хәтерләтә. Кәрәз системасы — теләсә нинди инженерлык конструкциясендә иң нык система. Ул бит барыбызга да мәгълүм алты кырлык. ХМАнең бөтен кәрәзләре дә күрше яки башка кәрәзләрдән бәйсез эшли. Әмма кирәк булганда теге яки бу кәрәз вәкаләтләрен үз системасының нинди дә булса кәрәзенә тапшыра.

Аерым бер кәрәзләргә тулырак мәгълүмат биреп тору максатында штаб-квартиралар эшләп килә. Алар Нью-Йоркта, Мәскәү, Казан һәм Монреальдә урнашкан. Быел Санкт-Петербург шәһәрендә дә шундый ук штаб-квартира ачылачак.

1995 елда ХМАнең БМОга югары категория буенча ассоциация әгъзасы итеп кабул ителүе очраклы гына түгел. ХМАнең ике вәкиле

даими рәвештә БМОның Нью-Йоркта урнашкан штаб-квартирасында эшли. Алар халыкара әһәмияткә ия булган күп кенә мәсьәләләрне әзерләүдә катнаша һәм төбәкләрдәге бүлекләр, штаб-квартиралар аша аларны тормышка ашыруда булыша.

1995 елда Татарстан башкаласына, ХМАнең Казандагы штаб-квартирасының эше белән танышу, халыкара программаларны тормышка ашыру мөмкинлекләрен өйрәнү максатында, БМОның Генераль секретаре урынбасары Джозеф Вернар Рид килгән иде. Ул безнең Президентыбыз М.Ш.Шәймиев белән дә очрашып сөйләште. Әйтергә кирәк, федераль хакимият рөхсәтеннән башка, Россиянең Тышкы эшләр министрлыгы санкция бирмичә торып, БМО Генераль секретаре урынбасарының федерация субъектына килү хокукы юк иде. Әмма ХМАнең статусы һәм аның структурасы моны эшләргә мөмкинлек бирде. Джозеф Вернар Рид ул вакытта безнең республикадагы үзгәрешләрне күреп яхшы мәгънәдә сокланган иде.

**— Россия Фәннәр академиясенең бюджет оешмасы булуы мәгълүм. Ул Россия салым түләүчеләре хисабына очын очка ялгап яши. Сезгә туры һәм анык сорау: Халыкара мәгълүматлаштыру академиясе нинди акчага яши һәм эшли?**

— Дәүләтнең Милли академияләре электән үк билгеле бер чикләүләр эченә куелган. Алар бюджет хисабына яши. Академиклар стипендияләрне салым түләүчеләр хисабына ала.

Җәмгыятебез, гамәлдә, базар шартларында яшәү сәбәпле фән үз чыгымнарын үзе каплауга сәләтле булырга, ягъни үз эшчәнлеге хисабына финансланырга тиеш. Әйтергә кирәк, Россия Фәннәр академиясе кебек академия дөньяның башка бер генә илендә дә юк. Чит илдә алар барысы да үз чыгымнарын үзләре каплый. Бу илләрнең хөкүмәтләре килешү нигезендә фундаменталь темаларны эшләү һәм тикшерүгә билгеле бер заказлар бирә һәм аларга тиешенчә түли. Әгәр дә хөкүмәт заказлары юк икән, бу академияләр яшәп калу өчен темаларны һәм эш кырын үзләренчә сайлап алырга хокуклы.

Халыкара мәгълүматлаштыру академиясе — чит ил академияләре үрнәгендә төзелгән беренче академия ул. ХМАнең барлык структуралары да үз чыгымнарыңны үзең каплау принцибы нигезендә мөстәкыйль рәвештә финанслана. Әгәр дә тикшеренүләр һәм эшләнмәләргә сорау булса, җәмгыять алар өчен түләргә тиеш. Сорау булмаган очракта бюджеттан салым түләүчеләрнең акчасын көтеп яту — мәгънәсезлек ул. Халык хуҗалыгының кайбер тармаклары, завод-фабрикалар үз ихтыяҗлары буенча безгә тикшеренүләр, эшләнмәләр өчен заказ бирәләр һәм үз акчалары белән исәп-хисап ясыйлар. Салым түләүчеләрнеке белән түгел. Кыска итеп әйткәндә, ХМА «Тәкъдим — сорау — тәкъдим» принцибы буенча эшли.

Бүгенге көндә бик күп фәнни-тикшеренү институтлары һәм Россия Фәннәр академиясе фәнни учреждениеләренең күпчелеге ябылуга дучар ителеп килә. Күп очракларда бу хәл үзен аклый да: кеше

аркасына яшеренеп ятучыларны үрчетү кирәкми. Кирәкле тематикалар буенча бик мөһим фундаменталь тикшеренүләр һәм эшләнмәләргә исә дәүләт акча таба.

ХМАнең башка төрле акча эшләү ысулы да бар. Безнең академиядә әгъза-корреспондентлар һәм хакыйкый әгъзалар сайлап алуда конкурс системасы эшләп килә. Конкурста катнашучылар билгеле бер күләмдә акча кертә.

**— ХМА һәм Татарстан Фәннәр академиясе арасындагы үзара мөнәсәбәтләр нинди?**

— Мөнәсәбәтләр бик яхшы. Бездә Халыкара мәгълүматлаштыру академиясе төзелгәндә Татарстан Республика Фәннәр академиясе аны оештыручылардан берсе булды. ХМАне аякка бастыруда ТР Фәннәр академиясе президенты Мансур Хәсән улы Хәсәнов зур ярдәм итте. Ул, сүз уңаенда әйтеп китик, ХМАнең академигы булып тора.

ХМА үз эшчәнлегендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе тулыландырып бетерә алмаган бушлыкны биләп алды. Без барыннан да элек мәгълүматлаштыру, инвестицияләр салу проблемалары, фәнни тикшеренүләр, эзләнүләр, зур төгәллеккә ия булган, ашыгыч мәгълүматлар кабул итү, аларны безнең республика һәм башка төбәкләр производствосына урнаштыру белән шөгыльләнәбез.

ХМА һәм Татарстан Фәннәр академиясе — көндәшләр түгел, ә бәлки бер-берсен тулыландырып торучы фәнни үзәкләр. ТР Фәннәр академиясе нефть битумнарын чыгару һәм аларны куллану буенча халыкара конференция үткәргәндә, Халыкара мәгълүматлаштыру академиясе инвесторлар эзләп тапты. Нәтиҗәдә, елына 500 мең тонна чамасы нефть битумы сату буенча контрактка кул куелды.

**— ХМАдә фәнни кадрлар әзерләү концепциясе нинди?**

— Фәнни кадрлар әзерләүдә соңгы, иң югары баскыч булып Халыкара мәгълүматлаштыру академиясенең әгъза-корреспондентларын, хакыйкый әгъзаларын әзерләү, конкурс аша сайлап алу һәм аларны раслау тора. Бүгенге көндә ТР Халыкара мәгълүматлаштыру академиясенең 89 хакыйкый әгъзасы (академиклары) һәм әгъза-корреспондентлары бар.

Алар арасында Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиев, Россия Федерациясенең Европа берлекләрендәге даими вәкиле В.Н.Лихачев, ТР Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х.Мөхәммәтшин, күренекле хәрби конструктор М.Т.Калашников, Татарстан Фәннәр Академиясе президенты М.Х.Хәсәнов, Казан технология университеты ректоры С.Г.Дьяконов, КДУ ректоры Ю.Г.Коноплев бар. Академиянең гыйльми секретаре — Казан Икътисад институты ректоры Н.Г.Хәйруллин. Ул шулай ук Татарстан Республикасының ректорлар советы рәисе дә әле.

БМОның Генераль секретаре Кофи Аннан, РФ Премьер-министры Е.М.Примаков, Казахстан президенты Нурсолтан Назарбаев, Кыргызстан президенты Әскар Акаев, күп кенә ерак чит илләрнең җитәкчеләре шулай ук ХМА академигы исемен йөртәләр.

**— Халыкара мәгълүматлаштыру академиясенә хакыйкый әгъза итеп раслаганда конкурс комиссиясе әгъзаларын Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиев хезмәтләре бик нык кызыксындырган, дип ишеткән идем...**

— Минтимер Шәрип улы Шәймиевнең кандидатурасы бертавыштан үтте. Аның эше, чынлап та, гадәти түгел иде. ХМАнең кәрәз системалы эшчәнлегенә бәйсез рәвештә, ул барлык дәрәҗәдәге җәмгыяви-сәяси тормышта һәм халык хуҗалыгы тармакларында Татарстан Республикасы белән идарә итүнең кәрәз системасын тәкъдим итте.

**— Матбугатта Казанда Халыкара мәгълүмати-экология парламенты оешу хакындагы хәбәрләр күренгәләде. Бу нинди оешма?**

— Әйе, 1999 елда БМО, безнең академия исәп-хисапларына нигезләнеп, Казан шәһәрендә Халыкара мәгълүмати-экология парламенты төзү турындагы карар кабул итте. Бу моңарчы күрелмәгән очрак булды. Хәзерге вакытта әлеге парламент Европа Советының консультатив әгъзасы статусын алды. Күптән түгел ХМА штаб-квартирасы Казанда булган Халыкара мәгълүмати-экология парламентын БМОның ассоциация әгъзасы итеп кабул итү турында тәкъдим белән чыкты. Шул чакта Казан парламентының статусын тулысынча халыкара дип әйтеп булачак.

*Июнь, 2000 ел.*

## Язмыш йөртә татарны

### УНИКЕ ЙОЛДЫЗ ҺӘМ ӨЧ УК

Әлеге җир — диндәшләребез адыгларның җире — мине һәрвакыт үзенең әкияттәгедәй матурлыгы белән сокландырды һәм тетрәндерде. Адыгея Республикасының төньяк өлеше — иксез-чиксез бодай, шикәр чөгендере, көнбагыш, кукуруз басулары белән Кубань тигезлегенең дәвамы булса, көньяк өлеше — кеше кулы тимәгән урманнары белән Зур Кавказ таулары һәм тау итәкләре.

Җәйге кояшлы көндә республика башкаласы Майкоп тирәсеннән зәңгәрсу төтен арасыннан ак карлардан папахалар кигән Кавказ таулары күренеп тора. Әлеге урыннардан илле чакрым чамасы ераклыкта, тау астында, дөньяда иң зәңгәр Кара диңгез җәелеп ята.

Ходай бүләк иткән зөбәрҗәт анда яшәүче халыкларга беркайчан да бәхет китермәгән диярлек. Ике тегермән ташы — Төркия белән Россия империясе арасындагы бу край, гомер-гомергә канлы бәрелешләр өчен сәбәп булып хезмәт иткән.

Әлеге әкияти җирләрдә яшәүче адыглар — Төньяк Кавказдагы иң борынгы халыкларның берсе. Адыглар — бүгенге адыгейлар, черкеслар, кабардылар, шулай ук шапсуг, бедуин, абазиннар һ.б.ның ата-бабаларының гомуми исеме. Барлыгы унике кабилә.

Россиядә 1830 елда чыгарылган карта буенча, адыг халыклары Кубань елгасының Азау диңгезенә, Пицундага кадәрге бөтен сул ягын биләгәннәр.

Әйтәсе дә юк: басып алучылар өчен менә дигән тәмле калҗа. Бу җирләрдә рус-кавказ сугышы йөз елдан артык (башка мәгълүматларга караганда, 300 ел) барган. Ахырда күп миллионлаган халык кырып бетерелгән диярлек, исән калганнар башка илләрдә сыену тапкан. Тарихи ватанда адыг кабиләләренең ун процентган кимрәге яшәп калган.

1864 елда император Александр II йөзьеллык сугышта Төньяк Кавказ халыкларын җиңү һәм әлеге җирләрне Россиягә кушу турында Россия империясе манифестын игълан итә.

Шул ук елда исән калган унике адыг кабиләсе башлыклары хәзерге Красная Полянадан ерак түгел очрашу оештыралар һәм анда бертигез зурлыктагы унике йолдызны һәм кисештерелгән өч уклы символиканы раслыйлар.

Гомуммилли әләмдәге тигез зурлыктагы унике йолдыз адыг-черкес берлеген оештыручы унике кабиләне гәүдәләндерергә тиеш була. Халык идеалын сурәтләүче символика итеп дошманнарны, аларның җирләренә һәм һавадагы, судагы, коры җирдәге ирекләренә кул сузучыларны юк итәргә тиешле кисештерелгән өч ук сайлап алына. Кабиләләрнең вәкилләре ул чакта туган җирләренә тугрылыкка ант итәләр. Геноцид вакытында кабиләләрнең берсе — убыхлар — бөтенләй юк

ителә. Башка кабиләләрнең зур күпчелеге туган җирләреннән куыла һәм бөтен дөньяга таратыла. Бүген адыглар 45 илдә яши. Аларның күпчелеге Төркиядә, төрле чыганакларга караганда, аларның андагы саны 2 дән 3 миллионга кадәр җитә. 10 — 100 мең чамасы булып, бергәләп, адыглар Иорданиядә, Сүрия, Мисыр, Согуд Гарәбстаны, Пакистан, Ирак, Иран, АКШ, Германия, Голландиядә яшиләр.

Иорданиядә, мәсәлән, король гвардиясе тулысынча адыг-черкеслардан тора.

Геноцидның коточкыч фаҗигаләрен кичергән адыглар, тарихи ватаннарыннан еракта яшәсәләр дә, үз телләрен, мәдәният, гореф-гадәт, этикетларын саклап калганнар.

Адыгларның кайбер кабиләләре бүген дә, чит җирдә яшәп, геноцидка дучар ителәләр. Болар — Босния мөселманнары — босняклар — йөз елдан артык элек туган Кавказ җирләреннән куылган адыг-шапсугларның токымнары.

Адыг-шапсугларның күпләп күчеп килү авырлыгына түзә алмыйча, Төркия хөкүмәте 250 мең адыг-шапсугны Балканга күчерә. Әмма Балкан сугышында (1877—1878 еллар) шапсугларның яртысы һәлак була, бер өлеше кире Төркиягә кайта, 50 мең кеше Боснидә кала. «Босния мөселманнары»ның төп умыртка сөяге менә шулардан тора да инде. Әлеге халык унбишенче гасырдан ук мөселман була. Броз Тито аларның милләтчелеген бетерә, «адыг-шапсуг» яки «боснак» этносын юкка чыгара һәм, бик гади генә итеп, Босния мөселманнары дип атый. Күргәнебезчә, тарих бернәрсәгә дә өйрәтми. Бүген Балканда 130 ел элек чәчелгән орлыкларның җимешен җыялар.

Адыгея үзе исә, йомшак тире корып тартылгандай, 1922 елда Краснодар составында автономияле өлкә, ә 1991 елның сентябрендә Россиянең мөстәкыйль субъекты була һәм Адыгея Республикасы дип атала.

Укучылар сизми калмагандыр: адыг һәм татарларның — элек һәм хәзер дә туган җирләреннән себерелгән, «тынычлык сөюче күршеләр»нең империалистик тыкшынулары давылы тарафыннан куылган, күп хәсрәт-газаплар күргән халыкларның язмышында уртак нәрсәләр күп.

## ҮЗ-ҮЗЛӘРЕН САКЛАУГА ЫШАНЫЧ

Татарларның төп өлешен игелекле адыг төбәкләренә Октябрь революциясе җилләре, аннары Идел һәм Чулман буйларындагы көчләп күмәкләштерү давыллары китереп ташлаган.

Гражданнар сугышының ачлык елларында, иген уңмаудан, ачлык, үлемнән качарга тырышып, Идел буендагы күп кенә татарлар әлеге кояшлы төбәккә килеп урнашкан.

Татарларның икенче төркеме утыз беренче елда килгән. Күмәкләштерүдән, үз диннәренә тугрылыклы булган, ирекле хезмәткә омтылган өчен Сталин лагерьларына озатылудан — большевиклар геноцидыннан котылырга тырышып, качак татарлар Пенза өлкәсеннән киләләр һәм Киров исемендәге хутор оештыралар. Ерак та түгел, «Политот-

дел» дигән хутор барлыкка килә. Аның кешеләре — Татарстаннан, Ульян һәм Саратов өлкәләреннән килгән татарлар.

Бүгенге көндә Адыгея Республикасында 4 мең чамасы татар яши. Авылда яшәүче күпләр Майкопка күчкән. Совет заманнарында бу шәһәрдә һәм аның тирәсендә хәрби частьлар урнашкан булган. Үз срокларын тутыргач, күп кенә татар офицерлары үз гаиләләре белән тау елгасы Белаяның зур булмаган сусаклагычы янындагы гүзәл көньяк шәһәрендә яшәргә калганнар. Майкоп татарлары үз шәһәрләре турында, яратып: «Безнең кечкенә Парижыбыз», — диләр. Чынлап та, шундый уңайлы һәм матур планлаштырылган урамнары, игътибарга лаеклы архитектурасы булган шәһәрләр Россиядә күп түгелдер. Шәһәр Зур Кавказның көнбатыш сыртлары иңкүлегендә урнашкан. Шунлыктан монда йомшак климат.

Һәркайдагыча, мондагы татарлар да заводларда эшлиләр, эшмәкәрлек белән шөгыльләнәләр, үзләренең табиблары, галимнәре бар. Элеккеге хәрбиләр дәүләт учреждениеләрендә, иҗтимагый оешмаларда эшләрен дәвам иттерәләр.

Адыгея Республикасында татарларны әдәплелекләре, хезмәт сөючәнлекләре, чисталыклары, милләтара һәм конфессиональара түземлелекләре өчен хөрмәт итәләр. Ислам динендәге җирле халыклар белән бер үк диндә булу да ярдәм итә моңа.

Адыгея Республикасында «Дуслык» татар мәдәни-иҗтимагый җәмгыяте моннан тугыз ел элек оештырылган. Күп еллар буе аны республикада хөрмәтле кеше, юрист Валерий Габдрафиков җитәкләгән. Хәзер бу эшне Казанда ГИДУВ тәмамлаган табиб Алям Ильясов дәвам иттерә. Җәмгыять өчен ул бик күп эшләгән.

Майкопта шимбә һәм якшәмбе көннәрендә татар мәктәбе уңышлы эшли, хатын-кызлар һәм балалар хорлары оештырылган. А.Ильясов алар өчен үз акчасына милли киемнәр тектергән.

«Дуслык» татар иҗтимагый оешмасы үтенече буенча республикага Татарстан мәдәният хезмәткәрләре еш килә. Казан артистларына биредә иң яхшы концерт һәм театр залларын бирәләр. «Казан» милли мәдәният үзәге хезмәткәрләре Адыгея милли музее өчен татарларның милли киемнәрен алып килгәннәр.

Адыгеяда Сабантуй бәйрәмен уздыру традициягә кереп бара. Узган җәй ул Кошехабль районында үткәрелгән һәм татарлар өчен генә түгел, ә адыглар, әрмән, казах һәм башкалар өчен дә бөтенхалык бәйрәменә әверелгән.

Майкопта мәчет төзегәннәр. Имам вазифасын татар башкара. Мәчеткә адыглар да, ислам динендәге башка халык вәкилләре дә йөри.

## ПОКЛОННАЯ ТАВЫНДАГЫ ИСЕМ

Адыгея республикасының милли музее Майкопның үзәк урамнарының берсендә урнашкан. Экспозицияләр белән танышып йөргәндә, искитмәле мыек иясе бюстына юлыгам. Язуын укыдым да, кем әйтмеш-

ли, телсез калдым! Чокып язылган язуда: «Советлар Союзы Герое Гыйззәтуллин Хамазан Гатауллович» диелгән. Чак кына читтәрәк барлык хөкүмәт бүләкләре һәм хәрби батырлыклары тасвирланган фотопортреты белән витрина тора.

Майкоп үзәгендә заманча йорт диварында мемориаль такта: «Бу йортта Советлар Союзы Герое Гыйззәтуллин Хамазан Гатауллович яши». Әсгат абый Идрисов белән дүртенче катка күтәреләбез. Иркен ярты квартирада безне йорт хуҗабикәсе Әшраф Шакировна һәм Хамазан абый каршылыйлар. Ул озын буйлы, куе чал чәчле, искитмәле мыеклы һәм, еллар үтүгә карамастан, хәрби буй-сынлы. Татар гадәте буенча ике куллап күрешеп, кочаклашабыз.

Әсгат абый шундук «үгезне мөгезеннән» ала һәм йорт хуҗасы турында сөйли башлый:

— Безнең Хамазан Адыгеяда өч Советлар Союзы Героеның берсе. Икесе — рус. Ә ул безнең татар каныннан.

Ә герой үзе елмая, чапаевча чал мыегын хәрбиләрчә сыпырып куя һәм минем сорауларга җавап бирә. Аңа Советлар Союзы Герое исемен бирү фактына җиткәч, әле 1984 елда ук Минскида чыгарылган «Навечно в сердце народном» («Мәңгегә халык күңелендә») дигән кызыл тышлы калын китапны күрсәтә. Әлеге Белоруссия энциклопедиясенең Советлар Союзы Геройларына һәм Дан орденнарының тулы кавалерларына, әлеге югары исемнәрне республиканы немец басып алучыларыннан азат иткән өчен алган кешеләргә багышланган махсус чыгарылышы икән. Белешмәдә сугыш геройлары турында ике мең мәкалә бар, күбесе фотопортретлар белән. Анда безнең герой турында да мәкалә бар...

Х.Гыйззәтуллинның тормыш һәм сугышчан юлын, башкаларныкы кебек үк, җиңел дип булмый. Әнисе иртә үлә. Үги әнисендә чит балалар өчен күңел җылылыгы булмый. Авыл хәерчелектә яши. Шадрин районы ул вакытта әле Чиләбе өлкәсенә керә.

Хамазанны хәрби хезмәткә алгач, кырыгынчы елда, тормыш бөтенләй үзгәрә. Ерак Көнчыгыш чикләрендә хезмәт итә. Җиңү көнен Эльбада өлкән лейтенант дәрәҗәсендә каршылый.

— Без бервакыт хатыным белән Киевтә туристик сәяхәттә булдык, —дип искә ала Хамазан абый. — Ватан сугышы музеена кердек. Украинаны азат итүдә катнашкан Советлар Союзы Геройларының бронзадан коелган исемлеген карыйбыз... Музей хезмәткәре килеп: «Сез үз фамилиягезне эзләмисезме», — дип сорый. «Әйе», — дибез хатыным белән бертавыштан.

Музей хезмәткәре янында торган мәктәп балаларына мөрәҗәгать итте: «Яле, балалар, тиз генә Советлар Союзы Герое Хамазан Гатауллович Гыйззәтулинны табыгыз әле!»

— Монда Гыйззәтуллиннар бишәү! — дип кычкыралар балалар. Кайсыдыр, кычкырып: «Менә ул, менә ул Хамазан Гатауллович!» — дип өстәп куя.

Сугыштан соң герой офицер Польшада, Германия, Грозный, Саха-

линда хезмәт итә. Рота командиры, батальон штабы начальнигы, батальон командиры була. Аннары Майкопка күчерәләр, шушында алтмышынчы елны подполковник дәрәҗәсендә демобилизацияләнә.

Бер тапкыр улларының берсе Мәскәүдән командировкадан кайта һәм керә-керешкә:

— Карагыз әле, нәрсә алып кайттым мин! — дип кычкыра.

Геройның улы Поклонная тавында Советлар Союзы Геройлары фамилияләре язылган стенд фонында фотога төшкән икән, ә анда «Гыйззәтуллин Хамазан Гатауллович» дигән язу аермачык булып күренеп тора.

## БУЛАТ — БАТЫРЛАР ИСЕМЕ

— Әйе, шәп фамилия эләккән миңа, — дип көлә әңгәмәдәшем, Бөек Ватан сугышы батыры, отставкадагы подполковник Абдулла Усман улы Тимер-Булат. — Чөнки бит борын-борыннан «булат» баһадирлар кушаматы булган. Һәм миңа да гомерем буе кирәк чакта каты да, йомшак та, үткен дә булырга туры килде...

Күрәсең, аның Иделнең Саратов ярларында яшәгән ата-бабалары ук әле булат тимер белән эш иткәннәрдер. Ә әти-әниләре, Идел буендагы ач үлемнән котылырга тырышып, революциянең беренче елларында бер телем икмәк һәм җылы эзләп Майкопка килгәннәр. Гади эш кешеләре була алар. Чит җирләрдә үлемнән аларны хезмәт коткарып кала. Ачлыгы белән билгеле булган егерме беренче елда шушында Абдулла туа. Укый-яза белмәгән әти-әниләре балаларына белем бирергә тырыша. Абдулла сугыш алдыннан Ростов тимер юл транспорты инженерлары институтына укырга керә. Әмма инженер булырга язмаган аңа. Киләчәктә сугыш тимере белән эш итәргә туры килә. Аларның группасын бернинди кисәтүсез-нисез Бузулук пехота, аннары Куйбышев хәрби-сәяси училищесына күчерәләр. Майкопта татарлар сугышка кадәр аз була. Рус телле мохиттә яшәп, Абдулла туган телен начар белә. Әмма, кем әйтмешли, очрак әфәнде ярдәм итә. Куйбышевта ул шәһәр китапханәсенә йөри, ә анда татар телен бик яхшы белүче татар хатыны эшли.

— Ана телен оныту зур гөнаһ,— ди ул аңа.— Энем, әйдә татарчага өйрәтәм...

Шулай итеп, хәрби училищеда укыган арада Абдулла туган телен дә, кириллицадан тыш, гарәп язуын да үзләштерә.

Училищены тәмамлагач, аны Мәскәүне сакларга җибәрәләр. Биредә ул корал буларак булатның җиңелмәслегенә, сугышчан туганлыкның тимер кебек ныклыгына төшенә.

Яшь офицер Тимер-Булат өч тапкыр яралана. Калинин, Нарва, Великие Луки янындагы, крепость-шәһәр Кенигсбергны алгандагы иң дәһшәтле сугышларда катнаша. Үзенең соңгы сугышын Тимер-Булат Порт-Артур янында үткәрә. Биш орден һәм дистәдән артык медаль белән бүләкләнә.

1954 елда Тимер-Булат хәрби-сәяси академияне уңышлы тәмамлый һәм хезмәтен дәвам иттерергә... туган Майкоп шәһәренә җибәрелә.

## ИДРИСОВ АКАДЕМИЯЛӘРЕ

Майкоптагы «Дуслык» татар иҗтимагый үзәге күпләгән лаеклы кешеләрне берләштерә. Алар арасында доцент, Адыгея дәүләт университеты кафедрасы мөдире Рәшит Фәхретдинов, таулы республикада танылган юрист Валерий Габдрафиков, тәҗрибәле табиб Алям Ильясов һәм башкалар бар. Татар иҗтимагый үзәгенең бүгенге рәисе Алям Ильясов Казанда ГИДУВны тәмамлаган. Безнең башкалада аның дуслары күп.

Болар — Майкоптагы татарларның урта буын вәкилләре.

Якташыбыз, отставкадагы полковник Әсгат Абдулхак улы Идрисов турында аерым сөйлисем килә. Ул «Дуслык» татар мәдәни-агарту җәмгыятенә нигез салучыларның берсе. Дустанә Адыгея Республикасында яшәүче милләттәшләренең милли үзаңын яңартуда актив катнаша.

Әсгат абый 1925 елда Минзәлә районының Шуган авылында туган. Хәзер бу авыл Мөслим районына керә.

Абдулхаклар гаиләсе бу авылда хәллеләрдән санала, ә аннары инде кулаклар дип үк йөртә башлыйлар. Йортлары әйбәт (ишегалдында икенчесе, ярдәмче йорт та бар), өч атлары, берничә сыерлары һәм умарталыклары бар. Бөтен гаилә бал кортлары кебек эшли. «Буржуйлык»-ның иң төп сәбәпчесе сепаратор була. Ул вакытлар өчен ишетелгән нәрсәмени?!

Большевиклар ничек кенә тырышмасын, — «яхшылык белән» дә үгетлиләр, куркытып та карыйлар, уртак казанда оҗмах та вәгъдә итәләр, — Абдулхак Идрисов колхозга керүдән барыбер баш тарта. Моның өчен большевиклар аңа яманаты чыккан Чистай төрмәсендә башка «оҗмах» күрсәтәләр.

Ике айдан соң «кулак» Абдулхакны «бер карарга килү» өчен вакытлыча азат итәләр. Һәм гаилә башлыгы шундый карарга килә: гаиләсен кисәтеп, үзенең ныклы хуҗалыгын, гаиләсен ташлап, Пермь шәһәренә кача.

Күп балалы гаиләне урамга куып чыгарып, большевиклар бөтен мөлкәтне тартып алалар. Авылдашлары сыендыра Идрисовлар гаиләсен. Ә картайган әти-әниләре — крепостной улы, сиксән яшьлек Галиулла бабай һәм Әсгатнең әбисе фаҗигале 1937 елда күрше авылда, чит кешеләрдә үләләр.

1931 елның көзенә таба Абдулхак авылга Пермьнән бөтенләй таныш булмаган бер кешене җибәрә. Гаиләсен алып килү өчен.

— Әле дә хәтеремдә, ач-ялангач, яланаяклы биш бала, әниебез белән ике атна дәвамында пароход койрыгында Чаллыдан Пермьгә кадәр Кама буйлап йөздек. Әлеге ач гаиләне туендырыр өчен әти икмәк заводына эшкә урнашты һәм пычкы чүбе тутырып эшләнгән агач барактан бер бүлмә алды.

Кечкенә бүлмәдә биш бала һәм әти-әни яшәдек. Әти аннары эшкә Пермьнең Мотовилихин районына, артиллерия заводы коммуналь хуҗалыгына күчте. Анда баракта инде безгә ике бүлмә бирделәр. Билгеле булганча, Мотовилихин районында Пермьнең төп оборона заводлары урнашкан була. Ул чакта да, хәзер дә күпчелек татарлар яши торган район бу. Әнием пенсиягә киткәнчегә кадәр шунда эшләде.

— Шулай итеп, державаның оборона сәләтен ныгытуга безнең Минзәлә татарлары гаиләсе зу-у-ур өлеш кертте, — дип көлә Әсгат абый.— Җиде классны тәмамлаганнан соң мин дә шушы артиллерия заводына токарь өйрәнчеге булып кердем. Токарныйның суппортына буем җитми иде әле. Аяк астына күтәртмә куярга туры килде. Кичләрен хәрби-механика техникумына чаба идем.

— Шәп белгеч идем,— дип көлүен дәвам иттерә якташым,— хәтта сугышка да алмадылар.

Әмма хәрби комиссариатка берничә тапкыр мөрәҗәгать иткәннән соң, 1944 елда Әсгат Идрисовны хәрби очучылар әзерли торган авиация-техник училищега җибәрәләр. Аннары истребитель-самолет очучылары әзерләүче Ерак Көнчыгыш хәрби-диңгез училищесына күчерәләр. Аны 1949 елда бик яхшы билгеләренә тәмамлап, Тын океан флотының Сахалин истребительләр полкында хезмәт итә.

Якташымның квартирасында сугыш еллары альбомын карап утырганда, Әсгат Идрисовның әнисе белән төшкән фоторәсемгә игътибар итәм. Чираттагы һәр офицер дәрәҗәсе бирелгән саен, алар истәлеккә фотога төшә торган булганнар. Искитмәле бит — баракта үскән ялааяклы татар малае диңгез авиациясендә хәрби очучы булсын әле! Кызганыч, әтисе, элеккеге «кулак» кына шатлыклы ул көннәргә кадәр яши алмаган. Ул сугышка кадәр үк әлеге «татлы тормыш»тан авырып үлә. Әсгат Абдулхаковичның барлык дүрт кыз туганы да Пермьнең хәрби заводларында эшли.

Табигый сәләт, хезмәт сөю, түземлелек һәм җыйнаклылык нәтиҗәсендә Ә.Идрисовның хәрби карьерасы әйбәт бара. 1960 елда ул хәзер Ю.Гагарин исемен йөрткән хәрби-һава академиясен, ә соңыннан финанс-икътисад институтының читтән торып уку факультетын тәмамлый. Өлкән очучы, звено командиры, эскадрилья штабы начальнигы була.

— Татар офицерларын — хәрби белгечләрне аерым билгеләп үтәсем килә, — ди Әсгат Абдулхакович. — Минем кулдан авиаполкларның күпләгән командирлары узды. Татар хәрби очучыларына сорау һәрвакыт зур булды, чөнки алар ныклы дисциплина, тәртиплелекләре, аеклыклары, төпле белемнәре белән аерылып торалар. Алар бурычка тугрылыклы.

Ә.Идрисов хәрби карьерасын 1975 елда тәмамлый. 15 орден һәм медале бар. Озак еллар Адыгея Республика газетасында журналист булып эшләгән. Әле хәзер дә матбугатта еш чыгыш ясый. Аның материаллары зур кызыксыну тудыра. Ул Казанда татарларның Бөтендөнья конгрессының икенче съездында делегат булып катнашкан.

## ТАТАРСТАН АДЫГЕЯ ӨЧЕН ҮРНӘК БУЛЫП ӘВЕРЕЛДЕ

2001 елның маенда ТР Президенты М.Ш.Шәймиевнең инаугурациясе вакытында Адыгея Республикасы Президенты Аслам Джаримов 1834 елда Казанда басылган Коръән бүләк итте. Аны Косоводан репатриант (кайчандыр сөрелгән җиреннән үз иленә кайтучы) Шәриф Аслания алып кайткан. Аның ата-бабалары кыйммәтле бу китапны Төркия аша алып чыкканнар, аннары 160 елдан артык Балканда саклаганнар.

1998 елда, Балканда этник сугыш кызган чакта,— ә анда Косово мөселман-адыгларын тулысынча кырып бетерү процессы барды, АР җитәкчелеге Косоводан кайткан утыз гаиләне сыендырды. Алар башта тулай торакларда, җайлаштырылган балалар бакчаларында яшәделәр. Соңрак Майкоптан җиде чакрым ераклыкта индивидуаль төзелеш өчен җир кишәрлекләре бүлеп бирделәр. Хәзер анда икешәр катлы коттеджлар үсеп чыккан. Бистә Масохабль дип атала, ул «бәхетле тормыш» дигәнне аңлата.

Шулай итеп, көтмәгәндә генә Изге китап аша татар белән адыгей халыклары арасында тагын бер рухи җеп сузылды.

1998 елда ТР белән АР арасында сәүдә-икътисади хезмәттәшлек турында хөкүмәтара килешү төзелде. Бу исә яңа перспективалар ачты. Шунысын әйтү дә җитә: соңгы ике елда төбәкара сәүдә әйләнеше җиде тапкыр артты. Мәгариф һәм Мәдәният министрлыклары белән элемтәләр урнаштырылды.

Узган елның октябрендә Майкопка ТР Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х.Мөхәммәтшин җитәкчелегендәге Татарстан хөкүмәте делегациясе килде. Фәрит Хәйруллович Адыгея Республикасы җитәкчелеге, «Дуслык» ТИҮ хатын-кызлар ансамбле белән очрашты, җәмгыять рәисе урынбасары Вәлит Рәхмәтуллинда кунакта булды.

Барлык очрашуларда, Татарстан Республикасы Адыгея өчен күп яктан үрнәк булып тора, дип ассызыклап күрсәтелде.

...Бай рухи тормыш белән яшиләр татарлар Адыгея Республикасында. Әлеге оҗмах почмагында үзләренә лаеклы урын тапканнар. Барлык халыклар һәм милләтләр белән искитмәле килешеп көн күрәләр. Матди яктан да әйбәт тәэмин ителгәннәр. Очрашулар вакытында әлеге республикада яшәүче татарлар берләшү һәм үзләренең борынгы милләтен саклау өчен барысын да эшләргә, алдагы халык санын алу вакытында безнең милләтне этник төркемнәргә: мишәр, типтәр, керәшен татары һ.б.га таркатырга тырышучы аерым сәясәтчеләрнең провокацияләренә бирелмәскә тиешләр, дип һәрдаим басым ясап әйтәләр.

«Без — бердәм, куәтле милләт. Без — татарлар!» — диләр язмыш ихтыяры белән Кавказ тавы итәкләренә барып урнашкан ыругдашларыбыз.

## Кемнәр алар татар морзалары?

«Вакыт барын да күрә,
ишетә һәм ачып бирә»
*Софокл*

Язучы гомерендә әллә нинди көтелмәгән сюрпризлар була. Шулай бервакыт Уфада Россия мөселманнарының үзәк Диния нәзарәтенең кабул итү бүлмәсендә илнең баш мөфтие Тәлгать Таҗетдинны көтеп утырабыз. Ул Мәскәүдән кайтып җитәргә тиеш иде. Арабызда урта яшьләрдәге, фырт кына киенгән, кара чәчле бер ир-ат бар. Аның җәйге аяз көндәге күк йөзе шикелле зәп-зәңгәр күзләре минем игътибарны җәлеп итте. Өстендәге заманча тегелешле костюм да, күзләре шикелле үк, зәңгәр.

Кабул итү бүлмәсендә генә була торган киеренкелеккә, тынлыкка нокта куеп, Тәлгать Таҗетдин килеп керде. Зәңгәр күзле ир, тиз генә аның белән татарча нидер сөйләшеп алды да, чыгып та китте.

— Бу кем булды? — дип сорадым мин Тәлгать Таҗетдиннан. Аның гаҗәпләнүе йөзенә үк чыкты.

— Ничек кем? Бу — Риф морза Акчурин. Татар дворяннарының, ягъни Татар морзалары мәҗлесенең җитәкчесе. Штаб-квартиралары монда аларның, Башкортстан башкаласында.

Бу сүзләрдән мин тораташтай катып калдым, бары берникадәр вакыттан соң гына телгә килеп:

— Андый кешеләр дә бармыни ул? Ник монда, Башкортстанда? — дип сорадым.

— Бар, андый кешеләр дә бар,— дип елмайды Тәлгать Таҗетдин. — Үзе белән очрашып сөйләшергә киңәш итәр идем.

Тарихтан укып мин рус дворяннары турында беләм. Бер ун ел элек Россия дворяннары яхшы гына шаулашып алганнар иде. Дворян катлавыннан булган кенәз Голицын, Лопухин, Гагарин, Мусин-Пушкин, Мещерский токымнары яңгырдан соңгы гөмбәләр шикелле баш калкыттылар. Телевизордан күреп, ишетеп белдем: Россия дворяннары җитәкчесе итеп кенәз Андрей Кириллович Голицын сайланган. Бөек княгиня, тәхет варисы Леонида Георгиевнаның Россия империясе дворяннары токымын Россиянең элеккеге данын кайтарырга чакырып мөрәҗәгать итүе турындагы тапшыру әле дә күз алдында тора.

Халыкның күпчелеге моңа чираттагы мәзәк итеп карады. Югары сословие вәкилләрен дә дан-шөһрәт яратучы мактанчыклар, шарлатаннар дип кабул итте. Алай гына да түгел, казаклар белән беррәттән яңа «туган» дворяннарга да «шамакай» дип исем тактылар.

Берничә ел үткәч ачыкланды: казакларның да, дворяннарның да тирән тарихи тамырлары бар икән. Социализм чорында аны бик оста итеп халыктан яшергәннәр. Ә татар дворяннары — морзалар турында Совет кешеләренең ишеткәне дә сирәк булгандыр.

Сизеп торам, минем кадерле укучыларым, милләттәшләремнең татар морзалары, бәкләре һәм кенәзләренә карашлары төрле. Тискәре фикердәгеләре дә җитәрлек. Әмма ничек кенә булмасын, ул безнең тарих, татар тарихы. Аллаһы Тәгалә аны ничек яраткан, заман җилләре ничек үзгәрткән булса — без аны шулай белергә тиешбез. «Тарихын, ыру-нәселен белмәгән адәм хайванга тиң», дип борынгылар бик дөрес әйткән.

Татар дворяннары темасы күңелемә шулкадәр тирән керде ки, мин архивларда, фондларда төрле эзләнүләр үткәрдем, бу катлауның исән вәкилләре белән очрашып сөйләштем.

Татар морзалары мәҗлесен 1992 елда Уфада Сәид Хәнәфи улы Еникеев оештырган. Ул үзе данлыклы һәм борынгы кенәзләр нәселеннән. 1919 нчы елгы. Бик укымышлы, интеллигент кеше иде. «Иде» дим, чөнки Сәид Еникеев 1997 елның февраль аенда вафат булды.Сәид Хәнәфи улы әтисенең, бабасының үз нәселләре турында горурланып сөйләгәннәрен яхшы хәтерли иде. Татар халкы тарихының бу өлеше турында сөйләрлек заман җитүен гомер буе көтте ул.

Россия һәм чит илләрдә йөреп, татар морзалары турында бай материал җыйды. Аның 30 еллык хезмәтенә йомгак булып, «Татар дворяннары тарихыннан очерклар» исемле китабы чыкты.

1996 елның сентябрендә Уфада патшабикә Екатерина Икенченең татар кенәзләре, морза һәм бәкләрен Россия дворянлыгына кертү турында Указының юбилеен билгеләп үттеләр. Анда Россия дворяннары Советы да катнашты. Бу җыенда Татар морзалары Мәҗлесе җитәкчесе итеп Риф Үзбәк улы Акчурин сайланды. Ул Акчуриннар нәселе вәкиле. Бу нәсел тамыры белән Алтын Урданың танылган ханы Бехан Акчурага барып тоташа. Патша хөкүмәте татар дворяннарын кысрыклый башлагач, морзаларның беришләре Башкортстанга күчеп китә, икенчеләре хәзерге Пенза җирлегендә кала. Бу турыда архив материалларында язылган.

Риф морза Акчурин 1957 елда Башкортстанның Стәрлетамак шәһәрендә туган. Монда ул төзүчеләр техникумын тәмамлаган. Соңыннан Уфа нефть институтында белем алган. Аны шушы ук институтта кече фәнни хезмәткәр итеп гыйльми эшкә калдырганнар.

Хәзер ул Россия Федерациясенең Дәүләт Думасы депутатының ярдәмчесе. Морзалар җитәкчесе булуы татар тарихын саклау өчен иҗтимагый башлангычтагы хезмәте.

Риф Акчуринны кабул итү бүлмәсендә беренче тапкыр күргәннән соң, без аның белән берничә мәртәбә очраштык. Казанда, Бөтендөнья татарлар конгрессында да бергә булдык. Үземә бирелгән теманы башлар өчен, ниһаять, әңгәмәдәшем белән бер өстәл артына утырдык.

**— Кадерле милләттәшем! Сезгә ничек мөрәҗәгать итим. Риф Үзбәкович, Риф морза Акчурин, кенәз Риф Акчурин димме, әллә Риф әфәнде дияргәме?**

— Руслар ни диләр әле, чүлмәк дисәң дә ярый, тик мичкә генә тыкма, диләрме? Үзегезгә ничек ошый, ничек җайлы, шулай дәшегез. Ничек әйтсәгез дә үпкәләмәм.

**— Бик яхшы! Риф морза, татар дворяннары каян хасил булган? Кенәз, морза, бәк дигән титуллар татарларда ничек барлыкка килгән?**

— Моңа ачыклык кертү өчен тарихка кечкенә генә сәяхәт ясап алырга кирәк булыр. Пензада соңгы бер-ике елда табылган архив документларына караганда, хәзерге Мордовия республикасы, Пенза, Рязань, Тамбов, Нижгород һәм Ульяновск өлкәләре җирләрен Чыңгызхан токымнары яулап алгач, Алтын Урдага караган кече дәүләт оештыралар. Ул Темников кенәзлеге дип атала.

1243 елда Алтын Урда оешкач, Темников кенәзлегеннән мордва-мишәр феодаллары Батый ханга хезмәт итә башлыйлар.

1289 елда татар бәге Сәет-Әхмәт ясак җыю өчен хәзерге Мордовия өлкәсенең Темниково һәм Краснослободский районнары җирлегенә килә һәм монда төпләнә. Сәет-Әхмәт нәселе артканнан-арта бара. Акчуриннар, Еникеевлар, Кудашевлар, Кугушевлар, Тенишевлар, Чанышевлар шушы нәсел тармаклары.

Пензада яшәүче тарихчы Вадим Первушкин фикеренчә, Алтын Урдадагы «морза» руслардагы кенәз сүзен аңлата. Бары тик Чыңгызхан нәселеннән булучылар гына морза булалар.

Соңгы вакытта кайбер мөселман илләрендә киң таралган һәм хөрмәтләү мәгънәсенә ия булган «морза» сүзеннән аермалы буларак, титул атамасындагы «морза» сүзе ялгызлык исеменнән соң куела. Темников Мещерасы кенәзлек булып, 1360 елдан XVI гасырның беренче чирегенә кадәр яши. Монда чит милләттәге кенәзләрне морзалар дип йөртәләр.

Төрек-монгол феодалларында, шул исәптән, Алтын Урда суперэтносына кергән Мәскәү кенәзлегендә дә морза иң югары статус булып тора. Ул Идел һәм Кама буе халыкларындагы морза титулыннан күпкә дәрәҗәлерәк. Моны раслау өчен, тарихтан бер-ике факт китерү дә җитә.

Беренче факт. XIV—XV гасырның данлыклы гаскәр башлыклары Мамай һәм Тимурга морза булмаганга күрә, хан титулы бирелмәгән. Алар Чыңгызханның хатын-кыз кардәшләре ягыннан туган. Ә бу тәхеткә хуҗа булу мөмкинлегеннән мәхрүм итә.

Икенче факт. 1550 елда Иоанн IVгә патша титулы бирелә. Бу титулны алганда, аның әнисе ягыннан Чыңгызхан кардәше икәнлеге дә зур роль уйный.

**— Гафу итегез, кенәз Риф, сүзегезне бүлдерәм. Тарихтан һәркайсыбыз яхшы белә: 1380 елның 8 сентябрендә Куликово кырында зур сугыш була. Елъязмаларның берсеннән укыган идем: Дмитрий Донской гаскәрләрендә күп кенә рус кенәзлекләре, украин, белорус отрядлары һәм... Мещера крае, ягъни Темников кенәзлеге вәкилләре дә Мамайга каршы сугышканнар. Бу бит сезнең бабаларыгыз, төп дәүләтләрен — Алтын Урданы җимерү өчен көрәшкәннәр дигән сүз?..**

— Шулай килеп чыга шул. Безнең бабайларыбызның Мамай гаскәрләренә каршы сугышулары турында тарихны буыннан буынга сөйләп килделәр. Әмма бу вакытта Мамай гаскәре белән Алтын Урдадан аерылып чыга һәм Иделнең уң ягындагы Сарытау шәһәренә (хәзерге Саратовка) килеп төпләнә. Узган елларда алып барылган тикшеренүләр дә моны раслый. Тарихи чагыштыру ясасак, Мамай гаскәрләре узган

сугышта Власов Армиясе хәлендә була. Темников кенәзлеге вәкилләре Алтын Урданы таркатырга маташучы Мамайга каршы көрәшкән булып чыга. Бабаларымның хәлен мин бик яхшы аңлыйм: алар бу сугышта Русь мәнфәгатьләрен дә, Алтын Урда мәнфәгатьләрен дә якларга мәҗбүр булганнар.

Темников морзаларының күбесе чыгышлары белән монголлар була. Темников Мещерасының барлык кенәз фамилияләре дә Бехан Акчурага барып тоташа. «Россия империясенең Дворян ыруглары» китабының III нче томын әзерләгәндә алып барылган тикшеренүләр күрсәткәнчә, бу нәсел вәкилләре татар морзалары арасында киң таралган. Бүген алар Россия, АКШ, Төркия, Кытай, Урта Азия, Япония һәм Австралиядә яшиләр.

Илнең беренче башкаласы Сараклыч шәһәре була. Рус Православие чиркәве бу шәһәр урынына XVIII гасыр башында Саров монастырен оештыра. (Хәзер Саров шәһәре — Арзамас-16, Россия Федерациясенең иң эре атом үзәге.)

Монастырь өчен җирне Бехан токымыннан булган стольник, кенәз Д.Кугушев бүләк итеп бирә. Дошманнарның еш һөҗүм итүләреннән саклар өчен Бехан Акчура 1388 — 1389 елларда башкаланы Каньгуш дигән борынгы шәһәргә күчерә. (Хәзерге Мордовия республикасы, Ельников районы Каньгуши авылы.)

XVII гасыр башында Россия дәүләте составына кергәнче Темников Мещерасында Бехан нәселе алдынгылыкны тота. Алар җитәкчелек итү белән шөгыльләнәләр һәм Мәскәүнең рәсми документларында һәрвакыт кенәзләр булып саналалар. Беханныкыларның иң атаклысы — кенәз Еникей, Темников воеводасы. Ул 1552 елда Казанны һәм ханлыкны алганда татар, мордва морзалары белән идарә итә.

**— Әйе, Риф морза, без татар тарихының иң четерекле мәсьәләләренә кагылдык. Тарихи чыганакларда Иван Грозный гаскәрләренең өчтән берен (кайберләрендә — яртысын) Мещера татарлары тәшкил иткән дип язылган. Димәк, үзләренең бәк, кенәз һәм морза титулларын саклап калу өчен, алар Казан ханлыгында яшәүче ватандашларына каршы яуга чыкканнар була түгелме?**

— Әйе, уртак тарихыбызның мондый сәхифәләре дә булган. Әмма менә нәрсәне онытырга ярамый: Казан ханлыгын басып алганда, Мещера татарлары Россия державасына хәрби яктан да, икътисади яктан да нык бәйле була.

Тагын бер тарихи факт. Казанны яулаганда Мещера ягы татарлары бәк, кенәз һәм морзалар җитәкчелегендә хәрби операцияләрдә артык катнашмыйлар.

**— Риф Үзбәкович, әйдәгез әле, Темников дәүләте турында әңгәмәбезгә кире кайтыйк...**

Беханныкылар Темниковта 1570 елларга кадәр идарә итәләр. Темников Мещерасы XVI гасырның соңгы чирегендә гомум Россия составына кертелә. Бехан нәселе крайда хакимлекне югалтмый. Еникейдан соң Мәскәү хөкүмәте воевода итеп рус кешесен билгели. Бер сүз белән генә әйткәндә «процесс башлана». Аның ахыры исә болай була: Темниковтагы

рус воеводаларына ярдәмче итеп Бехан нәселе вәкилләрен билгеләүне туктаталар. Гомуми рус коллыгы һәм христиан диненә күчү монгол чыгышыннан булган морзаларның барлык өстенлекләрен дә бетерә.

**«Мавр эшен эшләде. Маврның башка кирәге юк», дигән шикелле килеп чыга түгелме соң бу?**

— Шулай дип аңлатырга да мөмкин. Романовлар патшалык иткән чорда кенәз титулы әтиләре кенәз булганнарга гына бирелә. Бу титулга бик сирәк очракта гына хәрби хезмәттә танылучылар да ия була.

XVII гасырда Алексей Михайлович патшалык иткән чорда Православие динен кабул иткән морзалар гына кенәз булып санала.

1680—1690 елларда чукындырылган морзаларга «стольник» чины бирелә һәм алар аерым исемлек белән Боярлар кенәгәсенә кертелә. Ләкин «стольник» булу өчен морзаларның православие динендә булуы гына җитми, аларның ничек эш күрсәтүе дә бик мөһим санала. Мәсәлән, морза Боһдановлар чукыналар, әмма аларга «стольник» чины да, кенәз титулы да бирелми. Шулай да XVII йөз ахырында мөселман динендә калып та, нык эш күрсәткән морзаларга кенәз титулы бирү очраклары булган. Мәсәлән, кенәз Моратовлар.

Чукындырылып та кенәз була алмаганнар, башта «морза» исеменнән мәхрүм калалар. Аларны яңа керәшеннәр дип йөртә башлыйлар. Яңа керәшеннәрнең балалары борынгы Россия дворяннары белән кушылып, туганлашып бетәләр. Аларның морза икәнлеген хәтта фамилияләреннән дә белеп булмый.

**— Риф Үзбәкович! Хәтеремә бер морзаның Россиядәге тормышны сурәтләп, «урлашалар» дигәне килеп төште. Сүз тарихчы Николай Михайлович Карамзин турында бара. Ул Парижга үзенең якын дусты Петр Яковлевич Чаадаевка кунакка килә. Чаадаев Россия тормышы белән бик кызыксына. Карамзин: «Урлашалар, атакай», дип җавап бирә. Минем кайбер танылган шәхесләрнең килеп чыгышы, нәсел тамырлары турында сорашасым килә иде.**

— Әйе, күп кенә танылган рус язучылары, философлар, гаскәр башлыклары татар морзалары нәселеннән. Мәсәлән Чаадаев, Чегодаевлар Алтын Урда ханы Чегодай токымы. Аларның имениесе Теше елгасы янына урнашкан була. Алардан ерак та түгел кенәз Юсуповлар, Щербатовлар, Татищевлар, Кутуевлар һәм Николай Михайлович Карамзиннарның нәсел тамыры — Кара-Морза яшәгән.

Мещера краенда яшәгән морза, кенәзләрнең кайсына гына карасаң да данлыклы шәхесләр. Мәсәлән, рус флотының танылган җитәкчесе, адмирал Федор Федорович Ушаков шулай ук татар морзалары нәселеннән. Аның бабасы Ушак морза Мокша һәм Цна елгалары кушылган урында гомер иткән. Соңыннан аларның имениесе Мордовиянең Лямбирь авылында була.

Татар морзаларының данлы фамилияләре бик күп. Мәсәлән: Кутузов, Суворов, Ермолов, Менделеев, Тургенев, Куприн һ.б.

**— Риф морза, әңгәмәбезнең тарихи өлешеннән читкә тайпылганчы, шуны да сорыйм әле: ранглар буенча кайсы югарырак: морзамы әллә кенәзме?**

— Морзалар шул ук кенәзләр инде алар. Әмма Россия империясенең дворян ыругларындагы иерархия буенча кенәз морзадан өстенрәк санала.

Княжна — кенәз ыруыннан булган, никахта тормаган кыз. Морза һәм кенәзләр нәселендәге хатын-кыз кияүгә чыккач, княжна титулын югалта. Княжна — кенәзнең хәләл җефете. Иреннән аерылган очракта княжня да үзенең титулын югалта.

Сез әйткәндәй, әңгәмәнең тарихи өлешеннән читләшкәнче, менә нәрсәне ассызыклап үтәсем килә. Без, татар дворяннары, балаларыбыз турында тарихи документларны саклап калучыларга бик рәхмәтле. Алар Санкт-Петербург фондларында сакланган. Пенза шәһәрендә яшәүче яшь тарихчы Вадим Первушкин бик кыйммәтле мәгълүматлар тапты. Түбән Новгород архивында университет профессоры Валерий Павлович Марихинның Мещера ягы бәк, кенәз һәм морзаларның яшәү урыны төшергән карта саклана.

**— Риф морза, бүгенге Россия матбугатында «яңа русларның» кенәз, Россия дворяннары җәмгыяте члены булуы (дөресрәге бу исемне сатып алуы) турында хәбәрләр күренә. «Яңа татарлар» морза һәм кенәз була алалармы?**

— Һәркем үзенчә акылдан шаша дигәндәй, яңа руслар да үзләренчә юләрләнә. Англиянең «Санди таймс» газетасы язуынча, Россиянең калын кесәле байлары «лорд» исемен ала башлаганнар. Бу исемнең бәясе инглизләр өчен күп түгел — лорд булу — нибары 200 мең фунт тора.

Татарларда бу нәрсә булмады һәм булачагы да юк. Татар дворянлыгы нәселдән нәселгә генә күчә. Яхшымы бу, әллә начармы — монысына без, әлбәттә, бәя бирә алмыйбыз.

**— Нинди үкенеч, берәр кенәз яки морза булып булмасмы,— дигән идем.**

— Көлмәгез, көлмәгез. Татар аристократиясе шундый мәсхәрәләнде, мохтаҗлыклар кичерде. Аллаһы Тәгалә моны берәүгә дә күрсәтмәсен! Татарларның югары катлаулары һәрвакыт Россия власте белән чәкәләшеп яшәде. Петр I нең 1713 елның 3 ноябрендә кабул иткән Указыннан соң кенәз һәм морзаларның хәле катастрофик чиккә җитте. Бу Указ нигезендә барлык мөселман феодаллары ярты ел эчендә православие диненә күчеп бетәргә тиеш була, Указга буйсынмаучыларның милке конфискацияләнә, имениеләре алына, аларны кенәз һәм морза исемнәреннән мәхрүм итәләр. Байлык һәм титулларыннан коры калган мөселман морзаларын җан башыннан түләнә торган окладка күчерәләр, күбесе гади крестьянга әйләнә.

Петр Указына буйсынып чукынучы татар морзалары фамилияләрен русчага үзгәртәләр, рус исемнәре алалар. Шул юл белән үзләренең милкен саклап калалар. Аларга Дон, Хопер елгалары буендагы җирләрне бүлеп бирәләр. Без алда санап үткән татар морзалары фамилияләренең тарихы шулай.

Татар морзалары һәм кенәзләренең күбесе чукындырудан баш тарта. Аларның титулларын, имение һәм җирләрен тартып алалар, үзләрен лашман итеп, урман кисәргә җибәрәләр. «Лашман» сүзе «урман кешесе» дигән мәгънәгә ия.

Петр I нченең Каспий флотына корабльләр төзү өчен Казанда адмиралтейство оештыру турында Указы Казан ханлыгы һәм Мещера татарларының тормышын кискен үзгәртә. Лашманлыкның бар авырлыгы алар җилкәсенә төшә. Урман кисү һәм Казан адмиралтействосына сал җибәрү өчен 15 тән 60 яшькә кадәрле ир-егетләрне алалар. Урман эшендә кешеләр ачлыктан, суыктан, төрле имгәнүләрдән кырылалар гына. Лашманчылар землянкаларда яшиләр. Хөкүмәт аларга сукыр тиен дә түләми. Бары тик 1757 елдан — Батырша восстаниесеннән соң әз-мәз генә түли башлыйлар.

Татар халык җыры «Кара урман»ны лашманчылар шул җәһәннәмгә тиң елларда иҗат иткәннәр.

Тагын бер кызыклы факт: күп кенә морза һәм кенәзләр лашманчылар, крестьяннар булсалар да, үз титулларын югалту белән килешмиләр. «Бу исемне сез безгә бирмәдегез һәм аннан мәхрүм дә итә алмассыз», — диләр алар Үзәк Россия хөкүмәтенә.

**— Риф морза, Темников дәүләт кенәзлеге кайчан Россия дәүләтенә керә?**

— Моның төгәл вакыты әлегәчә билгеле түгел. Күптән түгел — җитмешенче елларда да — Казан ханлыгы бетерелгәнче Пенза өлкәсе Россия дәүләтенә кергән дигән фараз яши иде. Ә хәзер Темников Мещерасы, шул исәптән Пенза өлкәсе территориясе дә Россия составына 1480 елда кертелгән диләр.

**— Риф әфәнде, Мещера ягы кенәз һәм морзаларның нәселе, нигездә, Башкортстан җиренә килеп тупланган. Ничек шулай килеп чыкты соң? Аларның күченүе кайчан булды?**

— Бу процесс лашманлык чорында, ягъни 1713 елның 3 ноябрендә Петр I Указын кабул иткәч башлана. Чукынырга теләмәгән морза һәм кенәзләр башкорт җирләренә күченеп киләләр. Бу күченү гасыр ахырына кадәр дәвам итә һәм бары тик 1796 елның 15 маенда Екатерина Икенче татар морзалары һәм кенәзләре турында Указ кабул иткәч кенә туктый.

Башкортстанга күчеп килгән татар морзалары һәм кенәзләре монда үзләренең икенче ватаннарын таптылар.

Менә шуңа күрә дә татар морзалары Мәҗлесенең һәр утырышы, тантанасы башкорт халкына рәхмәт сүзләре белән башлана. Без үзебезне сыендырган бу кардәш халыкка бары изгелек кенә телибез.

**— Риф Үзбәкович, Екатерина Икенче Указы турында тулырак сөйләсәгез иде.**

— Татар һәм башкортларда танылган «Әби патша юллары» дигән җыр бар. Халык аны бик яратып җырлый. Уйланганыгыз бармы, ни өчен икән?

Татар халкы Екатерина Икенчене яратып, «әби патша» дип йөрткән. Тарихта язылганча, ул мөселман татарларга карата бик шәфкатьле булган. Яңа керәшен конторaларын бетереп, мәчет һәм мәдрәсәләр төзергә рөхсәт бирә. Гомумән, татар дворяннарының дәрәҗәсен күтәрү өчен тырыша.

Екатерина II нче хакимлек иткән чорда Россия мөселманнарының җыены оештырыла. Аның үзәге итеп Оренбург шәһәре сайлана. Соңыннан ул Россия мөселманнарының Диния нәзарәте дип үзгәртелә һәм Уфа шәһәренә күчерелә.

Шул чорда кабул ителгән кайбер документлардан өзекләр китерәсем килә.

**Императрица Екатерина II нең 1784 ел, 22 февральдә кабул иткән Указы:**

«Известно, что между обитающими в разных губерниях Всероссийской Империи, так называемыми, князьями и мурзами татарского происхождения, оставшимися в магометанском законе, находятся такие, коих предки за их верную Всероссийскому престолу службу получили от высоких предков наших жалованные грамоты и поместные дачи и другие неоспоримые доказательства, что служба и состояние их были равными с прочими благородными. По разным обстоятельствам не пользовались они в течение сего времены сими выгодами и были поверстаны подать лично платящих, но как непременное желание ваше есть, дабы всех, какого рода и закона не были, пользовались неотъемлемыми приемуществами и коим порода его от заслуженных предков происходящая или же отмененные личные заслуги дают ему право. То следуя сему Всемилостивешую волю вашу объявляем, что все те, кои, так называемые, князья и мурзы татарского происхождения, каком бы законе они от праотцев не осталися, предъявлять жалованные предкам их государственные грамоты на недвижимые имения или другие письменные виды, утверждающие благородство, с явным доказательством, что они от тех родов произошли, восстановлены были в состояние им свойственное и понаписали их герольдию особым списком, воспользовались всеми теми вольностями, выгодами и преимуществами, каковыми от щедроты наших предков и наше императорское российское дворянство пожаловано, исключая только прав покупать и приобретать крепостных или поданных христианского исповедания, коими никто в империи нашей не будучи в христианском законе, пользоваться не может.»

(Полное собрание Российских законов, 16, 936. Центральный государственный исторический архив СССР. Фонд 1343, опись 21, дело 862.)

12 ел буе юллама белән бюрократиянең барлык баскычларын да таптап чыккач, императрица Еникеевларның кенәзлеген раслаучы Указга кул куя. Ноябрь аенда Указ Уфага килеп җитә. Анда күп кенә морзаларга дворян титулы бирү турында язылa, Екатерина Икенченең вафаты сәбәпле, Павел I имзасы белән дөнья күрә, әмма без аны Екатерина II нче Указы дип атыйбыз.

1796 елның 29 ноябрендә Бөек Императорның Указы Сенатта тыңланылды. Анда татар кенәзләре Акчуриннар, Чанышевлар, Дивеевлар, Маматовлар, Маматкозин-Сакаевлар, Кудашевлар, Янбулатовлар, Яушевлар, морзалар Кашаев, Биглов, Еникеев һәм Терегуловлар турында — аларның аксөяк нәселдән икәнлеге губерния дворяннары һәм өяз депутатлары җыенында исбатланды. Дворяннар кенәгәсенә кертергә лаек дип табылдылар. Шул нигездә, югарыда әйтелгән фамилияләрне окладтан һәм барлык төр ясаклардан азат итеп, элекке дәрәҗә, байлыкларын кире кайтарырга.

Фәрман бирәләр: Император хәзрәтләренең бу Указын Уфа наместниклар идарәсенә җибәрергә.

1. Стәрлетамак округы, Абдулла авылы, кенәз Акчуриннар, 11 кеше.

2. Бәләбәй округы, Күзәй авылы морзаларыннан кенәз Чанышевлар, 23 кеше.

3. Бәләбәй округы, Каргалы авылы морзаларыннан кенәз Дивеевлар, 7 кеше.

4. Бугуруслан округы, кенәз Маминнар, 13 кеше.

5. Бәләбәй округы, Абушан авылы, кенәз Маматкозин-Сакаевлар, 12 кеше.

6. Бәләбәй округы, Ахун авылы, кенәз Кудашевлар, 9 кеше.

7. Оренбург губернасы Сәит бистәсе, кенәз Ямбулатовлар, 7 кеше.

8. Бәләбәй округы, Арслан авылы, кенәз Яушевлар, 18 кеше.

9. Бәләбәй округы, Байморза авылы, кенәз Кашаевлар, 5 кеше.

10. Бәләбәй округы Каргалы авылы, морза Терегуловлар, 19 кеше.

Шундый ук Указлар соңрак морза Дашкиннарга, Енгалычевларга, Үтәшевләргә, Мамлеевларга һәм Макуловларга да килә.

Екатерина II нче Указының 200 еллыгына багышлап, 1996 елның сентябрь аенда Уфада юбилей конференциясе булды. Бәйрәм чараларында Россия дворяннарының берләштерелгән Советы да катнашты.

**— Риф морза, бераз гына структура турында. Татар морзалары Мәҗлесе Россия дворянлыгы составына керә. Дворянлыкның символында ике башлы бөркет. Россия таҗы һәм Православие чиркәвенең тәресе сурәтләнә. Татар морзалар Мәҗлесенең аерым символикасы бармы һәм ул нинди?**

— Татар морзалары Мәҗлесенең геральдикасы башкача. Мәҗлес символы —гөмбәзенә ай куелган мәчет. Ишегебезгә бите ачылган китап, факел, җәя белән ук, киек җәнлек сурәте төшерелгән. Бу символиканы рәссам Ренат морза Еникеев ясады.

**— Әйтегез әле, татарларның катлаулы тарихында морза һәм бәкләр нинди роль уйнаган? Гомумән, аларга роль бирелгән дип саныйсызмы?**

— Җәмгыятьтә тарихи үсешнең билгеле бер баскычын үтеп, татар җәмгыяте үз аристократиясен тудырган «Кыпчак кыры әреме» дигән китабында Морат Әҗи болай яза: «Һәр милләт аристократиясенең төп бурычы — халыкның тарихын, мәдәниятен, хәтерен саклап калу. Аристократиясе булмаган халык берсен икенчесеннән аерып булмаган колларга, көтүгә әйләнә». Ә сезнең сорауга болай дип җавап бирергә мөмкин: кенәз, морзалар гомуми һәм хәрби җитәкчелек эшен алып барганнар.

**— Урынлы сорау туа — кемгә каршы хәрби җитәкче булганнар? Заманчарак итеп әйтсәк: «Кемгә каршы дус без, туганнар?»**

— Үзләренең җәмгыятьләрен, дәүләтләрен саклау өчен хәрби җитәкчеләр булганнар, әлбәттә. Әгәр дә 1552 елны күздә тотасыз икән, бу хакта сөйләштек инде.

**— Әйе-е, Риф морза, әңгәмәбез бер дә җиңелләрдән булмады әле. Бәлки бәк, кенәз, морзалар институты нәкъ менә сез санап үткән тарихи фактлар аркасында башта Казан ханлыгында, соңыннан Казан губернасында тиешле үсеш ала алмагандыр?**

— Шулай булуы да бик ихтимал. Ләкин христианлыктан баш тарткан титуллы татарларның да тормышы авыр булган бит. Шул ук лашманлык, татарларның Башкортстан җиренә күченеп кенә, үзләренең телен һәм динен саклап кала алуы да бик яхшы мисал булып тора. Тагын менә нәрсәне онытырга ярамый: әлегә кадәр бәк, морза һәм кенәзләрнең Казан төркеме бик начар өйрәнелгән. Күп нәрсәне без бөтенләй белмибез.

Уфада татар аристократиясе институтын Темников Мещерасына нигезләнеп торгыздык. Бу группа кенәзләренең тарихын яхшылап өйрәндек. Аларга бәйле тарихи документлар да сакланып калган.

Татар милләте үзенең үсешендә ике төрле идеологик юлдан бара. Беренчесе — Россия татарлары, ягъни Мещера крае. Икенчесе — Төрек татарлары. Бусы — Казан ханлыгы, соңрак Казан губернасы.

**— Риф морза! Сезнең бабаларыгыз да үз вакытында мәҗбүри чукындыруга каршы булганлыктан, Россия җитәкчелеге тарафыннан төрле кысрыклануларга дучар ителгән. Соңрак мөселман ягына — башкорт җирләренә күчеп китәргә мәҗбүр булганнар. Сез сизәсезме: бабаларыгыз ике төрле тормыш алып барганнар бит?**

— Ничек сизмисең ди, сизәм, әлбәттә. Монда Темников Мещерасының геополитик һәм геоэкономик хәлен исәпкә алырга кирәк. Бер якта — көч җыеп килүче яшь Россия дәүләте. Картадан карасаң, астарак Алтын Урда дәүләте, соңрак Ногай һәм Әстерхан ханлыклары. Үнда — тагын бер ныклы дәүләт — Казан ханлыгы. Минем фикеремчә, Темников Мещерасы бәк, кенәз, морзаларына үзләренең мөстәкыйльлеген саклап калу бик кыйммәткә төшкәндер.

**— Нәкъ тормыштагы шикелләме? «Мәскәүгә ышан, үзең дә тик торма» диләрме әле.**

— Әйе-е. Нәкъ шулай. Бу «Мәскәүгә ышан...» дигән әйтем, миңа калса, бүген дә бик актуаль яңгырый.

**— Риф Үзбәкович, бәлки татар аристократиясе мәгърифәтчелек өлкәсендә үзенең миссиясен үтәгәндер? Ләкин монда да аңлашылмаучылык бар. Татар халкының төп мәгърифәтчеләре гади халык вәкилләре бит. Мисал өчен: Мөхәммәдъяр, Габдулла Тукай, Гаяз Исхакый, Садри Максуди, Ризаэтдин Фәхретдинов, Зыя Камали, Мәҗит Гафури, Шиһабетдин Мәрҗани. Алар барысы да диярлек алдынгы карашлы мулла балалары булганнар.**

— Сез морзалар нәселеннән чыккан мәгърифәтчеләрне санарга оныттыгыз: Йосыф Акчура, Исмәгыйль Гаспринский, Еникеевлар, Тенишевлар, Терегуловлар, татар әдәбияты классиклары Шәриф Камал, Әмирхан Еники, исеме дөньяга танылган математик, Башкортстан фәннәр Академиясе президенты Роберт Нигъмәтуллин (Терегулов) дөньядагы иң зур тюркологларның берсе, Мәскәү академигы Әдһәм Тенишев, Истанбул университеты профессоры Надир Дәүләт һ.б. Төркестанда гражданнар сугышы герое Әлимҗан Акчурин, Пушкин һәм Лермонтовның татарча тәрҗемәләре белән танылды. Бохара шәһәрендә бер урам аның исемен йөртә. Кардиохирург Ренат һәм генерал-полковник Рәсим Акчурин турында сөйләп торасы да юк, дип уйлыйм.

**— Акчуриннар нәселенең иң танылган кешесе, әлбәттә Йосыф Акчура (1876—1935). Ул сәяси тюркизм теоретигы. Төрек республикасы Президенты Кәмаль Ататөркнең киңәшчесе була. Әнкарә шәһәренең бер урамы аның исеме белән атала. Йосыф Акчура хәрби училище бетергәч, төрекләрнең демократия хәрәкәтенә кушыла. Аны ике тапкыр кулга алалар. Ул Ливиядәге сөргеннән Парижга кача. Сорбоннаны тәмамлый. Цюрихта Ленин белән очраша. Төркия Милли җыены депутаты. Истанбул университеты профессоры була.**

**Мәгърифәтчелек үсеше турында сөйләгәндә, аның нинди юнәлештә булганлыгын да исәпкә алырга кирәк.**

— Сез, мөгаен, хаклыдыр. Беренчедән, бер төркем татарларны икенчесенә каршы кую дөрес түгел. Икенчедән, Мещера ягы татарларының безнең гасырда яшәгән буыны бик күп талантлар бирде. Мәсәлән, язучы һәм шагыйрьләр Кәрим Тинчурин, Һади Такташ, Гадел Кутуй...

**— Үзебезнең әңгәмә темасына яңадан кайтыйк әле, Риф Үзбәкович. Татар морза һәм кенәзләре хәрәкәте ни өчен нәкъ менә Уфада башланды? Ник, мәсәлән, Казанда, Мәскәү яки Пензада түгел?**

— Аллаһы Тәгалә кушуы белән. Башкортстанда татар кенәз һәм морзалары күп. Аннары, бу республиканың политик хәле дә бик тотрыклы.

**— Бүгенге татар морза һәм кенәзләренең нинди өстенлекләре бар?**

— Хәзерге дворяннарның бернинди өстенлекләре дә юк. Әмма аларга Ходай Тәгалә бик зур миссия биргән. Үз милләтенең мәдәниятен саклап калу, буыннан-буынга тапшыру миссиясе.

**— Иптәш Акчурин, сез берәр төрле газета яисә журнал чыгарасызмы?**

— Әйе, Татар морзалары мәҗлесенең татар һәм рус телләрендә «Морзалар хәбәрчесе» газетасы бар. Без газета укучыларыбызга мондый киңәш бирәбез: үз тарихыбызны, тамырларыбызны, телебезне онытмыйк, көндәлек һәм рухи тормышыбызда мөселман диненә туры калып, шәригать законнарына таянып Мөхәммәт пәйгамбәребезнең изге Коръәндә язганнарынча яшәргә кирәк.

Редакция адресы:
ПУ-1, Уфа, Һәдия Дәүләтшина урамы, 3, тел. 29—12—92.

**— Татар морзалары мәҗлесе кем хисабына яши? Сезнең матди чыгымнар да бар бит...**

— Аерым предприятиеләрнең, шәхесләрнең спонсорлык ярдәме белән көн күрәбез, Спонсорларыбыз үзләре дә морза һәм кенәзләр нәселеннән чыккан кешеләр.

**— Риф әфәнде, шундый әңгәмәгә вакыт табуыгыз өчен рәхмәт сезгә. Соңгы соравыма җавап бирсәгез иде: күпме кеше дворянлык сословиесе вәкиле булу турында Татар морзалары мәҗлесеннән диплом яки таныклык алды?**

**— 280 кешенең кулында мондый таныклык бар. Тагын 10 гә әзерләдек.**

* * *

Гадәти булмаган танышым белән хушлашуым да ничектер коры чыкты. Мин бары тик: «Сезнең җитәкчелектә Татар морзалар мәҗлесе эшчәнлеге милләтебез үсешенең нигезе булсын, милләтара дуслыкны тагын да ныгытсын. Барыбызга да исәнлектә-иминлектә яшәргә язсын!» — дидем.

**PS.** «Алтын Урда» демократик дәүләтендә крепостное право шикелле, кимсетү, кысрыклаулар булмый. Ыругның һәр кешесе үзен азат хис итә. Морзалар да үзләренә буйсынучылар белән бик сак идарә итәләр. Хокук бозуларга юл куелмый. Әгәр кемгә дә булса үз морзасы ошамый икән, ул бер төн эчендә тирмәсен сүтеп, башка морза җиренә күчеп китә алган».

(Сәид морза Еникеев. «Морзалар хәбәрчесе» газетасы, 1996 ел, 20.)

* * *

1993 елда Кытайның Харбин шәһәрендә Шәйхетдин Акчурин белән таныштым. Ул анда 1968 елдан яши, кытай теленең харбин сөйләмендә иркен сөйләшә. Аның абыйсы Гайнетдин Акчурин. Йортның хуҗабикәсе Хәдичә апа Акчурина — узган гасырда дан тоткан сәүдә магнатлары Акчуриннар нәселеннән.

«Харбин татарлары Ш.Акчуринга Харбин шәһәре мәчетенең планын калдырганнар. 1949 елда коммунистик Кытайда мәчетне казарма, соңыннан склад итәләр. Кытай Дәүләт Советына күп тапкырлар хатлар язып, Шәйхетдин Акчурин мәчетне яңадан дин тотучыларга бирдертә».

(Академик Рәиф Әмиров. «Морзалар хәбәрчесе» газетасы, 1996 ел, 22.)

* * *

Күп гасырлар дәвамында көнчыгыш славян һәм төрки халыклар үзара кушылып беткәннәр. Күп кенә рус дворяннары үзләренең нәсел тамырлары Алтын Урдадан булуы белән горурланалар. Элек-электән дәүләт кешеләре арасында мөселманнар да булган. Алар Ватан азатлыгы өчен фидакарьләрчә көрәшкәннәр һәм Россия патшаларының хөрмәтен яулаганнар.

**А.К.Голицын,** Россия дворяннары җитәкчесе.

* * *

1998 елда татар бәге Сәит Әхмәтнең Мещерага килүенә 700 ел тула. Россия дворянлыгы бу вакыйганы билгеләп үтте. Бик күп татар морзаларының нәсел тамыры Сәит Әхмәткә барып тоташа. Мәсәлән, Акчуриннар, Байгильдиннар, Бегильдиевләр, Бибарсовлар, Бигловлар, Богдановлар, Дашкиннар, Дәүләткильдеевлар, Дивеевлар, Енгалычевлар, Исеевлар, Кугушевлар, Кудашевлар, Кутыевлар, Маминнар, Мамлеевлар, Муратовлар, Тенишевлар, Терегуловлар, Үтешевлар, Шахмалевтьевлар, Яушевлар һәм башкалар.

Бәйрәм чаралары Рязань өлкәсендә — Ока елгасы буенда үткәрелде. Бизәп эшләнгән тирмәләр, атлар табуны, халык җырлары, театрлаштырылган тамашалар булды. Мәҗлес делегациясе бу бәйрәмгә үз бабаларының туган җирләрен, авылларын карап, Саранск һәм Темников аша килде.

(Ирек Биккенин. Газета «Столица». 1997 ел, 20 июнь.)

* * *

«Татарстан Республикасы дворяннары җыены. 420045. Казан, Ершов урамы, 14 — 22, 30 август, 1996 ел.

Татар морзалары мәҗлесе җитәкчесе кенәз Акчурин Риф Үзбәковичка.

Хөрмәтле Риф Үзбәкович!

Сезне Морзалар мәҗлесенең чираттагы съезды һәм татар морзаларын дворянлыкка кабул итүнең 200 еллыгы белән котларга рөхсәт итегез. Бик кызганыч, әмма без бу съездда катнаша алмыйбыз. Күркәм инициативагызны хуплыйбыз һәм Сезне Татарстан Республикасы дворяннары исеменнән дә кайнар котлыйбыз.

Сезгә уңышлар телибез һәм киләчәктә очрашуларга өметләнеп калабыз.

Сезне ихтирам итеп Татарстан Республикасы дворяннары җыены җитәкчесе фон Эссен А.Г., җитәкче урынбасары Куликовская Е.Е. («Морзалар хәбәрчесе» газетасы, 1996 ел, 21.)

* * *

Татар морзалар Мәҗлесе җыеннары рус дворяннарының региональ җыеннарыннан бик азга аерыла. Чөнки һәммәсе дә рус телендә генә сөйләргә һәм язарга тырышалар. Юкса, бабайларыбыз, аталарыбыз безгә мирас итеп искиткеч бай, матур тел калдырганнар бит.

Безнең бабаларыбыз дин тотканнар, дуңгыз ите һәм исерткеч эчемлекләрдән тыелганнар, үзләре гади булгач, тәкәбберлекне яратмаганнар. Безгә дә шул күркәм гадәтләрне үз итәсе бар.

(Хаҗи Рәшит морза Биглов. «Морзалар хәбәрчесе», 1996 ел, 21.)

Татар морзалары мәҗлесенең чираттагы җыены ахырында бөтен зал аягүрә басып,Габдулла Тукайның «Туган тел»ен җырлады. Бу җыр Татар морзалары мәҗлесенең гимнына әверелде.

(«Морзалар хәбәрчесе», 1996 ел.)

* * *

Темников Мещерасы татарлары нигез салган Облат бистәсеннән губерна шәһәре Пенза барлыкка килгән.

(«Новая биржевая газета». Пенза, 1996 ел, 12.)

* * *

1552 елның 15 октябрендә Иван Грозный гаскәрләре Казан шәһәрен яулап алды. Шул көннән башлап, татар халкы үз дәүләтчелеген югалтты.

Татар халкы тарихындагы бу кара көн гасырлар дәвамында рус шовинизмы күләгәсе артында калды.

СССР таркалгач кына татар халкы ел саен 15 нче октябрьне «Хәтер көне» итеп билгеләп үтә башладылар.

(«Морзалар хәбәрчесе», 1997 ел, 30.)

*Июнь, 1998 ел.*

## Абыйлы-энеле Акчуриннар

Генерал-полковник Рәсим Сөләйманович Акчурин белән билгеләнгән очрашу һич көтмәгәндә өзелде. Рәсим Сөләймановичны космонавт Валентина Терешкованың юбилей тантанасын үткәрү буенча дәүләт комиссиясе составына керткәннәр икән. Ул миннән гафу үтенеп, шушы тантанага Ярославльгә китеп барды.

Төп-төгәл бер айдан, якшәмбе көнне, якташыбызның фатирына шылтыраттым.

— Әйдәгез, килегез, — ди Рәсим Сөләйманович миһербанлы тавыш белән һәм Чертановадагы зур торак корпусны ничек табарга икәнлеген аңлатып бирде.

Фатирның ишеген яшь чырайлы, җыйнак кыяфәтле, гражданлык киемендәге чибәр ир-ат ачты. Ул — якташыбыз Рәсим Сөләйманович Акчурин икән. Бүлмәләрнең берсеннән ачык йөзле, сөйкемле ханым килеп чыкты. Бу — Рәсим Сөләймановичның хәләл җефете Фәүзия Әхмәтсәгыйр кызы, шушы кунакчыл йортның хуҗабикәсе.

Минем күп мәртәбәләр сынап караганым бар, кайберәүләр мактаулы исемнәре, җәмгыятьтәге социаль хәле һәм белем дәрәҗәсенә карамастан, очрашуның беренче минутларыннан ук күңелне үзләренә җәлеп итәләр. Андый кешеләр белән аралашу бик җиңел. Зур тартым көче бар аларда. Ирле-хатынлы Акчуриннар нәкъ шундыйлардан булып чыктылар.

Безнең очрашу чәй өстәле артында берничә сәгатькә сузылды. Минем үтенечемне канәгатьләндерергә тырышып, Мәскәү фатирының хуҗалары хәтерләрендә сакланган истәлек-хатирәләрне бөртекләп барладылар, үзләренең тамырлары, туган-тумачалары һәм бергә үткән гомерләре турында сөйләделәр.

Русиядә Акчуриннар нәселе киң таралган. Кенәз һәм морзалардан булган атаклы нәсел тарихта билгеле бер урын алып тора. Кенәз Бехан Акчура «Алтын Урда» ханнары ризалыгы белән бик күп шәһәрләр һәм татар, мукшы авылларын биләгәннәр, шул исәптән, Сараклыч шәһәренең дә хәзерге Мордовия Республикасына кергән Саров, яисә Арзамас-16 ның хуҗасы булганнар.

Акчуриннар фамилиясе Мәскәү архивларының XVII гасыр документларында очраштыргалый.

Эшкуар Хәсән Акчурин танылган мәгърифәтче Шиһабетдин Мәрҗани белән берлектә татар халкының тарихи музеен оештырганнар. Соңыннан бу музейда Габдулла Тукай да булгалаган. Акчуриннар нәселенең күренекле вәкилләренең берсе булган Хәдичә Акчурина үткән гасырның ахыры — XX гасырның башында яшәгән күренекле татар мәгърифәтчесе Исмәгыйль Гаспринскийның хатыны һәм көрәштәше дә булган.

Аның якын туганы Йосыф Акчура да татар тарихында сизелерлек эз калдырган. Белемле һәм алдынгы карашлы шәхес буларак, татар, аерым алганда кырымтатар мәдәнияте һәм мәгърифәте үсешенә үзеннән зур өлеш керткән ул.

Гражданнар сугышы елларында Йосыф Акчура Төркиягә күчеп китә һәм Төркия президенты Мостафа Кәмал Ататөркнең киңәшчесе булып эшли.

Акчура нәселенең вәкилләрен Русиядә, БДБ илләрендә, Аурупа, Азия һәм Америка континентларында да очратып була. Гомумән, Акчуриннар нәселенең тамырлары бик тирәнгә — ерак гасырларга барып тоташа. Акчурин фамилиясе «Ак-чура»дан килеп чыккан, ягъни «ак-батыр».

Ә минем әңгәмәдәшләремнең туганлык тармаклары Пенза губернасының көньягында тамыр җәйгән. Әтиләре — Сөләйман Сафа улы, Неверкин төбәгенең Әдельша авылында, ә әнисе — Тәскирә Кыям кызы шушы ук Пенза өлкәсенең Бекмасеевка авылында туган.

Әтисе бик яшьли ятим кала һәм ул башта туганнарында, аннары ятимнәр йортында (приютта) тәрбияләнә. Ә әниләре Тәскирә Кыям кызы зур фабрикант гаиләсендә туып-үсә. Ата-аналары патша армиясенә шинель тегү өчен сукно тукыганнар.

Егерме яшьлек Сөләйман Сафа улы 1929 елда Сарытауда культура агарту училищесын тәмамлый һәм сылу кыз Тәскирәгә өйләнеп, утызынчы еллар башында Үзбәкстанның Ташкент тирәсендәге Зенгиат шәһәренә юл тота. Яшь белгечне педагогия училищесының директоры итеп билгелиләр.

— Бала чакта, Сөләйман дигән кеше чибәр Тәскирәне урлап Үзбәкстанга качкан дигән сүзләрне ишеткән идем,— ди көлемсерәп Фәүзия ханым.

— Шулайдыр,— дип килешә Рәсим Сөләйманович.— Ләкин алар бергә озын һәм бәхетле гомер кичерделәр.

Зенгиатта Тәскирә дә педучилище бетерә һәм башлангыч классларда укытучы булып эшли. Әмма бик кыен шартларда эшләргә туры килә аларга. Бу якларда дин ифрат дәрәҗәдә көчле. Ата-аналар балаларын укырга җибәрмиләр. Укытучыларга таш белән аткан очраклар да булгалый.

Монда, Зенгиатта, 1931 елның декабрендә, аларның баш балалары, гаиләнең нигезе һәм ышанычы булган Рәсим дөньяга килә, Рәсим — «тиз йөрүчән» дигән сүз, чыннан да, исеме — җисеменә туры килгән икән, тормышта ул моны горур рәвештә раслады.

1932 елны Сөләйман Акчуринны укытучылар әзерләү эшләрен оештыручы буларак Ош шәһәренә күчерәләр. Җиде айлап шунда эшләгәннән соң, аны Әндиҗанга мәктәп директоры итеп җибәрәләр.

Кая гына яшәмәсеннәр, яшь педагог Акчуриннар җәмгыятьнең укымышлы катламы арасында, милләтләре буенча кем булуларына да карамастан, зур ихтирам казаналар. Барлык гомерләре диярлек шушы Әндиҗан шәһәрендә үтә. 1938 елны кызлары Флора туа.

Әтиләре шәһәрнең күренекле мәгърифәтчесенә әверелә. Тиз арада аны халык белемен күтәрүнең шәһәр бүлеге (гороно), соңга таба өлкә бүлеге (облоно) җитәкчесе итеп билгелиләр.

Бөек Ватан сугышы елларында Әндиҗанда тормыш кискен үзгәрә. Русиянең көнбатыш һәм үзәк өлкәләрендә яшәүче бик күп руслар һәм татарлар көньякка күчеп килергә мәҗбүр булалар. Аларның балалары рус мәктәпләрендә укыйлар, ләкин тәрбиянең нигезен алар өйдә, гаиләдә ала. Татар балалары, мәсәлән, өйдә гел татарча сөйләшәләр. Мөселман йолаларын тоталар. Рәсим Сөләйманович үзенең әтисе ягыннан әбисе Алия һәм бабасы Кыямны бик җылы сүзләр белән искә ала. Алар оныклары Рәсимгә үзләренең нәсел тамырлары, ерак Ватаннары булган Пенза җире турында һәрдаим сөйләгәннәр, милләтне, телне һәм гореф-гадәтләребезне олыларга өйрәткәннәр. Ул елларда Әндиҗанда күбрәге рус һәм татар яшәгән. СССР таркалганчыга кадәр Казаннан бик еш кына артистлар килеп А.С.Пушкин исемендәге шәһәр паркында концертлар куя торган булганнар.

1946 елның 2 апрелендә Әндиҗан шәһәрендә төпчек энеләре, булачак кардиохирург Ренат дөньяга аваз сала.

— Ул елларны бик сагынып искә алабыз,— диләр бертавыштан Акчуриннар.— Алтын көннәр булган икән алар. Көтмәгәндә, бер минут эчендә, барсы да җимерелде. СССР юкка чыкты. Руслар һәм татарларның да күбесе Әндиҗаннан күчеп киттеләр. Гомерләрен мәгърифәтчелек эшенә багышлаган әтиебез һәм әниебез 1981 елны бер-бер артлы диярлек бу фани дөньядан китеп бардылар.

Флора сеңлебез балалары белән, әтиебезнең сеңлесе Арифа апа һәм башка туганнарыбыз язмыш кушуы буенча башка дәүләт җирендә торып калдылар. Аларның хәлен белеп һәм әти-әниләрнең каберләрен зыярәт кылып кайтыр өчен генә дә хәзер бик күп акча кирәк.

— Быел, Алла бирсә, әти-әниләребезнең каберләренә барабыз, туганнарыбызның хәлләрен белешеп кайтабыз,— диләр Фәүзия ханым һәм Рәсим Сөләйманович Акчуриннар.

Укучыларыбызның, билгеле, түземсезлек белән әңгәмәдәшемнең ничек итеп зур хәрби начальник дәрәҗәсенә ирешүе турында тизрәк беләселәре киләдер.

Рәсим 1949 елны Әндиҗанда урта мәктәпне тәмамлап, Ленинград политехник институтының автоконструкторлар әзерләү бүлегенә укырга керә. Ике курсны уңышлы тәмамлагач, кинәт язмыш тормыш юлында кискен борылыш ясый. 1951 елны Сталин тарафыннан чыгарылган декрет буенча, Рәсим Акчурин хәрби училищега укырга җибәрелә.

Бу елларда салкын сугыш хәвефе ил өстендә киң колач җәйгән иде. Хәрби көчләр системасында һава һөҗүменә каршы Оборона гаскәрләре төзелә башлый. Студент Акчуринның хәрби училищега барырга һич тә күңеле тартмый.

Ләкин Ленинградның Выборг ВЛКСМ райкомында нык торалар: «Без синең белән шаяртмыйбыз. Менә сиңа путевка. Ленин комсомолының йөзенә кызыллык китермә».

Шулай итеп, Рәсим Латвиядәге Алуксне шәһәренең, нигездә, ябык (яшерен) хәрби училищесына китә. Училищеның хәтта исеме дә күрсәтелми. Хәрби часть номеры белән генә йөртелә. Монда зенит-артиллерия фәннәрен өйрәтәләр. Өйгә хат язарга да тыела.

Улына югары уку йортын тәмамларга бирмәүләренә канәгатьсезләгеп белдереп, иптәш Сталинның үзенә хат юллый әтисе. Ләкин тиешле органнар аны тынычландыралар. Аның күңеле улының өстенә бик матур хәрби курсант киеме киенеп ял итәргә кайткач кына тынычлана.

1954 елда Рәсим хәрби училищены лейтенант дәрәҗәсендә тәмамлап, Кыргызстанда урнашкан ҺҺКО (Һава һөҗүменә Каршы Оборона — ПВО) гаскәрләренең взвод командиры итеп җибәрелә, җир астыннан уран табу руднигын (мәгъдәнен) һәм аны эшкәртү предприятиеләрен һава киңлегеннән торып саклау вазифасы йөкләтелә аларга. Шулай итеп, Төркестан хәрби округында яшь офицер унбер ел хезмәт итә һәм майор исеме алып, дивизион командиры дәрәҗәсенә күтәрелә.

1965 елны майор Р.С.Акчурин ҺҺКО (ПВО) Хәрби Командалык Академиясенә укырга керә. Биш ел вакыт сизелми дә үтеп китә. Аңа подполковник исеме биреп, полк командиры итеп эшкә җибәрәләр. Укуны тәмамлау белән үк Мәскәү хәрби округына полк командиры итеп билгеләнү академия тарихында гадәти хәл түгел.

**— Сез Мәскәүдә хезмәт итә башладыгызмыни? — дип сорау бирәм мин.**

Генерал-полковник рәхәтләнеп көлде һәм:

— Барысы да шулай дип уйлый. Әлбәттә, юк. Аның исеме генә ҺҺКОның (ПВО) Мәскәү хәрби округы дип атала. Аның киңлеге Архангельски өлкәсеннән башлап Кострома өлкәсенең көньяк чикләренә кадәр җәелгән. Мәскәү — зур дәүләтнең башкаласы буларак, дошманның көтелмәгәндә һөҗүм иткән канатлы ракеталарына каршы боҗра белән уратылып алынган. Мин җитәкләгән часть Кострома өлкәсенең Нея шәһәрендә урнашкан иде. «Сусаниннар» үткән җирләрдән дә арырак ул. Аннан соң кеше аягы баса алмаслык куе урманнар китә.

Өч елдан соң Р.С.Акчуринны Горький шәһәрендәге зенит ракета гаскәрләренең ҺҺКО (ПВО) корпусы начальнигы итеп билгелиләр. Монда аңа чираттагы хәрби исем — полковник исеме бирелә.

Тагын бер елдан (1974) полковник дәрәҗәсендә яңа гына эшкә тотынган Р.С.Акчуринны Ярославльдәге ҺҺКО (ПВО) корпусының командиры урынбасары итәләр, бер елдан соң шушы корпусны ул үзе җитәкли. Бу генерал-лейтенант урыны. 1976 елда аңа генерал-майор, биш елдан генерал-лейтенант исеме бирелә. Бер үк вакытта ул Ярославль хәрби гарнизоны белән дә җитәкчелек итә. Яшь генералның Ярославльдәге тормышында төрле вакыйгалар булып ала. 1981 елның 9 январенда аның төпчек улы Тимур туа. Шушы ук көнне Ярославль өлкәсенең партия оешмасы аны партиянең XXVI съездына делегат итеп сайлый. Ул заманда, әйтергә кирәк, бик зур әһәмияткә ия булган вакыйга иде бу.

1983 елда генерал-лейтенант Р.С.Акчуринны Мәскәү хәрби окру-

гының зенит ракета гаскәри берләшмәсенең җитәкчесе итеп, ә ике елдан соң Оборона министры һәм КПСС Үзәк Комитетының карары белән аны яңа эшкә — илебезнең ҺҺКОның (ПВО) зенит ракета гаскәрләренең командующие (җитәкчесе) итеп билгелиләр.

1990 елда аңа «генерал-полковник» исеме бирелә.

1992 елны билгеләнгән хезмәт итү срогын тутырып, Р.С.Акчурин лаеклы ялга китә. Хәзер ул Россия Федерациясе хөкүмәтенең консультанты.

Хәрби хезмәт турында сөйләшүне тәмамлаганда мин аңа тагын бер сорау бирдем:

**— Тыңлап утыргач, чыннан да, Сезне «тиз йөрүчән» дип әйтәсе килә. Сезнең хезмәт юлыгызда югарыга үсеш хәрәкәте шундый салмак агып бара ки, алдан күреп эшләгән диярсең...**

— Билгеле, сез уйлаганча җиңел генә түгел,— ди минем әңгәмәдәшем.— Хәрби хезмәтнең үз төсмерләре (нюансы), үз кытыршылыклары бар. Ярославльдә бик авыр корпусны җитәкләргә туры килде.

Минем кул астында дистәдән артык ҺҺКО (ПВО) полкы һәм бригадасы, өч авиация полкы, өч тыл хәрби часте. Бу гаҗәеп зур гаскәр. Территориянең чикләре төньяктан көньякка мең чакрымнарга җәелгән. Шушы корпус белән сигез ел җитәкчелек иттем, шул вакыт эчендә оборона министрлыгыннан һәм генераль штабтан тәгълиматлар алырга һәм бик күп өйрәнү, күнегүләр үткәрергә туры килде.

**— Хәрби гаскәрләрнең командирлары татар милләтеннән булган офицерларны бик яраталар икән. Моңа карата Сезнең фикерегез ничек?**

— Татар милләтеннән булган офицерларны аларның тәртипле, эшне төгәл үтәүчән, тәрбияле һәм куелган бурычларына турылыклы булганлыклары өчен югары бәялиләр һәм нык ихтирам итәләр. Шуңа күрә, безнең халык үзенең саклаучылары белән горурлана ала,— дип төгәлли әңгәмәбезнең бу өлешен генерал-полковник. 1990 еллар башында илдә сан буенча ике мең генерал булса, шуның сиксән генерал һәм адмиралы татар милләтеннән санала иде. Ләкин билгеләнгән бер биеклеккә җиткәч, татарларга карата мөнәсәбәт үзгәрә. Нишләтәсең, шундый инде ул безнең илдәге «тигез хокуклы» милли сәясәт.

Генерал-полковник бу мәсьәләгә кагылышлы бер кызык хәл турында сөйләп китте:

— 1982 елны Ватаныбызның һава һөҗүменә Каршы Оборонаның (ПВО) Хәрби Советы утырышында Ленинградта урнашкан ҺҺКО (ПВО) армиясе белән җитәкчелек итүче командующий мәсьәләсе көн тәртибенә куелгач, минем кандидатурамны тикшергәннәр. Оборона Министрлыгы һәм КПССның Үзәк комитетында да сөйләшү булды, минем кандидатурам һәркайда яклау һәм хуплау тапты. Әмма ләкин эшкә билгеләмәделәр. Соңыннан гына беленде, ул заманда КПСС Үзәк Комитетының Политбюро әгъзасы, Ленинград өлкә Комитетының Беренче секретаре П.В.Романов бу эшкә тыкшынып: «Китсәнә, Октябрь революциясе Ватанына командующий итеп җибәрергә татардан башка кандидатура табылмадымыни?» — дигән.

Ләкин шуны әйтәсем килә, халыкта мондый әйтем бар: «Җир түгәрәк. Кем белән теләсәң шуның белән теләсә кая очрашып була». Тикмәгә генә әйтелгән сүзләр түгел бу.

Күптән түгел генә В.С.Черномырдин миңа П.В.Романовның гаризасын тикшерергә җибәргән. Элеккеге чиктән тыш куәтле Политбюро әгъзасы пенсия акчасының яшәр өчен җитешмәве турында зарланып язган, ягъни өстәмә сорый. Мин эчкерле кеше түгел, кешеләргә карата беркайчан да усаллык тотмыйм. Аның гаризасын да уңай хәл иттек...

Күптән түгел Мәскәү шәһәре һәм өлкәсенең татар җәмгыяте Рәсим Сөләймановичны татар милли-мәдәни мөхтәрияте президенты итеп сайлады.

— Русиядә бик күпләр илебез күпмилләтле дип мактанырга яраталар,— ди минем әңгәмәдәшем.— Шулай булгач, милли мөхтәриятләрне әле кичә, 50, 70, 80 ел элек төзергә кирәк иде инде. Ләкин ул заманнарны үзегез беләсез: башка сәясәт, башка идеология. Ул чактагы лозунгларда: «Барлык милләтләр дә берләшергә һәм Совет халкы дигән бер җәмгыять төзелергә тиеш», диелгән иде. Ул елларда кеше акылына ят орлык чәчү бүген, күргәнебезчә, әче җимешләрен бирә. Бер милләтнең дә, этнос буларак, үзе теләп үләсе килми булып чыкты.

Хәзер анда-монда карамыйча, бер яктан икенче якка ташланабыз, ашыгып, милли идеяләрне аңлап җиткермичә, оештыру, хокук һәм финанс ягыннан кирәгенчә эшләп бетермичә, «Башта ботка пешерегез, аннары ачыкларбыз», дигән Русия принцибыннан чыгып мөхтәриятләр төзелә.

Совет чорында татарларның менталитеты шактый үзгәрде, яхшы якка, әлбәттә.

Ләкин миңа бер деталь ошап бетми: татарларны «безнеке һәм безнеке түгел», «чиста һәм бөтенләй үк чиста түгел»гә бүлгәләп карау. Бу хәл бигрәк тә Мәскәүдә сизелә. Кайбер шәхесләр монда татарларны пенза, нижгар, касыйм, идел буе, урал мишәрләренә бүлгәлиләр. Минем карашка, бүген безгә бүлгәләнеп утыру кирәк әйбер түгел. Киресенчә, аерым халык буларак үзебезнең этносны, мәдәният, борынгы телебезне саклап калу өчен бергә берләшергә кирәк. Русиягә дә аңларга вакыттыр, татарлар үзләренең милли рухи кыйммәтләрен аякка бастырырга омтылалар икән, моның белән алар Русиядән, яки башка халыклардан аерым яшәргә җыена дигән сүз түгел.

Мисалга, Швейцария, АКШ һәм башка дәүләтләрне алыйк, бу илләрдә халыклар бер-берсе белән күршеләр булып, тигез булып яшиләр. Моңа карап Швейцариядә конфедерация отылмый бит. Киресенчә, ота гына.

Минемчә, Русия хөкүмәтенә Русияне кәгазьдә генә Федерация итеп күрергә түгел, ә аны чын мәгънәсендә Халыклар Федерациясе итәр өчен конфедерация юлына басарга кирәктер. Бу Русияне этник, милләтара, дини конфессияләр арасындагы кискен үзгәрешләр, җимергеч борылышлардан саклап калачак. Ахыр чиктә, таркалудан сакланып калуның да иң дөрес юлы бу.

Күренекле милләттәшебез турында язылган хикәяне очлар алдыннан кунакчыл һәм көләч йөзле хуҗабикә Фәүзия Әхмәтсәгыйровна

турында да берничә сүз әйтмичә булдыра алмадым. Аның әти-әниләре чыгышлары буенча Сарытау губерниясенең Яковлевка дигән зур татар авылыннан. Фәүзия ханым Акчуриннар шикелле үк Әндиҗан шәһәрендә туган. Әндиҗан медицина институтының балалар авыруларын дәвалау факультетын тәмамлаган.

Бер елдан соң, булачак кардиохирург Ренат Сөләйманович та шушы институтка укырга керә. СССР заманында Әндиҗан медицина институты илдә танылган институтларның берсе була. Фәүзия дә, Ренат та институтка бернинди таныш-белешсез, үз көчләре белән керәләр. Фәүзия ханым ординатураны тәмамлагач, шушы институтта ук өлкән укытучы булып эшли.

Генерал Р.С.Акчурин барлык гомерен диярлек хәрби хезмәткә багышласа, Фәүзия ханым табиб буларак халыкка хезмәт итә. Хәзер ул медицина белән бәйле коммерция структурасында эшли.

Олы балалары үз гаиләләре белән аерым яшиләр. Олы улы Марат — Русиянең хәрби көчләре полковнигы, кызы Римма — табиб-терапевт, уртанчы уллары Илнур — эшкуар, кече уллары Тимур — студент.

Гаиләдә милли гореф-гадәтләргә ихтирам зур. Барлык дини бәйрәмнәрне дә билгеләп үтәләр, бигрәк тә, Ураза һәм Корбан гаетләре көннәрендә өйләренә кунаклар чакырып дога мәҗлесе үткәрәләр. Бу эшләрнең башында, билгеле инде, гаиләнең терәге булган Фәүзия ханым тора. Милли ашлар пешерү буенча да гаять зур оста ул. Тавык шулпасында пешкән токмач, бәлеш, чәк-чәк, гөбәдия, өчпочмаклар өстәлдән гел өзелеп тормый.

Совет тәрбиясе алуга да карамастан, гаиләдә әти-әниләрен дә истән чыгармыйлар, алар рухына багышлап Коръән укыталар.

Саубуллашкан вакытта Акчуриннар гаиләсе миңа бик кыйммәтле бүләк тапшырды — молнияле футлярга салынган гарәп һәм фарсы телләрендә басылган Коръән. Аны олы уллары Марат, командировкага баргач, Тәһраннан Хөмәйни музееннан алып кайткан булган.

Үз чиратымда мин аларга татарларның ислам динен кабул итүдән башлап, Казан ханлыгының җимерелүенә кадәр булган тарихи вакыйгаларны үз эченә алган «Континентлар һәм цивилизацияләр тоташкан җирдә» исемле сирәк басмалы китапны бүләк иттем.

Ә Казанга кайту белән шатлыклы хәбәр ишеттем: абыйлы-энеле Акчуриннар — генерал-полковник Рәсим һәм бөтен дөньяга танылган кардиохирург, академик Ренат Акчурин Икенче Бөтендөнья татар конгрессына кадерле кунаклар итеп чакырылганнар икән.

## ЙӨРӘК ҺӘМ ҖӘМГЫЯТЬ

Бертуганнары — сеңлесе Флора һәм энесе Ренат турында сөйләгәндә Рәсим Сөләйманович болай ди:

— Ренат бик тә үзсүзле иде. Һичнәрсә белән исәпләшмичә алга барды. Табиб булып чыгар дип уйламаган да идек. Башта ул Әндиҗан

медицина институтына укырга керде, шунда өч курсны тәмамлагач, Мәскәүнең Беренче медицина институтына күчте. Әйтерсең лә бу хәлләр әле кичә генә булган да, шулкадәр гомер дә узмаган. Ә бит Ренатка да инде 50 яшь тулды, күптән түгел юбилеен үткәрдек. Бер уйлаганда, бу әллә ни зур яшь түгел, гомернең чәчәк аткан чагы гына.

Шушы уңайдан, И.С.Тургеневның күптән таныш бер хикәясеннән өзек искә килеп төште: «Өйгә килеп керсәм, мич башында йоклап яткан илле яшьләрдәге картны күрдем»...

— Классик зур хата җибәргән. Илле яшьлек карт буламыни ул? — дип кеткелдәп көлә Рәсим Сөләйманович.

Бөтендөнья һәм безнең илнең медицина практикасында менә дигән әйбәт табиблар, табиб-хирурглар аз түгел. Ләкин безнең милләттәшебез Ренат Акчурин медицина тарихына, гомумән, Русия тарихына беренче класслы хирург булып кына түгел, ә Русиянең беренче президенты Б.Ельцинның йөрәгенә операция ясаучы кардиохирург булып та керәчәк. Тарихка ул, мөгаен, сәяси хәлләрне үзгәртеп җибәрүче, дөресрәге, 1996 елның ахырында тотрыгы какшаган җәмгыятебезне кискен үзгәреш, җимергеч борылышлардан саклап калучы кеше буларак та керәчәк ул.

Ул көннәрдәге хәлләрне искә төшерик әле. Төрле-төрле төстәге «Ватанны коткарып калучылар» дәүләт җитәкчесенең йөрәк хастасына сөенделәр. Алар уйлавынча, хакимлек көче аларның кулларына үзе килеп керә дә, халыкны тагын тигез сафларга бастырып, бәхетле киләчәккә алып китәчәкләр, имеш. Бөек держаиваның чиктән тыш буталчык, ыгы-зыгылы көннәрендә ирексездән уйлап куясың: ил башлыгының авыруыннан мәсхәрәле көлү өчен кеше ни дәрәҗәдә оятсыз, әдәпсез булырга тиеш, барыбер, ул шәхескә карашыбыз ничек булса да. Алар бүген дә халык бәхете өчен тырышабыз дип чаң кагалар.

Президентка операция ясалган көнне гади бер русияле хатынкызның Мәскәүдәге Пушкин мәйданында телевидение аркылы әйткән сүзләре әле дә исемдә: «Нинди каты бәгырьлеләр без — русиялеләр. Президент йөрәгенә ничә җөй салынганы белән кызыксынабыз. Кемгә кирәк ул, нәрсәгә? Президент та шундый ук гади җир кешесе.Миңа да кайчандыр операция булган иде. Аллага шөкер, исән-сау. Әйдәгез, бөтен дөньяга минем сәламәтлегем турында да сөрән салыйк соң, ләкин кемгә кирәк ул. Безнең рус халкы кирәксә-кирәкмәсә дә шау-шу күтәрергә ярата. Мәсхәрә: рәхимсез, миһербансыз җәмгыять бу...»

Бик күп журналистлар бүген танылган кардиохирург белән очрашырга телиләр. Ләкин юк, бик сирәкләре генә максатларына ирешә ала, чөнки Ренат Сөләйманович еш кына читкә чыгып китә. Быел да озак вакытлар Германиядә булып кайтты. Менә мин аның олы абыйсы генерал-полковник Р.С.Акчуринның ярдәме белән Русия медицина фәннәре Академиясенең әгъза-корреспонденты Ренат Сөләйманович Акчуринның кардиоүзәктәге (Мәскәү) эш кабинетында утырам. Ренат Сөләйманович чираттагы авыруның йөрәгенә бик тә катлаулы операция ясап чыкты. Ләкин арганлыгы сизелми. Минем сорауларыма бик теләп җавап бирде. Казан белән, Татарстандагы хәлләр белән кызыксынды. Әңгәмә

барышында шунысы ачыкланды, Ренат Сөләйманович бер-ике көннән Казанга, медицина инструментлары эшләү заводына барачак икән. Ул яңа, тагы да уңайрак инструментларга заказ бирәчәк.

## ЙӨРӘККӘ ЮЛ САЛУ

Минем беренче соравым мондый булды:

**— Табиб һөнәрен сайларга Сезне нәрсә этәрде?**

— Минем абыемның, әйтергә кирәк, минем бик яраткан абыем Рәсимнең сөйләвеннән сез беләсездер инде, безнең нәселдә табиблар юк. Нигездә, укытучылар. Ләкин без мәктәптә укыган елларда күренекле табиблар турында табиб-әдипләр тарафыннан язылган бик күп китаплар дөньяга чыкты. Мәсәлән, мин академиклар Амосов һәм Париннын китапларын, Бакулев һәм Вишневский кебек бөек шәхесләр турындагы монографияләрне йотлыга-йотлыга укыдым. Мөгаен, шулар миндә табиб булу теләген тудырганнардыр.

Мәскәүнең Беренче медицина институтын бетергәч, район поликлиникасында участок табибы булып эшләдем. Аннары ординатураны тәмамлагач, Бөтенсоюз фәнни үзәктә академик Б.В.Петровский җитәкчелегендә хирургия һәм микрохирургия буенча кандидатлык һәм докторлык диссертациясен якладым.

**— Барысы да аяк-кул тегеп куюдан башланамы?**

— Әйе. Бармактан башладым мин. 1976 елны берәү эштә баш бармагын өздерткән, шуны тегеп куйдык. Бу — микрохирургия! Йөрәк хирургиясенә караганда реконструктив (яңадан кору) хирургия күпкә кызыграк дип әйтә алам. Унбиш ел буена кул-аякларны яңадан кешенең әгъзасына тегеп — «эләктереп» куйдым, шулар өчен профессор В.С.Крылов җитәкләгән безнең коллектив Дәүләт премиясенә лаек булды.

**— Соңга табарак кардиохирург булырга тәвәккәлләдегезме?**

— Белгәнегезчә, сиксәненче еллар азагында танылган академик Е.И.Чазов яңа кардиология үзәге ачты. Евгений Иванович берничә мәртәбә мине шунда күчәргә кыстады. Йөрәк хирургиясе белән тамыр хирургиясен берләштерү вакыты җитте, дигән фикергә килде ул. Мин баш тарттым. Реконструктив хирургиядән бер дә аерыласым килмәгән иде. Ахыр чиктә ризалаштым. Стажировкага АКШка җибәрделәр. Атаклы кардиохирург Дебейкида стажировка үттем. Шуңа күрә мин бу гаҗәеп кешене үземнең укытучым дип әйтергә тулы хокукым бар. АКШтан кайткач, мин йөрәккә операция ясый башладым.

**— Йөрәк аорта һәм коронар кан тамырларына шунт салу ничек була — шул турыда кыскача сөйләсәгез иде...**

— Йөрәк аорта һәм коронар кан тамырларына шунт салу — ул йөрәк мускулатурасының кан әйләнешен нормаль хәлгә китерү өчен эшләнә. Трансплантацияләү (күчереп утырту) ярдәмендә, җәрәхәтләнү аркасында кан үтеп йөри алмаган тамырларны урап үтү өчен яңа кан юллары ясала. Моның өчен аорта һәм коронар (җәрәхәтләнгән та-

мырга) түбән очлыклардан (нижние конечности) алынган кан тамырын (вена), мамарный, пациентның үз артериясен куллану яки катнаш ысуллар кулланыла. Шунт салганда ясалма кан әйләнеше (йөреше) барлыкка китерелә. Йөрәк аорта һәм коронар кан тамырларына шунт салу — профилактик чара дип санала: ул миокард инфарктын булдырмый кала, кешенең гомерен озайтуны гарантияли (кайвакытта 20—30 елга кадәр). Операция уңышлы тәгәлләнгәндә пациент үзе ияләшкән режимда эшләвен дәвам итә һәм үзенә йөкләнгән гаять зур йөкләмәләрне физик һәм психологик яктан җиңеп чыга ала.

**— Миңа калса, бездә йөрәккә элек тә операция ясый иделәр...**

— Әлбәттә. Минем студент елларында ук элеккеге СССРда коронар хирургия белән шөгыльләнә иделәр. Шулай да йөрәк хирургиясенә без микрохирургия тәҗрибәсен алып килдек. Бу эштә без беренчеләрдән булып микроскоп куллана башладык — үзебез уйлап тапкан инструмент ул. Сүз уңаенда әйткәндә, без уйлап тапкан хирургия әсбапларының күбесен Казан заводы эшләп чыгара. Дебейки аларны бик югары бәяләде. Без аңа Казан заводы эшләп чыгарган инструментлар җыелмасын бүләк иттек. Моңа бик куанды ул.

* * *

1996 елның 8 октябрендә «Нью-Йорк таймс» газетасы Мәскәүдә Президент Ельциннныкына охшаш операция ясауда катнашкан Доуренс Альтманның репортажын бастырган иде.

Табиб Акчурин өстенә зәңгәр һәм саргылт яшел төстәге халат кигән иде, дип яза америка табиб-журналисты. Аның башына ювелирлар куллана торган лупалар, микроскоп беркетелгән. Стерилизацияләү чаралары көнбатыш стандартларына туры килә, тик бер ассистентның гына маскасы борынын бөтенләйгә капламаган. Шунт салуның мөһим һәм катлаулы өлеше тәмамланганчы операция бүлмәсендә абсолют тынлык хөкем сөрә. Табиб Акчурин әйтүенчә, гадәттә, операция бүлмәсендә әкрен генә музыка уйнап тора, бу юлы нигәдер алай булмады. Пациентның үзенчәлекләрен (анатомиясен) истә тотып, аңа ике өстәмә җөй салырга туры килде. Гомумән, операция бик шома үтте, ди.

Операция барышында хирург үзен бик тыныч тота, «бик итагатьле, йомшак кына сөйләшә, кайбер башка хирурглар кебек кычкырынып инструментларны идәнгә атып бәрми». Ул һәрвакыт операция бүлмәсендәге шәфкать туташына мөрәҗәгать иткәндә гел ихтирамлы мөгамәләдә булды.

Операция бүлмәсе озынча түгәрәк формада. Альтманга ул Америка госпиталендәге операция бүлмәләренә караганда иркенрәк булып күренде. Бүлмәнең стеналары тутыкмый торган корычтан эшләнгән.

«Мондый операция бүлмәсенең өстенлеге зур, аны чистартырга җиңелрәк»,— дип яза Альтман. Америка госпитальләрендәге шикелле гел буяу белән буяп торасы да юк. Операция бүлмәсе Германиянең «Симменс» фирмасы тарафыннан, аларның дизайны буенча төзелгән. Бина барлык кирәк аппаратура тупланмасы белән тәэмин ителгән —ясалма йөрәк һәм үпкә (махсус машина), кан басымы, йөрәк тибеше, ЭКГ һәм башка

яшәү өчен иң әһәмиятле күрсәткечләрне күзәтеп тору өчен мониторлар, рентген җайланмалары, тагын әллә нинди түшәмнән асылынып торган лампалар өстенә беркетелгән камералы телевизион мониторлар һ.б. Аппаратураларның күбесе Германия һәм Англиядә эшләнгән.

Альтман тасвирлаган бу операция бүлмәсе, элеккеге СССР Сәламәтлек саклау министрлыгының Дүртенче баш идарәсе начальнигы булган, Брежневтан башлап барлык хөкүмәт башлыкларын да дәвалаган академик Евгений Чазовның кардиология үзәгендә урнашкан. Америка табиб-репортеры Чазов үзәген: «Русия стандартларына туры китереп ясалган чиста һәм зиннәтле бина. Холл һәм коридорларның стеналарына мәрмәр һәм керамик плитә җәелгән, ә Акчуринның офис ишегалдында паркет».

Альтманның язуына караганда, Чазов үзәген, Ельцинның консультантлары командасы белән җитәкчелек иткән табиб Андрей Воробьев эшләгән караңгы, күңелсез, иске кан авыруларын өйрәнү (гемотология) институты белән чагыштырып карасаң — җир белән күк арасы, диярсең. Иң кирәкле даруларның, җайланмаларның булмавы, институтның ярты гасыр буена бер генә мәртәбә дә ремонтланмавы турында зарланганнар Альтманга институт табиблары. Ярым караңгы коридорларда кешеләр бер-берсенә килеп төртелә, чөнки коридорлар кирәгенчә яктыртылмый, һәр җирдә экономия.

Б.Ельцинга операцияне Чазов үзәгендә ясарлар, ахрысы, дигән булган Альтманга Акчурин. Чөнки операциядән соң авыруны күзәтү эшләре Кремль госпиталендә, Чазов үзәгенә караганда, начаррак куелган. Мәсәлән, Кремль госпиталендә анестезия белгечләре (анестезиолог) операция бетү белән эшләрен тәмамлап авыру яныннан китәләр һәм операциядән соңгы күзәтүләрдә катнашмыйлар, ә Чазов үзәгендә бу эш мәҗбүри.

«Йөрәккә шунт салу операциясе вакытында Акчурин микроскоп белән эш итә, бу алымны Америкада бик сирәк кардиохирург кына куллана»,— ди Альтман. Шуның өчен Акчурин «Казан фабрикалары» ярдәмгә чакырган да инде, анда аның махсус заказы буенча уникаль энә эшләп биргәннәр, ул гадәти энәләргә караганда өч тапкыр нечкәрәк, аннары аның өчен башка җиңел һәм уңайлы хирургия инструментлары да эшләп чыгарганнар, мәсәлән, карандашка охшаган кайчы, аны вакыт әрәм итеп ачып маташасы юк.

Казан инструментлары Акчуринга үтә нечкә җөйләр салырга ярдәм итәләр. Америка хирургларының күбесе шунт салганда микроскоп ярдәменә мохтаҗ түгелләр, лупа белән генә файдаланалар. Ә Акчурин лупаны эчке күкрәк артериясен кабырга читлегеннән чыгарганда гына куллана. Аяктан алган артерия һәм веналарны тегеп куйганда ул микроскоп куллана. «Йөрәккә салган җөйләр бик нечкәләр, аларны микроскоп белән эшләргә кирәк, моның нәтиҗәсе бик әйбәт», — дип аңлата Акчурин. Күпчелек Америка хирурглары моның белән килешмиләр. Алар уйлавынча, өч-дүрт мәртәбә зурайтсаң, лупа белән дә шул ук нәтиҗәләргә ирешеп була.

Бу араларда Акчурин Дебейки янына Хьюстонга барачак, Бэйлор медицина үзәгендә үз профильләре буенча техниканың яңа казанышла-

ры белән танышачак. Аннары ул Дебейки командасының берничә әгъзасы белән Мәскәүгә кайтачак, үзләре белән Акчуринда да, Чазов үзәгендә дә әлегә кадәр булмаган җайланмалар, мәсәлән, операциядән соң кризис вакытында пациентка ярдәмгә килү аппараты һ.б. алып кайтачаклар.

Табиб Акчуринның «Нью-Йорк таймс» корреспондентына хәбәр итүенчә, елга ул 650 пациентның йөрәгенә шунт сала. Операцияләрнең уңышлы үтүе һәм катлаулану очраклары буенча аның рейтингы АКШ һәм башка алга киткән илләр кардиохирургларыныкы белән тигез. Ләкин табиб Альтман ахырга таба өстәп куя. Бу фактларны раслаучы мәгълүматларны бәйсез чыганаклардан алганым юк».

Р.С.Акчурин белән әңгәмәдән.

## ЙӨРӘКНЕ АЛЫШТЫРЫП БУЛАМЫ?

*(Р.С.Акчурин белән әңгәмәдән)*

**— Президентка операция ясаган көннәрдә җәмгыять авызында имеш-мимешләр күп булды. Имеш, сез АКШтан хәзерге заман таләпләренә җавап бирә торган иң-иң яңа аппарат алып кайткансыз, ул тик шундый төр операцияләрдә генә кулланыла икән, андый аппарат әле Русиядә булганы юк...**

— Әйе, дөрес, «ясалма йөрәк» дигән аппаратны мин АКШтан алып кайттым. Берәр нәрсә була калса, саклык чарасын (подстраховка) күрү өчен пациентның хәле катлаулана башласа, аппарат ярдәмгә килә. Бәхеткә, аппаратның кирәге чыкмады. Операция вакытында һәм аннан соң да өзлегү (осложнение) фактлары булмады. Ул аппарат үзе музыкаль үзәктән зур түгел, тәгәрмәчләргә көйләнгән. Ул хәзер дә безнең операция бүлмәсендә тора. Кирәк булган очракта һәрбер кеше өчен әзер. Дөресен генә әйткәндә, «ясалма йөрәк»не безгә Бэйлор медицина колледжы бүләк итте. Бу бүләкнең бәһасе — 300 мең доллар. Аннары алар безгә 130 мең доллар торган эхокардиограф алып бирделәр. Бу прибор аркылы хирурглар пациентның йөрәк хәлен, торышын үңәч (пищевод) аркылы тикшереп карыйлар. Эхокардиографны без хәзер һәрбер операциядә дә кулланабыз диярлек.

Менә шундый бик кыйммәтле аппаратларны кулга төшереп калдык без ул көннәрдә, шөкер, кирәге чыкмый калса да.

Операциягә әзерләнгән көннәрдә матбугат битләрендә ачы тавыш купты: имеш, Президент өчен генә океан артыннан үтә кыйммәтле - җиһазлар кайтартканнар. Ачыклау өчен мисал китерәм: Б.Н.Ельцинга операция алдыннан мин Ганновер һәм Берлин клиникаларында булдым. Америка коллегаларыбыз безгә бүләк иткән «ясалма йөрәк» аппаратлары аларның йөрәк-кан тамыры бүлегендә 20 данә басып тора. Менә шулай. Безнең бөтен илгә бер.

Германиядә мин коллегаларыма мондый сорау бирдем: «Операция өчен пациент күпме түли?» Анда барысы өчен дә дәүләт түли. Кеше гомер буена медицина страхованиесенә акча күчерә, ә дәүләт үз чиратында медицина хезмәтен бушлай күрсәтә. Менә сиңа ерткыч, кансыз капитали-

стик дөнья һәм безнең «бушлай» медицина! Ләкин тәҗрибә күрсәткәнчә, Русия чиновниклары, авырулар турында түгел, медицина страхованиесеннән үз кесәләренә ничек өлеш кертү турында күбрәк уйлыйлар.

**— Йөрәк проблемасы хәзерге көндә иң зур проблемалардан саналамы?**

— Әйе, бу шулай. Мәсәлән, АКШта ел саен 200 мең кеше йөрәкне алмаштыруга мохтаҗ. Бу проблема аларда донорларга килеп терәлә. АКШта алар 2 мең кешегә якын. Русиядә йөрәкне күчереп утыртуны бөтенләйгә туктаттылар. Катлаулы мәсьәлә, әлбәттә. Беренчедән, күпләр аны шәфкатьсезлек, диләр. Икенчедән, йөрәкне күчереп утырту кыйммәт — 250 мең доллар тора. Безнең хөкүмәтнең андый акчасы юк. Ә ярлы халыкка каян килсен?

Дебейки, мәсәлән, киләчәк — медицина инженерлыгы кулында, дип раслый. Бу өлкә буенча бөтен медицина дөньясында эш алып барыла.

Бер егерме елдан йөрәкне ясалма йөрәккә алмаштыру гамәле гадәти күренешкә әвереләчәк, дип саный дөнья кардиохирургиясенә нигез салучы табиб Дебейки.

Ышанып әйтә алам, йөрәк аорта һәм коронар кан тамырларына шунт салу медицина өчен иң мөһим мәсьәлә. Без елга җиде мең операциягә кадәр җиткерәбез, ә 130 мең операция, йә күбрәк тә ясарга кирәк иде.

**— Йөрәк аорта һәм коронар кан тамырларына шунт салу бик кыйммәттер ул? Танылган кешеләрдән кемнәргә операция ясадыгыз?**

— Мин кайчандыр үз командам белән бергә В.С.Черномырдинга, О.И.Лобовка һ.б. операция ясаган идем. Әле беркөнне генә «Белое солнце пустыни» кинофильмының баш геройларыннан берсе булган «капитан Сухов»ка ясадым. Әйтәм бит, бу чагыштырмача кыйммәт операция. Әле хирургка һәм хезмәт күрсәтү персоналына түләгән хәерче эш хакын алып ташласаң да, 3 — 4 мең доллар түлисе. Бездә чит илгә караганда кыйммәткәрәк төшә. Чөнки операция ясау өчен бик күп әйберне без чит илдән валютага сатып алабыз.

**— Нәрсә, безнең илдә тиешле җиһазлар, материаллар бөтенләй юкмыни?**

— Чит ил клиникалары, институтларына караганда күп нәрсә әйбәтрәк. Ләкин барысы да берәр генә данә. Алга таба клиникаларны җиһазландыру, үстерү өчен... Әйе! Акча җитми. АКШта, мәсәлән, фәнгә бер елга 180 миллиард доллар сарыф ителә, ә бездә — 6 миллиард сум. Монда теләсәң, теләмәсәң дә: «Держава өчен күңел рәнҗи!» диярсең.

**— Сезнең дәрәҗәгез бу дөньяның бик зур кешеләре белән эш итәргә мөмкинлек бирә. Дөресрәге, алар сезнең белән эш итәргә омтыла. Сез аларга йөрәк хирургиясенең, гомумән, медицинаның авыр хәлдә икәнлеге турында сөйлисезме?**

— Сөйлим. Президент белән дә сөйләштек. Операциягә кадәр дә, соңыннан да. Ярдәм итәргә ышандырды... Минемчә, бүген илнең чалкан яткан икътисадын яңабаштан аякка бастырырга кирәк.

**— Сез гел минем команда дип сөйләргә яратасыз. Ул кемнәрдән гыйбарәт?**

— Минем командам — чыннан да алтын фонд ул. Монда бу мәкаль бик урынлы: «Один в поле не воин». Минем командам квалификацияле белгечләрдән, үз эшләренең осталарыннан тора. Команданың һәрбер әгъзасы — чын-чынлап оста. Баш хәреф белән. Болар: медицина фәннәре кандидаты А.А.Ширяев, бүлек җитәкчесе Королев, фәннәр докторы һәм кандидатлары Брандт, Евгений Абрамов, Марголина һәм Водясов; ясалма кан әйләнеше буенча табиблардан: медицина фәннәре кандидаты Портигулов, профессор Лепилин — анестезиолог-реаниматолог, табиб Елена Васильевна Филатова, шәфкать туташлары — Элла һәм Мария.

Бу команда белән мин 1984 елдан бирле эшлим һәм ел саен йөрәккә 200 — 240 операция ясыйбыз. 30 — 40 процент авыруларның операцияләре катлаулылыгы белән нәкъ Президентныкы шикелле үк.

**— Бу команданы сез үзегез үстердегезме?**

— Әйе, бу минем егетләр, минем команда. Бүген әле минем эшкә башларга әзер торган тагын ун аспирант һәм ординатура бетереп чыгучы бар.

**— Түрә пациентлар арасында дәвалаучы табибларга карата залимлык (деспотизм) күренешләре сизелмиме?**

— Киресенчә. Безнең югары дәрәҗәле, гадирәк итеп әйткәндә зур урындагы кешеләр югары культуралы һәм көчле холыклы кешеләр. Мин моны В.С.Черномырдин һәм башкалар турында да әйтә алам. О.И.Лобов исә, операциядән соң алтынчы көнне Куркынычсызлык Советының утырышында катнашты.

Ә Б.Н.Ельцинга килгәндә, ул бик көчле шәхес. Ул үз-үзенә генә залимлек кыла. Борис Николаевич бик тә тыңлаучан пациент. Б.Н.Ельциннан да яктырак һәм акыллы кеше очратканым юк әле минем.

Белгәнебезчә, операция алдыннан Борис Николаевич Барвихада кунды, анда көндез табиблар консилиум үткәрделәр һәм пациентның алдагы ир-ат катлаулы операциягә әзер икәнлеген әйттеләр. Б.Н.Ельцинның күңеле күтәренке иде, табибларның рухын күтәрер өчен шаяртып сөйләште. Медицина үзәгенең җитәкчесе Сергей Мироновны күргәч, елмаеп сорап та куйды: «Нәрсә, сез пычак беләнме инде?»

**— Сез үзегезнең «сыйфат билгесе» өчен барыбер җаваплы. Вакыт-вакыт пациентыгызга кергәләп йөрисездер?**

— Билгеле. Кайвакытта ул үзе кардиоүзәккә керә, кайвакытта мин аңа барам. Президентның сәламәтлеге бүген нормаль хәлдә. Теге вакытта аны үпкә авыруы азрак йончытты. Хәзер, Аллага шөкер, барысы да үтте, артта калды. 10 — 15 ел тулы канлы актив хезмәт еллары белән тәэмин ителгән ул. Операциядән соң пациентларның күбесе йөгерәләр, теннис уйныйлар, мәсәлән, В.С.Черномырдинны алыйк, ул шундый ук операцияне сигез ел элек кичерде.

**— Ельцин палатасында хәзер кем ята? Шул бүлмәдә яткан дәваланучылар моңа ничек карый?**

— Авыру кешегә кая ятса да барыбер, тик нормаль шартлар гына булсын. Бу вакытта кеше тормышы, яшәү турында гына уйлана.

**— Операция вакытында тулаем тынлык астында эшлисезме, әллә музыка уйнап торамы?**

— Әкрен генә җиңел музыка уйный. Гадәттә бу классика. Президентка операция вакытында «Испан гитарасы» (Вивальди), башка классик һәм хәзерге заман музыкасы яңгырады.

**— Русия Президентына операция ясарга ризалык белдергәч, моның никадәр җаваплы эш икәнлеге турында үз-үзегезгә хисап бирдегезме?**

— Чынлап әйтәм, ул вакытта мин аның турында уйламаска тырыштым. Мин аңа гади пациентка караган кебек карадым. Эшләнгән эшнең җаваплылыгы һәм әһәмияте турында мин соңыннан гына уйландым. Күптән түгел мине Медицина фәннәре академиясенең утырышында Русия медицина фәннәре академиясенең әгъза-корреспонденты итеп сайладылар. Менә шунда гына эшләгән эшемне бәяләп бетермәгәнмен икән, дип уйландым. Олы академиклар мин эшләгән эшнең техник яктан эшләнешен генә түгел, ә аны эшләргә алынуга батырчылык итүне зур әһәмияткә ия, диделәр.

Чыннан да, мин бу операцияне бик яхшы эшләдем, чит илдә, бәлки, бу кадәр үк уңышлы да чыкмас иде. Мин һәрвакыт ассызыклап киләм, безнең белгечләр чит илнекеләргә караганда яхшырак эшлиләр. Аларга шартлар гына җитми.

**— Президентка операция ясалган көннәрдә Дәүләт Думасында хөкүмәт җитәкчеләренең сәламәтлеге турында белешмә алу өчен махсус комиссия төзергә кирәк, дип зур истерика купты. Бу күренешкә сезнең мөнәсәбәтегез ничек?**

— Тыныч мөнәсәбәттә. Кем әйтмешли, ул эшне әле бүген түгел, кичә үк эшләргә кирәк иде, әлегә кадәр кая караганнар соң? Бик күп илләрдә бу эш күптән практикага кертелгән. Минемчә, медицина комиссиясен барлык депутатлыкка кандидатлар да сайлауларга кадәр үк үтәргә тиешләр. Сайлауга кадәр, йә булмаса эшкә билгеләнгәнче үк. Халык үзенең язмышын психик яктан сәламәт, физик яктан көчле кешеләр хәл итә икәнлеген белеп торырга тиеш. Автомобиль йөртү хокукын, аучылык билетын, хәтта базарда әйбер сату өчен кәгазь алу өчен дә кешеләр мең комиссия үтәләр. Җитәкчелек постына сайлану өчен йөрәк авыруы киртә була алмый, дип саныйм мин. Ә Дәүләт Думасының Президентка җитди операция ясалганын белә торып, шул форсаттан файдаланып аның сәламәтлеге турында белешмә таләп итүе — ул сәяси уен, пычрак тамаша һәм әдәпсез шау-шу. Истән чыгармыйк, без барыбыз да җир кешеләре, Алла коллары...

## ДОКТОР МАЙКЛ ДЕБЕЙКИ — ТЕХАСНЫҢ БӨЕК ШӘХЕСЕ — РЕНАТ АКЧУРИННЫҢ ОСТАЗЫ.

Бэйлор колледжы гасыр башында, ягъни 1900 елны төзелгән... Ул халыклар медицина Мәккәсе. Башта ул Далласта урнашкан булган, ә 1943 елда Хьюстонга күчерелгән. Бэйлор колледжында укыталар, дәвалаunion һәм фәнни-тикшеренү эшләре алып баралар. Ул 50 фәнни

һәм уку-укыту үзәген берләштерә, аның еллык бюджеты 180 миллион доллар тәшкил итә.

Арттырып әйтүем түгел, колледжның төп хәзинәсе булып Дебейкиның кардиология үзәге тора. Ул АКШтагы йөрәк, үпкә һәм кан буенча ике институтны бергә берләштергән өч үзәкнең берсе булып санала: беренчесе — атеросклероз, икенчесе — тик йөрәк авырулары белән генә шөгыльләнә. Әгәр бу медицина үзәге Бэйлорның аяз күге булса, Дебейки аның якты йолдызы. Аның даны бөтен дөньяга таралган. Студент вакытта ук ул насос уйлап тапкан, соңыннан ул насос «йөрәк-үпкә» машинасының төп компоненты булды. Ул машина ярдәмендә йөрәккә ачык килеш операция ясау мөмкинлеге туа, шул ук «байпас» алымы Президентка операция ясаганда кулланырга да рөхсәт ителгән иде.

Дебейки ясалма йөрәк ясау өлкәсендә пионер, ул аны беренче мәртәбә кешеләрдә кулланучы да. 1953 елда Дебейки инсультка (мидәге кан әйләнешенең бик нык бозылуы) бик уңышлы операция ясый, димәк, инсультны хирургия юлы белән дәвалау мөмкинлеген дә ачучы ул.

1968 елда аның җитәкчелегендә фантастик дәрәҗәдәге мультитрансплантация ясала, ягъни бер үк донорның йөрәге, үпкә һәм бөерләре берьюлы дүрт кешегә күчереп утыртыла. Бу операция — Дебейкига күрсәтелгән барлык дан-шөһрәтләрдән дә югарырак — президентлардан Гувер һәм Джонсонның киңәшчесе булу, Азатлык медале кавалеры — АКШның иң югары бүләге, Ласкер исемендәге премия лауреаты (Нобель премиясенә тиң), дөньядагы бик күп Академияләрнең мактаулы академигы һәм докторы булудан да өстен. Ул 1300 фәнни эшнең авторы. 50 дән артык оригиналь хирургия инструментын уйлап табып, гамәлгә керткән кеше.

«Мин бик күп Русия хирургларын беләм,— ди Дебейки,— алар белгечлеге ягыннан һич тә Америка хирургларыннан ким түгел. Мисал өчен Ренат Акчуринны әйтә алам. Мин Ренатны эштә сынап карадым. Ул миндә — Бэйлордта — зур практика үтте... Акчуринны Президентка операция ясаячак, дип әйтәләр».

Шул ук кардиохирург Ренат яки йөрәк хәлләре турында...

## ЙӨРӘК ҺӘМ МИ

**— Хәзер операцияләрне бик еш ясарга туры киләме?**

— Кызганычка каршы, бик еш. Үз клиникамда атнага 4-5 операция ясыйм. Әле бер-икене башка клиникаларда ясарга туры килә. Үзегез беләсез, һәрбер операциягә әллә ничә сәгать вакыт китә.

**— Сезне хәзер операция ясарга бик күп җирләргә, шул исәптән чит илләргә дә чакыралардыр?**

— Әлбәттә, чакырулар бик күп һәм бик файдалы һәм уңай шартларда. Чынлап әйтәм, күбрәк операцияне үз илебездә эшлисе килә. Шул максаттан чыгып, тиз араларда минем команда Казан клиникалары һәм хастаханәләрендә операция ясарга барачак, шулай ук Томск,

Төмән һәм Әлмәт шәһәрләренә бару да планлаштырылган. Әйе, гаҗәпләнмәгез, татар нефтьчеләренең башкаласы Әлмәттә дә операция ясарга план кордык. Нефтьчеләр Әлмәттә Америка белгечләре белән бергәләп специальләштерелгән госпиталь төзиләр. Мин моны — акчаны кирәк эшкә салу, дип саныйм. Теләк булганда, җирле хөкүмәт башлыклары эшкуарлар белән берлектә медицина мәсьәләсендә бик зур эшләр башкара алырлар иде. Мәсәлән, Тула, Томск һәм Төмән шәһәрләрендә башкала медикларының исен китәрерлек бай җиһазландырылган клиника һәм шифаханәләр бар.

**— Хәзер матбугат битләрендә «акыллы башларның» Русиядән бик күпләп читкә китүләре турында язалар. Билгеле, бу хәл медицина хезмәткәрләренә дә кагыладыр...**

— Һичшиксез. Медицина йолдызларының шактые океан артына китеп югалды. Минем коллегаларымның күбесе Израильдә хезмәт итә. Ләкин аларның күбесенең кулларында Америка, Израиль дипломнары булса да, үзләренә җан азыгы һәм хезмәтләреннән рәхәтлек тапмый интегәләр.

Менә, мәсәлән, минем хөрмәтле укытучым, профессор Крылов. Медицина өлкәсендәге беренче адымнарымны мин аның җитәкчелегендә ясадым: ординатура, аннары кече һәм өлкән хезмәткәр булып эшләдем. Без аның белән иң нечкә тукымаларны, вена һәм артерияләрне тегеп куя идек, үз вакытында ул да Израильгә китте. Күптән түгел хат алдым, яңадан Русиягә кайтырга җыенып йөри. Кызганычка каршы, илне ташлап киткән бик күпләр чит илләрдә психологик яктан яраклашып бетә алмыйлар.

Ахыр чиктә эш «акыллы башлар»ның китүендә түгел, ә медицинаның ифрат дәрәҗәдә ярлы булуында. Безнең медицинаның хәле бүген яңа үсеп килә торган Африка илләрендәгедән дә начарraктыр.

**— Матбугатта мондый хәбәр күзгә чалынды, имеш, Дебейки Интернет буенча лекцияләр укый. Бу хәбәргә сез ничек аңлатма бирәсез?**

— Бу медицина практикасында үзенә күрә бер революция. Мондый медицина ярдәмен безнең илдә дә кулланасы иде, бу иярчен аша элемтәгә караганда йөз мәртәбә арзанракка төшә. Мәскәүдә Интернет буенча консилиум үткәрүче ярымлегаль шәхси фирмалар эшли башлады инде. Билгеле, зур акча түләп... Ләкин, бездә ул әле зур супермаркет кибете янында бәләкәй коммерция кибете торган шикелле генә булса да — барыбер яхшы.

## ЙӨРӘК ЭШЛӘРЕ
## (ШУЛАЙ УК ӨЙ ҺӘМ ГАИЛӘ ТУРЫНДА)

**— Хатыныгыз белән кайчан һәм кайда таныштыгыз?**

— Латин Америкасында. Перуда. 1970 елның җәендә. Хәтерлисезме, ул елны Перуда көчле җир тетрәү булды һәм бик күп кеше һәлак

булды. Совет хөкүмәте шулчак медицина хезмәте күрсәтергә дип, Перуга медицина персоналы туплап, госпиталь җибәрде. Җәй көне булганга, студентларның кайсысы өйләренә, кайсы төзү отрядлары белән эшкә таралып беткәннәр иде. Кыр госпитален комплектлаштыру өчен Мәскәүдә калган студентларны тулай торраклардан эзләп йөрделәр. Мине Беренче медицина институтының, ә булачак хатыным Наташаны Икенче медицина институтының тулай торагыннан табып алдылар.

Ауган йорт өемнәрен казыячакбыз, сүтәчәкбез, диделәр. Асылда, хәрабәләр дә сүттек, зыян күргәннәргә медицина ярдәме дә күрсәттек, шәм һәм фонарь яктысында операцияләр ясадык. Булачак медиклар өчен бу бик яхшы практика булды. Экзотик илнең менә шундый уңайсыз шартларында без Наташа белән таныштык. Анда без өч ай булдык. Мәскәүгә кайткач өйләнештек. Наташа хәзер балалар күзен дәвалаучы табиб, Мәскәүнең бер поликлиникасында эшли.

**— Ә балаларыгыз нәрсә белән шөгыльләнә?**

— Олысы Максим — Коммерция югары уку йортын тәмамлады, кардиоүзәк каршындагы уртак предприятиедә эшли. Медицина бизнесы белән шөгыльләнә. Бу төр бизнес безнең илдә беренче адымнарын гына атлый әле. Кечесе, Андрей — медицина институтын тәмамлады.

**— Сез автомобильләр белән мавыгасызмы?**

— Бу эшкә бик һәвәс мин. Брежневтан һич ким түгел, ләкин минем мөмкинлекләрем генә генсекныкы кебек түгел. Гомумән, егерме еллап машина йөртәм.

**— Беренче автомашинам «копейка» иде, дип әйткән идегез бер әңгәмәгездә. Нәрсә, ул «мерседес»ның беренче чыгарылышымы?**

— (Озак итеп, рәхәтләнеп көлә.) Шулай ди. Ул «Жигули»ның беренче моделе. Әйбәт машина иде. Озак еллар хезмәт итте. Аннары «Газ-2410» маркалы «Волга» машинасы алдым. Анысы да яхшы иде, ышанычлы хезмәт итте. Прицеп тагып, мин аның белән дачага барлык төзү материалларын ташыдым. Егермешәр капчык цемент төягән чаклар булды. Хәзерге машинам «Мицубиси». Бик шәп машина, тотылганны алган идем алуын.

**— Сезнең дачагыз еракмы?**

— Нахабино ягында. Гап-гади авылда, гап-гади авыл өе, зур бакчасы бар.

**— Үзбәкстанда туып, озак еллар шунда яшәгән кешеләр телне йотарлык пылауны үзләре әзерлиләр. Миңа калса сез дә үзегез пешерәсездер сыман?**

— Тыйнаксызлык булса да, мактана алам, пылауны мин искиткеч тәмле, нәкъ үзбәкчә пешерәм. Мин пешергән башка Шәрык азыклары да ярыйсы гына килеп чыга.

**— Ә татар милли ашлары белән ничегрәк?**

— Миңа үзебезнең милли азыклар бик тә ошый. Минем әти-әниләрем моңа бик осталар иде. Хәзер бу эштә олы абыемның хатыны Фәүзия ярдәм итә, ул татар халык ашларының тылсымчысы. Күрәсезме, мине тәмле тамак дип әйтергә була (көлә). Ләкин, кызганычка каршы, мондый күңелле шөгыльләргә минем вакытым җитешми.

**— Сезнең хоббиегез? Театрларга, югары җәмгыять (свет) мәҗлесләренә, ауга, балык тотарга йөрергә вакыт таба аласызмы?**

— Хобби (көлә). Сүз тапканнар да инде. Наташа оештырса, кайчакларда театрларга баргалыйбыз. Мәҗлесләрдә дә булгалыйбыз. Ләкин болар минем табигатемә туры килми. Аучылык белән аз-маз вакыт туры килгәндә шөгыльләнәм. Гомумән, мин табигать кочагында булырга яратам.

**— Саубуллашыр алдыннан медицина турында бер анекдот сөйләгез әле...**

— Ике «яңа рус» этләрен урамга алып чыкканнар, имеш. Берсе — алтын чылбыр белән чылбырланган берьюлы ике питбульлар тотып чыккан. Икенчесе — бәләкәй такса белән, анысы да алтын бәйдә.

— Нәрсә мондый бәләкәй эт — такса алдың? Бакслар җитмәдеме?

— Әйдә бәхәсләшәбез, минем такса бер минут эчендә синең ике кеше ашаучы питбульларыңны чәйнәп йота.

— Әйдә, — дип килешә «яңа рус».

Такса чыннан да берничә секунд эчендә кеше ашардай ике этне кабып йота.

— Каян мондый такса алдың? — дип гаҗәпләнә «яңа рус», кулындагы алтын чылбырларны кыса төшеп.

— Һи! Өч мең долларга крокодил сатып алдым да, биш мең түләп хирургтан пластик операция ясаттырдым, — дигән тегесе.

## ЙОМГАКЛАУ УРЫНЫНА. ЙӨРӘК НӘКЪ 68 МИНУТКА ТУКТАП ТОРДЫ

Русия өчен генә түгел, ә бәлки бөтен дөнья өчендер, 1996 елның 5 ноябре гадәти көн генә булмады. Президент Борис Ельцин үзенең вәкаләтләрен һәм кара әрҗәне вакытлыча Премьер-министр В.С.Черномырдинга тапшыру турындагы Указга кул куйды. Президентның йөрәгенә операция 6 ноябрьдә иртән сәгать 7 дә башланды.

Аның йөрәге нәкъ 68 минутка тукталып торды. Кардиоүзәккә керү юллары автоматлар белән коралланган милиция хезмәткәрләре белән чолгатылып алынган иде.

Язмышның мыскыллы көлүеме, әллә алдан әзерләнгән план буенчамы, белмим, ул көнне Русиянең Бәйсез Профсоюзлар Федерациясе икътисадны күтәрүне таләп итеп бөтен ил буенча пикетлар, забастовкалар оештырдылар. Дәүләт Думасындагы ал төсләр һәм кызыллар йөрәге туктатылган Б.Н.Ельцинны Президентлыктан алып атырга кирәк, дип котырындылар. Шулай туры килергә кирәк бит, ул көнне Америкада президент сайлаулары булды. Галәмәт күп тавыш җыеп, сайлауларда Билл Клинтон җиңеп чыкты. Борис Ельцинны ул беренче кеше булып уңышлы үткән операция белән котлады. Котлаулар шулай ук Германия, Франция, Англия һәм башка илләрдән дә килде.

Операция вакытында, кардиоүзәктә, Президентның хатыны Наина Иосифовна һәм кызлары булдылар. Операция 14.00 сәгатьтә тәгәлләнде.

13 сәгать 15 минутта кардиоүзәккә Премьер-министр В.С.Черномырдин һәм Президент администрациясе башлыгы А.Чубайс килделәр.

Шушы ук көнне 1996 елның 6 ноябрендә, Октябрь революциясе бәйрәме алдыннан Русия телеканалы буенча, элек программага кертелгән «Аншлаг» урынына, «Русия бишьеллыгы» исемле тапшыруны әйләндерделәр. Борис Ельцинның Татарстанга һәм Свердловскига визитларын да күрсәттеләр.

Гайдар, Бурбулис һәм Панфилова белән төшкән кадрлар экранда күренеп китте.

Ә шул шау-шуның сәбәпчесе булган кеше ул мизгелләрдә кардиоүзәк палатасында тын гына, әкрен генә, ләкин зур ышаныч белән бик катлаулы операциядән исән-имин котылып хәл җыеп ята иде.

1996 елның 8 ноябрендә Б.Н.Ельцин иртән сәгать 6 да уянды һәм мөстәкыйль рәвештә сулыш алуга күчте. Президент шул көнне вәкаләтләрен вакытлыча тапшырып тору турындагы Указны гамәлдән чыгару турындагы Указга кул куйды.

— Операция искитәрлек дәрәҗәдә уңышлы чыкты, көтелгәннән дә күпкә әйбәтрәк, — диде операция барышын күзәтеп утырган Майкл Дебейки.

Ул көннәрдә без Президентның көч-куәтенә һәм кардиохирург Р.С.Акчурин һәм аның командасының фидакарьлегенә сокланып таң калдык.

Без, Русия медицина Академиясенең хакыйкый әгъзасы Ренат Сөләйман улы Акчуринның якташлары, аның батырлыгына һәм һөнәри осталыгына карап сокланабыз, аңа нык сәламәтлек, ак бәхетләр телибез!

* * *

## ТАТАРСТАНДА ОЧРАШУЛАР

Русия Президенты Б.Н.Ельцинга операция ясаганнан соң, 1997 елның 11 июнендә Ренат Сөләйманович Татарстанга беренче тапкыр кунакка килде. Ул медицина инструментлары эшләү заводында булды, Казанның истәлекле урыннары белән танышты. Хәтта Иделдә балык тотарга да вакыт тапты. 15 июньдә Чаллыярда үткәрелгән Сабан туен зур кызыксыну белән карады. Соңгы елларда Ренат Сөләйманович һәм аның бертуган абые Рәсим Сөләйманович безнең республикада бик еш кунак булалар. Аларга бездә булган яхшы яңалыклар бик ошый.

*Июль, 1997 ел.*

## Тинчуриннар Ростов-Донда

Менә мин яңадан ничәмә-ничә йөз еллар элек борынгы бабаларыбыз яшәгән Тын Дон буена урнашкан Ростов шәһәрендә. Монда XX гасырның күренекле шәхесе драматург Кәрим Тинчуринның туганы (бертуганының улы) Хәсән Юныс улы Тинчурин яши. Язучының бик күп истәлекләр һәм архив документларын саклаучы бу кеше малай чагыннан ук күпне күргән: башта Сталин, аннары Гитлер лагерьларында үлемнең салкын пыяладай күзләре белән берничә тапкыр очрашкан.

Хәсән абыйның әтисе Юныс белән Кәрим Тинчурин бертуган булганнар икән. Олы абыйлары Габделкәрим япон сугышында Русия империясенең иминлеге өчен көрәштә һәлак булган.

Акыл төзелеше, фикер сөреше һәм характерлары буенча абыйлыэнеле Тинчуриннар бер-берсеннән нык аерылып торсалар да, язмышлары бер үк төрле: Юныс та, Кәрим дә Сталин репрессияләре чорында юк ителәләр.

1896 елда туган кече энеләре Юныс, Свердловск ягына сөргенгә озатыла һәм 1932 елны тайга урманнарында эшләп йөргәндә ачлыктан үлә. Ә Кәрим 1937 елда кулга алына һәм 1938 елда халык дошманы дип гаепләнеп атып үтерелә.

Шушы ук елны Урал тайгасында әтиләре Гали бабайны да сталинчылар атып үтерәләр.

## СТАЛИН ЛАГЕРЬЛАРЫНДА...

Утыз беренче елның чатлама салкын кыш көне иде. НКВДның коралльы вәкилләре Тинчуриннарның гаиләсенә — 68 яшьлек гаилә башлыгы Гали бабайга, 35 яшьлек улы Юныска һәм аның 7 яшьлек оныгы Хәсәнгә юлга җыеныр өчен барлыгы берничә сәгать вакыт бирәләр. Раскулачивать итү барышында НКВД хезмәткәрләре иң беренче чиратта мөселман руханиларын кулга эләктерә иделәр, алар «яңа» тормыш төзүгә каршы коткы тараталар, имеш. Сөргенгә куу өчен иң «уңай» вакытны да сайлап ала белгәннәр, чатлама салкында урманга, йә булмаса чокыр-чакырга төшеп качарга бик теләмәссез, янәсе.

НКВД коралльы гаскәрләренең кайвакытта «киң күңелле һәм үтә гуманлы» булуларын күреп шаккатасың. Менә бит әле Юнысның йөкле хатынын да тайгага сөргенгә җибәрүдән азат иткәннәр, аның карамагында әле әтисез калган уллары: дүрт яшьлек Хөсәен һәм бер яшьлек Әбүбәкер дә бар. Соңыннан урындагы хөкүмәт башлыклары аны ире

белән рәсми рәвештә аерылышу турында гариза язарга мәҗбүр иткәннәр. Иреннән аерылып, аның туганнары белән араны өзгәндә генә аңа авылда яшәп калырга рөхсәт итeләчәк. Ни хәл итсен инде, яшь хатын намусына каршы килсә дә, балалары хакына хурлыклы бу эшне эшләргә ризалык белдерә.

Ул елларда алар яшәгән Таракановка авылы Пенза өлкәсенең Керенский районына керә булган.

Соңыннан район исеме большевиклар әмере белән, гәрчә аның 1917 елдагы вакытлыча хөкүмәт башлыгы Керенский фамилиясе белән бернинди уртаклыгы булмаса да, Беднодемьянский дип үзгәртәләр. Бу факт — Сталинның өстен хокукларыннан (привилегия), ягъни Кремльдәге фатир, махсус паек, дача һәм башкалардан оста файдаланучы трибун шагыйрьнең исемен мәңгеләштерү иде.

Таракановкада елганы туфрак өеме белән киртәләп, авылны икегә бүлеп торган ясалма сулык ясадылар һәм аны күл дип атадылар. Ә авылны Белозерски дип исемләделәр. Әкияттәгедәй бу матур җирләр Пенза өлкәсенең төньягында, Мәскәү — Самара — Уфа автотрассасы буенда, Темников шәһәре тирәсендә урнашкан.

Сөргенгә озатылучыларны Пенза аркылы алып киттеләр. Беренче мәртәбә тимер юл вокзалы күргән Хәсәнгә бик кызык булып тоелды. Пыхылдап пар атып утырган паровозларны күреп шаккатты малай. Шушы көннең кышкы күренеше мәңгегә күңеленә сеңеп калды аның. Ул аны Гитлер лагерьларында газап чиккәндә дә, ачлык елларда бер кисәк ипигә тилмергәндә дә күз алдына еш китерде. Хәзер дә әле еш кына төшенә керә. Ә менә поездлардагы терлек ташый торган вагоннардагы ышкыланмаган тактадан ясалган ятак сәкеләрдән борынны кытыклап нарат исе килә.

НКВД хезмәткәрләре йомшак күңеллелек күрсәтеп вагон идәннәренә салам китереп җәйделәр, тәрәт итү өчен тәпәннәр куйдылар, туннары, киез итекләре булганнарга аларны кияргә рөхсәт ителде.

Тауар поезды яңа социалистик тормыш дошманнарын төяп каядыр еракка, Свердловск тайгасына таба ыргыла, юлда очраган вак-төяк тукталышларда да тәүлекләр буе туктап торулары җанга тия башлады, азык-төлек тәмам булды, әсирләр су урынына кар ашарга ябыштылар. Үләт котырынырга тотынды. Тимер юл станцияләрендә әсирләрне махсус җиггүле атлар каршылады. Үлекләрне чаналарга төяп билгесез юнәлешкә таба алып киттеләр. Ә поезд әлеге исән калган әсирләрне төяп тәгәрмәчләрен салкын рельсларга бәрә-бәрә төньякка таба баруын дәвам итте.

Айлар буена юлда алҗып, ачлыктан чат сөяккә калган әсирләрне, ниһаять, иксез-чиксез тайгадагы адәм заты күренмәгән бер кечкенә генә станциягә китереп төшерделәр. Кар көртләрен ера-ера торак урынга барганда әсирләр стихияле рәвештә икегә бүленделәр һәм исән калуларына сөенешеп һәр ике як үзенчә Аллага табына башлады: татарлар азан әйтә, урыслар иелә-бөгелә чукына иделәр. Шушы кыен вакытларда кешеләрне Тәңре үз канат астына ала, берләштерә сымак иде.

Шуннан соң «халык дошманнарын» олауларга төяп тайга уртасына ташландык баракларга илтеп тутырдылар. Ягылмаган салкын вагоннарга караганда, монда җәннәт иде. Олылар икенче көнне үк урман кисәргә тотындылар, тагын ике торак йорт төзелде.

Әтиләре еш кына авыргалап алды. Шуңа да карамастан бабасы, әтисе һәм Гайшә апалары ялсыз-нисез урман кистеләр. Бәләкәй Хәсән йорт эшләре белән мәшгуль иде. Үтә дини кеше буларак, бабалары Сталин лагерьларында да шәригать кануннарын тотты, яшьләрне дингә өндәде.

Ике елдан соң җитмеш яшьлек Гали бабайга һәм оныгы Хәсәнгә туган авылларына кайтып китәргә әмер бирелде. Таракановкага кайткач, Хәсән мәктәпкә укырга керде. Бабалары җимерелеп бетә язган йорт-җирне төзәтергә кереште, аннары мәчетне карады һәм авылдашларын дини йолаларны үтәргә чакырды. Ләкин «кулак» һәм «халык дошманы» ярлыгы гомер буена муенга тагылып калды.

Якты, бәхетле киләчәк төзүчеләр һәрдаим аның йөзенә бәреп әйтеп килделәр: «Кара син, Аллаң белән бик маташма, тагын эләктерүләре бар!».

Тиздән Урал ягы сөргеннән әтисенең сеңлесе Гайшә апа кайтты һәм Юнысның абыйсының үлгәнлеге турында хәбәр итте. Шулай итеп, Кәримнең тагын бер туганы дөнья куя.

Утыз җиденче ел Тинчуриннар гаиләсенә тагын да зуррак, авыррак хәсрәтләр алып килде. Тынгы белмәс бабаларын халыкны «дини агу» белән агулаган өчен тагын кулга алдылар. Бу юлы аны Советка каршы пропаганда эше алып баруда гаепләделәр. Соңыннан гына, илдә Горбачев үзгәртеп кору җилләре исә башлагач кына, Хәсән Гали бабайның Тамбов өлкәсендәге бер төрмәдә атып үтерелгәнен ачыкланды.

— Ул елларда Кәрим Таракановкага килгәләдеме соң? — дип сорыйм мин әңгәмәдәшем Хәсән Юнысовичтан. — Синең һәм аның гаиләсе арасында элемтә сакландымы?

— Юк, килмәде,— ди. Бабасының әйтүенә караганда, Кәрим соңгы мәртәбә туган авылына 1923 елда кайткан булган икән. Әмма туганнары һәм авылдашлары белән элемтәне өзмәгән. Язышып торган.— Мин үзем, шәхсән, аның хатыны Зәһидә ханым белән хат алышып тордым. Ул миңа Кәримнең китапларын җибәреп торды.

Кулга алынганчы Гали бабай улы Кәримгә Казанга кунакка барды. Бик канәгать булып кайткан иде. Күрәсең, ул вакытта инде танылган драматург Кәрим һәм килене Зәһидә бабайны бик җылы каршылаганнардыр. Бабай Таракановкага бик зур капчык күтәреп кайтты. Бушатып карасалар, анда Кәримнең әсәрләре басылган китаплар.

— Тфү, шайтан! — дип, чын йөрәктән төкеренеп куйды бабай. Бер кила конфет куйсалар иде, ичмасам, ди.

Ә Хәсән шатлыгыннан ни эшләргә дә белмәде. Бу китаплар белән ул мәктәптә бик озак мактанып йөрде. Ул вакыттагы мәктәп директоры

Рәшит Мозаффаров китапларны мәктәп китапханәсенә тапшыруны күз яше белән ялынып сорады, чөнки ул елларда китапларга бик кытлык заман иде. Мондый бүләккә укытучылар бик нык шатландылар, укучылар инде җиде кат күктә иделәр.

Шуннан бер ел вакыт үттеме-юкмы, 1937 елның сентябрь аенда, Хәсән укыган класска Кәрим Тинчурин китапларын күтәреп мәктәп директоры һәм укытучылар килеп керделәр.

Мәктәп директоры Рәшит Мозаффаров сискәндерерлек итеп әмер бирә:

— Хәсән Тинчурин, торып бас!

Бөтен класс алдында, күзләрен усал ялтыратып мәктәп директоры газетадагы мәкаләне укып чыкты һәм:

— Хәсән Тинчурин! Синең абзыең язучы Кәрим Тинчурин, халык дошманы булып чыккан. Менә монда, газетада басылган. Хәзер мәктәптән чыгабыз һәм син үз кулларың белән абзыеңның китапларын яндырачаксың...

Мәктәп ишегалдында барлык укучылар да җыелган. Кәрим Тинчурин китапларын бер өемгә өеп куйганнар. Мәктәп директоры Хәсәнгә шырпы сузып:

— Башла!

Йөрәк рәнҗеде, күздән елга булып яшьләр акты. Хәсәннең куллары калтырады, шырпы кабыза алмыйча азапланды.

Менә китапларга ут капты. Мәктәп директорына ияреп кул чаптылар, шулай итеп, 1937 елны туган авылы Тaракановкада Кәрим Тинчурин китапларына аяусыз каты җәзалау акты оештырылды.

Ә Кәрим Тинчуринның үзен 1937 елның 18 сентябрендә кулга алдылар һәм шушы ук елны атып үтерделәр. Бу хакта Казанда бик күп бәхәсләр дә булды. Кайберәүләр исбат иткәнчә, Кәрим Тинчурин Сталин лагерьларында сугыштан соң гына һәлак булган, имеш.

Юк, дөрес түгел бу! Эш болай ки, Кәримнең якын туганы Шакир Үтәмешев НКВДның полковнигы дәрәҗәсенә кадәр үсә, һәм илленче еллар уртасында ул яшерен документлар яткан архивларга керү бәхетенә ирешә. Гали бабайның һәм аның улы Кәримнең гаепләнү материаллары белән таныша һәм аларның 1938 елда атып үтерелгәнлекләрен ачыклый. Заманында бу турыда Шакир Үтәмешев бик зур сер итеп кенә Тинчуриннарның туганнарына, шул исәптән, Хәсән Юнысовичка да хәбәр итә.

## ГИТЛЕР ЛАГЕРЬЛАРЫНДА

НКВД хезмәткәрләре талап бетергән авылда яшәп калуның кирәге калмый, өстәвенә әле «халык дошманы» баласына. Шуны исәпкә алып, 16 яшь тулу белән Хәсән Ростовка артиллерия училищесына укырга китә. Гайшә апасы да шунда яши.

Лəкин Ростовка керəсе юлда, Хəсəн утырып барган поездны тупикка кертеп бастырдылар һəм 15 көн буена эшелоннар көне-төне Мəскəүдə ачылачак беренче Сталин күргəзмəсенə азык-төлек һəм башка йөк ташыдылар. Билгеле инде, Хəсəн имтиханнарга өлгермəде. Мəктəпне тəмамларга һəм берьюлы ФЗОны да бетерергə булды.

Инде тормыш юлына аяк басам гына дигəндə, сугыш башланып китте. Халык ополчениесе составы белəн Хəсəнне Ростов-Дон тирəсендə окоплар казырга җибəрделəр. Көтмəгəндə дошманның артиллерия гаскəрлəре шəһəргə һөҗүм ача. Хəсəн һəм аның иптəшлəре дошман кулына пленга төшəлəр. Оккупантлар əсирлеккə төшкəн яшь егет-кызларны эшелоннарга төяп, бик нык коралланган сакчылар астында Германиягə алып китəлəр. Шулай итеп, Хəсəн Тинчурин өчен тагын кара көннəр килə, монысы исə, фашистлар лагерьларында башланды...

Əсирлəрне Германиянең Дюссельдорф тирəсендəге Рур өлкəсенə алып килделəр һəм аларга остарбайтер статусы биреп, сакчылар саклый торган баракларга урнаштырып, иң зур металлургия комбинатына эшкə беркеттелəр. Хəсəн тимер кою цехына элəкте. Эш искиткеч авыр. Иң кара эшлəрне əсирлəр башкарды. Комбинатка һəм яңадан баракка көчле сак астында алып баралар. Аякта агач башмаклар. Эш арасында əле көлешеп, шаяртышып алырга да вакыт таптылар, янəсе Буденныйның атлы гаскəрлəре килгəн кебек шак-шок килеп баралар... Бик начар ашаттылар. Бер яктан əйбəт иде, пөхтə алманлылар бараклардагы кандала һəм бетлəргə каршы киң көрəш алып бардылар.

Шулай итеп, Хəсəнгə япь-яшь килеш дистə еллар буена тоталитар режимның тəртиплəреннəн: Сталин һəм Гитлер лагерьларын татып карарга туры килде:

— Мине шаккатырган əйбер шул булды,— ди Хəсəн Юнысович,— эшне һəм яшəешне оештыру мəсьəлəлəре Сталин һəм Гитлер лагерьларында да бер үк төсле, шундый охшаган ки, хəтта хəйран калырлык. Эш урыннарында һəм бараклар да бер үк эчтəлекле плакатлар эленеп тора. Аннары тагын шунысы истə калды, совет əсирлəренə немец телен өйрəнергə рөхсəт юк иде. Бəлки аларның телен белсəк, качарга маташырлар дип курыкканнардыр. Бəлки əле алар халыкка социаль-коммунизм тəгълиматларын өйрəтерлəр, дип тə өреккəннəрдер...

Барысы да көтмəгəндə, 1945 елның язында хəл ителде. Совет остарбайтерлар лагерен Америка солдатлары азат иттелəр. Алар үз тарафларыннан совет əсирлəрен туган иллəренə кайтырга түгел, ə Америкага китəргə кыстадылар. Лəкин телəк белдерүче булмады. Барысы да беравыздан: «Өйгə!» диделəр.

Алда нəрсə көтəсен беркем дə берни дə белми иде əле. Кайберəүлəрне Гитлер лагерьларыннан «фашистларга хезмəт итүдə» гаеплəп турыдан-туры Себергə, Казахстанга Сталин лагерьларына алып киттелəр. Бөек ата балаларына мəкерле читлек əзерлəп куйганын кем белгəн соң?

Ә эшелоннарның стеналарына «Ил сезне көтә!» дигән плакатлар эленгән иде. Ләкин эшне аңлаган әсирләр өстәп: «Мөртәтләр» дип язып куйдылар.

## ЯЗМЫШКА КАРШЫ КИЛЕП

Рур предприятиеләренең яшь эшчесе (остарбайтер) Хәсән Тинчуринга язмыш көтмәгәндә елмаеп куйды. Энә үтәсеннән үткәреп тикшергәннән соң, аны СССР Кораллы көчләре сафына күчерделәр. Яшь совет солдаты өч ел буена Германиядә хәрби җайланмаларны демонтажлап, төяп Советлар Союзына кире кайтарып җибәрү белән шөгыльләнде. 1948 елны Х.Тинчуринны хәрби хезмәтен узып бетерер өчен Көньяк Сахалинга җибәрделәр.

Кырык тугызынчы елны армиядән демобилизацияләнде, эштән аерылмыйча Ленинград суднолар төзү техникумына укырга керде, ә тугыз елдан соң Одесса су юлы транспорты институтын тәмамлап, су транспорты инженеры булды. Проектлаштыру институтында баш конструктор булып эшләде, озак еллар буена Ростов өлкәсе администрациясендә җитәкчелек эшләрендә булды.

Ростов-Донда үзенә йорт төзеп, хатыны Тәскирә белән бергәләп Мәрьям исемле кыз үстерделәр. Ул институт тәмамлап, әтисенең эшен дәвам иттерә.

Миңа еш кына Ростов-Донда булырга туры килә һәм форсаттан файдаланып милләттәшләрем белән очрашырга тырышам. Аларның барысының да диярлек язмышлары кабатланмас һәм кызыклы. Шулай ук Хәсән Юнысович белән дә очрашкалыйм. Әңгәмәбезнең ахырында ул һәрвакыт ачынып болай ди:

— Туган илебездә коммунизм төзү безнең өчен бик кыйммәткә төште. Мин үзем тоталитар режим корбаны. Халыклар атасының бәхетле киләчәк төзү юлында һәлак булган бабам Гали, әтием Юныс һәм Кәрим абзыемның хәтта каберләрен дә белмибез...

## СОҢГЫ СҮЗ

Җыяр ризыклары, эчәр сулары читтә булгангадыр, Тинчуриннар нәселе Ростов-Донда төпләнеп калган. Шамил Арифулла улы Тинчурин мең ярым миллион халкы булган шәһәрнең баш хирургы. Ростов медицина институтын тәмамлаганнан бирле ул шәһәр хастаханәсенең хирургия бүлеген җитәкли. Үз эшенең чын остасы, бик хөрмәтле табиб. Шамил Арифулла улының тырыш хезмәте хөкүмәт тарафыннан югары бәяләнде — 1984 елда ул Халыклар Дуслыгы ордены белән бүләкләнде.

Шамил Тинчурин Ростов-Дондагы табиблар династиясен җитәкли. Аның хатыны Лия — акушер-гинеколог. Медицина институтында

бергә укып, бергә диплом алып чыккан бу матур пар тормыш юлыннан да 35 ел буе кулга-кул тотынып атлый. Балаларында да үз һөнәрләренә мәхәббәт тәрбияли алганнар. Олы уллары Руслан кардиохирург, ул өлкә хастаханәсендә эшли. Төпчекләре Ринат та хирург, ул әтисе белән бергә шәһәрнең үзәк хастаханәсендә катлаулы операцияләр ясый. Киленнәре Татьяна — лор, Оля — педиатр.

Шамилнең әтисе Арифулла абый танылган драматург Кәрим Тинчуринның туганнан туган абыйсы. Әле утызынчы еллар башында ук колхозлаштыру чорында Арифулла абый белән Хәйрелбанат апа Ростов-Донга күченеп килгәннәр. Алар Тинчуриннар нәселен репрессия һәм Сталин лагерьларыннан Кәрим генә коткарып калды дип еш искә алганнар. Казанның милли-сәяси һәм мәдәни тормышында кайнаган алдынгы карашлы кеше буларак, Кәрим Тинчурин, әлбәттә, күпне белгән. Казанда яисә туган авыллары Тараканлыда бергә җыелганда, Кәрим һәрвакыт «Канкойгыч дәһшәтле көннәр якынлаша, яхшы чакта әле паровозлар йөреп торганда тизрәк күчеп китү ягын карагыз», ди торган була. Шул киңәшне тотып, Тинчуриннар Дон якларына килеп төпләнәләр. Ростов-Донда эшчән, зыялы, гадел, затлы нәсел барлыкка килә.

Ростовта Тинчуриннарның тагын бер буыны яши. Кәрим Тинчуринның бертуган Заһидулланың кызы һәм улы монда гомер кичерә. Рәвилә Заһидулла кызы Тинчурина Төньяк Кавказдагы тимер юл хастаханәсендә невропатолог булып эшли. Күптән түгел аңа Россия Президенты Указы белән «Россиянең атказанган табибы» дигән мактаулы исем бирелде.

Рәвилә ханым бу төбәкнең иң хөрмәтле табибы. Кызы Фәридә дә әнисе юлыннан китте — узган ел ул Ростов медицина институтын тәмамлады.

Рәвилә ханымның абыйсы Фәрит Заһидулла улы Ростов университетында белем алган. Хәзер ул Ростовтагы оборона заводларының берсендә баш инженер.

Сүз дә юк, Ростов-Дондагы Тинчуриннар кланы башында Хәсән Юныс улы Тинчурин тора. Кәрим Тинчуринның күләмле генә гаилә архивы да анда саклана. Хәсән абыйның туганнары Әбүбәкер белән Хөсәен Ростов-Донда гомер итәләр.

Тамырлары белән Тараканлы авылыннан чыккан Тинчуриннар Татарстаннан ерак Ростов-Донда югалмаганнар, киресенчә, затлы, мактаулы нәсел булып үсеш алганнар.

## Кавказлы әсир

Имам Шамилнең оныгының оныгы (праправнук) бүгенге көндә Мәскәүдә яшәгәнлеге турында мин һич көтмәгәндә һәм уйламаганда, Коръәннең безнең илдәге тарихы турындагы китабымның бер бүлеген язганда белдем. Бүлек Изге Китапның тәрҗемәчесе, патша хөкүмәте тарафыннан Калугада сөрген срогын үтеп яткан имам Шамил янына «командировкага» барып кайткан генерал Дмитрий Николаевич Богуславскийның тормыш юлы һәм иҗатына багышланган иде. Татарстан Республикасының Русия Федерациясендәге вәкаләтле вәкиле Шамил Кәлимуллович Әбдрәшитов белән без, Дәүләт Думасының Дагстан депутатлары аркылы, Мәскәүдәге «Дагстан» милли-мәдәни җәмгыяте рәисләренең берсе булган табиб-травматолог Могамед әфәнде Абдулхәбиров белән элемтәгә кердек. «Әй-йе, имам Шамил токымыннан булган бердәнбер кеше, дөресрәге, аның оныгының оныгы Мәскәүдә туган һәм яши. Аның исеме Шамил Шеффи Гази-Магома. Ләкин аның тамырларында кем каны күбрәк — дагстанныкымы яки татарныкымы — әйтүе кыен.

Табиб Могамед әфәнде Абдулхәбиров атаклы Шамил нәселенең бердәнбер вәкиле булган Шеффи Гази-Магоманың өй телефонын бирде. Ул Мәскәүнең Чертаново торак массивында яши икән. Телефон трубкасын күтәренке тавышлы ир-ат алды. Телефон аша аз-маз танышкач, иртәгесе көнне иртән, сәгать унда метроның «Пражская» юнәлешенә таба барган поездының беренче вагоны турысында очрашырга сөйләштек. Беренче мәртәбә капма-каршы очрашасы кешемнең бер ун минутка алданрак килеп, атаклы кавказлы имам Шамилнең литографиядә эшләнгән портретын карап утырам һәм язучыларга хас булган кызыксыну белән үземә фараз кылам: минем янга ни кыяфәтле кеше килеп чыгар икән?

Ниһаять... Йа Аллам! Ни күрим, метроның киң баскычларыннан миңа таба каһарман имам Шамил үзе төшеп килә сыман. Шул ук кардай ак сакал, тик азрак кыскарак кына. Имам Шамил йөрткән кара мех каймалы ак чалма урынында, шуңа охшатып, ак йон җептән бәйләнгән баш киеме. Якынрак килеп бассам, миңа таба кавказлыларга хас үткен, ләкин җылы карашлы күзләрнең миңа төбәлгәнлеген күрәм.

— Казаннан килгән язучы сез буласызмы? — ди бу кеше.

— Әй-йе, — дип баш белән ымлыйм һәм исәнләшергә дип ике кулымны сузам.

— Нәрсә сез гел елмаясыз? — ди минем яңа танышым, гаҗәпләнеп.

— Бабагызның бабасы белән шулкадәр охшаш булуыгызны күреп мин елмаерга мәҗбүр булдым, дим Шеффи Шамилгә. — Кирәк бит, дүртенче буын вәкиленә шулай нәкъ бабасының бабасы йөзен күчереп куярга...

— Табигатьне алдап булмый ул, — дип килешә минем белән

мәскәүле-кавказлы һәм мине үзенә кунакка чакыра. Гади өч бүлмәле Чертаново фатирында әңгәмәбезне дәвам иттерәбез.

**— Шеффи әфәнде, ир-ат ягыннан булган нәсел шәҗәрәсенең рәсемен ясап күрсәтмәссезме, әйтик, бабагызның бабасы имам Шамилгә кадәр?**

— Әйдәгез. Арттан таба, бабамның бабасы Шамилдән башлыйк алайса. Аның 1839 елда туган икенче улы, үзе белән бергә сөргендә булган Магомед-Шеффи. Мин аның турыдан-туры оныгының улы булам. Магомед Шеффи, әтисенең ризалыгы белән, Кавказ эскадронының лейб-гвардиясенә җибәрелә һәм Петербургка хәрби хезмәткә озатыла. Хәрби хезмәт барышында яхшы гына карьера ясап, 1871 елны патша тарафыннан, нигездә, кавказлардан төзелгән взводтагы тоткыннарны, әсирләрне саклап озата баручы кораллы отрядның (конвой) командиры дәрәҗәсенә күтәрелә. Гомеренең шактый вакытын Казанда үткәрә. Казанга эшкә күчерелгән вакытта ук инде генерал-майор дәрәҗәсендә була. Беренче хатыны Әминә (Әминәт) үлгәч, Магомед Шеффи Казанның татар морзасы Ибраһим Аппаковның кызы — Мәрьям Аппаковага өйләнә. Карт бабам Магомед Шеффи 1904 елда дөнья куя һәм Пятигорскида күмелә.

Магомед Шеффиның улы Заһид-Шеффи, ягъни минем бабам, Русиядә бик танылган шәхесләрдән булган. Ул Касыйм сәүдәгәре Байбековның сылу кызы Хәдичәгә өйләнгән була. Заһид-Шеффи Петербург Үзәк Мәчетен төзүдә актив катнаша. 1918 елда Мәскәүдә татар мәктәбе ача. Ул Мәскәүдә үлә һәм шундагы татар зиратында җирләнә.

Заһид-Шеффиның улы Гази Магома — 1907 елда Мәскәүдә туа. Ул минем әтием була инде. Халык хуҗалыгы институтын тәмамлагач, ул озак еллар буена Мәскәү автопредприятиеләрендә баш инженер булып эшләде. Әтием рус кызы Мария Федоровна Егоровага өйләнгән. Әмма татар әбием Хәдичәне бик яхшы хәтерлим. Ул да Мәскәүнең мөселманнар каберлегенә күмелгән. Тамырларымда авар, татар һәм рус каны аккан мин — Шамил Шеффи Гази Магома — 1937 елда Мәскәү шәһәрендә туганмын. Серго Орджоникидзе исемендәге инженерлык-икътисад институтын (хәзер Идарә итү академиясе) тәмамлап, Мәскәүнең төрле предприятиеләре һәм учреждениеләрендә эшләдем. Хәзерге вакытта финанс куркынычсызлыгы агентлыгында (Агенство финансовой безопасности) хезмәт итәм.

Имам Шамилнең соңгы токымы булып минем балалар тора: улым Тимергә 25 яшь, ул инженер һәм кызым Катя — унберенче класс укучысы.

**— Шеффи әфәнде, әйдәгез әле яңадан башлангыч чорга әйләнеп кайтыйк. Атаклы нәсел башлыгы Шамил кайчан һәм кайда туган? Гаиләнең истәлекле әйберләре (реликвия) бу турыда ни сөйли һәмниләрне хәтерләтә?**

— Минем борынгы бабам Шамил 1797 елның азагында Дагстан тауларындагы авылларның берсендә — Гимры авылында дөньяга килгән. Быелгы елның (1997) 30 октябрендә Мәскәүдә Союзлар Йортының Колонналы залында имам Шамилнең тууына 200 ел тулуга багышланган тантаналы кичә үткәрелде.

**— Ә сез борынгы бабагызның туган иләндә булганыгыз бармы?**

— Гимры авылында мин беренче мәртәбә 1965 елда булдым. Ул бик биек тау башында урнашкан. Искиткеч матур җирләр. Гимры авылы хәзер Дагстан Республикасына керә.

**— Шулай да, милләте буенча Шамил кем булган икән? Бүген аны чәчәннәр — чәчән, ингушлар — ингуш, аварлар — авар булган диләр. Халыкта мондый мәкаль бар: «Җиңүнең атасы (хуҗасы) күп, тик җиңелү генә ятим». («У победы много отцов, а поражение всегда сирота».)**

— Шамил милләте буенча авар. Чын мәгънәсендә. Ул үзе табигать тарафыннан бирелгән зур талант иясе була. Яшьтән үк катлаулы дөньяның асылын өйрәнүгә тартыла. Гарәп телен һәм әдәбиятын, логика һәм риториканы (сүз сәнгате), гарәп һәм башка халыкларның хәрби сәнгатен өйрәнә. Аның укытучылары да Көнчыгышның зур ислам уку йортларын тәмамлаган күренекле шәхесләр була, әлбәттә. Ислам динен тоткан кавказ мөселманнары өчен имам иң бөек дин башлыгы булып санала.

**— Шундый зур дәрәҗәле урынга сезнең ерак бабагыз кайсы елда сайланды икән, рәхим итеп әйтә алмассызмы?**

— Нәрсә соң ул Дагстан? Даг — тау, ә стан — ил. Тау иле. Гомергомергә монда дистәләгән милләт халкы яшәгән. 1834 елда шушы халыкларның вәкилләре һәм руханилары Шамилне үзләренең имамы итеп игълан итәләр. Җирле халыкларга аның тәэсире зур була. Ул хакимлек иткән җирнең чикләре Көнбатыш Кавказга кадәр барып тоташа, ягъни бүгенге Кабарда-Балкар, Карачай-Черкес һәм Адыгей республикаларын да үз эченә ала дигән сүз. Имамның абруе бәхәссез зур була. Шамил гражданлык һәм хәрби хакимиятне дә үз кулына туплый. Ләкин Шамилнең хакимияткә килүе Кавказ халыклары һәм Русия өчен дә иң катлаулы вакытка туры килә. 1801 елдан башлап, Кавказ халыклары Русиягә кушылуга каршы газават әләме астында бертуктаусыз азатлык өчен көрәш алып баралар. Кавказ халыкларының җитәкчесе буларак, Шамил теоретик дәүләт-имамат (политик власть дин башлыклары кулында булган идарә формасы) төзи һәм тау кабиләләрен Кавказны Русиядән азат итү өчен көрәшкә күтәрә.

Заманына күрә бик яхшы тәэмин ителгән һәм саны буенча да күп булуга карамастан, патша армиясе кавказ халыклары белән сугышта әллә ни зур уңышларга ирешә алмый.

**— Кавказда имам Шамил исеме белән бәйле булган тарихи урыннар күп. Аерым алганда, сез «Шамил ташы» турында нәрсә әйтә алыр идегез?**

— Андый таш бар, билгеле. Ул Дагстанда Гуниб авылы тирәсендә. Ләкин әйдәгез әле рәттән барыйк. Кавказ сугышында рус гаскәриләренең хәле 1856 елда урысларның гаскәр башлыгы итеп генерал кенәз Александр Иванович Барятинскийны билгеләгәч, азрак үргә күтәрелә башлый. Рус хөкүмәте Кавказда зур көч туплый.

Изге сугышта имамның көрәштәшләре булган мөритләренең сафлары кимегәннән-кими. Мәсәлән, әсирлеккә төшкән көнендә имамның барлыгы 250 актив сугышчысы калган була. Бу вакытта генерал А.И.Барятинский

җитәкләгән рус армиясендә 25 мең кеше санала. 25 ел буена каршылык күрсәткәннән соң, ахыр чиктә бу сугышның мәгънәсезлеген аңлаган Шамил 1859 елның августында Гуниб авылы тирәсендә барган көрәшләрнең берсендә рус гаскәрләренә әсирлеккә бирелә. Үзен озата барган 40 мөриткөрәштәше белән бергә, Шамил генерал Барятинский ставкасына таба юнәлә. Генерал зур йомры таш өстендә утыра. Аны күрү белән имам бер кулын хәнҗәр өстенә куя, ә икенчесе белән кылыч сабына таянган килеш командующий алдына килеп туктый.

Генерал таш өстеннән тора һәм имамга каршы атлый. Генерал янына килеп җиткәч, Шамил тарихка язылып калган сүзләрен әйтә: «Дагстанга ия булуыгыз белән тәбрик итәм һәм патша галиҗәнапларына тау халкы белән идарә итүендә һәм аларның иминлеген тәэмин итү юлында чын күңелдән зур уңышларга ирешүен телим».

Имам Шамилнең бу сүзләре чокып язылган бу таш — бүген дә Гуниб авылы кырыенда ята.

Шулай итеп, Кавказ халкын коллыкка төшерү ниятеннән башланып, ике ярым гасырга сузылган бу сугышта, рус гаскәрләре беренче мәртәбә җиңүче булып чыктылар. Гаскәр башлыгы җиңү турында армиясен җыеп суворовча кыска гына итеп белдерү ясый: «Гуниб алынды. Шамил әсирлеккә төште. Кавказ армиясен тәбрик итәм». Русия патшасы исеменә Петербургка да командарм кыскача гына, ләкин җиңүчән пафоста хәбәр җибәрә: «Бүгеннән Сезнең таҗыгызга бөтен Аурупада тиңе булмаган алмаз беркетелде. Шуны Сезгә патша галиҗәнапларына җиткерүем белән бәхетлемен!»

Тиздән Русия патшасы Кавказ сугышындагы зур казанышлары өчен генерал А.И.Барятинскийны генерал-фельдмаршал дәрәҗәсенә күтәрә, зур армиянең командующие һәм Кавказның башлыгы буларак, Александр Иванович монда 1862 елга кадәр хезмәт итә.

**— Имам Шамил һәм башка әсирләрнең алдагы язмышлары ничек хәл ителгән?**

— А.И.Барятинский Шамилне почетлы эскорт белән Петербургка патша карамагына озата. Русия башкаласында патша Александр II Шамилне җылы каршылый һәм аның хөрмәтенә кабул итү оештыра. Патша указы белән аның даими яшәү урыны итеп Калуга шәһәре билгеләнгәнен Шамил Петербургка барганда юлда ук ишеткән була инде.

Шамил төньяк башкалада кунак булып йөргән арада, Калуга шәһәренең генерал-губернаторы Виктор Антонович Арцимовичка (кушаматы «кызыл». Үткән гасыр урталарында да «кызыл»лар булган икән ләбаса) әсиргә төшкән имам һәм аның гаиләсенә яшәр өчен уңайлы шартлары булган торак урын табарга дип әмер бирелә.

Озак эзләгәннән соң, ниһаять, Арцимович өч катлы аерым йортны (хәзерге Пушкин урамы, 4 йорт) алпавыт Сухотиннан хак түләп вакытлыча файдаланугa ала. Өч катлы бу таш йортның 13 бүлмәсе бар. Йорт тирә-ягыннан биек һәм нык таш киртә белән әйләндереп алынган. Өй алдында бик матур бакча. Йорт территориясе яхшы каралган. Хезмәтчеләр һәм хуҗалык кирәк-яраклары өчен ишегалдында аерым кечкенә йорт (флигель) бар. Төп йорт җимеш бакчасы эченә урнашкан. Икенче

каттагы бүлмәләр Шамилнең үзенә билгеләнгән. Бер бүлмәсендә балконы бар, ул бакчага карый. Беренче һәм соңгы каттагы бүлмәләр аның күпсанлы гаиләсенә һәм хезмәткәрләренә бүлеп бирелгән.

**— Шамилнең токымы буларак, сезнең Калугада булганыгыз бармы? Йорт һәм алпавыт утары сакланып калганмы?**

— Сиксәненче елларда Калугага барган идем мин. «Шамил йорты»нда да булдым, калугалылар аны шулай дип йөртәләр. Ул Пушкин һәм Бауман урамнары чатында урнашкан. Ләкин йортның тышкы күренеше бик күңелсез. Сез уйлаган утарда җимеш бакчасы да күптән юкка чыккан. Кечкенә йорт та сүтелгән. Моңаеп калган соры өч катлы йортның пычрак тәрәзәләре генә узган-барганга сагышлы карашын ташлый. Ә йортның урам ягындагы штукатуркасы урыны-урыны белән кубарылып төшеп, йолкыш этнең укмашып, асылынып төшкән сырт йоннарын хәтерләтә. Миңа калса, атаклы әсир киткәннән бирле бинага кеше кулы, гомумән, тимәгән булса кирәк. Кыскасы, дәүләт сагы астында ул. Хәзерге көндә ул йортта ниндидер бер учреждение урнашкан.

**— Имам Шамил әсирлеккә төшкәч, генерал-фельдмаршал А.И.Барятинский белән элемтәләре бөтенләйгә өзелгәнме? Бу турыда музейда, йә булмаса гаилә архивларында берәр истәлекле язма сакланмаганмы?**

— Сакланган, әлбәттә. Үзен әсиргә төшерүче кеше белән ул соңгы сулышына кадәр якын мөнәсәбәттә булган. Уңае туры килгән саен алар бер-берсенә сәлам юллаганнар.

Генерал-фельдмаршалның чирләп киткәнен ишеткәч, үлем түшәгендә яткан Шамил А.И.Барятинскийга мондый хат яза:

«...тагын Алладан шуны сорыйм, ул сезнең исегездән минем турындагы истәлекләрне җуймасын... Ходай сезгә исәнлек-саулык бирсен, бүген кылган изге догам сезнең өчен... Миңа калса, сезгә тугрылыклы кешенең мәңгегә аерылышу алдыннан язган соңгы хушлашу хаты бу... Авыру һәм хәлсез Шамил».

Александр Иванович Барятинский үзенең әсиреннән унҗиде яшькә яшьрәк булуга карамастан, Шамилнең вафатыннан соң барлыгы сигез ел гына яши һәм 1879 елда якты дөньядан китеп бара.

Шамил Калугага 1850 елның 10 октябрендә, ягъни Гуниб авылы тирәсендә әсирлеккә төшкәннән соң, нәкъ ай ярым вакыт үткәч килеп җитә. Аны озатып баручылар арасында олы улы Гази Магомед, изге сугыштагы ышанычлы көрәштәшләреннән ике мөрит һәм патша армиясенең полковнигы Дмитрий Николаевич Богуславский бар. Имамның өч экипаждан торган атлы поездын җайдаклар саклап бара. Калугада генерал-губернатор Арцимович сайлап куйган аерым йорт әле ремонтланып бетмәгәнгә күрә, Шамилне вакытлыча шәһәрнең «Кулон» кунакханәсенә урнаштыралар. Ленин урамында урнашкан бу йорт әле хәзер дә бар.

Шәһәргә килеп төшкәч тә, Шамил, улы белән бергәләп, Калуга һәм аның әйләнә-тирәсенә сәяхәт кыла. Аңа бигрәк тә шәһәр тирәсендәге урманнар һәм калкулыклар ошый. Гомумән, шәһәр белән бик канәгать була. Күңеле күтәренке чакларда гел үзалдына: «Чәчәнстан! Чын мәгънәсендә Чәчәнстан! Шушы ук урманнар, чәчүлекләр, шундый ук таулар һәм чокырлар, рәсемдә ясап куйгандай тугайларда сибелеп

утырган авыллар...» — дип куя торган була. Икенче көнне олы улы Гази Магомед белән генерал-губернатор В.А.Арцимович янына килеп чыга һәм үзе яшәгән йортны карый. Шамилне күрергә кызыксынучан Калуга халкы килә. Урта полоса кешеләре өчен ул, күрәсең, сәеррәк булып күренгәндер. Кавказлының йөзен кызыл-сары сакал бизәп тора. Бите шадра. Башында бик матур, кырына кара мех тоткан черкес җөббәсе (якасыз җилән). Өстеннән бик шәп тунын киеп җибәрә. Аягында сары төстәге тиредән тегелгән сафьян итек. Олы улы аурупача костюмнан, ә башында һәрвакыттагыча папаха (бүрек).

Барысыннан да бигрәк, Калуга халкын аның карашы шаккатыра. Акыллы, көләч, йөрәккә үтеп керердәй үткен, шул ук вакытта, җылы да караш: «Минсез сез ничек яшәдегез монда...», диядер шикелле. Калуга халкын күп сораулар борчый: «Бу атаклы кавказ кешесенең ничә хатыны, күпме баласы бар, алар ниндиерәк микән һ.б.». Шәһәрдә килгән яңа кешенең сүрәте төшерелгән открытка чыгарганнар, бу открытканы калугалылар бик тиз сатып алып бетергәннәр. Бигрәк тә, литографиядә басылган бу открыткаларны Калуганың аксөякләр нәселеннән булган ханымнар сатып алырга ашыккан. Аларның бу данлыклы кавказлыны тизрәк күрәсе килгән.

Шамил үзе дә шәһәр хатын-кызларына күз төшерергә яраткан. Аларның күлмәкләрендәге муен һәм күкрәк тирәсен ачык калдырып уелган зур изүләрен (декольте) күреп, гаепләү йөзеннән телен шартлатып, башын чайкаган. Бик күп көнчыгыш телләрен камил белсә дә, рус телен белмәгән, аңламаган. Яшь хатыны Шуанат (кыз вакыттагы исеме Анна Ивановна) монда күчеп килгәнче, аның тәрҗемәчесе булып рус кешесе — Громов хезмәт иткән.

Аерым йорт ремонтлаганчы Шамил Калугада хатыннары, балалары һәм якыннарыннан башка, ялгызы гына яши. Шуңа күрә, барлык буш вакытын шәһәр белән танышуга, русларның әхлак кагыйдәләрен өйрәнүгә сарыф итә. Дворяннар җыены үткәргән кичәләргә, балларга һәм циркка йөри, губерния гимназияләренә, шифаханәгә баргалый. Бераздан гимназиядә рус теле дәресенә керә һәм гаҗәпкә кала: «Ничек инде рус балалары үз телләрен өйрәнеп утыралар?..» Шамилне асрап яшәтер өчен казнадан унбиш мең акча җибәрелгән, ул заманда бу бик зур мал булып санала. Кәеф-сафа корып йөрер өчен аңа матур коляска һәм дүрт ат бүләк итәләр. Калугага килеп төшеп, төп-төгәл бер айдан соң, Калуга дворяннары башлыгы Щукин имам Шамилгә аның йорты әзер булганлыгын әйтә. Шамил йортны җентекләп карап чykканнан соң, таңга калып Щукинга: «Сүзем юк, бу мизгелдә нинди хисләр кичерүемне сүзләр белән генә әйтеп булмыйдыр»,— ди.

— Якын кешеңнең яхшылык итүе, билгеле, бик тә күркәм эш, ләкин мин сезгә карата (русларга) күпме яманлык эшләгән кеше, шулай булуга да карамастан, сез миңа туганына эшләгәндәй изгелек эшлисез». Кавказлы әсир тагын өстәп куя: «Әгәр миңа Калугада йортны үземә сайларга кушсалар, мин нәкъ шушыны сайлаган булыр идем»,— ди.

**— «Кавказлы әсир» кайчан гаиләсе белән кушыла алган соң?**

— Калугада, Шамил тирәсендәге яңа кешеләргә, аның Дагстанда

гарәп һәм башка көнчыгыш телләрендә язылган бик бай китапханәсе калганлыгы билгеле була. Имам руслар белән бәрелешүләр вакытында китапханәм югалгандыр инде, дип уйлап, бик кайгыра. 1860 елда А.И.Барятинский приказы белән Иран келәмнәренә төрелгән Шамил китапларын берничә олауга төяп Калугага хуҗасына алып килеп тапшыргач, аның шатлыгы эченә сыймый.

Тиздән җиде олауга төялеп, гаиләсе һәм мөритләре килеп җитә. Шамилнең гаиләсе, мөритләрне дә санап, егерме ике кешедән тора. Ике хатыны — Зәйдән һәм Шуанат, ике улы — Гази Магомед һәм Магомед Шеффи, биш кызы — Нәфисәт, Фатимат, Нәджават, Баху-Меседу, Сафият, ике кияве — Абдурахман һәм Абдурахим һәм ике килене — Кәримат һәм Әминәт.

Бүлмәләргә урнашу демократик тәртиптә булды, кемгә кая ошый, шунда урнаштылар.

Имамның хатыннары, кызлары һәм хатын-кыз хезмәтчеләр өченче катны сайладылар.

Имам үзе, китапханәсе белән бергә, икенче катның апартаментларына урнашты. Аның янында гел яшь хатыны — «сөйгән җимеше» Шуанат булды.

**— Шамилнең икенче хатыны Шуанат рус милләтеннән, кыз чакта Анна Ивановна Улухова булган ди, имеш. Дөресме?**

— Риваятьләргә караганда, ул яртылаш рус, яртылаш әрмән була. Анна, Моздок сәүдәгәре Иван Улухановның кызы. Кыз вакытында Шамил тарафыннан әсирлеккә төшерелә. Соңыннан, Шамилдән утыз яшькә яшьрәк булуына карамастан, аңа гашыйк була, үз теләге белән ислам динен кабул итә һәм аңа Шуанат исеме кушалар. Ул үз телен бик оста белә һәм Калугада сайлап алган мәхәббәт дустының тәрҗемәчесе була.

1867 елда Анна — Шуанат ир бала таба һәм аңа Магомет Камил исеме бирәләр.

**— Калугада гаиләсе белән кушылган тормышын ни рәвешле алып бара? Алдагы язмышы ничегрәк хәл ителгән?**

Рус патшасының бөек әсиренә карата булган акыллы сәясәте аркасында, Шамил Калугада һәм, гомумән, Русиядә югары хөрмәткә ия була. Моңа да карамастан, «Кавказлы әсир» иркенлек яратса да, тормышта үтә тыйнак кеше була. Азыкка талымсыз, уртак казаннан гадәти ашамлыкларны барысы белән бергә утырып ашаган. Аз йоклаган. Ләкин йокларга кич белән бик иртә, әмма бер үк вакытта ята торган булган. Чиста чишмә суыннан гайре эчемлек кулланмаган. Кайвакытларда кичләрен уллары белән экипажга утырып шәһәр буйлап йөреп керә. Сирәк-мирәк кенә Дворян Җыены йортына дәрәҗәле урыннардагы яңа дуслары, танышларына кунакка баргалый.

Буш вакытларында ул китапханәсенә кереп, гыйлем дөньясына чума. Аны еш кына мөселманнарның Изге Китабы — Коръән, Мөхәммәд пәйгамбәрнең хәдисләрен һәм башка гарәп телендәге китапларны укып утырганын еш күргәннәр.

Әмма хатын-кыз Калуганың кырыс (салкын) табигатеннән зарланган. Аларга Дагстан җылысы җитми. Кыш көннәрендә көннәр буена

бүлмәләреннән чыкмый утырганнар. Кайчак, азрак караңгы төшкәч, экипажга утырып һава сулап кергәннәр. Ә җәй көне хатын-кыз бакчада эшләгән.

1866 елның 26 августында әсирлеккә төшәргә нәкъ ун ел дигәндә, Калугада тантаналы вакыйга булып ала. Шамил, уллары белән бергәләп, Дворян Җыенына килә һәм Русиягә тугрылыклылыгы һәм гражданлыгын үзгәртүе турында ант итә. Калуганың киң җәмәгатьчелеге алдында Шамилнең данлыклы сүзләре яңгырый: «Мин зур ышаныч белән Аллаһы Тәгалә алдында ант итәм! Мин үземнең гаиләм белән бергә Александр II патшага, җирле идарә башлыкларына һәм Русия дәүләтенә тугрылыклы булу турында үземә бирелгән барлык йөкләмәләрне тулысынча кабул итәм!»

Бу вакыйгадан соң күп тә үтми, Шамилне барлык кавем-кабиләсе белән дворянлык дәрәҗәсенә күтәрәләр.

**Автордан искәрмә материал:** Беренчедән, патша армиясендә сугышып Казанны алу камалышында батырлыклар күрсәткән татарларга патша тарафыннан дворян дәрәҗәсе һәм Хопер, Югары Дон үзәннәреннән яңа җирләр бирелү турындагы мәгълүматлар тарихта шактый. Бу адәмнәр соңыннан диннәреннән ваз кичеп, христиан диненә (православие) күчәләр һәм, ахыр чиктә, исем-фамилияләрен дә үзгәртәләр.

Икенчедән, Дмитрий Николаевич Богуславский турында берничә сүз әйтәсем килә. Коръәнне гарәпчәдән русчага тәрҗемә иткән беренче кеше булып, Казан духовный академиясенең дин тәгълиматлары белгече, профессор Гордий Семенович Саблуков санала. Аңа кадәр җиде ел элек Коръәннең төп нөсхәсеннән эшләнгән беркемгә дә билгеле булмаган тәрҗемә дөньяга пәйда булган, аны генерал Дмитрий Николаевич Богуславский ясаган. Ул 1826 елда туган, ә 1893 елда вафат булган.

Яшь офицер Д.Н.Богуславскийга тарих өчен 1853 — 1856 елларда барган рус — төрек сугышы турында материал тупларга йөкләтелгән булган. Бу эшкә ул бик җитди караган. Күрәсең, шушы вакытта бу яшь офицерда Көнчыгышка карата фәнни кызыксыну тугандыр. 1856 елда полковник Богуславскийны Петербургка Төп штабка күчерәләр. Төньяк башкалада яшәү дәвереннән файдаланып, яшь полковник Шәрык телләрен өйрәнә башлый һәм Санкт-Петербург университетының көнчыгыш телләре факультетын үзлегеннән укып тәмамлый. Менә шуңа күрә дә, патша армиясенең Баш штабы җитәкчеләре хөрмәтле «Кавказлы әсир» янына пристав итеп җибәрергә полковник Д.Н.Богуславский кандидатурасына тукталганнар. Югарыда әйтелгәнчә, имам Шамил үзенең олы улы, ике мөрите һәм Петербургтан аларны озатып килгән полковник Д.Н.Богуславский белән бергә, 1859 елның 10 октябрендә Калугага килеп җитәләр. Көнчыгыш телләрен яхшы белгән яшь полковник Шамил белән иркен сөйләшә һәм алар үзара ышанычлы мөгамәлә урнаштыралар.

Богуславский Калугада ике ай яшәгән, монда полковник вакытны юкка әрәм итми. Үтә укымышлы имам Шамил ярдәмендә көнчыгыш телләре буенча белемен тирәнәйтә. Богуславскийны соңыннан капитан Руновский алмаштырган. Шамил укымышлы «пристав» белән аерылышуны авыр

кичергән. Соңга таба Богуславский Тышкы эшләр министрлыгында әйдәп баручы тәрҗемәче хезмәтен башкара һәм еш кына Төркия башкаласы Константинопольдәге Русия илчелегендә булгалый. Шул чакта ул генерал дәрәҗәсенә күтәрелә. Төркия башкаласында озак еллар яшәү дәверендә Коръәнне гарәпчә нөсхәсеннән русчага тәрҗемә итә башлый. Бу турыда генерал Д.Н.Богуславский болай дип язган: «Бу тәрҗемәләрне кылганда аны матбугатта бастырып чыгаруны күздә тотмаган идем. Озак еллар Көнчыгышта яшәгәч, эштән бушаган араларда, мөселман әдәбияты белән мавыгып киттем, шул исәптән Коръәнне берничә кат зур игътибар белән укып чыктым, аңардан күчермәләр ясап, тәрҗемәгә бик авыр бирелә торган урыннарын мөселман укымышлыларының аңлатмаларыннан файдаландым. Бу эш мине тәмам сихерләде, хәтта тулы бер Коръәнне тәрҗемә итеп бетергәнемне дә сизмәдем. Коръәннең русчага янә бер тәрҗемәсе барлыгын миңа Русиягә кайткач кына мәгълүм булды. Ләкин ул төп нөсхәдән түгел, ә Казимирскийның французчага тәрҗемәсеннән эшләнгән булып чыкты. Бу соңгы тәрҗемәне алып төп нөсхә белән чагыштырып караган идем, зур чиккә тайпылышлар һәм төгәлсезлекләр күрдем, ә тәрҗемәнең кайбер битләрендә Коръәннең гарәпчәдәге төп мәгънәсе бөтенләй диярлек капма-каршы мәгънәдә бирелгән. Тәрҗемә белән танышып чыккач, үз тәрҗемәмне очлап чыгарга һәм аны фәкать мөселман чыганакларыннан алынган комментарийлар һәм искәрмәләр белән бастырырга кирәк, дигән фикергә килдем». Коръән белгечләре Дмитрий Николаевич Богуславскийның бу тәрҗемәсен мөселманнарның гыйбадәт кылу кагыйдәләренең үзенчәлекләрен күздә тоткан бердәнбер русча тәрҗемә булган һәм булып калачак, диләр.

Яңадан имам Шамилгә кайтыйк.

**— Шеффи әфәнде, бөек кавказлы үзенең Русиядәге тормышын ничек тәмамлый?**

— Шамил рус патшасына, аны кая да булса көньяккарак күчерүен үтенеп гариза яза. Имам Калуганың салкын һавасын, хатыны, киленнәре һәм оныкларының еш кына салкын тидереп интегүләрен сәбәп итеп күрсәтә. Шамилнең үзенә Калуга бик тә ошый. Шулай да ул гаиләсе фикере белән дә килешә. Тау халыкларының җитәкчесен әсир иткән генерал А.И.Барятинский 1815 елда Калуга тирәсендә туган булган. Ул Кавказда хезмәт иткән елларда аның утары әле сакланган булган. Әйтерсең лә язмыш кушуы буенча имам Шамил һәм генерал-фельдмаршал вакытлыча торак урыннар белән алмашканнар...

Тиздән «Кавказлы әсир»нең үтенечен канәгатьләндерәләр. 1868 елның 25 ноябрендә Шамил үзенең шактый зур гаиләсе белән Калугадан Киевка күчеп китә. Ләкин ул монда озак яши алмый. Мөгаен, гомеренең азагына җиткәнен сизептер, ул хаҗ кылырга, ягъни һәрбер мөселман өчен изге булган Мәккә һәм Мәдинә шәһәрләренә барып кайтырга теләген белдерә. Рөхсәт бирәләр һәм ул хаҗга китә. Шул китүдән Шамил Русиягә яңадан әйләнеп кайта алмый. 1871 елның 4 февралендә 73 яшендә Мәдинә шәһәрендә вафат була. Мәдинә шәһәрендә, Мөхәммәт пәйгамбәр кабереннән ерак түгел җиргә күмелгән ул. Бу факт изге адәмнәр барлыгы турында сөйли түгелме?

Әйе, әңгәмәбез җиңелләрдән түгел. Бабасының әтисе язмышын тәфсилләп чыккач, Шеффи әфәнде белән беразга тынып калдык, галәмнең ни дәрәҗәдә киң һәм катлаулы икәнлеге турында уйладык, ахрысы. Аннары мин яңадан әңгәмәдәшемнән сөаль ала башлыйм.

**— Сез үзегезнең Шамил нәселеннән икәнлегегезне күптән беләсезме?**

— Бала чактан ук. Бу турыда миңа әтием сөйләгән иде. Әле дә хәтерлим, ул миңа бик матур якасыз җилән (черкес җөббәсе) тегеп бирде. Сигезенче класста укыганда, бугай. Мин аңардан мәктәпкә бардым. Ул вакытта имам Шамилнең кем икәнлеген мәктәптә белмиләр дә иде диярлек. Ләкин Шеффиның сәер костюмнан мәктәпкә килүе — гаҗәп күренеш булган.

**— Сез шундый атаклы нәселдән булуыгыз белән горурлана идегезме?**

— Мин моңа бик тыныч карыйм. Минем әтием Магома Шамил бала чакта ук болай өйрәтте: «Үзең чын ир-ат һәм тәрбияле кеше бул. Беркайчан да нәселең белән горурланма!» Ул хәзер генә, Төньяк Кавказда, ягъни Чәчәнстанда булып үткән вакыйгалардан соң гына имам Шамилнең исемен телгә ала башладылар һәм югары чөйделәр. Ә совет чорында аны белүче бик аз иде. Без барыбыз да бер үк коммунистик җәмгыять төзедек...

**— Ничек, Сезгә калса, үткән гасырдагы ерак бабагыз имам Шамил холкы һәм акыл төзелеше белән бүгенге кавказлылардан азрак аерылып тормыймы? Ул хәзерге чәчәннәр, кавказлы һәм, гомумән, башка халыклардан да укымышлырак, мәдәниятлерәк һәм түземлерәк булып күренә түгелме?**

— Үткән гасырда яшәгән Шамил бүген аның эшен дәвам иттерүчеләргә караганда күпкә укымышлырак, мәдәниятлерәк булган. Бу, һичшиксез, дөрес. Диннәрне тигез күргән, дин ирегене таныган башка милләт вәкилләренә дә зур ихтирам белән караган. Чиркәүләр төзүне дә ул нормаль эш дип саный. Ул акыллы сәясәт алып барган... Ләкин... Мин ниндидер дәрәҗәдә бүгенге чәчәннәрне дә аңлыйм. Аларның карашларын һәм кылган гамәлләрен һәрдаим хупламасам да, мин аларны аңлыйм. 400 еллык кабалага кайсы халык түзәр иде, йә? 1996 елда Русия хөкүмәте моны официаль рәвештә таныды. Чәчән халкы үзен юк итүгә корылган реакцион сәясәтне — туган оясыннан чит җирләргә, Совет империясенең ерак Урта Азия төбәкләренә көчләп күчерүне беркайчан да кичерә алмаячак. Чәчән халкы Русиягә карата үпкә катыш әрнү хисен көчләп басарга тырышса да, бик күп нәрсәне барыбер оныта алмаячак. Ничек кенә булмасын Русия сәясәтчеләренә һәм халкына бу хәл белән килешергә генә кала.

**— Сез ничек уйлыйсыз, чәчәннәр Русиядән тулы бәйсезлек таләп итәргә, мөстәкыйль дәүләттә яшәргә теләк белдерергә хаклымы?**

— 100 һәм 150 ел элек алар хаклы иде. Ләкин бүген, цивилизацияле (мәдәниятле) кешелек дөньясы бергә берләшү законы белән яшәгәндә, йомшак итеп әйткәндә, кемнәндер тулысынча бәйсез яшәргә омтылу, минем карашка, бөтенләй үк акыллы чара түгелдер. Соңгы

дистә елда халыкара хәлләр тамырыннан үзгәрде. Аурупа илләренә карагыз әле. Икътисад ягыннан көчле булган дәүләтләр арасындагы чикләр ачыла, таможня учреждениеләре бетерелә, илләр бердәм валюта булдырырга омтылалар. Бүгенге шартларда катгый рәвештә бәйсезлек таләп итү — мәдәниятле дөньядан аерылып яшәү дигән сүз. Әгәр халык үзенең телен, милли мәдәниятен, социаль-икътисади мөмкинлекләрен күздә тотып, гомумдөнья цивилизациясендә үз урынын таба икән, билгеле, ул халык үзен саклап калачак һәм хәзерге заманда лаеклы этнос буларак үсә алачак. Без телибезме-юкмы, ләкин чикләрне барыбер бетерергә һәм гомумкешелек мәйданында яшәргә туры киләчәк. Башкача яшәргә омтылу — мәгънәсезлек ул.

**— Соңгы вакытта Грозныйда булып үткән вакыйгаларга карашыгыз ничек? Шәригать кануннары нигезендә җәзалау турында әйтүем.**

— XX гасырның мәдәниятле кешесе буларак — карашым тискәре якка таба. Гаеплеләргә җәза бирер өчен дәүләт һәм дәүләт кануннары бар. Бүгенге көн хакыйкатен алар ничек яктырталар — бу икенче мәсьәлә. Җәмгыять алдында бурыч һәм йөкләмә булып, үзе таянып эш иткән кануннарны камилләштерү мәсьәләсе тора.

**— Сез ничек уйлыйсыз, Чәчәнстандагы хәрби хәрәкәт Русиянең башка регионнарына да күчмәсме? Мондый куркыныч Русиягә янамыймы?**

— Әйе, мондый куркыныч бар. Күп нәрсә Чәчәнстан белән янәшә яшәгән халыклар һәм җитәкчеләрнең зирәклегеннән тора. Шулай ук, Русия җитәкчеләренең һәм сәясәтчеләренең фикерләү дәрәҗәсеннән дә, әлбәттә. Әгәр кайбер хәсрәт сәясәтчеләрнең алда да «нык тотарга һәм бернәрсәне дә кулдан ычкындырмаска» кебек империячел категорияләр белән эш итсәләр, бәла-казаны көт тә тор!

**— Мин Сезгә, тамырларында татар каны аккан кешегә, мөстәкыйльлекнең Татарстан үрнәгенә ничек карыйсыз, дияр идем?**

— Нигездә, әйбәт. Мин бу үрнәкне бик хуплар идем, әлбәттә, әгәр Татарстан берәр яңа, төпле икътисади үрнәк тәкъдим итсә. Сездә дә, сәрхуш Русиядәге кебек үк, товар-акча мөнәсәбәтләре хөкем сөргәндә, мин мөстәкыйльлекнең мондый үрнәген тулаем кабул итә алмыйм. Әллә сездә Русиягә караганда икътисад көчлерәкме? Һич юк! Милли-мәдәни, мәгърифәти, телне тергезү һәм саклап калу юнәлешендә Татарстан, һичшиксез, зур эшләр башкарды. Моның өчен рәхмәт әйтергә кирәк.

**— Шеффи әфәнде! Сезгә соңгы сорау. Менә сез, имам Шамил, тарихи ватан булган Дагстан авылы Гимрыга барган идегез. Белгәнебезчә, аңа һәйкәл кую һәм мемориаль комплекс төзү турында күптән сүзләр йөри. Бу мәсьәлә бүген ничек тә булса хәл ителәме?**

— Әлегә эш бәхәсләр дәрәҗәсендә генә тора. Берәүләр, шәригать законнары буенча һәйкәл куярга ярамый, диләр, ә икенчеләре — киресенчә, ярый дип сукалыйлар. Минемчә, һәйкәл һәм мемориаль комплекс аның туган җирендә булырга тиеш. Шулай ук, Калугада һәм Киевта да булсын иде. Чөнки гомеренең күпмедер вакыты шунда узган.

*Декабрь, 1997 ел.*

## РЕНАТ ИБРАҺИМОВ:

### «Мин «Газпромда» да җырлыйм»

Мәскәүнең «Яңа Черемушки» метросыннан йөргән 60 нчы номерлы троллейбуска утырып, алдан ук килешенеп куелган кешем белән очрашып сөйләшер, әңгәмә корыр өчен, әлегә миңа таныш булмаган «Газпром» иленә таба юл тоттым.

Алдымда, чыннан да, купшы диварлардан төзелгән әкәмәт матур бер шәһәрчек — «Газпром» империясенең башкаласы басып тора. Ул үзе Кызыл Пресня яры буенда урнашкан Ак йортныкы шикелле үк металлдан челтәрләп эшләнгән биек койма белән әйләндереп алынган. Пропускка алдан ук заказ бирелгән иде. Өченче корпустагы океан артында эшләнгән тиз йөрешле лифтка керүем булды, күз йомганчы тугызынчы катта идем инде.

Берничә метр үткәч тә, кабул итү бүлмәсенең ишегенә килеп төртелдем. Ишектә язу: «Мәдәният идарәсе башлыгы, Русия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының халык артисты Ренат Исламович Ибраһимов».

Шул вакыт, әйтерсең лә, зур сәхнәгә чыккандай, мөлаем елмаеп кабинетыннан «шеф-чиновник» — халкыбызның яраткан артисты Ренат Ибраһимов үзе килеп чыкты һәм мине үз бүлмәсенә чакырды.

Эш бүлмәсе — түрәләр кабинеты өчен гадәти саналган чит ил мебель гарнитуры белән җиһазландырылган. Стенада төсле фото: шушы империянең башлыгы Рем Вяхирев дуслары Вячеслав Добрынин, Владимир Винокур, Ренат Ибраһимов һәм Русиянең башка күренекле сәхнә йолдызлары арасында.

Тугызынчы каттан Мәскәү офыкларына күз төшереп, уйларымны бер ноктага туплап, кабинет хуҗасы белән әңгәмә кора башлыйм.

### ОЧРАШУ

**— Ренат! Тыныч кына яшәп яткан Казан шәһәреннән соң бу болганчык, ыгы-зыгы, шау-шулы Мәскәүдә үзегезне ничек хис итәсез?**

— Бик әйбәт хис итәм, хәтта бик тә яхшы дияр идем. Дөресен әйткәндә, мин бу урында әле быелның май аеннан гына эшли башладым. Табигатем буенча эшлекле кеше мин, ләкин ихлас күңелдән әйтәм, иҗат мөмкинлекләреңне, уй-теләкләреңне тормышка ашырырга мөмкинлек булмаган җирдә яшәү күңелсезрәк. Билгеле, кайвакытларда ял итеп аласы да килә.

Ләкин, халык әйтмешли, хәрәкәттә — бәрәкәт. Ә Мәскәүдә, Русия башкаласында эшләү минем өчен яңалык түгел. Мәскәү минем тормышымда, Казаннан кала, икенче шәһәр. Үз вакытында Мәскәү миңа зур иҗат дөньясына юл күрсәтте.

**— Озак еллар буена дөньяның мәшһүр сәхнәләрендә чыгыш ясаганнан соң, бүгенге социаль-икътисади хәлнең иң катлаулы бер дәверендә, Русиянең таркалып барган хуҗалыгының шыгырдавык арбасына җигелү сездәй актив иҗат кешесе өчен авыр эш түгелме?**

— Мин иҗат кешесе, аппаратта эшләгәнем юк иде. Бүген чиновник хезмәтен башкарсам да, асылда, җырчы мин. Ә Русиянең «Газпром» акционерлык гиганты миңа Казанда финанс кытлыгы сәбәпле тормышка ашыра алмаган иҗат планнарымны үткәрергә ярдәм итәчәк. Шул сәбәпле мин Казанда җыр театры, студия төзи, кыйммәтле аппаратура ала алмадым. Монда, «Газпром» кысаларында мин мәдәният өлкәсендә зур масштаблы чаралар үткәрә алачакмын.

**— Яңа эшегез нидән гыйбарәт?**

— Безнең мәдәният идарәсе «Газпром» системасында эшләгән төбәкләрдәге иҗат берлекләре, коллективларын барлау, системалаштыру һәм аларның эшләрен координацияләү белән шөгыльләнә. Дөресен әйткәндә, «Газпром» үз кешеләрен мәдәни азык белән дә туендырырга тиеш. Бу —төрле фестивальләр, бәйгеләр үткәрү, үзешчән сәнгать коллективларына, яшь талантларга профессиональ ярдәм күрсәтү, талантлы яшьләрне дөньякүләм фестивальләр һәм бәйгеләрдә катнашуга әзерләү.

**— Миңа калса, Татарстан да сезнең игътибар үзәгеннән читтә калмагандыр...**

— Билгеле. Татарстанда «Газпром»ның көчле структуралары эшли. Идарәнең эш планында мәдәният өлкәсендәге бик күп мәсьәләләр хәл ителәчәк, ә Татарстандагы хәлләрне мин бик яхшы күзаллыйм. Әле без Казанда «Газпром» акционерлык җәмгыятенең мәдәният филиалын төзергә уйлыйбыз. Шуны да истән чыгармыйк, безнең Казаныбыз ул Идел һәм Урал буе халыкларының да милли-мәдәни үзәге булып тора.

**— Билгеле булганча, «Газпром» Русия Акционерлык Җәмгыяте «Прометей-АСТ» телекомпаниясен оештыручы булып санала. Моннан тыш, «Газпром» әле Самарадагы «Терра» шикелле төбәкара телекомпанияләрне дә оештыручы икән. Бу телекомпанияләрне контрольдә тоту да сезнең вазифага керәме?**

— Әйе, югарыда әйтелгән барлык телекомпанияләрнең дә эшен контрольдә тоту безнең идарә вазифаларына керә.

**— Ренат! Тагын бер нәрсә кызыксындыра, гомумән, сезне Мәскәү чиновниклары, «Газпром» империясе әһелләре ничек кабул иттеләр?**

— Бик яхшы. Профессиональ җырчы аларга эшкә килгән икән, бу начар түгел, дип уйладылар булса кирәк.

**— Сезнең әти-әниегез кемнәр? Сезнең гаиләдән кем дә булса иҗат эше белән шөгыльләнүче, җырчылар бармы?**

— Мин Львовта туганмын. Әти-әниләрем чыгышлары буенча Татарстаннан. Сугыштан соң Украинада яшәп калган булганнар. Ләкин мин тугач та (мин гаиләдә соңгы бала), алар Казанга кайтып киткәннәр. Шулай булгач, минем барлык үткән гомерем Казан белән нык бәйләнгән.

Әтинең музыкаль белеме юк, ләкин ул бик күп төрле музыка коралла-

рында искиткеч әйбәт уйный иде. Татар халык көйләрен дә яратып уйный иде ул. Ә әни ягыннан минем туганнан-туган абыем Рафаил Билалов пианист һәм композитор, туганнан-туган сеңлем Луиза Казан симфоник оркестры музыканты.

**— Мәктәп елларыгыз ничек үтте? Ул елларда нәрсә белән мавыктыгыз?**

— Әле дә хәтеремдә, безнең өйдә китапханә бар иде, нигездә, ул тарихи китаплардан тора иде. Әти тарихи китаплар укырга яратты. Ә миңа әдәби китаплар ошый төшә иде. Мин шулай ук ЖЗЛ сериясен бик яратып укыдым. Казанның 25 нче мәктәбендә укый башладым, 6 нчы мәктәпне тәмамлап чыктым.

**— Балачакта, мәктәп һәм студент елларында сәхнә кумирыгыз кем иде?**

— Ул елларда безнең барыбызны да бертигез итеп совет мәдәнияте тәрбияләде. Үз илебез җырчыларының грампластинкалары бар иде. Чит ил сәнгате, талантлы җырчылары һәм музыкаль группалары турында без хәбәрдар түгел идек. Үзегез беләсез, безнең ил ябык иде. Кемгәдер ошарга тырышу хисе булса да, андый кешеләр әллә ни юк иде. Безнең ил җырчыларыннан Георг Отс, Мөслим Магомаев һәм якташыбыз Федор Шаляпин ошый иде миңа.

**— Сезгә Аллаһы Тәгалә тарафыннан аерым талант бирелүе турында кайчан аңладыгыз?**

— Мин әле Казанда балалар бакчасына йөргәндә үк җырлый башлаган идем. Барлык бәйрәмнәрдә дә катнаштым, хорда җырладым. Мәктәптә дә шулай ук булды. Ә менә консерваториягә укырга кергәч инде аңлый башладым, җыр ул тоттың да җырладың гына түгел, ә аның өчен табигать биргән талантны үстерү өчен укырга, күп итеп тир түгәргә кирәк икән әле.

**— Консерваториядә бергә укыган иптәшләрегезне искә төшергәлисезме?**

— Студент чактагы иптәшләремнән Зилә Сөнгатуллина, Венера Ганиева, Рубин Абдуллин, Руслан Дәминов һ.б. исемнәре әле дә күңелемдә саклана.

**— Үзегезнең җыр осталыгыгыз белән бик күпләрнең кумиры булдыгыз. Талант ияләренең күбесе уңышлардан башлары әйләнеп «йолдыз» чире белән авырый башлыйлар. Бу чир сезгә дә йокмадымы?**

— Бу, беренчедән, кешенең холкыннан, икенчедән, гаиләдәге тәрбиядән киләдер. Бәхеткә, бу авыру мине читләтеп үтте.

**— Сезгә нинди аудитория каршында чыгыш ясарга җиңелрәк? Нинди җырларыгыз халыкка күбрәк ошый? Кайсы җырларны үзегез яратып башкарасыз?**

— Кем алдында чыгыш ясасам да миңа барыбер, мин сәхнәгә бер үк дәрәҗәдә тырышып әзерләнеп чыгам. Билгеле, татар авылында мин рус җырлары гына җырлый алмыйм, татарча репертуар әзерлим. Үзем өчен миңа барлык чыгышларым да истәлекле. Татар җырларыннан мин үземнең җырлау манерасына якынрак булган җырларны сайлыйм.

Күбрәк мин рус, итальян һәм инглиз телендәге җырларны башкарам. Аурупа мәдәниятенә якынрак кеше мин.

**— Чит ил җырлары, аерым алганда, итальян җырлары, нәрсәсе белән башкаручыларны үзенә җәлеп итә?**

— Итальян, неаполитан җырлары җырчыдан аерым вокал мөмкинлекләрен таләп итә. Бу барлык җырчыга да бирелми, һәр артистның үз амплуасы. Һәм һәр кеше дә үзе белгән эшен эшләргә тиеш.

**— Чит ил тамашачысы сезне ничек кабул итә?**

— Чит илләрдә мин еш кына булам. Америка, Финляндия татарлары алдында җырлаганым бар. Читтә дә мине бик җылы кабул итәләр, гомумән, Русиядән килгән артистларны чит илләрдә күтәп алалар.

**— Сезне нинди милли хисләр били, аларны тормышка ашырып буламы?**

— Миндә андый хис бар. Бөтен теләгем, хыялым — татар җырын, татар музыкасын халыкара аренага чыгару. Ә моңа бөтен мөмкинлекләр, нигез бар. Ләкин Татарстанда моның өчен шартлар тудырылмаган. Композиторлар, җырчылар көн саен ипи турында уйламыйча, халкына тугрылыклы иҗат итсеннәр өчен республикада ныклы матди база булырга тиеш.

**— Дусларыгыз күпме?**

— Беренчедән, дуслар күп булмый ул. Иң якын дусларым минем хатыным Альбина, балаларым. Башка бик якын дусларым юк та шикелле.

**— Тавышымны югалтырмын, яисә дуслар хыянәт итсә, дигән куркыныч уйлар күңелегезгә килгәне юкмы?**

— Юк. Мондый саташулар белән авырганым юк та, булмас та. Мин тормышны матур ягыннан гына күрә беләм.

**— Хоббиегыз?**

— Рәсем сәнгате. Консерваториягә кадәр мин музыка һәм сәнгать училищеларын тәмамладым. Берзаман мин рәсем белән бик нык мавыктым: табигать күренешләре, натюрморт, портретлар ясадым. Танылган рәссам Илдар Зариповтан дәресләр алдым, бик күп күргәзмәләрдә катнаштым. Үземнең аерым күргәзмәләремне дә оештырдым. Кайбер хезмәтләрем әле дә саклана, ләкин күбесе дачабыздагы янгын вакытында юкка чыкты.

**— Нинди ашамлыкларга өстенлек бирәсез? Кайсы халык ашлары сезгә ошый төшә?**

— Аш ягына килгәндә мин нәзберек кеше түгел. Үзебезнең татар ашларын яратам. Ләкин соңгы вакытта аларны сирәгрәк ашарга тырышам, чөнки анда камыр һәм ит күп. Аннары ит һәм бәрәңге биологик яктан үзара ярашмыйлар.

**— Мәскәүгә күчеп килгәч, берәр сәхнәдә чыгыш ясаганыгыз бармы?**

— Берничә мәртәбә танылган җырчылар белән бергә концертта катнаштым. Гел чакырып торалар, анысы.

**— Казанда «Газпром» империясенең вәкилен түгел, ә үзебезнең якташыбызны, талантлы җырчыны кайчан күтәргә була?**

— Казан — минем ватаным. Анда миңа белем биргән консерватория һәм талантлы укытучылар бар. Казанга мин эчке дулкынлану белән кайтам.

## Сугышлар шулай бетә...

### «БҮЛӘКЛӘНҮГӘ ТӘКЪДИМ ИТЕЛГӘН»

*(Непряха авылында интервью. Май, 1966 ел)*

Бөек Ватан сугышы геройлары, Рейхстагны штурмлауда һәм алуда катнашучылар турындагы бу язмамда мин канкойгыч тарихи вакыйганың шаһиты булган теге яки бу солдатның, офицерның ролен киметеп күрсәтергә теләмим. Гитлерның сугыш машинасы — Рейхстагны алуда катнашкан һәркем Советлар Союзы Герое исеменә лаек. Хәтта ул Ватан азатлыгын яклап, шушы соңгы яуда гына сугышкан булса да.

Җиңү Байрагын Рейхстаг өстенә кадап, Бөек Ватан сугышы тарихына кергән һәм бу батырлыклары өчен Советлар Союзы Герое исемен алган грузин егете Мелитон Кантарияга, рус егете Михаил Егоровка бернинди дә гаеп тагасым килми. Әмма бу изге тарихи вакыйга да безнең илгә хас тәртипсезлектән, буталчыклыктан азат калмаган. Хәтта кайбер командирлар коньюнктурщинага буйсынып, тарих фактларын бозып күрсәтүдән дә тайчанмаганнар.

Өлкән буын яхшы хәтерли: Бөек Ватан сугышында катнашучылар турында алтмышынчы елларда гына яза башладылар. Аңа кадәр халык сугыш яраларын төзәтте, ил хуҗалыгын торгызды. Исән калган һәм һәлак булган фронтовиклар турында истәлекләр сөйләргә вакыт юк иде.

60 нчы еллар башында һәм аннан соң мин, «Красное прикамье» газетасының (Сарапул, Удмуртия) яшь журналисты, сугышның бик күп геройларын эзләп таптым. Рейхстагны алуда катнашучылар — полк штабы башлыгы, Сарапулда туып үскән подполковник Петр Волгин, 674 нче полкның взвод командиры, Сарапул районы Мазунино авылыннан сержант Леонид Васильевич Медведев, 756 нчы полкның рота командиры, Сарапул районы Непряха авылыннан лейтенант Николай Петрович Печерских турында яздым.

Хәтеремдә, 1966 елның 5 маенда Сарапул хәрби комиссариатында мин лейтенантның шәхси эш кәгазьләреннән түбәндәгеләрне күчереп алдым: «Рейхстагны алуда катнашкан өчен Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителде. Югары Главкомандованиенең 4 рәхмәте белдерелде. Берничә тапкыр яраланган».

Н.П.Печерских белән очрашудан соң «Удмуртская правда» республика газетасының 1966 елның 9 май санында «Ул Рейхстагны штурмлаган» дигән мәкаләм чыкты. Мин анда болай яздым: «Егерме тугызынчы апрельдә иртәнге сәгать 3 тә Печерских хезмәт иткән рота Шпрее елгасын кичә башлый. Күпергә иң беренче булып үз отделениеләре белән Данилов һәм Глушков керә. Рейхстаг ягыннан гитлерчылар көчле ут ача. Пулялар, күпердән рикошет ясап, янгырдай ява, снарядлар ярыла.

Безнең артиллерия дә эшкә керешә. Ул арада Печерских ротасы солдатлары Шпрее аша җәяүлеләр йөри торган күпердән тиз генә чыгып, Рейхстаг каршындагы күп катлы йорт янына урнашалар. Иң беренче кызыл байракны шул йортка эләләр.

Печерских бер төркем солдатлар белән тәрәзә аша өйгә керә һәм фатирларны гитлерчылардан чистарта башлыйлар. Йортны тиз азат итәләр. Әмма Печерских үзе яралана. Соңгы эш — Рейхстагны аласы бар. Мәйдан аркылы якын килә торган түгел — аны су белән тулы канал әйләндереп алган. Печерских шул вакыт канализация торбасыннан шуып килергә дә, Рейхстаг подъезды каршындагы люктан чыгарга дигән фикергә килә.

Люктан иң беренче булып сержант Глушков чыга һәм ачык ишектән Рейхстагка килеп керә. Аның артыннан солдатлар төркеме ыргыла. Шунда Глушков: «Кабаланмагыз! Берәмләп керегез!» — дип кычкыра.

Рота командиры Печерских үзе күп кан югалтудан Рейхстаг баскычында аңын җуя һәм аны госпитальгә озаталар. Алар полкында хезмәт иткән Егоров һәм Кантариянең Рейхстаг түбәсенә Кызыл байрак кадавын ул госпитальдә белә.

1966 елның май аенда, әлеге мәкаләмне әзерләп йөргәндә, мин бу эштә ниндидер алдашу булганлыгын сизенгән шикелле, Николай Петрович Печерскихтан кат-кат сорадым: «Җиңү Байрагын иң беренче булып Рейхстагка кем кадады соң?

— Егоров белән Кантария. Безнең 150 нче Идрицкий укчылар дивизиясенең 756 нчы полк солдатлары,— дип күз дә йоммый җавап бирде Н.П.Печерских.

— Сез моны каян беләсез? Сез бит госпитальдә булгансыз,— дидем мин, бирешергә теләмичә.

— Госпитальдән соң, безгә 756 нчы укчы полк командиры полковник Ф.М.Зинченко сөйләде. Госпитальдән 1945 елның 9 маенда чыктым мин. Ул көнне Рейхстагны штурмлауда катнашучылар бергә җыелып фотога төштек. Безнең арада Егоров белән Кантария дә бар иде.

## РЕЙХСТАГ ТҮБӘСЕНӘ БЕРЕНЧЕ БАЙРАКНЫ КЕМ ЭЛГӘН?

*(Читтән торып интервью. Одинцово шәһәре. Мәскәү өлкәсе. Январь, 1998 ел.)*

Бу язма авторының үтенече белән, тарихи вакыйгалар турында 136 нчы артиллерия бригадасы ветераны, отставкадагы полковник Николай Дмитриевич Иванов хат язып җибәрде. Ул — Газетдин Казыйхан улы Заһитов үзенең дүрт иптәше белән бергә хезмәт иткән дивизия командиры. Николай Дмитриевич хәзер түбәндәге адрес буенча яши: 143000, Мәскәү өлкәсе, Одинцово шәһәре.

1945 елның Беренче маенда иртәнге сәгать өченчедә сержантлар М.Егоров һәм М.Кантария батальон командирының политбүлек буен-

ча урынбасары А.Берест белән бергә Рейхстаг түбәсенә менәләр. Әмма бу вакытта түбәдәге скульптуралар арасына Кызыл байрак урнаштырылган була. Аны 30 нчы апрель төнендә — 22 сәгать 40 минутта 136 нчы артиллерия бригадасы артиллерист-разведчиклары Г.Заһитов, М.Минин, А.Бобров, А.Лисименко куя. Алар белән капитан В.Маков җитәкчелек итә.

Бу биш солдатның батырлыгы ни сәбәпле күләгәдә кала соң? Моны төшенер өчен, 1945 елның апрель ахырында булган вакыйгаларны хәтердә яңартырга кирәк.

1945 нең апрелендә Германиянең корыч калканы — Рейхстагны штурмлау вакыты килеп җиткәч, 3 нче удар Армиянең хәрби Советы Рейхстагка һөҗүм итү өчен ирекле ләр отряды төзү тәкъдиме белән чыга. Партия җыелышлары үткәреп, иң тәҗрибәле батыр сугышчыларны сайлап алалар.

3 нче артиллерия Армиясе командалыгы һәм һәр дивизия шулай итеп һөҗүм группасы җыя. Үзем яраланганчы командалык иткән 832 нче артиллерия дивизионыннан да бер группа сайланган. Капитан В.Н.Маков җитәкчелек иткән бу группа Рейхстагны алганда капитан Неустроевның беренче батальоны составына керә. Бу батальон 150 нче Идрицкий дивизиясенең 756 нчы укчы полкныкы була.

Инде әйткәнемчә, капитан В.Д.Маков группасына иң батыр сугышчылар, сержантлар Г.Заһитов, М.Минин, А.Бобров, А.Лисименко языла.

Һәр группага Җиңү Байрагы бирәләр. 3 нче удар Армиянең Хәрби Советы кабул иткән мөрәҗәгатьтә болай язылган була: «Рейхстаг өстенә беренче Җиңү Байрагын кадаган группаның һәр сугышчысына Советлар Союзы Герое исеме биреләчәк».

79 нчы укчы корпус командиры приказы белән 1945 елның 30 апрелендә 21 сәгать 30 минутта хәлиткеч штурмга әзерлек башлана.

Капитан Неустроев батальоны Рейхстагка юнәлүгә, сержантлар Г.Заһитов, М.Минин, А.Бобров, А.Лисименко һәм капитан В.Маков, төп көчләрне дә көтеп тормыйча, бина эченә ыргылалар. Алар ут ачып, киң гранит баскычтан өскә күтәреләләр. Әмма бикле зур ишеккә тап булалар. Бераз тоткарлык килеп чыга, ишек каршына бер взводка якын солдат җыела.

Нәкъ шул вакыт капитан В.Маков үзенең солдатлары белән килеп җитә. Заһитов һәм Лисименко каяндыр бүрәнә табып китерәләр, бергәләп таран ясап ишекне ачалар.

Капитан В.Маков егетләре граната һәм пулялар белән юлны чистартып, алга үтәләр. Аларга укчы-солдатлар ярдәм итә. Чардакка җитәрәк, тимер торба кисәге табалар. Байрак эләр өчен яхшы таяк булыр дип аны да алалар һәм юан чылбырдан үрмәләп бер-бер артлы түбәгә чыгалар. Алар ут яктысында скульптураларны күреп алалар. Баш өстендә, бертуктаусыз чыжылдаган пуляларга да карамыйча, өлкән сержантлар Газетдин Заһитов һәм Михаил Минин беренче Кызыл байракны шул скульптураларга урнаштырырга булалар. Минин, байрак тукымасында үзенең һәм 4 көрәштәшенең исемен язып, мәңгеләштереп куя. Заһитов

кулъяулыгын ерткалап тасмалар ясый да, шулар белән байракны юлда тапкан тимер торбага бәйлиләр. Скульптураны капшап, җайлы урын табалар да, шунда байракны урнаштыралар. Егылмасын өчен, аны «Җиңү Алиһәсе» скульптурасының таҗына яхшылап бәйләп куялар. Соңыннан капитан В.Маков өлкән сержант А.Бобров белән аска төшә һәм рация аша корпус командиры генерал-майор Переверткинга хәбәр җибәрә. Сугышчан биремне үтәп, 22 сәгать 40 минутта Рейхстагка Кызыл байрак кадаулары турында әйтә. (Бу хәбәрне архив материаллары да раслый.) Рейхстаг түбәсенә беренче байрак шулай куела.

1 Май төнендә сәгать өченчедә Рейхстагка байрак белән сержантлар М.Егоров һәм М.Кантарияне китерәләр. Алар белән лейтенант А.Берест җитәкчелек итә. Бу өчлек бернинди каршылыксыз Рейхстагка керә, җиңел генә түбәгә менеп, икенче Җиңү Байрагын урнаштыра.

1945 елның 1 Маенда 13 нче артиллерия бригадасы командалыгы өлкән сержантлар Г.Заһитов, М.Минин, А.Бобров, А.Лисименко һәм капитан В.Маковка Советлар Союзы Герое исеме бирү турында рәсми документлар әзерли. 2, 3, 6 нчы май көннәрендә 79 нчы укчы корпус командиры, өченче удар Армиянең артиллерия командующие бу ходатайствоны язмача раслый.

Шуннан соң Җиңү Байрагы турында тарихның иң ямьсез өлеше башлана. Байракны Рейхстагка капитан В.Маков группасының урнаштыруы югары җитәкчелеккә бер дә ошамый. Бу эштә планнар башкачарак була. Әмма бер дә аптырап тормыйлар: зур тарихи алдашуга керешәләр.

В.Маков группасының батырлыгы бөтенләй онытыла. Әле хәзер дә рәсми органнар Рейхстагка Җиңү Байрагын кадаган чын геройлар турында мәгълүмат бирмиләр. Сугыш ветераннарының хакыйкатьне ачарга теләүләре дә нәтиҗәсез кала. Ватан һәм Кораллы Көчләрнең җитәкчесе булып И.В.Сталин торган елларда дөреслекне әйтергә дип авыз ачу да иң зур җинаять саналды.

Шунысы сөенечле, М.Егоров һәм М.Кантария икесе дә югары әхлаклы кешеләр булып чыга. Алар бервакытта да Рейхстагка Җиңү Байрагын икенче булып, В.Маков егетләреннән соң кадауларын яшермиләр. Бу хакта «Җиңү Байрагы» дигән китапта да язалар. Әмма рәсми версия шулкадәр көчле була ки, М.Егоров һәм М.Кантария язганнарга әһәмият бирмиләр.

136 нчы артиллерия бригадасы ветераннары Советы 5 геройның исемен халыкка «җиткерү» өчен күп нәрсә эшләде. Әмма каты цензура хакимлек иткән тоталитар режим чорында ветераннарның дөреслекне табарга тырышуы хөкүмәткә һәм партиягә каршы гамәл дип бәяләнде. Капитан Маков группасы турында беркем дә бер нәрсә сөйләмәде. Бары тик сиксәненче еллар ахыры, туксанынчы еллар башында гына дөреслек әкренләп өскә калка башлады.

Хәрби көчләрнең Үзәк музеендагы Җиңү залына урнаштырылган Җиңү Байрагы янында капитан В.Маков, өлкән сержантлар Г.Заһитов,

М. Минин, А.Бобров һәм А.Лисименко портретлары белән күргәзмә оештырылды. Анда Рейхстагка байрак куючыларның нәкъ менә шушы сугышчылар булуы турында язылган.

Поклонный тавындагы мемориаль музейда да В.Маков группасының беренче булуы турында документлар бар.

Сугыш энциклопедиясенең соңгы басмасындагы «Җиңү Байрагы» язмасында (1995 ел, 3 том, 292 бит) Рейхстагка Җиңү Байрагын В.Маков солдатлары кадавы хакында язылган.

Батырларга 1945 елның маенда ук бирелергә тиеш булган Герой исемен генә тапшырасы кала. Кызыл Йолдыз орденлы сугыш тарихы институты да күпьеллык эзләнүләрдән соң, капитан В.Д.Маков, өлкән сержантлар Г.К.Заһитов, А.П.Бобров, М.П.Минин, А.Ф.Лисименко Россия Герое исеменә лаек, аларның полкташ ветераннары язган үтенечне канәгатьләндерергә кирәк дип тапты. Шундый зур институтның бу фикере кырык бишнең маенда күз буяу өчен ясалган тарихи ялганны төзәтү өчен иң үтемле дәлил.

Бүген 5 батырның икесе исән. В.Маков — Мәскәү өлкәсенең Железнодорожный шәһәрендә, М.Минин Псковта яши.

**— Николай Дмитриевич, зинһар өчен, минем якташым Газетдин Заһитов белән ничек танышуыгыз турында сөйләгез әле...**

— Мин сугыш башланыр алдыннан Томск артиллерия училищесын тәмамладым. Прибалтикага хезмәт итәргә җибәрделәр. Сугышның иң беренче көннәреннән үк Англия кораллары белән коралланган Латвия дивизиясендә сугыштым. Иң беренче айларның бар авырлыгын үземнең җилкәдә татыдым. Өч тапкыр чолганышта калдым. Соңгы чолганыштан 1941 нең ноябрендә чыктым. Шул чакта миңа Мәскәү өчен сугышларда катнашырга 832 нче аерым разведка-артиллерия дивизионы тупларга куштылар. Валдайда, Селигер елгасы янындагы Рождество авылында бу хәрби дивизионны җыйдык. Дивизион 27 нче Армия командующиена буйсынды. Соңыннан бу Армия 3 нче удар Армия дип үзгәртелде.

Кырык бернең ноябрендә сезнең якташыгыз Газетдин Заһитов та шушы дивизионга килде һәм оптик разведка батальонына билгеләнде. Үзен бик яхшы профессиональ сугышчы итеп күрсәтте, өлкән сержант дәрәҗәсенә җитте. Ул вакытта дивизионда 400 ләп хәрби иде.

1944 елның ноябрь азагында безнең дивизион 136 нчы Армия бригадасы составында Берлин операциясенә кереште.

**— Сезнең сугыштан соңгы тормышыгыз нинди булды?**

— Сугышны майор, дивизион командиры булып тәмамладым. Аннан соң артиллерия полкы командиры урынбасары, полк начальнигы, бригада командиры урынбасары булып хәрби хезмәт юлын дәвам иттем. 1960 елда Фрунзе исемендәге академияне бетердем. Соңыннан стратегик ракета гаскәрләренең баш командующий аппаратында эшләп, 1992 елда ялга киттем. Хәзер отставкадагы полковник, Ватан сугышы инвалиды, пенсионер. Мәскәү өлкәсенең Одинцово шәһәрендә яшим.

## РЕЙХСТАГНЫҢ БЕРЕНЧЕ СОВЕТ КОМЕНДАНТЫ

*(Краснодарда 1999 елның 9 маенда булган интервью)*

Краснодар шәһәренең «Юбилейный» микрорайонындагы яңа йортның ике бүлмәле фатирында, исеме бөтен Советлар Союзына таныш булган, Степан Андреевич Неустроев яши. 756 нчы полкның беренче батальоны капитаны, Рейхстагны алганда батальон белән командалык иткән кеше. Бу батырлыгы өчен аңа Советлар Союзы Героеның «Алтын Йолдыз»ын бирәләр. С.А.Неустроев исеме тарихка Рейхстагның беренче совет коменданты булып кергән.

Сугыш героеның бүгенге тормышы бик тыйнак, хәтта фәкыйрь дияргә дә мөмкин. Зур гына буп-буш бүлмә ишегендә полковник мундиры эленеп тора. Аның түшендә Герой йолдызы. Йокы бүлмәсенең бар җиһазы — ике тимер карават һәм күчереп йөртмәле кечкенә «Юность» телевизоры. Степан Андреевич үзе соңгы айларда бик еш авырый.

Сугыш героеның Берлин, Рейхстаг өчен барган көрәшләр турында хикәятен тыңлагач, мин әңгәмәдәшемә мондый сорау бирдем:

**— Рейхстаг өстенә беренче Җиңү Байрагын кем куйды соң?**

— Капитан В.Маков группасындагы өлкән сержантлар Г.Заһитов, М.Минин, А.Бобров һәм А.Лисименко, — дип күз дә йоммый чатлатып җавап бирде элеккеге комбат С.А.Неустроев. — 1945 елның 30 апрелендә төнге 22 сәгать 40 минутта булды ул. Мин кырык бишенче елдан бирле бу хакта сөйлим.

**— Ә сержантлар М.Егоров һәм М.Кантария белән ничек булды соң?**

— Сержантлар М.Егоров һәм М.Кантарияны Рейхстаг штурмыннан соң берникадәр вакыт үткәч, дөресрәге, 1945 елның 1 Маенда төнге сәгать өченчедә экскурсиягә китергән шикелле генә алып килделәр. Мин аларны фидакарь сугышчы булганнары өчен хөрмәт итәм, әмма катгый итеп әйтәм: Егоров белән Кантария Рейхстаг өчен булган һөҗүмдә катнашмадылар. Ә бөтен дан-шөһрәт аларга булды.

Шул ук вакытта сержантларның намусына пычрак атарга да ярамый, сугыштан соң алар һәрвакыт үзләренең беренче байракны кадамауларын әйтеп килделәр, моны берәүдән дә яшермәделәр.

**— Степан Андреевич! Тарихны шулкадәр оятсыз бозу кемгә кирәк булды икән?**

— 756 нчы полк командиры полковник Ф.М.Зинченко белән 150 нче Идрицкий дивизиясе командиры В.Шатиловка һәм Югары командирларның да кайберләренә кирәк булган, күрәсең...

Җиңү Байрагын Рейхстаг түбәсенә кадау белән сугыш бетмәде әле. Беренче майда иртәнге ашны китерделәр. Әмма без аны авызга алырга да өлгермәдек, немецлар, байракны күрептер инде, һөҗүмгә күчтеләр. Башта Рейхстаг янындагылары сугыша башлады, соңыннан бина эчендә качыппосып калган фашистлар да баш күтәрде, 3 нче май иртәсенә кадәр Рейхстагта каты бәрелешләр булды. Бары тик 3 нче майда гына иртәнге җиденчеләрдә гитлерчылар ак флаг күтәреп, бирелергә мәҗбүр булдылар.

Рейхстаг бер мәлгә тынып калды. Тиздән Г.К.Жуков белән Хәрби Совет членнары килеп җитте. Мин, Рейхстаг коменданты буларак Жуковка барысын да сөйләргә тиеш идем. Әмма аның тән сакчылары мине якын да җибәрмәделәр.

**— Степан Андреевич, сугыштан соңгы тормышыгыз ничек булды?**

— Яңа, 1947 елны мин Уралда каршы алдым. Соңыннан МВД органнарында хезмәт иттем. Уралдагы немец әсирләре лагереның начальнигы булдым. Йортлар төзедек, юллар салдык. Соңыннан үзебезнекеләр лагерена начальник итеп билгеләделәр. 1953 елда Берия амнистия игълан иткәч, мин дә запаска киттем. 1953 тән 1957 гә кадәр заводта слесарь булып эшләдем. 1957 дә яңадан хәрби хезмәткә чакырдылар. Чиләбе-44 дигән җирдә атом заводын саклаучы полк бар иде. Шунда башта комбат, соңыннан полк командиры булып хезмәт иттем. Бик җитди, куркыныч эш. Соңыннан Хрущев, юләрлек белән, хәрбиләрне кыскартты. Мин дә 1962 елда ялга киттем. 15 ел Краснодарда яшәдем. Соңыннан Севастопольгә күчеп килдем. 1994 тә аннан да киттем.

Ике балам бар иде. Улым гаиләсе белән 1986 елда авиакатастрофага эләгеп, вафат булды. Кызым Севастопольдә калды. Монда, Краснодарда, студент оныгым — кызымның улы белән яшим.

Гомумән алганда, минем тормыш юлын башкачарак узасым килгән иде. Хөкүмәтнең азакка кадәр уйланылмаган һәм халыкка каршы булган реформалары беренче чиратта безне — картларны бетереп атты. Җәмгыять таркалды. Кешеләр тигез булмаган катлауларга аерылдылар. Без шуның өчен сугыштыкмыни? Җәмгыятьтә җинаятьчелек гөрләп чәчәк атсын өчен миллионнарча егет һәм кызлар яу кырларында башларын салдылармыни?

Краснодар уртасында яшәүче бу бетерешкән, хәлсез картны тыңлаганнан соң, уфтанып куйдым. Ирексездән хәтергә җыр юллары килеп төште:

«Эх, батяня, батяня, батяня комбат...»

## РЕЙХСТАГ ӨСТЕНДӘГЕ БЕРЕНЧЕ ҖИҢҮ БАЙРАГЫ

*(Читтән торып интервью. Псков шәһәре, 1998 ел, февраль.)*

Газетдин Заһитовның фронтташ дусты Михаил Петрович Мининның адресын табып, мин аңа ике генә сорауга җавап бирүен үтенеп, хат җибәрдем.

Михаил Петрович миңа бик тәфсилләп хат язды. Сорауларыма тулы җавап биреп, сугыш чоры хатирәләре белән уртаклашкан, үзенең һәм Газетдин Заһитовның фоторәсемнәрен җибәргән. Мин аңа моның өчен бик рәхмәтлемен.

**— Михаил Петрович! Рейхстагны алу турында сөйләсәгез иде...**

— Гази Заһитов белән минем беренче очрашу агитаторлар семинарында 1942 нче елның май уртасында булды. Карап торышка, башка солдатлардан бернәрсәсе белән дә аерылмый иде ул. Уртача буйлы, киң

җилкәле, чем-кара кыска, каты чәчле ир-егет. Яңакларында һәм борынында шадра эзләре бар. Зәңгәр күзләреннән ниндидер наз, самимилек бөркелә.

Сугышка Г.Заһитов медицина техникумының өченче курсыннан киткән. Техникумда алган белеме аңа фронтта һәрвакыт ярдәм итте. Аңа еш кына иптәшләренә беренче медицина ярдәме күрсәтергә, үзен куркыныч астына куеп башкаларның гомерен саклап калырга туры килә иде. Иптәшләре аны «лейб-гвардии медик» дип йөрттеләр. Ул дусларының шаяртуына тамчы да үпкәләми, киресенчә, үзе дә җор телле кеше булгач, рәхәтләнеп көлә, шаярта иде. Г.Заһитов кыю сугышчы, ышанычлы дус булуы, Ватанны чиксез яратуы белән көрәштәшләренең ихтирамын яулады.

...Без билгеләнгән сәгатьтә буш калган Моабит төрмәсенең киң коридорында сафка тезелдек. Корпусның политбүлек начальнигы, полковник И.С.Крылов уртага чыкты. Ул иң зур тарихи мәсьәләне хәл итәр өчен ике һөҗүм группасы төзү кирәклеген аңлатты һәм барлык солдатларны ике төркемгә бүлде. Берсенең командиры итеп капитан В.Д.Маков, икенчесенә майор М.М.Бондарь билгеләнде.

Полковник Крылов «Рейхстаг түбәсенә Җиңү Байрагын эләргә» дигән бурыч куйды. Ул кулындагы ике төргәк кызыл тукыманы Маков белән Бондарьга тоттырды. Рейхстаг түбәсенә беренче Кызыл Байрак элгән сугышчылар яки сугышчылар төркеменә — алар хәтта 100 кеше булса да Советлар Союзы Герое исеме биреләчәген әйтте. Аларның җитәкчеләре — взвод командирыннан алып дивизия командирына кадәр һәркайсы да бу югары исемгә лаек булачак. Үз чыгышын политбүлек начальнигы: «Бу сугышта һәлак булучыларның батырлыгын Ватан беркайчан да онытмаячак, аларның гаиләләренә һәрвакыт ярдәм итәчәк!» — дип тәмамлады.

Безнең һөҗүм группасы командиры В.Н.Маков озын буйлы, мәһабәт гәүдәле кеше иде. Күн курткасын капитан погоннары бизи. Курткасы астыннан Кызыл Байрак һәм Кызыл Йолдыз орденнары күренеп китә. Аның нык ихтыярлы, кыю кеше икәнлеге күз карашына чыккан. Без үзебезнең командирны бер күрүдән ошаттык.

«Кызыл Байракны кемгә тапшырабыз?» — дип сорады ул. Гиза Заһитов: «Безнең арада батарея парторгы Минин бар. Мин байракны аңа бирергә тәкъдим итәм», — диде. Башкалар да аны хуплады. Рейхстаг түбәсенә менеп җиткәнче сакларга кушып, командир миңа кызыл тукыма төргәге бирде.

Маков группасыннан мин А.Бобров, Г.Заһитов, А.Лисименконы гына беләидем. Алар белән бергә өч елдан артык бер разведка дивизионында хезмәт иттек. Барысы да коммунистлар, көрәштәшләренә һәрвакыт ярдәмгә килергә әзер батыр егетләр. Мин үземә ничек ышансам, аларга да шулай ышандым.

Соңгы сугышка керер алдыннан Г.Заһитов миңа тагын бер төргәк кызыл материя сузды. Анысын полковник А.П.Писарев биргән икән. Г.Заһитов гадәтенчә шаяртып: «Әйдә, Миша, безнең комиссар бул! Ике Кызыл Байрак өчен дә җавап бир», — диде.

Хәлиткеч бәрелеш алдыннан төп рубежга («Гиммлер йорты» подвалында) ике часть подразделениеләре дә җыелды.

Уң флангка майор В.И.Давыдов батальоны, сулга капитан С.А.Нестроев батальоны урнашты. Безнең штурм группасы алар уртасында калды.

К.Я.Самсонов батальоны иң кырыйдан сул флангтан һөҗүм башларга әзерләнә. Барлык өч батальон да алдагы бәрелешләрдә зур югалтулар кичергән. Шуңа күрә башка подразделениеләрдән җыелган солдатлар да шактый күп күренә. Алай да батальоннар 70-80% ка гына тулыландырылган.

Менә шундый аз составта һәм танкларсыз гына безгә Рейхстагны алу бурычы куелды.

Артиллерияне әзерлек сызыгына куярга биш минут кала А.Бобров, Г.Заһитов, А.Лисименко һәм мин почмактагы тәрәзәдән сикереп төштек тә каналга йөгердек. Г.Заһитов тәүлекнең кайсы вакыты булуга карамастан, бик яхшы ориентлаша иде. Каналны йөзеп чыгар өчен иң уңай җиргә алып килде.

Артиллерия һәм минометларны Тиргартен уртасына кертүгә, 22 сәгатьтә һөҗүм башлануын хәбәр итеп, яшел ракеталар күк йөзен балкытты. Бу вакытта без каналның икенче як ярына чыгып җиткән идек инде.

Төп көчләрнең килеп җитүен дә көтмәстән, без Рейхстаг ишегенә таба йөгердек. Бу маршрутны Заһитов көндез бинокльдән күзәтеп, бик яхшылап өйрәнгән иде. Шунлыктан без аның артыннан бертуктаусыз йөгердек. Исән калган фашистлар сулдан да, уңнан да ут ачтылар. Кирпеч һәм башка төзелеш материаллары өемнәре безне фашист пуляларыннан бик яхшы саклады лар.

Рейхстагка килеп җитәрәк, үзебез дә көчле ут ачтык һәм бер мәлгә дә туктап тормыйча, киң гранит баскычтан өскә йөгердек.

Ике якка ачылмалы бердәнбер зур ишек бикле иде. Аның уң һәм сул яңакларына яхшылап кирпеч түшәлгән. Тиздән бикле ишек каршына бер взвод чамасы солдат җыелды. Бергәләп ишекне этеп тә карадык, тибеп тә карадык — әмма ул бирешергә теләмәде. Бобров белән мин полковник Писарев биргән Кызыл Байракны ишек янына —стенага беркетергә булдык. Бу вакытта сәгать уклары 22 сәгать 10 минутны күрсәтә иде.

Байракны өскәрәк элү өчен Леша Бобров агач яки тимер торба кисәге эзләгән арада, мин кызыл тукымага карандаш белән беренче Җиңү Байрагын элүчеләрнең фамилияләрен «мәңгеләштердем»: Бобров, Заһитов, Лисименко, Минин. Леша 3 метрлы озын баскыч сөйрәп килде. Мин 2 метрлап мендем дә, Кызыл Байракны агачка бәйләп, стена ярыгына урнаштырдым.

Берничә минуттан стенада Кызыл байраклар саны шактый җыелды: һәр часть, подразделение үз байрагын Рейхстаг стенасына беркетте.

Ишек һаман ачылмаган иде әле. Эшнең болай озакка сузылуы безгә бер дә ошамады: кинәт һөҗүм иткәндә фашистлар каушап калачак һәм без дә максатка тизрәк ирешәчәк идек.

Гази баскыч төбендә яткан бүрәнәне алып килергә кирәк дигән тәкъдим ясады. Маковка бу фикер бик ошады. Ул да булмады, Лисименко белән Заһитов бүрәнәне күтәреп тә менделәр. Бүрәнә белән берничә тапкыр бәрүгә ишек ачылып китте. Солдатлар ташкын булып эчкә ыргылдылар. Гази Заһитов иң алда иде. Ул ишек ачылуга Рейхстаг вестибюленә бүрәнәсе белән «очып» керде. Аның артыннан Рейхстаг бусагасыннан Бобров, Лисименко һәм капитан Маков атлады.

Рейхстаг штурмы турында язучылар здание эчендә барган сугыш үзенчәлекләрен бер дә сурәтләп тормыйлар. Мин шуларга да тукталырга телим.

Артиллерия утыннан куркып, дошманнар җир астына төшеп качканнар иде. Рейхстагның беренче һәм өске катларында калучыларның каршылыкларын безнекеләр тиз җиңде. Совет гаскәрләренең һөҗүме бик тиз һәм көтмәгәндә булды, шуның белән безнекеләр вакыт ягыннан оттылар. Гитлерчылар аңга килеп, төп көчләрен сугышка керткәндә Рейхстагка Неустроев, Давыдов һәм башкаларның бригадалары кереп тулган иде.

Һөҗүмнең беренче уңышларыннан һәм фашистларның каушап калуыннан файдаланып, безнең командир Рейхстаг түбәсенә үк менәргә булды. Автоматларның бертуктаусыз тырылдавы, граната шартлаулары һәм солдатларның тавыш-гаугасын ярып, безнең капитан команда бирде:

«Минин, барысын да җый һәм флаг белән өскә мен!».

Заһитов, Бобров, Лисименко минем янда иделәр. Без дүртәүләп баскычтан өскә күтәрелдек. Гази алдан чапты. Баскычка чыга торган һәр коридорга гранаталар ыргыттык, автоматларыбыз да тынып тормады. Без икенче катка тиз менеп җиттек. Башка подразделение сугышчылары да нык ярдәм итте. Аларның бер төркеме фашистларны баскычка якын да җибәрмәде, икенчеләре безнең арттан йөгерде.

Чардакка җитәрәк, мин стенадан чыгып торган метр ярым озынлыктагы, 30 мм диаметрлы торба күреп алдым. Байрак бәйләргә бик шәп таяк булыр дип, торбаны да эләктердем.

Чардакка автоматлардан пулялар «яудырдык», берничә граната да ыргыттык. Заһитов фонарь белән яктыртып, йөк күтәрә торган чыгырны күреп алды. Ул ике яктан юан чылбырга тоташтырылган. Чылбыры шундый зур, аңа рәхәтләнеп аяк тыгарга, баскыч урынына файдаланырга мөмкин.

Без шул чылбырдан бер-бер артлы өскә мендек. Алдан Гази, аннан мин... Дүрт метр чамасы менгәч, тәрәзә аркылы түбәгә чыктык. Шул мәлне түбәдә снаряд шартлады һәм бөтен дөнья яктырып китте. Безгә бик яхшы булды ул — үзебез байрак эләргә уйлаган «Җиңү Алиһәсе» скульптурасын күреп калдык.

Көчле артиллерия атышы барса да, без байракны бронза сыннар өстенә кую ниятеннән кире кайтмадык. Шунда — түбәдә, мин 1945 елның 30 апрелендә 22 сәгать 30 минут — 22 сәгать 40 минут тирәсендә Рейхстаг түбәсенә байрак куючыларның фамилияләрен яздым: Бобров, Заһитов, Лисименко, Минин.

Байракны металл торбага бәйләр өчен, Заһитов үзенең кульяулыгын ерткалап, тасмалар ясады. Шул тасмалар белән Кызыл Байракны торбага бәйләдек.

Хәрби бурычны үтәгәннән соң гына мин үзебезне нинди зур куркыныч астына куюыбызны аңладым.

Мин бронза ат аркасына басып, җайдакның башындагы таҗына тотындым. Колакларны снаряд һәм мина шартлаулары яңгырата. Ул шартлаулардан хәтта бронза сыннар чайкала. Мин менә егылам, менә төшәм дип торам.

Тиздән ярдәмгә капитан Маков килеп җитте. Командир үз хисләрен яшереп тормады, шатлыктан һәркайсыбызны кысып кочаклады, үпте. Соңыннан корпус командиры, генерал-майор С.Н.Переверткинга сугышчан бурычны үтәү турында рация аша хәбәр итте. Ул матур сүзләр дә сайлап тормыйча, бар көченә трубкага кычкырды: «Иптәш генерал! Минем егетләр Рейхстаг түбәсендәге бер шәрә хатынның таҗына беренче булып Җиңү Барагын элделәр!» Моны политбүлек башлыгы полковник Ф.Я.Лисицын да ишеткән. (Бу хакта ул 1961 елда ноябрь киңәшмәсендә әйтте.)

Артиллеристларның (безнең группаны шулай диләр иде) Рейхстаг түбәсенә байрак кадавын һәр сугышчы ишеткән һәм бу хәбәр аларда изге патриотик хисләр уяткан иде.

Безнекеләр караңгыда һәм бөтенләй билгесез урында сугышуларына карамастан, бу бәрелештә дошманны кырдылар гына. Газетдин Заһитов каты яраланды. Дошман пулясы аның партбилетын, «Батырлык өчен» медаленең колодкасын теткәләп, йөрәгенә бер сантиметр гына кала күкрәген тишеп үткән. Ләкин герой сугыш кырын ташламады. Саша Лисименко һәм укчылар подразделениесе өлкән сержанты Тканов аңа беренче ярдәм күрсәттеләр (индивидуаль пакетлар белән яраларын бәйләделәр). Заһитов полк санчастена барудан баш тартты.

Ул Җиңү Байрагын сакларга дип яралы көе өч тапкыр чардакка менеп төште.

Җиңү Байрагын без 1945 елның 1 Мае иртәсенә — сәгать 5 кә кадәр сакладык. Шул ук вакытта Рейхстагның беренче катында калган рация, радистлар һәм командир белән даими элемтәдә тордык.

Рейхстагка полковник Ф.М.Зинченко килгәндә, төн яңа көнгә авышкан иде. Ул автоматчылар төркеме белән зданиегә килеп керде һәм капитан Неустроевтан «5 нче санлы байрак кая?» дип сорады. Неустроев полкта бу байракның барлыгын белмәгәнгә күрә, Рейхстагка бик күп байраклар эленүен әйтте. Бу сөйләшүне тыңлап торган сержант Л.Щербина байрак һәм полк разведчикларының «Гиммлер йорты» янындагы бункерда утыруларын әйтте. Зинченко тиз генә аларны Рейхстагка алып килергә боерды да, үзе «Гиммлер йортына» китте. Боларның бөтенесен безнең Лисименко күреп-ишетеп торган.

1945 елның 1 Маенда төнге сәгать өченчедә без — Лисименко һәм мин Маков белән элемтәгә керү өчен аска төштек. Нәкъ шул

вакытта здание эченә яңа байрак керттеләр. Кыска күн куртка кигән лейтенант А.П.Берест алдан бара. Аңа М.Егоров һәм М.Кантария, тагын ике автоматчы ияргән. Алар коронация залына үттеләр. Тагын ниләр эшләгәннәрдер — анысы миңа караңгы. Әмма Беренче май иртәнге сәгать 5 кә кадәр М.Егоров һәм М.Кантария Рейхстаг баскычында да, түбәсендә дә булмадылар.

Рейхстагка байрак элүебезгә ике-өч сәгать вакыт үткәч, мин беренче катта икенче һөҗүм группасы командиры майор Бондарьны очраттым. Аның белән кулларына Кызыл Байрак тоткан ике сугышчы да бар. Мин үзебез кадаган Байракны күрсәтергә теләп, Бондарьны түбәгә чакырдым. Ул риза булды, әмма түбәгә менгәнче, авызына су капкан кеше шикелле, бер сүз әйтмәде. Минем арттан майор, ике сугышчысы да менде. Бондарь түбәдә дә сөйләшмәде диярлек. Бары сугышчыларына үз байракларын ат сынының уңъяк арт аягына кадаргга боерды. Соңыннан без өчәү түбәдән төшеп киттек.

С.Н.Переверткинга хәрби бурычны үтәү турында әйткәч, Маков безгә дә шатлыклы хәбәр җиткерде.

Корпус командиры капитан В.Н.Маков, өлкән сержантлар А.П.-Бобров, Г.К.Заһитов, А.Ф.Лисименко һәм мине Советлар Союзы Герое исеменә, соңгы һөҗүмдә катнашучы һәркемне Ленин орденына тәкъдим итәргә дип приказ биргән.

1945 елның Беренче маенда иртәнге сигезләр тирәсендә без бригада штабына килдек. Подполковник А.П.Бумагин бик җылы каршылады. Штаб башлыгы приказы белән безнең дүртебезне дә фоторәсемгә төшерделәр. Соңыннан «Правда» корреспонденты подполковник Борис Горбатовка Заһитов белән икәү интервью бирдек. Үзебезнең ничек итеп Рейхстаг түбәсенә Җиңү Байрагын элүебезне сөйләдек. Корреспондент безне бик зур игътибар белән тыңлады, әмма блокнотына берни дә язмады.

Иртәнге аштан соң разведдивизион штабы начальнигы, капитан Владимир Анатольевич Абрамов безне үзенә дәште. Ул һәммәбезгә дә Советлар Союзы Герое исеме бирү турында бүләкләү кәгазе язды (архив МО СССР фонд 33, ОП 686 196, дело 6078, п.п168, 189, 205, 212).

Югары командованиенең Маков группасы батырлыгына нинди зур бәя биргәнен аңлау өчен, Заһитовның бүләкләү кәгазенә күз төшерү дә җитә.

Безнең гаскәрләр Берлин үзәге Рейхстагка якынайгач, иптәш Заһитов аны штурмлау һәм Җиңү Байрагын элү өчен барган сугышларда катнашу теләген белдерде. 1945 елның 26 апрелендә сержант Минин, өлкән сержантлар Бобров һәм Лисименко белән бергә Заһитов та хәрби бурычны үтәүгә кереште. Һөҗүм итүче пехота алдыннан барып, Заһитов Рейхстаг юлын яхшылап өйрәнде һәм безнең пехотаның дөрес хәрәкәтен тәэмин итте.

28 апрельдә разведчиклар фашистларның тылына үткәндә, немец часовоена юлыгалар. Часовойны аталар һәм подвалга бәреп керәләр. Бу бәрелештә алар 25 немецны әсирлеккә алдылар.

29 апрельдә Заһитов үзенең иптәшләре белән немецлар арасына кереп, безнең артиллериянең Рейхстагка һөҗүмен коррекцияләделәр. Алар урнашкан йортны фашистлар уратып ала, әмма геройлар бирешмиләр. Автомат һәм гранаталар белән алар 40 немецны үтерәләр һәм безнең пехота килгәнче йортны саклап торалар.

30 апрельдә Заһитов үзенең иптәшләре белән карта буенча Рейхстагка разведка үткәрделәр. 100 м ераклыктагы каналны тикшереп, иң уңайлы кичү урынын билгеләделәр. Разведка нәтиҗәсе турында алар 79 нчы корпус командирына радио аша хәбәр иттеләр.

30 апрельдә, Рейхстаг штурмы башлануга, Заһитов анда иң беренче булып керде. Әмма кукрәген үтәли яралады. Пуля аның партбилетын да тишеп үтте. Яралы көе өлкән сержант Заһитов һәм сержант Минин Рейхстаг башнясына менеп, беренче Җиңү Байрагын урнаштырдылар.

Рейхстагны штурмлаганда күрсәткән батырлыгы һәм кыюлыгы өчен иптәш Заһитов Советлар Союзы Герое исеменә лаек.

**— Михаил Петрович, сезнең сугыштан соңгы тормышыгыз нинди булды?**

— Мин Псков өлкәсенең Палкин районы Ванино авылында 1922 елның 29 июлендә тудым. 1938 елда җиде классны тәмамлагач Ленинград авиация техникумына укырга кердем. 1941 елның 30 июнендә үз теләгем белән фронтка киттем.

1946 елның көзендә демобилизацияләндем. Туган җирем Палкин районына кайттым. Башта район газетасы секретаре, соңыннан редактор булып эшләдем. 1947 елны үземнең авылдашыма өйләнеп, 38 ел бергә бәхетле гомер иттек.

1950 елда Ленинградка күчеп килдек. Тагын ике елдан миңа лейтенант исеме бирделәр һәм Совет Армиясе сафларына чакырдылар. 1954 елда В.В.Куйбышев исемендәге хәрби-инженерлык академиясенә укырга кердем. Аны 1959 елда бик яхшы билгеләренә генә бетердем. Төрле хәрби җитәкче вазифаларын башкардым. 1969 елда инженер-майор дәрәҗәсендә демобилизацияләндем.

Хәзер Псковта яшим. Тормышым бик гади, дөресрәге, ярлы. Без 4 җан — үзем, кызым, оныгым һәм оныгымның улы минем II нче группа сугыш инвалиды пенсиясенә карап торабыз.

Илгә Җиңү язы китергән 1945 елның апрель кичендә иң беренче булып «Җиңү Алиһәсе» скульптурасының атына атланган Рейхстаг герое турында хикәямнең азагы шулай күңелсез тәмамлана. Тормышыбыз шундый булгач, нишлисең бит.

Минем урында берәр француз булса, гади генә итеп «Се ля ви» дияр иде.

## ТАРИХЧЫ ФИКЕРЕ

М.Егоров һәм М.Кантария үзләренең «Җиңү Байрагы» дигән китабында («Молодая гвардия» нәшрияты, 1975 ел) Рейхстаг түбәсенә иң беренче аяк баскан һәм байрак элгән сугышчылар — капитан В.Ма-

ков җитәкчелегендә өлкән сержантлар Г.Заһитов, М.Минин, А.Бобров, А.Лисименко булды, дип язалар.

В.Маков группасының батырлыгы турында башка китапларда да язылган: «Икенче бөтендөнья сугышы тарихы 1939 — 1945», 10 том (Воениздат, 1979 ел), «Соңгы һөҗүм» (Воениздат, 1970 ел һәм 1975 ел), «Совет Коралллы Көчләренең Икенче бөтендөнья сугышында азатлык миссиясе» (Политиздат, 1974 ел) һәм башкалар. Дөреслек әкренләп моңарчы объектив караштa булмаган язучыларның китапларына да керә башлады.

Шулай итеп, Рейхстаг түбәсенә 79 нчы укчы корпусның Кызыл Байрагын капитан В.Н.Маков группасы кадады. Бу группа 756 нчы полкның капитан С.А.Неустроев җитәкчелегендәге беренче батальоны сугышчылары белән бергә сугыштылар. Байракны кадау вакыты якынча 22 сәгать 30 минут — 22 сәгать 45 минут.

Соңрак, Беренче май төнендә сәгать 2 белән 3 арасында 756 нчы полк командиры Ф.М.Зинченко булышлыгы белән 3 нче Удар Армиянең Хәрби Советы Байрагын (Байрак №5) да Рейхстаг түбәсенә урнаштыралар. Бу байракны М.А.Егоров һәм М.В.Кантария элә. Аларга политбүлек буенча батальон командиры урынбасары лейтенант А.Берест җитәкчелек итә, И.Съянов ротасы автоматчылары да булыша.

Беренче май иртәсендә Рейхстагта нәкъ шушы байрак җилферди һәм ул Җиңү Байрагы булып кала да. Рейхстаг гөмбәзенә аны соңрак — 2 нче майда, төштән соң урнаштыралар.

*В.Сеоев*, тарих фәннәре кандидаты,
СССР Оборона министрлыгының сугыш
тарихы Институты бүлек начальнигы. 1990 ел., 5 май.

## ХӘРБИ ЭНЦИКЛОПЕДИЯ, 3 ТОМ, 1995 ЕЛ, 292 БИТ

*(Күчермә)*

### Җиңү Байрагы

Берлин Рейхстагы түбәсенә 1945 елның Беренче май төнендә эленгән Кызыл Байрак — совет халкының 1941 — 1945 елларда Бөек Ватан сугышында җиңү символы ул. Рейхстагка һөҗүм башлар алдыннан, 3 нче удар Армиянең хәрби Советы үз дивизияләренә тугыз Кызыл Байрак тапшыра. Алар СССР Дәүләт флагы үрнәгендә эшләнгән була. Байракның берсен, № 5 дип йөртелгәнен 150 нче укчы дивизиягә дә бирәләр. Барлык часть һәм подразделениеләрдә үзлектән ясалган байрак һәм флаглар була. Кагыйдә буларак, аларын Рейхстагка керергә һәм Җиңү Байрагын кадарга дигән приказ белән сугышкан барлык һөҗүм группаларына бирәләр. Беренче булып, 30.04.1945 елда 22 сәгать 30 минутта (Мәскәү вакыты белән) Рейхстаг түбәсенә («Җиңү Алиһәсе» сыннары өстенә) 136 нчы пушка артиллериясе бригадасы артиллерист-разведчиклары, өлкән сержантлар Г.К.Заһитов, А.П.Бобров, А.Ф.Лисименко һәм

79 нчы укчы корпусы сержанты М.П.Минин Җиңү Байрагын кададылар. Аларның җитәкчесе — капитан В.Н.Маков. Бу группа батальон капитаны С.А.Неустроев белән бергә һөҗүм итте.

2 — 3 сәгатьтән Рейхстаг түбәсендә (Рыцарь кайзер Вильгельм скульптурасында) 756 нчы укчы полкның 150 нче укчы дивизиясе командиры полковник Ф.М.Зинченко приказы белән разведчиклар: сержант М.А.Егоров һәм кече сержант М.В.Кантария да Кызыл байрак (Байрак № 5) урнаштыралар. Лейтенант А.П.Берест һәм өлкән сержант И.Я.Съянов ротасы автоматчылары аларга ярдәм итә.

2 нче майда бу байрак Җиңү Байрагы итеп Рейхстаг гөмбәзенә күчерелә.

Һөҗүм барышында һәм тулысынча союз гаскәрләренә биргәнче, Рейхстагның төрле урыннарында унлап байрак һәм флаг эленгән була. Алар арасында Беренче майда гвардия өлкән лейтенанты К.В.Новоселов самолеттан ыргыткан кызыл әләм дә бар.

9 Майда Рейхстагтан Җиңү Байрагын алып, аның урынына башкасын эләләр. 20 нче июньдә Җиңү Байрагын ЛИ-2 самолетында Мәскәүгә алып кайталар, аны зур тантана белән каршылыйлар.

Җиңү Байрагын Мәскәүгә җибәрер алдыннан, аңа болай язалар: «150 стр. ордена Кутузова II ст. Идрицкая див.79 с.к.3 УА ТБФ».

1945 елның 24 июнендә булган Җиңү Парадына бу Байракны алып чыкмыйлар (дубликаттан файдаланалар), Генераль репетициядән соң ул Белорус Фронтының 1 нче җыелма батальонында саклана, соңыннан СССР Хәрби Көчләренең Хәрби Музеена куялар. Анда ул иң изге ядкарь булып саклана.

Рейхстаг һөҗүме вакытында Кызыл Байрак кую бурычын үтәгән солдат һәм офицерлар, шул исәптән Берест, Бобров, Егоров, Заһитов, Кантария, Лисименко, Маков һәм Минин Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнделәр.

Җиңүнең бер еллыгы уңаеннан Егоровка, Кантарияга, алдынгы батальон командирлары капитаннар Неустроев һәм Давыдовка, өлкән лейтенант Самсоновка шулай ук өлкән сержант Съяновка Советлар Союзы Герое исеме бирелде.

РЕДАКЦИЯ:

Председатель:
армия генералы РФ Оборона Министры *П.С.Грачев*

Председатель урынбасары
генерал полковник
генерал штаб начальнигы *М.П.Колесников*

Россия Фәннәр Академиясе
член-корреспонденты,
профессор, генерал-полковник *Д.А.Волкогонов*

барысы 33 генерал

## БАТЫР ТУГАН ҖИРДӘ

Сугыштан соңгы елларда, алтмышынчы еллар башына кадәр, Рейхстагка байрак элгән геройларның фамилияләрен беркем дә белми иде. Аерым алганда, кыю татар сугышчысы Г.Заһитовның фамилиясе Татарстанда беренче тапкыр 1962 елда күренгәләп китте. Мин үзем, мәсәлән, кем соң ул Заһитов, дип озак уйландым, озак фаразладым. Кай якта туган? Сиксәненче еллар азагында гына ачыклый алдым: баксаң, ул минем якташым диярлек икән! Мин Актаныш районында, Агыйделнең сул ягында тусам, Гази Заһитов елганың уң ягында туган.

1997 елның ноябрь азагында Уфада Башкортстанның беренче Президенты Мортаза Гобәйдулла улы Рәхимов белән кунакчыл очрашу вакытында аңа сугыш героеның туган авылында буласы килүемне әйттем, Президент миңа бик теләп ярдәм итәргә булды. Икенче көнне үк Мишкә районы хакимияте башлыгы А.А.Аптулманова мине үз машинасында Янагуш дигән татар авылына илттереп тә куйдыртты.

Көн салкын булуга карамастан, Казаннан һәм Уфадан киләсе кунакларны көтеп, авыл үзәгенә күп халык җыелган. Авыл музеенда аның җитәкчесе, пенсиядәге укытучы Галимҗан Вилдан улы Бикбулатов безгә авылның тарихы, атаклы кешеләре, якташларының бүгенге тормышы турында сөйләде.

## АВЫЛ МУЗЕЕНДА

— Безнең Янагуш авылына (татарча Яңа Кош) 1688 елда Казан губернасыннан күчеп утыручылар нигез салган. Ыру башлыгы Акбирде Бикбулатов булган, 1988 елда без авылыбызның 300 еллыгын билгеләп үттек, — дип сөйләп китте Галимҗан абзый. — Көчләп чукындырудан качып, башкорт җиренә Идел буеннан, Казан ханлыгы җирләреннән бик күп татар-мөселманнар килеп урнашкан. Башта авылда 25 хуҗалык була, ир-атлардан 75 кеше исәпләнә. 1939 елда инде авылда 610 хуҗалык исәпләнә һәм анда 2100 кеше яши.

Утызынчы еллар башында коллективлашу үткәрелә. Мин шушы авылда 1928 елда туганмын. Гаиләбездә 12 бала иде. Мин сигезенче. Үзем авылыбызның ыру башлыгы Акбирде Бикбулатов токымыннан. Безнең авыл бик зур, анда электән үк, нигездә, өч нәсел вәкилләре — өч фамилияне йөртүче кешеләр яшәп килгән. Болар — Бикбулатовлар, Җәмилевләр, Заһитовлар. Шуңа бәйле рәвештә, кешеләрне бер-берсе белән бутамас өчен, барысының да кушаматлары булган. Безнең Бикбулатовлар арасында 5—6 кушамат бар. Мәсәлән, Аю, Баштатар, Вилданнар һ.б.

**— Сезнең токымның кушаматы нинди?**

Галимҗан абзый елмая:

— Ярар инде, монысын белмәсәгез дә ярар.

**— Нәрсә, әллә серме бу?**

— Нинди сер булсын, бөтен авыл белә.

Икебез дә көләбез, һәм кинәт Галимҗан абзый, як-ягына каранып ала да әйтеп куя:

— Безнең кушамат — Җәбрәй Вилданнар. Еврей, янәсе!

**— Ай-яй,— дип көләм мин.— Сезгә бик-бик югары статуслы кушамат такканнар...**

— Нишлисең бит,— дип көлүен дәвам итә әңгәмәдәшем.— Авылда кушаматны сайлап алмыйлар. Бу «мактаулы исемнәр»не халык үзе бирә.

**— Ә Заһитовларның кушаматы нинди иде?** — дип сорыйм мин, кызыксынып.

— Заһитовлар кланында һәр тармакның үз кушаматы. Газетдинның әтисе Казыйхан бабайның кушаматы «чолы» иде. Ул «с» хәрефен әйтә алмаганлыктан, «солы» сүзен «чолы» дип әйтә иде. Гази дә армиягә Заһитов булып кына түгел, ә «Чолы-Заһитов» булып китте.

**— Сезнең авыл фронтка күпме кешене озатты?**

— Кулына корал, винтовка тота белгән 448 сәламәт ир-ат сугышка китте. Ә әйләнеп кайтучылары 204 кенә булды. Алары да, нигездә, гариплəр иде. Авылның 300 еллыгын билгеләп үткәндә сугышта һәлак булган 224 авылдашыбызга һәйкәл куйдык. Һәркайсының исем-фамилиясе язылган.

**— Музей бинасы турында да әйтсәгез иде...**

— Әлеге йорт элек бер авылдашыбызныкы булган. Утызынчы елларда, коллективлашу башлангач, ул кеше властьларны тәнкыйтьләп чыккан. Шуннан соң аны Себергә сөрәләр. Ул соңыннан Урта Азиядә яшәде һәм шунда үлде.

Аның йортында элек авыл советы, медпункт урнашкан иде. Соңгы елларда, ремонтлап, музей ачтылар...

Чынлап та, музей бик әйбәт килеп чыккан. Бер бүлмәдә — авыл көнкүреше экспонатлары, икенчесендә — авылның атаклы кешеләре турында сөйли торган стендлар. Менә Бөек Ватан сугышында катнашкан авылдашыбыз, Советлар Союзы Герое Мәхмүт Сафа улы Айтугановка багышланган стенд. Сугыштан соң ул Ленинградта яшәде һәм шунда үлеп калды. Исән чагында авылга еш кайта торган иде.

Икенче бер стенд Социалистик Хезмәт Герое, шулай ук сугышта катнашкан авылдашыбыз, Уфа заводы токаре Хәернас Ильяс улы Чекаевка багышланган.

Бүлмәнең бер стенасы тоташтан авылдашыбыз Газетдин Казыйхан улы Заһитовның тормышына һәм сугыштагы батырлыкларына багышланган материаллар белән бизәлгән.

Шуннан соң авыл мәктәбенә кердек. Укытучылар белән бергәләп сугыш каһарманы Г.К.Заһитов стенды янында фоторәсемгә төштек. Баксаң, бу урта мәктәп директорының да фамилиясе Заһитов икән —Айрат Нәгыйм улы Заһитов. Колхоз рәисе дә Заһитов — Раик Тимерхан улы.

Без авыл читендәге зиратта. Сугыш героеның кабере зиратның нәкъ уртасында икән. Ак мәрмәр ташка: «Биредә Заһитов Газетдин Казыйхан улы күмелгән. 1921 — 1953. Берлинны штурмлауда катнашучы, Рейхстагка Кызыл Байрак кадап куючыларның берсе. Каһарманга мәңгелек истәлек»,— дигән сүзләр язылган.

## ГЕРОЙ КАБЕРЕ ЯНЫНДА

Сугыш батыры Газетдин Заһитовның бәхете булган икән әле, дип әйтүемә ачуланма, укучым! Сугыш утын үтеп, гәрчә мораль һәм физик яктан жаны-тәне теткәләнеп бетсә дә, ата-бабалары җиренә кайтып ауган ул. Хөрмәтләп күмелгән. Ә күпме исемсез ватандашларыбыз бүген дә әле сугыштан соң 50 — 55 ел үткәч тә, Көнбатыш төбәкләрдә күмелмәгән-җирләнмәгән килеш калды. Исемсез югалганнар исәбендә алар. Арада минем авылдашларым да — Актаныш районының Түбән Карач, Югары Карач, Урьяды, Татар Суыксуы авылларыннан киткән якын кардәшләрем дә бар.

Авыл музеен саклап-карап торучы, тарих укытучысы, хәзер инде пенсионер Галимҗан Вилдан улы Бикбулатов белән интервью Газетдин Заһитов кабере янында дәвам итә.

— Гази Заһитов күп үлемнәргә китергән ачлык елында — 1921 елда безнең авылда ярлы крестьян гаиләсендә туган. Бу елны авыл халкының яртысы ачтан үлде. Гази гаиләдә алтынчы бала булды. Ул ачлык вакытында да исән калды, сугыштан да исән-имин әйләнеп кайтты.

Аның әтисе Казыйхан абый Гази фронтта чакта, 1943 елда үлде. Әнисе, җиде бала анасы Хөсниямал апа улы Газетдинның фаҗигале төстә һәлак булуыннан соң да шактый яшәде әле.

Сугышка кадәр Гази үзенең туган авылында 4 классны, аннары күрше Урьяды авылында җиденче классны тәмамлый.

1938 елда Янагуштагы ике яшьтәше Гыйльмулла Бикбулатов һәм Мөфтихан Җәмилов белән бергә Гази Заһитов Бөре медицина техникумына укырга керә.

1940 елда Газетдинны Кызыл Армиягә хәрби хезмәткә алалар. Ул Балтыйк буенда, Таллин шәһәрендә хезмәт итә башлый һәм шулчак офицерлар курсын тәмамлый. Сугыш башланганда Эстониядә була. Майор Николай Дмитриевич Иванов командалыгындагы 832 нче разведка артиллерия дивизионында көрәшә.

1945 елның җәендә Гази авылга ялга кайта. Бер ай чамасы әнисе янында яши. Әтисе кабере янында була. Әмма ул үзенең җитди яра-

лануы хакында да, Рейхстаг герое булуы турында да бер сүз дә сөйләми. Шулкадәр дә тыйнак кеше була ул.

1946 елның 1 июлендә Газетдин демобилизацияләнеп өенә кайта. Башта гади колхозчы булып эшли. Аннары аны авыл советы рәисе итеп сайлыйлар. Шул ук елны күрше авыл кызы Камиләгә өйләнә. Бөтен авыл белән туй ясыйлар.

Шул елны, бездән ерак та түгел, Камай МТСы оештырыла һәм Газины анда механик итеп күчерәләр.

1953 елның августында Гази Уфага авыл хуҗалыгы техникасы өчен запас частьлар алырга китә һәм юлда автомобиль һәлакәтенә эләгә.

**— Хәзер авылда аның туганнарыннан берәр кеше яшиме?**

— Туган авылы Янагушта бертуган апасы Хөсникамал яши. Күптән түгел аңа 80 яшь тулды. Газетдинның кызы Наҗия күрше авылда, җиде баласы (бөтенесе дә кызлар) бар. Хөсникамал әбинең оныкларын санап та бетерерлек түгел. Газиның улы Миңнегаян Уфада яши. Ике улы бар. Күргәнебезчә, Гази Заһитовлар ыруы дәвам итә.

**— Галимҗан абый, Сез Газетдин Заһитов белән еш очраштыгызмы?**

— Ул фронттан кайтканда миңа 18 яшь иде инде. Мин дә егет, ул да ялгыз иде әле. Егет чакларыбыз бергә үтте. Бик тыйнак кеше иде. Фронттагы хәлләр турында сөйләргә яратмады. Бераз эчкәләп утырганда: «Еллар үтәр, безнең ничек сугышканнар турында да сөйләми калмаслар әле», — дип авыр сулап куя торган иде.

Ул чагында без аның Рейхстаг герое булуын, кан коюлы сугышка соңгы ноктаны куючы икәнлеген күз алдына да китерә алмадык, әлбәттә. Безгә, Рейхстагка Җиңү Байрагын беренче булып сержантлардан М.Егоров һәм М.Кантария кадады, дигән фикерне сеңдерделәр бит. Бары тик 1960 елда гына, авылдашыбыз Гази Заһитовның фаҗигале үлеменнән соң ничә еллар үткәч кенә, матбугат аша чын дөреслекне белә алдык.

— Менә шундый-шундый хәлләр,— дип тәмамлады үзенең сүзен авыл ветераны Галимҗан Бикбулатов.

Без, бер төркем кеше, сөйләшмичә генә зират капкасына таба юнәлдек һәм автомобильләргә утырыштык. Төрле маркадагы автомобильләр төркеме безнең «Волга»ны күрше колхоз җирләре чигенә кадәр озата барды.

«Туган җирең мамыктай йомшак булсын сиңа, сугыш каһарманы Газетдин Казыйхан улы Заһитов!» — диештек без барыбыз да.

## АЛТЫН ҖИТМӘГӘН

*(32 елдан соң интервью. Ижевск шәһәре, 25 февраль, 1998 ел.)*

Журналист һәм публицистларның язылмаган бер кагыйдәсе бар. Хикәяләүне нидән башласаң, шуның белән тәгәлләргә кирәк. Бу кагыйдәгә буйсынырга менә нәрсә этәрде мине: сугыш чорының төрле

документларында Удмуртия Республикасының Сарапул районында туып үскән һәм Рейхстаг штурмын оештыручыларның берсе Печерских Николай Петрович исемен еш очраттым. Ул да Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителгән була. Әмма, бу як халкы сөйләме белән әйтсәк, «фига» тотып кала.

Менә ул — Непряха авылы. Каманың уң як ярында, табигатьнең оҗмахка тиң почмагына сыенып утыра. 1966 елның апреленнән — минем Н.П.Печерских белән соңгы очрашудан соң авыл күзгә күренеп үзгәргән, матурланган. Яхшы йорт, каралты-куралар саны арткан. Бу авылны шәһәр кешеләре үз иткән, күпләп дачалар төзиләр.

Авыл картларыннан Н.П.Печерских турында сорашам:

«Күптәннән монда яшәмиләр. Исәннәр әле, исәннәр. Сәламәтлекләре дә яхшы. Ижевскида, улларында яшиләр», — дип җавап бирәләр миңа күпне белүче карчыклар. Икенче көнне Удмуртия башкаласы Ижевскида Камбарская урамын таптым. Шәһәр кырындагы йортларның берсендә өч бүлмәле фатирда Николай Петрович Печерских хатыны Елена Агафонгеловна, улы, килене һәм оныгы белән бергә яшиләр.

Николай Петрович көрәктәй зур сакаллы, нык карт. 80 яшен тутырган. Сөйләшкәндә күзгә туп-туры карап, ышанычлы итеп сөйли. Сәламәтлеге дә зарлана торган түгел.

— Сез мине хәтерлисезме, Николай Петрович? — дип сорыйм мин. — 1966 елда Сезнең Рейхстагны алуда катнашуыгыз турында язган идем.

— Син Василий Субботин бит әле? — дип соравыма каршы сорау белән җавап бирде карт.— Хәтерлим, ничек хәтерләмимим ди, син бит миннән Рейхстаг янында интервью алган идең.

Елена Агафонгеловна мине бер читкә алып китте һәм пышылдап кына:

— Аңа артык игътибар итмәгез. Бер ел инде шулай бутала. Хәтеренә әллә ни булды. Ә болай үзе исән-сау, Аллага шөкер.

Николай Петрович үзенең дә кулларын минем иңсәгә куя һәм сөйләвен дәвам итә:

— Менә син, Субботин, мине Советлар Союзы Героена тәкъдим иттеләр, дип яздың инде. Рейхстаг өчен. Рәхмәт сиңа, зурладың. Әле менә Мәскәүдән хат алдым. Герой медален кою өчен илдә алтын калмаган, дип язганнар. Беткән бит... Сабыр итәргә кушканнар. Алтын табу белән медаль ясап Ижевскига җибәрәчәкләр. Мин көтәрмен лә ул... Ашыгасы җирем юк бит. Хәзер илебезгә бик авыр...

Елена Агафонгеловна белән баш кагып утырабыз. Күз алдымда шагыйрь, элекке фронт газетасы корреспонденты Василий Субботинның роман-газетада чыккан «Сугышлар шулай бетә» дигән мәкаләсе.

«Фронт блокнотларымны актарып, дәһшәтле сугыш елларын хәтердә яңартам. Менә рота командиры өлкән лейтенант Печерских Николай Петрович белән әңгәмәнең язмасы. Печерских — Уралдан, Сарапул-

дан. Рейхстагны алган өчен командование аны Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим итте».

Менә кем белән бутый икән бит мине Рейхстагның бу билгесез герое. Юкса сугыш герое һәм фронт корреспонденты җиңелгән Рейхстаг янында очрашканда, миңа Актанышның ерак бер авылында яшәүче малайга нибары 8 яшь булган. Шунысын да әйтергә кирәк, шагыйрь Василий Субботин үзе дә күптән мәрхүм инде.

Картның чын күңелдән әйткән: «Мин күтәрмен әле. Илебезгә бик авыр бит», дигән сүзләре мине тетрәндерде. Ул моны банкротлыкка төшкән бөек державаны чын күңеленнән кызганып әйтте.

— Пенсия күп аласызмы соң? — дип сорыйм күптәнге танышымнан.

— О-о-о, бик күп алам! — ди карт шат елмаеп,— андый пенсия минем төшемә дә кергәне юк иде.

— Чынлап, хәзер пенсиясе күп аның, — дип иренең сүзен раслады Елена Агафонгеловна. Сигезенче ай икенче группа сугыш инвалиды пенсиясен ала. Егерме ел колхозчы пенсиясенә яшәде. Фронтовиклардан берсе военкоматка хат язып җибәр, дип акыл биргән.

Уйлап куйдым: «Юк! Бу илне, бөек державаны җиңүчеләр булмаячак. Беркайчан да, Ватан азатлыгы хакына барган сугышның тәмамлануына ярты гасырдан артык гомер үткән, безнең «халык мәнфәгатьләрен кайгыртучы» җитәкчеләр, аларның куштаннары, хакимият һәм сәяси эшлеклеләр меңнәрчә тонна алтынны урлап, яшереп куйганнар. Рейхстагның чын геройларына биш-ун медаль генә коярлык алтын да калмаган. Ә геройларның исәннәре һаман «Мин күтәрмен әле. Бүген илгә авыр», — диләр. Мондый шаккаткыч илне җиңеп буламы соң?!

Әлбәттә, Газетдин Казыйхан улы Заһитов, Михаил Петрович Минин, Николай Петрович Печерских кебек геройлар булганда һәм аларның нәселе яшәгәндә.

## ПРИЛОЖЕНИЕ

Красное Знамя, водруженное советскими воинами в ночь на 01.05.1945 года над зданием поверженного Рейхстага в Берлине является символом Победы Советского народа в Великой Отечественной войне 1941—1945 гг. Перед штурмом Рейхстага Военный совет 3-й ударной армии вручил своим дивизиям девять красных знамен, специально изготовленных по типу Государственного флага СССР. Одно из них (известное под № 5) было передано 150 стрелковой дивизии. Подобные самодельные знамена, флаги и флажки имелись во свех других передовых соединениях, частях и подразделениях. Как правило, они вручались штурмовым группам, которые шли в бой с главной задачей — прорваться в Рейхстаг и установить на нем Знамя Победы. Первыми в 22 часа 30 мин. (время московское) 30.04. 1945 года водрузили Знамя на крыше Рейхстага (на скульптурной группе «Богиня Победы») артиллери-

сты-разведчики 136-й армейской пушечной артиллерийской бригады ст.сержанты Г.К.Загитов, А.П.Бобров, А.Ф.Лисименко и сержант М.П.Минин из состава штурмовой группы 79 стрелкового корпуса, возглавляемой капитаном В.Н.Маковым. Группа действовала совместно с батальоном капитана С.А.Неустроева. Через 2 — 3 часа на крыше Рейхстага (на скульптуре конного рыцаря кайзера Вельгельма) по приказанию командира 756 стрелкового полка 150 стрелковой дивизии полковника Ф.М.Зинченко также установили Красное Знамя (№ 5) разведчики сержант М.А.Егоров и младший сержант М.В.Кантария, которых сопровождал лейтенант А.П.Берест и автоматчики из роты ст.сержанта И.Я.Съянова. 2 мая это знамя перенесено на купол Рейхстага в качестве Знамени Победы.

Всего в период штурма и вплоть до передачи Рейхстага союзным войскам на нем в разных местах установлено до 10 знамен, флагов и флажков. Среди них и алое полотнище, сброшенное 1 Мая с самолета гв.ст.лейтенантом К.В.Новоселовым. 9 мая Знамя Победы снято с Рейхстага его место занял другой алый стяг. 20 июня Знамя Победы на самолете Ли-2 доставлено в Москву, где встречено с особыми воинскими почестями. Перед отправкой на Знамени Победы сделана надпись «150-я стр.ордена Кутузова II ст. Идрицкая див.79 с.к. 3 УА I БФ». На Парад Победы 24.06.1945 года Знамя Победы не выносилось (использовался дубликат). После генеральной репетиции оно находилось в сводном батальоне 1 Белорусского фронта, затем отправлено в Центральный Музей ВС. СССР, где хранится как священная реликвия.

За выполнение задания по водружению Красных Знамен на Рейхстага во время его штурма большая группа солдат и офицеров, в т.ч. Берест, Бобров, Егоров, Загитов, Кантария, Лисименко, Маков и Минин награждены орденами Красного Знамени. К 1-й годовщине Дня Победы Егоров, Кантария, командиры передовых батальонов капитаны Неустроев, Давыдов и ст.лейтенант Самсонов, а также ст.сержант Съянов удостоены звания Героя Советского Союза.

РЕДАКЦИЯ:

Председатель:
генерал армии,
Министр обороны РФ *П.С.Грачев*

Зам.председателя
генерал-полковник,
начальник Генерального штаба *М.П.Колесников*

Член-корреспондент РАН,
профессор, генерал-полковник *Д.А.Волкогонов*

(Всего 33 генерала)

## Ике язмышның тантанасы һәм фаҗигасе

### РОССИЯ ПАТРИОТЫ — КЕМ УЛ?

Безнең тарих турында архив материалларын укып чыккач, күңелне авыр хисләр биләп ала. Йөрәккә авыр таш булып яткан хәтер йөген кайсы якка күчерергә икән — уңгамы, әллә сулгамы? Бу тормышта кемне герой, кемне антигерой дип санарга? 1954 елда бер имза белән Кырым һәм Севастопольне Украинага бүләк иткән ярымрус, ярымхохол Никита Хрущевнымы? Әллә шушы ярымутрауны аякка бастырган, безгә Россия императрицасы Екатерина Икенче буларак яхшы таныш немец принцессасы, Софья Фредерика Августанымы?

Россия патриоты кем ул? Бәлки Ирекледәр армиясе командующие, патша генералы Лавр Георгиевич Корниловтыр? Ул гражданнар сугышының хәлиткеч көннәрендә Россия язмышын үз кулларына ала һәм Ватаны өчен җәзалап үтерелә. Бәлки Россия патриоты итеп латыш Вольдемарас Азинны санаргадыр? Ул да үз гомерен яңа тормыш өчен корбан итә. Аны да җәзалап үтерәләр.

Мондый сорауларга безнең Россиядә җавап табу бик авыр. Бигрәк тә социализм төзү идеяләре белән яшәгән һәм кызыл командирлар — Чапаев, Щорс, Кочубей, Азин үрнәгендә тәрбияләнгән безнең буынга.

Удмуртия Республикасында Владимир Азиннан да абруйлырак булган икенче кешене табу мөмкин түгел. Урамнар, колхозлар, поселоклар, мәктәп һәм балалар бакчалары аның исемен йөртә. Азин белән бары тик В.И.Ленин гына тиңләшә ала.

Ижевск шәһәрендә Азин урамы бар, Удмуртиянең бер поселогы, тимер юл станциясе һәм хәтта хезмәт-төзәтү колониясе дә Азин исеме белән атала.

Кама буендагы Сарапул шәһәренең Азин урамында минем үсмерлек чорым үтте. Монда, Гагарин һәм Азин урамнары кисешкән җирдә, сквер бар иде. Анда дивизия начальнигының бронза бюсты куелган иде. Хәзер бу сквер урынына банк төзеделәр, бюстны да каядыр алып киттеләр.

Күптән түгел Әгерҗедә булдым. Анда да Азин урамы бар. Алай гына да түгел, Әгерҗенең бер мәйданында зур бюст куелган. Мин башта аны Габдулла Тукай бюсты дип уйладым. Шундый ук баш, шул ук кыяфәт. Якынрак килеп укысам — Азин икән. Гаҗәп охшашлык.

Татарстанда да Азин һәйкәлләре, аның исемендәге урамнар, мәктәп һәм колхозлар җитәрлек. Казандагы иң зур торак районнарның берсе Азино дип атала. Һәм бу микрорайонның урам исемнәре дә бик аңлаешлы: беренче Азин урамы, Икенче, Өченче, соңыннан Аркылы Азин урамы.

Юк, минем бар нәрсәгә дә Гражданнар сугышы геройларының исемен бирергә яраткан өлкән буынга шелтә бирәсем килми. Безгә бит һәрвакыт Азин татар, удмурт һәм башка халыкларның бәхете өчен

һәлак булган дип аңлатып килделәр. Без аның милли герой икәнлегенә шикләнмәдек тә. Ул хәзер генә теге яки бу тарихи шәхесне чагыштырып, мәсәлән, шул ук генерал Корнилов һәм Азинны, әгәр тегеләй булса, әгәр болай булса, дип уйлый башлыйсың. Соңгы еллардагы тормыш мәхшәренә кемнең кем булуы да онытыла башлады. Ә яшьләр безнең үткәнебезне бөтенләй белмиләр. Казанда, Дербышкида (аны Дәрвишләр бистәсе дип тә әйтәләр) мин шулай ук Азин урамнары исеменең тарихы белән кызыксындым. Сораган кешеләремнең тугызынчы-унынчысы гына дөрес җавапны әйтә алды. Күпләр Азинны Ватан сугышы герое дип белә, кайберләре Дербышкины аның туган җире дип саный. Берәү хәтта күз дә йоммыйча аны КПССның Татарстан Өлкә комитеты секретаре дип тә әйтте. Тарихны өйрәнгәндә үзебезне дә өйрәнәбез, диләр. Әйдәгез әле, без дә узган елларга кечкенә генә сәяхәт ясап алыйк.

## ДАВЫЛЛАР ЧОРЫ

1895 елның 26 сентябрендә Витебск губернасының Полоцк өязе Аринов волосте Марьяново авылында күчмә тормыш алып барган латыш тегүчесе Мартин Андреевич Азиньш гаиләсендә бер малай туа. Аңа Вольдемарас дип исем кушалар. Русчалатып, Владимир дип йөртәләр. Малай башта күрше хутор мәктәбендә укый. Соңыннан Полоцкида бухгалтер булып эшли. 1916 ел азагында егетне патша армиясенә алалар. Яңа, 1917 елны Азин Сычевка шәһәрендә инженер-төзелеш батальонында каршылый.

Илдә яңа тормыш башлана. Большевиклар партиясе подпольедан чыгып, дөньяны, җирне, илне яулап алу үрнәген, юлын күрсәтә. Төрле партияләрнең программалары белән танышып чыккач, Владимир Азин ленинчылар рәтенә керү турында катгый карар кабул итә.

Яңа властьларның башбаштаклыгына түзә алмаган Вятка губернасының хәлле крестьяннары июньдә баш күтәрәләр. Бу вакыйга тарихка «Вятка кулаклары фетнәсе» булып керә. Аны туктату өчен 150 латыш коммунистыннан торган махсус батальон оештырыла. Шул батальон составында кызылармияче Азин да 1917 елның октябрендә Двинск буенда көрәшә. 1918 нче елның язында латыш батальоны белән бергә ул Петроградтан кулак фетнәсен бастырырга кузгала.

Большевиклар власте хәлиткеч көннәр кичерә. Халыкның күпчелеге илдәге вакыйгаларны аңламый, яңа тәртипләргә каршы күтәрелә. Атланта илләре дә Россия чикләренә якынлаша. Советлар белән көрәштә интервентлар Чехословакия корпусын куллаалар. Аларга элеккеге патша армиясеннән иреклеләр һәм казакларның җитәкчеләре килеп кушыла. Ак чехлар белән бергә Себер, Урал, Идел буенда большевикларга каршы баш күтәрәләр.

1918 елның 7 августында ак чехлар Казанны яулап алалар. Бу Ижевск заводларында корал җитештерүчеләргә, металл чыгаручыларга сигнал була. Яңа власть бөтен Кама буенда каршылык күрсәтә. Көнчыгыш

фронты тиз арада иң кайнар ноктага әйләнә. Большевиклар хөкүмәте монда төп көчләрне җибәрә. 12 августта Азин җитәкчелегендәге латыш батальоны Вятские Поляныга килә. Аннан алар Казанга һөҗүм итәргә җыенучы 2 нче армиягә кушылу өчен Арчага юнәләләр.

Казанны азат иткәннән соң, 2 нче дивизиягә кушылып, «тимер дивизия» исемен алган Азин сугышчылары Ижевск һәм Воткинскига юнәләләр.

3 октябрьдә Әгерҗене, тагын бер көннән Сарапулны алалар. Ижевск һәм Воткинск шәһәрендәге корал заводлары эшчеләренең восстаниесен җиңү бурычы куела. Ленин, Троцкий һәм Свердлов баш күтәрүчеләргә карата иң каты чараларны, хәтта массакүләм атып үтерүне кулланырга чакыралар.

1918 елның 6 ноябрендә Ижевскины штурмлый башлыйлар. 7 ноябрь кичендә шәһәрне алалар һәм бу хакта Ленинга җиңү турында телеграмма җибәрәләр.

Шуннан соң Азинның «тимер дивизиясен» көньяк фронтка күчерәләр. Алар акларга каршы фидакарьләрчә сугышалар, җирле халыкның каршылыгын да уңышлы җиңәләр. Царицынны азат иткәч, дала буйлап Сальск ягына китәләр. Егорлыкка барып җиткәч, «тимер дивизиянең» триумфаль хәрәкәте тәмамлана. Кар күмеп киткән канау янындагы канкойгыч бәрелештә дивизия начальнигының аты абына, хуҗасы егылып төшә. Моңа кадәрге сугышларда Азинның җиде аты үлә, сигезенчесе исә хуҗасын үтерә.

Азинны аклар тотып ала да, Тихорецк станицасындагы штабка алып киләләр. Мәсхәрәләү һәм җәзалаулардан соң, анадан тума чишендерәләр, кулын телефон чыбыгы белән бәйләп, атның ияренә тагалар да, станция һәм ялан кыр буйлап сызгыра-сызгыра атны куалар. Соңыннан күкрәгенә «Кызыл ерткыч Азин» дигән язу эләләр һәм Тихорецкидан Фастовецкий станицасы ягына Сапатый курганындагы үләт базына алып китәләр. Бу базда төрле начар чирләрдән үлгән атларны күмә торган булалар.

Азинны коточкыч үлемгә дучар итәләр. Аны, борынгы җәза алымын кулланып, дүрткә ботарлыйлар һәм базга ыргыталар. Кызыллар бу станицаларны алгач, Азинны зиратка илтеп күмәләр. Кабер ташына штыклар белән «В.М.А.» дип язалар.

Бу кабер бөтенләй онытыла. Аны дала тузаны күмеп китә, күгән куаклары баса. 1930 еллар ахырыннан башлап, монда адәм заты аяк басмый. Шулай итеп, Гражданнар сугышында танылган кызыл командирның соңгы эзе дә югала. Бары тик Октябрь революциясенең 50 еллыгы алдыннан гына Фастовецкий исемле зур авылның 3 нче урта мәктәбе укучылары ташына өч хәреф язылган каберне эзләп табалар. 1988 елның көзендә кабергә һәйкәл куялар.

Краснодар краеның Тихорецк шәһәрендәге крайны өйрәнү музеенда «тимер дивизия» начальнигына багышланган экспозиция бар. Андагы иң беренче документ — Кавказ фронтының Унынчы Кызыл Армиясенә бирелгән 239 нчы приказы. Ул болай башлана: «В.М.Азин — милләте буенча латыш, натурасы белән казак. Давыллар чоры продукты. Сугыш һәм революция улы».

## ИРЕКЛЕЛӘР АРМИЯСЕ ГЕНЕРАЛЫ

1918 елның язында кызылармияче Владимир Азин Вяткада крестьяннар восстаниесен бастырганда, ак генерал Л.Г.Корнилов Кубаньда Кызыл эскадроннарга каршы сугыша. Ул бөтен дөньяга билгеле «Боз походын» җитәкли.

Мартның беренче яртысында генерал Корнилов җитәкчелегендәге Ирекләләр армиясе Ростов-Дон һәм Кубань далаларында Кызыл Армиягә каршы көрәшә. Аларның максаты Екатеринодарны, хәзерге Краснодарны азат итү була.

Кубаньда бу вакытта яз башлана. Ләкин кайвакыт табигать төрле сюрпризлар да ясап куя. Көннәрнең берсендә суык яңгыр коя башлый. Новодмитриевский станица күперен кызыллар шартлата. Аклар елганы күкрәктән суга батып кичәләр. Төнлә кинәт суытып җибәрә. Юлларны көзгедәй боз каплап ала. Аклар, зур югалтулар белән, Екатеринодарга килеп җитәләр. Иң үкенече — бу аяусыз сугыш нәтиҗәләрен командующий белә алмый кала.

Ирекләләр армиясе штабы 1918 елның 28 мартында Екатеринодардан көнбатышта — дүрт чакрым ераклыкта Кубань экономик җәмгыятендә урнаша. Большевиклар шәһәрне нык саклыйлар. Ирекләләр армиясе штурмына кызыллар көчле артиллерия уты белән җавап бирәләр. 31 март иртәсендә атыш көчәя. Командующий штабы урнашкан йорт түбәсе өстеннән снарядлар бертуктаусыз оча.

Лавр Георгиевич Корнилов бүлмәсендә үзе генә утыра. 7 сәгать 20 минутта тәрәзә янындагы стенаны үтәли тишеп, снаряд килеп керә һәм генералның өстәл астында шартлый. Шартлау көче Корниловны мичкә китереп бәрә. Аның үтәли тишелгән ботыннан кан шаулап ага, чигәсендәге ярадан да кан саркый, генерал соңгы сулышларын ала. Аны өйдән алып чыгалар һәм ул, ун минуттан аңга килә алмыйча, ишегалдында җан бирә.

Корниловның гәүдәсен олауга салып, Елизаветинская станицасына илтәләр. Армия командалыгы мәрхүмне станица чиркәве коймасы артына җирләргә карар кыла. Әмма чигенү турында ашыгыч приказ килә. Бу вакытта аклар һәм кызылларның көче тигез булмый. Екатеринодар штурмында Ирекләләр армиясе һәм Кубань крае сугышчыларының берләштерелгән гаскәрләре 9 мең кеше, ә шәһәрне саклаучылар — 20 мең кеше була.

Ирекләләр отряды чигенгәндә үзләре белән бергә командирларының да гәүдәсен алалар. Генералның вафатыннан соң ике тәүлек үткәч, аны православие йолаларына туры китереп, Екатеринодардан 50 чакрым ераклыктагы немец колониясе Гнадауда җирлиләр. Офицерлардан берәү гыйбадәт кыла. Аннан соң отряд үз юлын дәвам итеп, Донга таба китә.

Озак та үтми немец колониясенә кызыллар бәреп керә. Алар беренче эш итеп, аклар яшереп калдырган байлыкларны эзләргә тотыналар һәм генерал Корниловның мәетенә тап булалар. Мәрхүмне казып алып, яңадан Кубаньның башкаласына алып китәләр. Олау шәһәрнең төп

мәйданына җитеп туктый. Кызыллар сызгыра-сызгыра (Азин белән булган хәлне искә төшерегез) аны шәһәр урамнары буйлап йөртә башлыйлар. Шәһәр халкының бер өлеше гаепсез мәетне болай мәсхәрә итүдән туктарга куша. Әмма аларны берәү дә ишетми. Кемдер мәрхүмнең гәүдәсен шәһәр башлыгының балконына асарга куша. «Балконны бу хәшәрәт белән пычратырга ди монда. Агачка элегез аны, агачка!» —дип кычкыралар аңа җавап итеп.

Ике сәгатьләп шулай «күңел ачканнан» соң, мәетне шәһәр читенә алып чыгып яндырырга дигән приказ килә. Кыргый тамашадан искәргән тәртипсез халык көтүе олау артыннан атлый. Сугу-кыйнаулардан танымаслык хәлгә килгән мәетне һаман мәсхәрә итүдән туктамыйлар — таш, туфрак аталар, битенә төкерәләр.

Ниһаять, шәһәр бойнясында мәетне олаудан алып, саламга күмәләр һәм ут төртеп яндыралар.

Бу вакыйгадан соң берничә көн үтүгә, шәһәр урамнарында бер төркем кеше шамакайланып йөри. Алар Корниловны күмү вакыйгасын күрсәтәләр. Өйләр янына туктап, шамакайлар ишек кагалар һәм генералны искә алу өчен акча сорыйлар.

1918 елның 5 апрелендә Екатеринодардагы «Известия» газетасында мондый мәкалә чыга:

«16 апрель көнне 12 сәгатьтә иптәш Сорокин отряды Екатеринодарга контрреволюция герое генерал Корниловның мәетен китерә. Гәүдәне фоторәсемгә төшергәннән соң, ул шәһәр читенә чыгарылды һәм яндырылды.

1918 елның 6 апрелендә Иреклеләр армиясе вәкилләре Гнадау колониясенә генерал Корниловның гәүдәсен алырга дип киләләр. Тик аның кабере буш була, бары нарат табут кисәкләре генә килеп чыга.

Франция революционеры токымы, Себернең караңгы почмагында туып үскән, рус-япон сугышы герое. 1915—1916 елларда Германия армиясе тоткыны, Николай II нченең яраткан кешесе, кызы һәм улы белән бергә императрицаны кулга алган Вакытлы хөкүмәтнең баш командующие генерал Корниловның тормышы шулай тәгәлләнә».

1991 елда генерал Лавр Корнилов һәлак булган йортка мемориаль такта куялар, аны җирләгән урынга тәре кадаклыйлар.

## КОТЫЛУ ЮЛЫ — БЕРДӘМЛЕКТӘ

Үтеп баручы егерменче гасырда Россия тарихында үз эзләрен калдырган ике язмыш белән таныштык. Килешәсездер, ул елларның документаль шаһитлары йомшак нервлылар өчен язылмаган. Аларны укып чыккач, үзем дә шок халәтен кичердем. Кешеләргә шулкадәр катлаулы һәм каршылыклы язмыш бирелгәнлегенә шаккатасың. Алай гынамы соң, бөтен Россия язмышы тоташ каршылыклардан гына тора.

Тарих битләрен актарганнан соң башта мең төрле сорау туа. Кызыл дивизия начальнигы Азинның аяусыз сугышчы булуы һәм фаҗи-

гале үлеме михнәтле Россия тормышын җиңеләйттеме? Ул кылыч белән чапкалап үтергән кешеләрнең балалары рәхәт тормышта яшәдеме? Әллә киресенчә «кызыл чумага» каршы көрәшкән Корнилов яклылар Россияне бәхетле иткән булырлар идеме?

Сталин репрессияләренә кадәр яшәсә, Азин исән-имин калыр иде микән? Бу сорауга уңай җавап бирү бик авыр, чөнки 1937 елда Сталин революциягә бирелгән кызыл латышларны иң беренче булып юк итә.

Иреклеләр армиясе җиңү яулаган очракта, беренче большевик Ульяновның (Ленинның) яшьтәше Лавр Корниловның язмышы кайсы юлдан китәр иде икән? Бәлки ул Россия диктаторы булыр иде. Әмма Корниловның беркайчан да монархист булмавын исәпкә алсак, аның диктатор булуын күзаллау кыен. Корнилов идарә итү формасын халык үзе сайларга тиеш, дип саный. Хәрби кеше буларак, ул үзенең бурычын намус белән үти, генерал большевикларга каршы сугышуының максатын да Россияне Учредительное собраниегә җиткерү дип саный.

Мәскәүдә рус хәрби тарихына багышлап «Цейхгауз» журналы чыга. Шуның бер санында мин Лавр Георгиевич Корниловның фоторәсемен күрдем. Патша армиясе генералы формасында, кулында «корниловка» дип йөртелгән фуражка. Аның янына оныгы Лавр Алексеевич Шапрон дю Ларэның фоторәсемен урнаштырганнар. Ул 1932 елда Брюссель шәһәрендә дөньяга килгән һәм хәзер дә шунда яши. Бер-берсенә ике тамчы судай охшаган ике Корниловка да илле яшьләр чамасы.

Әмма шаккатырганы бу гына булмады. 1998 елның азагында беренче тапкыр Россиядә булган генерал оныгы болай ди: «Минем гаиләнең Россиягә карата матди претензиясе дә, әхлакый претензиясе дә юк. Россия өчен үзебезнең нәрсә бирә алуыбыз турында уйларга кирәк. Иң мөһиме — кемгә хезмәт итәргә. Егерменче гасырда Россиядә булган вакыйгалар кабатланмас өчен барын да эшләргә кирәк.

Мин бу юлларны язганда Россиянең Президенты 7 ноябрьне — Октябрь революциясе бәйрәмен — Килешү һәм Бердәмлек көне итеп үзгәртү турында мөрәҗәгать белән чыкты. Миңа калса, каршылыклы егерменче гасыр ахырында безнең халыкка иң кирәк сыйфатлар бу — бердәмлек һәм килешү. Алар гамәлдә кирәк, коры сүздә генә түгел. Бәлки шул чакта безнең үзара мөнәсәбәтләребез йомшарыр, җәмгыятебезне ак, кызыл, зәңгәрләргә бүлү тукталыр һәм, Мишель Нострадамус күрәзәлек итеп калдырганча, гасыр ахырында җәмгыятьтә милли бердәмлек һәм тынычлык урнашыр.

Бүген милли идея турында сөйләүчеләр күп. Сүз дә юк, ул социаль тотрыксызлыктан интегүче җәмгыятебезгә бик кирәк. Ләкин милли горурлыгыбызның мин-минлек, тәкәбберлек чиренә әйләнүеннән, башка халыкларга кырын караудан Ходай сакласын. Шуның өчен килешү һәм бердәмлек идеясен гамәлгә кертергә кирәк.

Егерме беренче гасырда җәмгыятебез нәкъ шушы идея нигезендә цивилизацияле үсеш юлын сайлар, дип ышанасы килә.

# Казак тамыры качактан

## ТЫН ЕЛГАСЫ ЯРЛАРЫНДА

Була шундый шәһәрләр, алар шунда ук үзләренең кабатланмас матурлыклары, бай тарихлары, гүзәл архитектуралары, ачык йөзле вә кунакчыл кешеләре белән күңелне яулап алалар... Андый калаларда бер генә тапкыр булу да җитә торгандыр — сагынып искә төшерәсең, хәтер түрендә кабаттан яңартасың. Мин шәхсән Ростов-Дон каласын үзем өчен шундый шәһәр дип исәплим. Аның хакында йөргән төрле риваятьләр үзләре дә күпме соклану һәм кызыксыну хисләре уята. Чүпрә кабарган кебек бик тиз арада җәелеп үскәнен күреп, халык аны «Рәсәй Чикагосы» дип атаган. Безнең илдә иң җанлы портларның берсе шушы кала янында урнашканлыктан, «Азов Ливерпуле» дип тә йөрткәннәр үзен. Шулай ук аның «Нәни Мәскәү», «Чәркәханәләр шәһәре», «Сәүдәгәрләр пайтәхете» дигән атамалары да киң билгеле. Соңгы йөзьеллыкта аңа әле эчке бер ярату хисе белән «Шәһәр-атакай» дигән исем дә кушканнар.

Шәһәр үзе XVIII йөздә Тимернечкә инеше тамагында төрек җирләре белән кисешкән урында кальга-крепость буларак салына. Митрополит Дмитрий Ростовский исеме белән атала. Нәкъ менә шунда, ил чигендә 1749 елда Елизавета Петровна әмере белән оештырылган Тимернечкә таможнясы эшли башлый. Тиз арада ул Рәсәй өчен икътисади яктан бик әһәмиятле төбәккә әверелә. Донда сәүдәгә, алышбирешкә капка ачу Россиянең дә, чит илләрнең дә сәүдәгәрләренә әкияти табыш китерә. Сәүдәнең гөрләп чәчәк атуы бик күп эшче куллар таләп итә. Шул рәвешчә крепость төзү зарурлыгы туа һәм аның беренче нигез ташы 1761 елның 23 сентябрендә салына.

Әлеге кальга-шәһәргә шул елларда ук татарлар да килеп урнаша башлый. Беренче карлыгачлар Идел белән Чулман якларыннан килгән сәүдәгәрләр, аларның ярдәмчеләре һәм ялчылары була.

Тарихта мәгълүм булганча, безнең ерак бабаларыбыз әле 635 елда ук Дон белән Кубань елгалары арасында Бөек Болгар дәүләтен төзиләр. Әлеге кодрәтле-шанлы дәүләт белән Кубрат хан идарә итә. Ул үлгәннән соң, биш улы уртак тел таба алмыйлар. Туганнар арасында бердәмлекнең булмавын күреп, Бөек Болгарга күрше дәүләт — Хәзәр (Каспий) диңгезе ярына урнашкан, шул исемне йөрткән Хәзәр каганлыгы һөҗүм итә һәм җиңүгә ирешә.

Бөек Болгар иле таркала. Улларның берсе — Батбай — хәзәрләргә буйсынып, Кубаньда торып кала. Аспарух исә, баш имәс, горур ватандашларын ияртеп, Дунай буена китә, яңа дәүләт төзи, бу ил бүген дә

Болгария исеме белән яшәвен дәвам итә. Кубрат ханның ике улы яуда ятып кала. Аларның яудашлары Урта Идел буена күченеп китәргә мәҗбүр булалар — бирелә алар Идел Болгары дәүләтен төзиләр. Улларның бишенчесе — Котраг исемлесе — үзенең тарафдарлары белән Дон елгасы койган урыннарда күченеп йөри. Шушы урында игътибарны бер нәрсәгә юнәлтәсе килә. Нәкъ менә алар әлеге мәһабәт елгага Тын дигән исем бирәләр. Соңыннан «өлкән туган» аны Дон (Тихий Дон) дип атаган.

Әгәр казак сүзенең дә тамыры татарның качак сүзеннән килеп чыкканлыгын әйтсәк, тарихның кара пәрдәсе ачыла кебек. Әнә шул ерак чорларда, хәер, аннан соң да Тын елгасы ярларына качкын-качаклар килеп урнашкан.

Әлбәттә, ул качаклар, тора-бара казаклар арасында, үзләрен кем генә дип атасалар да, йөрәкләрендә татар каны аккан милләттәшләребезне дә күпләп күрәбез.

1805 елга кадәр Дон казакларының башкаласы булып Черкасская дигән зур станица саналган, Донның һәр язны су баса торган ярына урнашкан бу станицаны хәзер Старочеркасская дип атап йөртәләр. Янәшәдә генә Татарская станицасы урнашкан. Исеменнән үк күренеп торганча, анда яшәүчеләр — татар казаклары, ягъни качаклар.

XVII гасыр (төгәле 1623 елгы) чыганакларында ук Татарская станицасыннан 500 кешелек атлы казаклар гаскәре оешу турында язып калдырылган. Алар һәммәсе Дон казаклары булып саналган, казак хезмәтен намус белән үтәгән. Юк, аларны берәү дә кимсетмәгән. Киресенчә, «үзебезнең татарлар», яисә «Дон татарлары», «Тирмәле татарлар» дип атап йөрткәннәр. Әй бу адәм балаларының, халыкларның язмышлары... Нәкъ җырдагыча, «ниләр күрми ир-егеткәй белән ат башы...»

Тора-бара Дон казакларының башкаласы, Черкасская станицасы бетерелә. Моның төп сәбәбе, әлбәттә, язгы ташу була. Елның-елында станица су басудан җәфа чигә. Аны башка урынга күчерәләр. Шулай итеп, картада Новочеркасск каласы барлыкка килә. Иш белән кушны аерып булмаган кебек, Татар станицасы да башкалага якынрак җиргә күчеп утыра.

1860 елда Новочеркасск каласының күз өстендәге кашын хәтерләткән Татарская станицасыннан, хәзер әйтүе кыен, ни сәбәп беләндер, 480 кеше Төркиягә күчеп китә. Октябрь инкыйлабына кадәр станицада 4 мең татар кешесе исәпләнә. Шушы станица, сөекле ана телебезне онытмыйча гореф-гадәт, йолаларын онытмыйча, мәдәниятебезне саклап, мөселман динен тотып, бүген дә яшәвен дәвам иттерә.

Ә Ростов-Дон шәһәренә әйләнеп кайтсак, иркен, мул тормышлы бу калага килеп урнашу узган гасырның 17 нче елына кадәр сәүдәгәрләр һәм аларның хезмәтчеләре хисабына барган. Бигрәк тә совет чорын-

да Ростов каласында һәм өлкәсендә татар халкы күпләп тамыр җибәргән. Хәзерге вакытта бәрәкәтле туфраклы бу төбәктә Казан, Пенза, Касыйм, Ульян татарлары гомер кичерә. Кайбер чыганакларда алар — 50 мең, икенчеләрендә исә 40 мең кеше дип күрсәтелә. Ростовның үзендә генә дә бүген 21 мең татар яши. Аларның төп өлеше — Пенза ягыннан чыгучылар.

Дондагы бу калада Пенза өлкәсенең һәр татар авылыннан диярлек килгән кешене очратып була. Биредә бердәм, тату якташлык җәмгыяте эшли.

Шәһәрнең бөтен илгә билгеле булган заводларында — әйтик, подшипниклар, вертолетлар ясау предприятиеләреме ул, әллә «Ростсельмаш»мы — аларда хезмәт куйган күп санлы милләттәшләребез уңганлык вә тырышлыклары белән аерылып торалар, шулай ук алар бизнес-эшмәкәрлек өлкәсендә дә үзләрен уңай яктан күрсәтәләр. Җитәкчеләр, табиблар, мөгаллимнәр арасында танылган йөзләрчә милләттәшләребезне санап була.

Татарларның күпчелеге үзләре салып кергән өйләрдә яши, аларның бакча һәм дачалары күпләргә үрнәк. Бәрәкәтле туфракның бәрәкәтле җимеше, дип әйтергә була моны. Уңган, тәвәккәл һәм аек кешеләр булганлыктан, алар күпләргә караганда чагыштырмача хәлле булулары белән дә аерылып торалар.

## ҮЗ КАНАТЫҢ ГЫНА ҮЗЕҢНЕ ҖЫЛЫТА

1991 елда Ростов каласында «Нур» исемле татар иҗтимагый үзәге төзелде. Ул өлкә хакимиятенең юстиция бүлегендә теркәлгән. Үзәкне Рөстәм Хәсән улы Уразгилдиев җитәкли. Бу милли оешма, шигъри тел белән әйтсәк, шәһәрнең нәкъ йөрәгендә, Зур Бакча (Большая Садовая) дип исемләнгән үзәк урамында (элеккеге Энгельс проспектында) гаҗәеп матур бинада урнашкан. Октябрь инкыйлабына кадәр өч катлы шушы гүзәл йорт Идел-Кама банк-финанс олигархиясенең зур банкларының берсе булып саналган.

Мин, Рөстәм Хәсән улы белән танышкач, аның кайсы яктан чыгуы белән дә кызыксындым. Ул: «Ростовта туганмын. Әти-әнием исә коллективлаштыру елларында Пенза өлкәсенең Шалдон районындагы Таракан авылыннан күчеп килгәннәр», — дип җавап бирде. ТИҮ җитәкчесе Ростов музыка-педагогия институтын тәмамлаган. Аның бертуган абыйсы — техник фәннәр докторы, профессор, академик Ренат Уразгилдиев — Ростов техник университетында (тимер юл транспорты инженерлары әзерләүче элеккеге атаклы институтта) беренче проректор булып эшли.

Элеккеге хәрби очучы, запастагы полковник Һашим Дәвәтьяров та олуг ихтирамга лаек. Бу шәхес — калада иҗтимагый үзәк оештыруны башлап йөрүчеләрдән берсе. ТИҮ эшенә инженер Сабирҗан Так-

таров та бик нык булыша. Бүгенге көндә ул дин әһеле. Ростовлылар имам хәзрәт Мәхмүд Тәпәевкә дә бик рәхмәтлеләр. Ростов телевидение һәм радио компаниясендә менә 30 ел инде Мәскәү университетының журналистика факультетын тәмамлаган Тәнзилә Ямбаева уңышлы эшләп килә. Чыгышы белән Түбән Новгород өлкәсеннән булган бу ханым атна саен бер сәгать дәвамында радиодан татар телендә чыгышлар алып бара.

ТИҮ каршында эшләп килгән үзешчән милли сәнгать түгәрәге дә танылып өлгерде. Һәвәскәр артистларның чыгышын милләттәшләребез һәрчак көтеп алалар. Шимбә һәм якшәмбе мәктәбен дә татар балалары үз итте. Хәзер анда 60 укучы Бөек Тукай телен өйрәнә. Бу фәннән заманында Казан университетында белем алган, бүгенге көндә завод эшчесе булган, әдәби телне бөтен нечкәлеге белән белгән Камил Гафиятуллин укыта.

Яңа дусларымның сөйләвенә караганда, Пенза татарларында Сабан туе үткәрү гадәткә кермәгән. Бу якларда мәҗүсилек чорларыннан ук яз бәйрәме — «Кыр keләве» үткәрү сакланып калган. Ростовта да дин әһелләре ТИҮ белән берлектә шушы борынгы бәйрәмне оештыра. Якташлар бергә җыйналып симез тәкә сатып алалар. Язгы сабан эшләре тәгәлләнүгә, шәригать кушканча, аны чалалар. Аннары табигать кочагына чыгып, учак ягалар. Кан-кардәшләрен изге эшләргә өндәп, муллалар намаз кыла. Шуннан соң бәйрәмдә катнашучыларның һәммәсе дә симез тәкә итеннән авыз итә. Барысы да Аллаһы Тәгаләдән игеннәр күкрәп үссен өчен яңгыр сорап дога кыла, бер-берләренә уңышның мул булуын тели. Ростовлылар миңа «Келәү»нең Корбан бәйрәме белән бернинди дә уртаклыгы булмавы турында да әйттеләр.

Әлеге бәйрәмдә исерткеч эчемлекләр кулланмаулары да миндә соклану хисе уятты. Шулай кем дә булса мондый адымны ясаса, аны аксакаллар, бөтен якташлык җәмгыяте кискен гаепләп чыга. Бер дигән гүзәл үрнәк бу. Ни аяныч, кайберәүләр Сабан туен шәрабсыз үткәрүне бәйрәмгә дә санамый. ТИҮ бинасыннан әллә ни ерак та түгел Дон төбәгенең туган якны өйрәнү музее урнашкан. Залларның берсендә Дон татарлары тарихына багышланган бай эчтәлекле экспозиция булдырылган, якташларыбыз көнкүрешен сурәтләүче йорт-кура әйберләре, милли киемнәр куелган.

## САБИРҖАН МӘЧЕТЛӘРЕ

1905 елда Ростовта мәхәллә халкы акчасына искитмәле Җәмигъ мәчете салына. Аны хәтта оккупация елларында немецлар да япмыйлар. Аны исә алтмышынчы елларда, «Хрущев җылылыгы» чорында ябалар, мәчетне солдатлар өчен клуб итеп үзгәртәләр. Шуннан бирле мөселманнар җәмгыяте белән Ростовның идарәче даирәләре арасын-

да гыйбадәт йортын чын хуҗаларына кайтарып бирү өчен тартышкөрәш бара. Яңа мәчет төзү өчен урын сорап баргач, кая ул! — казаклар аяк терәп каршы төшәләр: «Басурманнарга бер карыш та җир бирмибез!» —диләр.

Ахыр чиктә мөселманнар җәмгыяте акча җыйнап-туплап зур гына торак сатып алырга, шуны мәчет итеп файдаланырга мәҗбүр була.

Сабирҗан Тактаров исә үз мәчетләрен төзи. Аның Ростов үзәгендәге ике бүлмәле фатирында алар берничә дистә исәпләнә. Әлбәттә, макетлар гына икәнен төшенгәнсездер. Күбесе бүген дә эшләүче мәчетләргә карап ясалган.

— Бу эш белән көтмәгәндә, моннан ун ел элек шөгыльләнә башладым,— дип искә төшерә Сабирҗан Минһаҗетдин улы.— Ул вакытта туңдыру комбинатында баш инженер булып эшли идем. Беркөнне хезмәттәшем, рус кешесе Кижа утравындагы чиркәүнең үзе ясаган макетын күрсәтте. Шунда аңа: «Тырышсаммы, мин синекеннән әйбәтрәк ясый алам»,— дидем.

Сүзендә тора Сабирҗан. Күпмедер вакыт узуга ул чиркәү макеты алып килә. Иптәшләре аның нечкә зәвыгына һәм осталыгына сокланалар.

— Ни өчен чиркәү макеты дип сорыйсыңмы? — ди Сабирҗан һәм үзе үк җавап та бирә. — Ул чакта миндә бер генә мәчетнең дә рәсеме һәм фотосы юк иде. Аңарчы минем, гомумән, үз күзем белән мәчет йортын күргәнем булмады. Пенза өлкәсенең Каменский районындагы туган авылым Мочалейкада мәчетне мин туганчы ук җимереп атканнар.

Менә ни өчен язмам каһарманы Архангельск поморлары чиркәве макетын ясап «кулын шомарта». Соңрак, сиксәненче елларда, матбугат битләрендә мәчет рәсемнәре чыга башлагач, Сабирҗан үз күңеленә хуш килгән мәчет макетларын ясый башлый.

Аның ислам диненә бәйле беренче иҗат җимеше Әстерхан каласында бүген дә эшләп килгән өч манаралы, ике катлы мәһабәт мәчет макеты була. Сабирҗан аны шушы шәһәрдә яшәүче энесе салып җибәргән фоторәсеменнән карап ясый.

Икенче хезмәтендә исә Әфганстандагы дүрт манаралы, зур гөмбәзле мәчет бинасы тасвирлана. «Шуравилар», ягъни совет солдатлары тарафыннан өлешчә шартлатылган әлеге гыйбадәт йортын шулай бервакыт үзәк телевидениедән күрсәтәләр. Сабирҗан аны хәтерендә сеңдереп кала һәм иҗатка керешә.

Язмам каһарманы иң башта төзелеш кирәк-яраклары — бик әйбәтләп ышкыланган нәни борыс һәм такталар хәстәрли, аннары «бина»ның каркасын кора. Соңыннан аңа гөмбәз урнаштыра, манара куя. Шуларны башкаргач, макетка меңнән артык бик тә юка калай кисәкләре ябыштыра, милли бизәкләр төшерә.

Булдырганнар гына булдыра: укуда да, эштә дә, хәтта ки хоббида да. Хәзер инде өлкәнлек үренә күтәрелгәч тә, Сабирҗан гарәп хәреф-

ләрен өйрәнә, Коръәнне вәкамләп уку серенә төшенә. Бүген ул кала мәчетендә иң абруйлы хәзрәти затлардан санала.

Осталыкның чиге юк. Шулай да шушы олуг шәхеснең соңгы вакытта иҗат иткән хезмәте аның төп хыял җимеше дип әйтер идем. Ул —Ростов каласы мөселманнары йөрәгендә ничә еллар йөргән, иртәме-соңмы, барыбер дә бер салыначак җәмигъ мәчетенең макеты. Әгәр дә Ходай насыйп итеп, шәһәр хуҗалары кан-кардәшләребезгә җир дә бүлеп бирсәләр, әлеге мәчет Россиядә иң күркәм мәчетләрдән берсе буласы! Була гына күрсен, фәрештәләрнең амин дигән сәгатенә туры килсен.

##ҺАШИМ — КҮК УЛЫ

Төньяк Кавказ хәрби округы штабы Ростовта урнашкан. Шуңа да бу калада төрле гаскәри частьларның күп булуы берәүне дә гаҗәпкә калдырмый. Татар милләтеннән булган байтак офицерлар да, хезмәт итүләрен тәмамлаганнан соң, көньяктагы шушы шәһәрдә яшәп калуны хуп күрәләр. Хәзер сүзем шундыйларның икесе хакында.

Лаеклы ялга чыккан авиация полковнигы Һашим Лотфулла улы Дәвәтьяров белән мин «Нур» исемен йөрткән Татар иҗтимагый үзәгендә таныштым.

Һашим үзе Киров өлкәсеннән, алкын сулы Нократ елгасында коенып үскән егет. Туган авылы да шушы елга исемен йөртә. Ул — Архангельск өлкәсендәге Котлас исеме белән яманаты чыккан Сталин лагеренда һәлак булган изге хәзрәт оныгы. Бабасының догалары оныгына килеп ирешкәндер: Һашимның хәрби очучылар училищесын төгәлләгәч тә, аннары Юрий Гагарин исемендәге академиядә укып чыккач та хезмәт итүе һәрчак уңып кына тора. Истребительләрнең барлык төрләрендә дә оча ул. Хәрби хезмәтнең һәммә баскычларыннан узып, полковник дәрәҗәсенә ирешә, ПВОның авиакорпусы командующие биеклегенә күтәрелә. Соңгы ун елда Ставропольдәге югары хәрби очучылар училищесы башлыгы урынбасары булып эшли.

— Кайда гына хезмәт итсәм дә, үземнең кайдан һәм нинди тамырдан икәнемне онытмадым, һәрчак туган ягымны сагынып яшәдем,—дип искә ала яшьлеген Һашим Лотфулла улы.— Ел саен диярлек Нократка кайта идем. Хәзер дә күпне күргән, күпне кичергән әнием белән апамны онытканым юк. Хәлдән килгәнчә ярдәм итәргә тырышам.

Әнисенә хат язу өчен Һашим әфәнде гарәп хәрефләрен өйрәнә, әнисе — улына, улы әнисенә хатларны шушы хәрефләр белән яза.

Балачагыннан ук догаларны ятлап үскәнлектән, ул «коммунизм идеяләре шаулап чәчәк аткан» елларда да динне, шәригатьне онытмый, берәүгә дә сиздермичә ислам дине кануннарын өйрәнүен дәвам иттерә.

— Һәр очыш алдыннан бер генә мизгелгә күзләремне йомып, газиз

әниемне искә төшерә идем, —ди татар полковнигы Дәвәтьяров. — Аннары эчемнән генә бисмилламны әйтеп, «әнием, хәерле юл теләулыңа!» дип кабатлый идем. Белсә бер Ходай үзе генә беләдер. Бәлкем, мине бәла-казалардан әнә шулай әнием догалары саклап калгандыр.

Менә 14 ел инде Һашим әфәнде «гражданка»да. Техникумда укыта. Буш вакыты булдымы, ул тизрәк ТИҮгә ашыга.

## КЕШЕЛӘР ДӘ КОШЛАР НӘСЕЛЕННӘН

Майор Алимҗан Ибраһим улы Богдаловның берничә дистә елы очышка бәйле. 1977 елда үзе хезмәт иткән Ростов каласында лаеклы ялга чыга. Әмма очучы йөрәге эшсез тора алмый, Пионерлар йортына эшкә урнаша, анда хәрби-спорт бүлеген җитәкли.

Ростов каласы читендә авиация базасы белән янәшәдә «Военвед» дип исемләнгән гаҗәеп матур микрорайон урнашкан. Хәрби башлыклардан, элеккеге хезмәттәшләреннән Алимҗан ике бүлмә «яулап ала». Аннары яшьлек дәрте белән эшкә тотына: хәрби самолетларның инде вакыт сынавын узган, әмма әле тузмаган, файдаланырга яраклы узел вә агрегатларын җыя башлый. Укучылар белән дәресләрне хәрби шәһәрдә, хәрби аэродром янында үткәрә. Әнә шул рәвешле «Яшь очучы» клубы дөньяга килә. Озак та үтми, бу клуб хәрби-патриотик тәрбия бирү өлкәсендә иң яхшылардан берсе буларак бөтен илгә танылa.

«Яшь очучы» клубына 4 — 11 сыйныф укучылары кабул ителә. Шунысын да әйтү мөһимдер: начар билге алучыларга аның ишеге ябык.

Клубта остаз А.Богдалов укытуны нәкъ тормыштагыча итеп оештыра. Дәресләр үзенчәлекле эскадрильяләрдә үткәрелә. Биредә барысы да бар: командир да, штаб башлыгы да, башка төр хезмәтләр дә. Балалар, яшүсмерләр очыш теориясен, самолетлар төзелешен һәм двигательләрен, аэродинамика серләрен, радио хезмәтен, ату коралларын, кораллы көчләр уставын өйрәнәләр. Һәммәсенең дә киеме бер төстә — зәңгәр костюм, кокардалы фуражка, кош рәсеме тагылган погоннар...

Турысын гына ярып әйткәндә, клуб тиз арада булачак очучыларны әзерләү үзәгенә әйләнә. Әле кайчан гына беренче тапкыр шушы үзенчәлекле йортның ишеген ачып кергән юеш борынлы малай-шалайлар хәзер инде хәрби очучылар булып киттеләр, кайберәүләре исә пассажир самолетларында ил күген иңлиләр.

Ул 1925 елда Пенза өлкәсенең Пачельмен төбәгендәге Качкару авылында туа. Гүзәл табигатьле шушы якта, рус авыллары белән янәшә алты татар авылы да тезелеп киткән. Халык телендә ул «алтавыл» дип кергән.

33 нче елда Идел буенда ачлык котыра. Алимҗанның да әтиәнисе ачлыктан һәлак була. Шыр ялангач, хәерче йортта өч бала — 10 яшьлек Маһирә, 8 яшьлек Алимҗан, 4 яшьлек Рәхимә дөм ятим

булып кала. Мескен сабыйларны авыл советы рәисе Абдрахман Әләм улы Агаев гаиләсе, ике баласы янына куш итеп, үз канатына ала.

Җиденче сыйныфны тәгәлләүгә Алимҗан Пензадагы тимер юлчылар мәктәбенә укырга керә. Күпмедер вакыт кондуктор булып эшләгәннән соң, ул 1942 елның октябрендә үзе теләп фронтка китә. Техниканы шактый әйбәт белгәнлеген күреп, 17 яшьлек егетне хәрби авиация мәктәбенә юллыйлар. Ул аны 1944 елда тәмамлый, шунда Беренче Белоруссия фронтының 765 нче авиаполкы белән җәһәннәмгә тиң сугыш утына керә. Шул көннән бирле Нократ егете бөтен гомерен хәрби авиациягә багышлый.

Җиңүдән соң А.Богдалов Германиядә, Кавказда хезмәт итә. Офицерлар мәктәбен тәмамлый. 1949 елда хәрби авиатор киемен киеп беренче тапкыр туган авылы Качкаруга кайта, шунда авылның иң сылу кызы Разияне очрата.

— Мин аны нәни чагыннан ук белә идем,— дип елмая Алимҗан Ибраһимович. — Мин Аурупа иңләп сугышып йөргәндә әнә ул нинди матур кыз булып тулышып өлгергән. Язмышка да, Ходайга да рәхмәтлемен, хатынымнан уңдым мин. Безгә кайда гына, нинди генә гарнизоннарда яшәргә туры килмәде. Ул минем төп таянычым да, якын дустым да, акыллы киңәшчем дә булды. Ике улыбызны да әйбәт кешеләр итеп хатыным тәрбияләп үстерде дисәм, һич хилафлык булмас. Нәкъ мәкальдәгечә, ирне ир иткән бөек көч — ул яраткан хатының.

* * *

Туган яктан еракта, чит-ят туфракта кан-кардәшләрем белән бик еш очрашып торам. Көннән-көн шуңа ныграк ышана барам: алар — көчле рухлылар. Бу көчне алар милли һәм дини тамырыбыздан алалар. Әйткән сүзләрендә нык торалар, үз халкыбызга һәм Ватаныбызга тугры хезмәт итүнең асыл үрнәген күрсәтәләр. Минем шушы хикәятем әлеге фикернең гап-гади кан-кардәшләребезнең язмыш юлында да ачык чагылуын күрсәтә.

Бөтен ил буйлап сибелгән рухи мәркәзебез Казаннан бик еракта яшәгән милләттәшләребез кайбер сәясәтчеләрнең халыкны таркату, бүлгәләү юнәлешендә хәйләкәр, хәтта ки әйтер идем, мәкерле эш алып баруларын бик авыр кичерәләр. Ассимиляцияләшү, ягъни телдән язу һәм мәдәнияттән мәхрүм калуның нәрсә икәнен үз башларыннан үткәргәнлектән, алар милләтне бербөтен итеп саклап калуга өндиләр. Миңа да Ростовта булган чагымда милләттәшләрем авызыннан халкыбызның «Аерылганны аю ашар» дигән мәкален еш ишетергә туры килде. Иң мөһиме, иң сөендергәне шул: алар милләтебезне төрле этник төркемнәргә бүлүгә каршы чыгалар.

*Казан — Ростов-Дон — Казан.*

## Татар Мәскәве

### МӘСКӘҮЛӘРГӘ БАРДЫМ ӘЛЕ...

Мәскәү җирләрендә руслар һәм татарлар борын-борыннан бергә яшәгән. Төрки һәм славян төркеменә кергән әлеге халыклар бер-берләренә һич тә ят түгел. Драматик вакыйгалы еллар да булган, аларны күршеләрчә дустату, цивилизацияле рәвештә бергә яшәү еллары алыштырган.

Искиткеч зур Россия җирләренең башкаласы булачак шәһәр башта ук мишәр җирләрендә төзелгән бит! Бүген дә Мәскәүне көньяк-көнчыгыштан һәм төньяк-көнчыгыштан мещера (мишәр) урманнары — Рязань мещерасы һәм Владимир мещерасы яклары урап тора.

Билгеле булганча, «Москва» сүзе беренче тапкыр 1147 елда Ипатов елъязмасында телгә алына.

Тарихчылар әйтүенә караганда, Ока ярлары буенда мишәрләр инде тугызынчы гасырда ук, бу якларда христиан дине кабул ителгәнче байтак еллар элек үк гомер сөргәннәр. Мишәрләрнең «маскай», «маскау» дигән сүзләре «элмәк», «ат кылыннан үрелгән җәтмә» мәгънәләрен аңлата. Шунысы да бәхәссез: әлеге җирлектә бүгенге мегаполисның тарихи үзәген тәшкил иткән топонимнар да (елга, күл, авыл исемнәре) күбесенчә татарчадан килеп чыккан. Мәскәү елгасы аръягында бүгенгәчә Большая Татарская һәм Татарская урамнары, шулай ук Зур һәм Кече Татар тыкрыклары бар. Алар биредә өч гасыр дәвамында Татар бистәсе яшәп килгәнлегенраслыйлар.

Байтак елъязмаларда һәм тарихи әсәрләрдә (мәсәлән, П.В.Сытин, Д.Балашов һ.б. авторларда) Кремль ныгытмасы берничә тапкыр «кремник» дип телгә алына. Бу сүз дә төрки тамырга нигезләнгән: «керәм» һәм «нык». Ягъни «ныклы корылмага керәм». (Әйе, борынгы мишәрләр, бүгенге көн корылмаларының ныклыгын да искә алсак, сүз мәгънәсен яхшы тоемлаганнар.— *Я.Ш.*)

Мәскәү Кремленең егерме манарасы бар. Аеруча матур, нәфис һәм зифа буйлысы — Беклимиш манарасы, икенче төрле Москворецкая дип тә йөртәләр. Анысы инде, кем әйтмешли, кәҗәгә дә аңлашыла —Мәскәү елгасы белән янәшә булганга, билгеле. Ә менә Беклимиш исеме каян килгән? София Яры буеннан да, ГУМ ягыннан да, Мәскәү елгасының Зур күпереннән дә бердәй матур күренүче бу манараның исеме турында бераз аңлатма биреп үтү кирәктер.

«Беклимиш» — төрки сүз, мишәрчә — «бикләә», «бикләмеш» — бикләнгән, сакланган мәгънәсендә түгелме? Билгеле, шулай. Мәскәү Кремлендә нәкъ шушы манара янында бояр Беклимишевлар ихатасы булган. Аларның бабалары — Беклимиш морзалар — заманында хәзерге Арзамас тирәсендә, Теша елгасы буенда яшәгәннәр. Түбән Новгород

дәүләт университеты архивларында могҗиза белән исән калган «Мещера» дигән беренче чыганакларда шул турыда мәгълүмат бар.

Кремльдән ерак та түгел, Мәскәү елгасының аргы ягында, башкаланың бер урыны «Балчуг» дип атала һәм шундый ук исемдәге ресторан эшли. Татар телендә әле дә актив кулланылышта йөргән «балчык» сүзенә аңлатма биреп тору кирәкмидер. Ул Мәскәү елгасының язгы ташулардагы җимергеч көче, аннан соң утырып калган балчык-ләм, баткаклыгына карап бирелгән исем, әлбәттә.

Хәзерге Тынычлык проспектыннан арырак, Олимпия комплексы янында Мәскәүнең Җәмигъ мәчете урнашкан. Аны Рязань өлкәсенең хәзерге Еримиш районы Әзи авылыннан чыккан Салих Йосыпович Ерзин, Нури Ширинский һәм Хәбибулла Акбулатов дигән кешеләр 1904 елда төзегәннәр. Шунысы кызык: әлеге зур татар авылында 1928 елда Фикрәт Әхмәтҗанович Табеев туган. Белгәнебезчә, ул 20 ел буе Татарстан белән җитәкчелек итте, бүгенге көндә Мәскәүдә яши.

«Яуза» дигән гидроним да кызыксынучан кешеләрне битараф калдырмас. Күренекле рус тарихчысы һәм археологы, күп еллар дәвамында Мәскәүнең Тарих музееи җитәкләгән, Мәскәү тарихы буенча күп хезмәтләр язган белгеч Иван Евгеньевич Забелин (1820 — 1908) «Яуза» сүзе — «узкая» («тар») мәгънәсен белдерә дип исәпләгән. «Яуза» сүзе төрекчә «яузда» дип языла. Койрыклы «з» «да» иҗеге белән берләшеп, кушылып укыла. «Яу»ның ни икәнен беләбез инде, димәк, «Яуза» — «яу вакытында, яуда» дигәнне аңлата. Бу елга ярында сугышлар булып торган, яисә көтмәгәндә аргы яктан дошман һөҗүм иткән. Татар сүзлегендә «яу» сүзенең бер мәгънәсе — сугыш, көрәш, «яу кыры» — сугыш кыры ич инде.

Мәскәү елгасы аръягының көнбатыш өлешендә «Кырым» сүзе еш очрый: Крымский вал, Крымский мост, Крымская набережная, Крымский тупик. Тарихчылар һәм тел белгечләре күпме генә бәхәсләшсә дә, «кырым» дигән төрки сүз «озын чокыр», «туфрактан өелгән үр» мәгънәсен аңлата.

Элек-электән Мәскәүдә татарлар йөкче булып эшләгән. Тарихи урамга һәм мәйданга нәкъ менә алар «арба» һәм «ат» сүзләренең кушылмасы булган «Арбат» исемен биргәннәр. Арбат мәйданы йөкчеләр һәм ямчыларның төп тукталыш урыны булган.

Сүз уңаеннан: «Ямщик» сүзе дә русларга татар теленнән кергән. «Ям» тамыры — юл читендәге торак урыннарны — станцияләрне белдерә, атлы кешеләр аларда төн куну, тамак ялгау, атларын алыштыру өчен туктала торган булганнар. «Ямчы» — татарча «озатучы», русча «гонец» дигән мәгънәдә.

Руська ямчылык хезмәте Алтын Урдадан күчкән, анда ул төпле нигездә оештырылып, киң таралган булган инде. Без бу хакта Михаил Каратеевның «Русь и Орда» дигән трилогиясеннән дә укып беләбез. Язучы, тарихи елъязмаларга нигезләнеп, ул ерак еллар вакыйгаларын мөмкин кадәр дөрес тасвирлый. Алтын Урдада ямчылык хезмәте иксезчиксез империянең кан тамырлары системасына тиң булган. Мәсәлән, революциягә кадәрге тарихчы, «Очерк ямских учреждений от древних времен до царствования Екатерины II» дигән фундаменталь хезмәтнең

авторы И.П.Хрущов (КПСС ҮКның беренче секретаре Никита Сергеевич Хрущев белән бутый күрмәгез) болай дип яза: «Татарларның хакимлеге ерактан торып идарә итү формасында була. Татарлар әледәнәле килеп чыгып кына үзләренең хакимлеген сиздергән, нәкъ менә шушы килеп чыгулар атлар, кешеләр һәм тукталыш урыннарының уңайлылыгы белән тәэмин ителергә тиеш булган. Әнә шул тукталыш урыннары — «ям»нарга (станцияләргә) шул тирәдә яшәүче кешеләр атлар һәм хан кушуы буенча азык-төлек китерергә тиеш саналган».

Мәскәүнең иске өлешендәге кайбер урам исемнәренең (мин берничә Тверская-Ямская урамын күздә тотам) каян килеп чыкканлыгын укучым инде чамалагандыр дип беләм.

Мәскәүнең иске өлеше тарихына игътибар белән күз салсаң, Булгаковның Мастеры яшәгән йортны да табу авыр булмас. Ярымподвалдагы уңайлы фатирны хәтерлисезме? Менә шул, нәкъ менә Мансур тыкрыгында (Пречистенка тирәләре) 9 нчы номерлы зур булмаган агач йорт әлегә кадәр тора. Егерменче елларда анда Булгаковның дуслары Сергей Еромлинский һәм бертуган Топлениновлар яшәгән. Хуҗаларның горурлык билгесе — фарфор юынгыч та шул фатирның коридорында торган.

Тарихи елъязмаларга караганда, «Китай-город» 1535 елда Великий Посадны дошманнан саклау максатында төзелгән. Кыпчаклар телендә «китай», дөресрәге «катай» сүзе «крепость», «ныгытма» дигәнне белдерә. Ягъни, Кремль стенасы — «бер кат ай» (Кремльне ай рәвешендә әйләндереп алган). Аннары — «икенче кат ай». Нәтиҗәдә, «Китай-город» килеп чыккан.

Менә инде «Садовое кольцо»га да килеп җиттек. Биредә дә татар тамырларына яисә тарихына ия булган тарихи урыннар һәм биналар байтак. Мәсәлән, Садово-Спасская урамының 6 нчы йортында сигезьеллык татар мәктәбе эшләгән. Анда берьюлы 500 бала укыган. Мускиев, Апанаев, Чейкунов, Әсма Булатова, Кутуева кебек дәрәҗәле укытучылар дәрес биргән. Директоры Ишмаева Сафия Кәримовна, завучы Хәйдәр Биктимиров булган. Бөек Ватан сугышы башлангач, мәктәпне япканнар һәм бинасын солдатларга казарма итеп биргәннәр. Аның әлегә кадәр татарларга кайтарылганы юк.

Таганка мәйданыннан Котельный яр буена, Россия Федерациясендә Татарстан Республикасы Вәкиллеге урнашкан якка юнәлгәндә, тагын бер тарих исемә төште. Монда әүвәле Таганка бистәсе булган, анда төрле савыт-саба, таганнар җитештерелгән. Гомеренә бер тапкыр булса да табигатьтә кайнар ризык әзерләгән һәр рус кешесе таганның ни икәнен яхшы белә. Учак өстендә ризык пешерү өчен көйләнгән тимер өчаякка «таган» дигән татар исеме кушылган.

Садовое кольцоның икенче ягыннан Тверская урамына таба Кызыл мәйдан аша Большая Ордынка урамы сузыла. Урам исеме Алтын Урда белән бәйле. Төрки халыкларда «Орда» сүзе юк-югын. Бөтен тарихи документларда төркичә «урда» дип язына. «Орда» — шуның бозылган варианты. Большая Ордынка Алтын Урда чорында ук барлыкка килеп, ике башкала — Сарай һәм Сарай-Бәркәгә юнәлгән юл әнә шуннан башланып китkән.

Большая Ордынкага бер кырыйдан Зур Тылмач тыкрыгы килеп кушыла. Иске һәм Кече Тылмач тыкрыклары да аңардан әллә ни ерак түгел. «Тылмач» — төрки сүз, «тәрҗемәче» мәгънәсендә. Ул елларда Мәскәүдә төрки телле халыклар белән үзара сәүдә итешкәннәр. Тәрҗемәче-тылмач вазифасын татарлар башкарган. Алар күбесенчә Тылмач тыкрыкларында — сәүдәгәр татарлар туктала торган Крымский валдан ерак булмаган урында — яшәгәннәр.

Әсәдуллаев йорты — Мәскәү татарларының аерым горурлыгы булып санала. Октябрь революциясенә кадәр аны үз акчасына һәм Мәскәү татарларыннан җыелган иганә хисабына татар сәүдәгәре Әсәдуллаев төзеткән. Революциядән соң бирелә ВЦИК карары белән Мәскәүдәге «Татар хезмәт ияләренең мәдәни үзәге» оештырылган. Бөек Ватан сугышына кадәр монда шулай ук Нариманов исемендәге татар урта мәктәбе эшләгән. Мәскәүнең башка сигезьеллык татар мәктәпләрен тәмамлаган укучылар урта белем алырга бирегә килгәннәр. Бу мәктәптә күренекле татар мәгърифәтчеләре укыткан. Мәсәлән, революциядән соңгы елларда бу мәктәпнең директоры булып галим-математик, Сорбонна университетын тәмамлаган Сара Шакулова эшли. Ул да Рязань ягындагы Әзи авылы кызы.

Бүгенге затлы-дәрәҗәле ГУМ бинасы урынында унҗиденче гасырда 120 дән артык сәүдә рәте тезелеп торган. Аларның берсе «Саадашний ряд» дип йөртелгән. Даль сүзлегенең 4 томында, 126 биттә болай диелә: «Саадак, сагадак или сагайдак» — татар сүзе, «наличник» (йөзлек), җәя чехолы дигәнне белдерә, гадәттә, күннән эшләнә.

Мәскәүнең татар тарихы, татар мәдәнияте белән бәйле почмаклары турында тагын бик озаклап сөйләргә мөмкин. Мәсәлән, Коломна турында — татарча «колом», ягъни, «минем кол»; Зур Черкиз урамы турында — Куликово сугышы алдыннан Алтын Урдадан Мәскәү ягына күчкән кешенең исеме Серкиз булган. Басманная урамында беренче Мәскәү типографиясе салынган — «басма» дигән татар сүзенең русча «печать» икәнлеген беләбез.

Мәскәүнең Казан вокзалыннан юлга кузгалган яисә шунда килеп төшкән кешеләрнең Россиядә исәбе-саны юктыр. Тимер юл унтугызынчы гасыр урталарында төзелә башлый. Ул чакта бу вокзал Рязань вокзалы дип атала. Чөнки ул елларда тимер юл Рязаньга кадәр генә сузылган була әле. Унтугызынчы гасыр ахырында, тимер юл инде Казангача ук сузылгач, вокзал илнең ихтыяҗларын канәгатьләндерә алмый башлый. Аны өр-яңа проект белән тулысынча үзгәртеп төзергә кирәк була. Архитектура буенча конкурс үткәрелгәннән соң, вокзалның соңгы проектын башкарып чыгу эше 1912 елда күренекле архитектор А.Щусевка йөкләнә. Төзелеш 1913 елдан башлап 1926 елга кадәр дәвам итә. Шулай да аны 1919 елдан файдалана башлыйлар. Күренекле архитектор аны үз хыялында Көнчыгышка капка итеп күрә һәм вокзалның төп керү юлын, Казан Кремлендәге манарага охшатып, 87 метрлы Сөембикә манарасы рәвешендә эшли. Казан ул чакта тимер юлның соңгы пункты булып тора бит.

Бүген Казан вокзалында эшләүче 1100 кешенең яртысы диярлек

татарлар, күбесенчә, Түбән Новгород өлкәсенең Сергач ягы мишәрләре. Әлеге зур хуҗалыкка Сергач районының Шубино авылы кешесе Солтан Якубов җитәкчелек итә.

Беренче дулкын эмигранты, язучы Михаил Каратеев Аргентинада язган һәм беренче тапкыр 1971 елда Буэнос-Айреста бастырып чыгарган «Русь и Орда» трилогиясенең «Тарих арабескалары» өлешендә мондый кызыклы фактлар китерә: «Татарларны һәм аларның хәрәкәтләрен тасвирлау өчен безнең елъязмачылар бер генә төсне — караны, аның да иң куесын гына файдаланганнар. Әмма шул ук вакытта татарлар — гади кешеләр булсынмы, хакимлек итүчеләрме — бик күп уңай сыйфатларга ия булган. Барыннан да элек, алар артык намуслы, бурычка турылыклы, тәртипле булулары белән аерылып торганнар. Төрле тарихи чыганаклардан һәм документлардан мин чыгышы белән татарлардан килгән 92 кенәз, 50 бояр, 13 граф һәм 300 дән артык борынгы дворян нәселен язып алдым.

Татарлар Россиягә ике патша — Борис һәм Федор Годуновларны, биш патшабикә — Соломония Сабурованы (Василий Өченченең хатыны), Елена Глинскаяны (шул ук патшаның икенче хатыны), Ирина Годунованы (патша Федор Иванович хатыны), Наталия Нарышкинаны (Алексей Михайловичның хатыны һәм Петр патшаның анасы) һәм патша Федор Алексеевичның хатыны Марфа Апраксинаны биргән. Евдокия Сабурова — Иван Грозный улының, соңыннан атасы тарафыннан үтерелгән Иванның хатыны булган.

Шунысы да кызык: берничә татар кешесе рус чиркәве тарафыннан изгеләр сафына да кертелгән әле. Аеруча күренеклесе — Петр Ордынский, Батый ханның туганының улы, башта православие динен, аннары монахлыкны кабул иткән. Тагын бер татар — изге Петр, Казан газаплanучысы (мученигы).

Әлеге бүлекне бәян иткәндә, үзе яулап алган Мәскәү Кремлендә утырып, Парижга, хатыны Жозефинага хат язган Наполеонны искә төшердем: «*Кадерле Жозефина! Бу Мәскәүдә кайсы урысны кырыштырып карама, татарга килеп төртеләсең!*»

Дөрес, яңа Мәскәүдә минем милләт вәкилләренең исемнәре белән бәйле урам, бакча, парк һәм башка шундый урын исемнәре бөтенләй юк диярлек. Юкса, башкаланың танылган «Главмосстрой» төзелеш главкында — эшчеләр булсынмы, инженер-техник хезмәткәрләрме, җитәкчеләрме — татарлар зур өлеш тәшкил итә. Орехово-Борисовода Муса Җәлил урамы бар. Тагын «Крылатское» дигән бер район бар. Ул да теге ерак заманнардагы татар елларыннан калган. «Кырыла» һәм «ат» сүзләреннән, «атлар кырыла, үлә» мәгънәсендә. Бу урында Мәскәүгә яу чапкан җайдаклар өчен чокыр-тозаклар казыганнар.

Бүгенге көндә Мәскәүдә кайсыдыр белешмәләр буенча — 800 мең, ә икенчеләре буенча миллион татар гомер итә. Гади генә итеп әйткәндә, Мәскәүнең һәр унынчы кешесе — татар. Әмма, кыргычла-кыргычлама, үзе әйтмәсә, Мәскәү татарын бер күрүдә танып булмый. Чөнки, әле яңарак кына барып урнашкан татар-лимитчыларны да кертеп, алар барысы да диярлек русча сөйләшә.

Элек милләттәшләребез күбесенчә төзелешләрдә, авыр һәм зарарлы җитештерүдә, коммуналь сфераларда эшләгән булса, хәзерге буын зур һәм кече бизнеста да, фәндә дә, югары белем даирәсендә һәм медицинада да хезмәт куя, төрле дәрәҗәдәге хакимият коридорларында да алар инде ят кешеләр түгел.

## ТАТАРНЫҢ ЛАЕКЛЫ ӨЛЕШЕ ТУРЫНДА

### (Мәскәү мэры Ю.М.Лужков белән әңгәмәдән)

**— Юрий Михайлович, әлеге күп миллионлы мегаполиста йөзләрчә милләт вәкилләрен тәшкил иткән Мәскәү халкы ничек яши соң?**

— Чыннан да, Мәскәүдә күп гасырлар буена төрле милләт вәкилләре дус һәм тату гомер иткән. Без моның белән горурлана алабыз. Без моның кадерен беләбез. Минемчә, төрле милләт халыкларының дуслыгы — башкалабызның төп байлыгыдыр. Бүгенге көндә бар халык вәкилләренең дә нормаль яшәве һәм үсеше өчен бөтен шартлар тудырылган. Күп милләт вәкилләре төрле милли-мәдәният автономияләргә, ассоциацияләргә, берләшмәләргә туплана, аларның максаты — милли мәдәниятне, телне саклау һәм үстерү, башка халыклар белән цивилизацияле бәйләнешләр урнаштыру. Мәскәү һәрвакыттагыча халык талантлары смотры үзәге булып кала.

Шәһәр җитәкчеләре милли җәмгыятьләрне үстерүгә, халыклар арасында тынычлык һәм дуслыкны саклауга зур әһәмият бирә. Бу эшкә, гомумән алганда, Мәскәү хөкүмәтенең Милләтара һәм регионара элемтәләр комитеты җитәкчелек итә. Төрле чаралар оештырылганда иң яхшы Мәдәният сарайлары, концерт заллары тәкъдим ителә. Китапханәләребез дә милли хәзинә фондлары белән горурланырга хаклы. Башкалабызның университет, академия һәм институтларында элеккеге Советлар Союзының барлык регионнарыннан (һәм аннан гына да түгел) килгән күп милләт вәкилләре нигезле белем ала.

Милли мөнәсәбәтләрдә Мәскәү — гаҗәеп шәһәр. Тынычлык, дуслык, татулык шәһәре.

**— Юрий Михайлович, Сезнеңчә, татарлар Мәскәү тормышында нинди урын тота?**

— Татарлар Мәскәүдә гасырлардан гасырларга билгеле бер урын, дәрәҗәгә ия булган. Бүген дә башкаладагы татарлар, бөтен Россиядәге кебек үк, халык саны буенча икенче урынны били. Мәскәүдә алар сигез йөз мең дип исәпләнә. Димәк, Россия башкаласындагы һәр уникенче кеше татар булып чыга.

Совет заманында рәсми берләшмәләр юк иде. Шулай да, рәсми булмаган якташлык җәмгыятьләре эшләгәнен беләбез.

1999 ел ахырында Мәскәүдә башкала татарларының милли-мәдәни автономиясе оешты. Рәисләре итеп отставкадагы генерал-полковник, күп еллар буена илнең ПВО җитәкчеләреннән берсе булган Рәсим Сөләйманович Акчуринны сайладылар. Мәскәүдә аны бик хөрмәт итәләр. Аның фикеренә Мәскәү татарлары да, шулай ук Мәскәү

хөкүмәте чиновниклары да колак сала. Рәсим Акчуринда татар халкына хас булган бик күп уңай сыйфатлар тупланган. Зирәклек, сабырлык... Шунысын да әйтим, ул — илнең күренекле кардиохирургы, академик Ренат Сөләйманович Акчуринның бертуган абыйсы да әле.

Мәскәү хөкүмәте татарларның милли-мәдәни автономиясе эшчәнлегенә һәръяклап ярдәм күрсәтәчәк.

Автономиядән тыш, Мәскәүдә шулай ук Казан, Пенза, Түбән Новгород, Ульяновск татарларының якташлык җәмгыятьләре дә оешкан. Алары рәсми яктан теркәлмәгәннәр. Аларның да эшчәнлеге позитив характерда һәм без бу эшне хуплыйбыз.

Мәскәү татарлары хезмәт сөючәнлекләре, кешеләргә дустанә мөнәсәбәтләре белән аерылып тора, шуның өчен мин аларга рәхмәтле.

Башкаланың яңа районнарын, метрополитенны, федераль әһәмияткә ия булган объектларны төзүдә татарлар керткән өлеш зур. Мәскәү предприятиеләрендә алар тулы династияләр белән хезмәт итә. Татарлар менә дигән эшмәкәрләр дә әле. Бүген, ил икътисады базар мөнәсәбәтләренә юнәлеш тотканда, Мәскәү эшмәкәрлегендә татарлар сизелерлек урынны биләде һәм уңышлы рәвештә алга бара. Эшмәкәрлектә алар — намуслы, гадел. Җәмгыятьнең башка катламдагы эшмәкәрләре дә аларга ышаныч белән карый.

Тагын шуны да әйтәсем килә: Мәскәү вузларында, фәнни учреждениеләрдә дә татарлар күп. Бу милләт һәрвакыт укуга, белемгә омтылышы белән аерылып тора. Араларында күренекле шәхесләр бар. Легендар галим, совет компьютерының «атасы» Вәлиев Камил Әхмәтовичны мин һәрвакыт зур хөрмәт белән телгә алам. Белүемчә, ул Татарстанның Мамадыш районында туып үскән кеше.

Галим, нефтьче, профессор Вахитов Гадел Галәветдинович фәндә лаеклы урын тота, ул күп еллар Мәскәүдә нефть буенча Бөтенсоюз фәнни-тикшеренү институтына җитәкчелек итте. Мәскәүдә шулай ук профессорлар А.Әхтәмҗан, Ә.Борһанов, Ш.Мөхәммәдъяров исемнәре дә билгеле. Тагын М.Горький исемендәге әдәбият институты доценты Хантемирова Галия Закировнаны алыйк. Әлеге институтта сәнгатьле тәрҗемә кафедрасын оештыручыларның берсе ул. Аның җентекле эше нәтиҗәсендә Россия укучылары татар классигы Гаяз Исхакый әсәрләрен русча укып таныша алдылар. Мәскәү дәүләт университетында, башка вузларда һәм фәнни учреждениеләрдә татарларның байтак талантлы галимнәре эшли.

**— Юрий Михайлович, Мәскәү татарларының «мәдәни фронтта»гы эшчәнлеге турында да ишетәсе килгән иде...**

— О-о, монысы аерым тема. Бу өлкәдә башкарылган күпсанлы эшләрне берьюлы санап чыгу да мөмкин түгел. Мәскәүдә ел саен иң югары дәрәҗәдә һәм башкаланың бөтен татарлары һәм шулай ук бүтән милләт халыклары катнашында Сабантуй бәйрәмнәре үткәрелә. Әлеге милли бәйрәм гомумшәһәр чаралары исемлегенә кертелгән. Аны үткәрүдә Мәскәү хөкүмәте дә мөмкин булганча ярдәм итә. Шаулап-гөрләп үткән бу бәйрәм киләсе ел Сабантуена кадәр күңелләрдән китми.

Мәскәүдә татарларның вокаль-инструменталь ансамбльләре дә күп,

шактый гына башкаручыларның исемнәре дә билгеле. Чыгыш ясар өчен аларга иң яхшы концерт заллары бирелә. Аларның берсе Татарстанның күренекле җырчысы Илһам Шакиров исемен йөртә.

Шактый гына талантлы яшьләр Мәскәү консерваториясендә, башка музыка уку йортларында белем алалар. Күпләрнең Россиянең атказанган артисты, хәзер Мәскәүдә яшәүче Ренат Ибраһимов концертларына яратып йөрүен беләм.

Мәскәү татарларының мәдәни тормышы турында сөйләгәндә, мин канәгатьләнү хисе белән әйтә алам: бу мәсьәләдә Татарстан Республикасы һәм Мәскәү хөкүмәте арасындагы хезмәттәшлек турында ике яклы килешүнең бер пункты уңышлы рәвештә тормышка ашырыла. Бу юнәлештә зур эшчәнлек алып барган өчен ТР Президенты Минтимер Шәрипович Шәймиевкә тирән рәхмәтемне белдерәм. Мәскәүлеләр алдында даими рәвештә танылган иҗат коллективлары, эстрада осталары, Татарстан сәхнәсе артистлары чыгыш ясый. Алар арасында Илһам Шакиров та, Зилә Сөнгатуллина да, Салават Фәтхетдинов та һәм башка сәнгать осталары да бар. Казан, Чаллы театрлары үз спектакльләре белән гастрольгә килеп тора.

Татарстан Республикасының симфоник оркестры килү Мәскәү өчен һәрвакыт зур вакыйгага әйләнә. Искиткеч яхшы дирижер, профессор Фуат Мансуров җитәкчелегендәге югары профессиональ дәрәҗәдәге бу музыкаль коллективны күрер һәм тыңлар өчен хатыным белән мин дә барабыз. Моннан бер ел-ел ярым элегрәк, П.Чайковский исемендәге залдан мин әлеге гаҗәеп зур талантлы музыкантны һәм симфоник оркестрын оештыручы Фикрәт Әхмәтҗанович Табеевны 70 еллык юбилейлары белән котладым. Чыннан да, симфоник оркестр Татарстан Республикасы таҗының кыйммәтле бриллиантына тиң. Минемчә, күп дәүләтләр андый оркестрга ия булырга теләр иде.

Форсаттан файдаланып, Татарстан Республикасы вәкиллегенә җитәкчелек иткән Мириханов Назиф Мөҗәһитовичның һәм мәдәният, һәм икътисад өлкәсендәге уңышлы эшчәнлеген билгеләп үтәсем килә.

**— Юрий Михайлович, Россиянең теге яки бу регионында компактлы яшәүче татарлар үз газеталарын да чыгаралар. Күп республикаларда һәм өлкәләрдә, мәсәлән, Удмуртия Республикасында, Самара, Ульяновск өлкәләрендә, Санкт-Петербургта чыгучы татар газеталары республика, өлкә һәм шәһәр бюджеты тарафыннан финанслана. Ә сездә ничек?**

— Мәскәүдә хәзер татарлар өчен ике газета чыга. 1993 елның июленнән «Татарские новости» газетасы даими чыгып тора. Аны үзенең фикердәшләре белән бергә Мәскәүнең танылган эшмәкәре Мөслимов Ильяз Булатович оештырды һәм хәзер дә аны финанслый, редакцияли. Минемчә, әйбәт газета. Тенденциоз түгел. Мәскәү татарларының тарихын да, бүгенге тормышын да объектив яктырта.

Күптән түгел «Фатиха» хәйрия фонды оештырган «Ватандашлар» — «Наши соотечественники» газетасы дөнья күрде.

Билгеле инде, Мәскәү татарлары өчен басмалар кирәк. Хәзерге вакытта без алар белән хезмәттәшлек итү формаларын эзлибез. Һичшиксез, сез әйткән регионнарның да тәҗрибәсен истә тотарбыз.

**— Мәскәү хөкүмәтенең дин тотучы татарлар белән үзара мөнәсәбәте ничек? РФ Президентының гыйбадәт йортларын чын хуҗаларына кайтару турындагы Указы тормышка ашырылачакмы?**

— Мөнәсәбәтләр бик әйбәт. Монда башка төрле карашлар була алмый. Татарлар гомер-гомергә чит диннәргә дә түземле мөгамәләдә булды. Без моның кадерен беләбез. Инде 1995 елның маенда ук Мәскәү хөкүмәте мөселман диния идарәсе балансына Выползов тыкрыгы, 7 йортта урнашкан Җәмигъ мәчетен тапшырды, өстәвенә, чирек гектардагы мәйданын 0,71 гектарга җиткереп бирде. Хәзер ул мәчеткә реставрация ясалды. Капиталь ремонт һәм реставрация өчен кирәк булган акчаның шактый өлешен Мәскәү хөкүмәте иганә итте. Мәчет үзәк җылыту системасына кушылган. Янәшәсендә төзелгән өч катлы бинада югары мөселман көллияте һәм мәдрәсә урнашкан.

Мәскәүлеләр шәһәрнең тарихи сәхифәләрен яхшы хәтерли. Билгеле булганча, 1555 — 1565 елларда барган Ливон сугышларында руслар белән беррәттән, татар отрядлары да сугышкан. 1812 елгы Ватан сугышында батырлык күрсәткән татар полклары хөрмәтенә Мәскәүдә Тарихи мәчет төзелгән, ул бүгенге көндә дә эшли.

1941 — 1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар истәлегенә башкаланың Поклонный тавында православие чиркәве һәм синагога белән рәттән мәчет тә төзелде. Мәскәүнең бу районы, һичшиксез, мәскәүлеләр өчен генә түгел, элеккеге Советлар Союзы кешеләренең барысы өчен дә изге урын санала.

Отрадное районында эшмәкәр Рәшит Баязитов Мәскәү хөкүмәтенең турыдан-туры ярдәме белән тулы бер дини-мәдәни үзәк, шул исәптән, мәчет тә торгызып куйды. Без Мәскәү мөселманнарының изге эшләрен киләчәктә дә хуплаячакбыз һәм булдыра алганча ярдәм итәчәкбез.

**— Юрий Михайлович, 1913 елда Мәскәү үзәгендә халыктан җыелган акчага һәм шулай ук миллионер Әсәдуллаев хисабыннан «Татар мәдәни үзәге» төзелгән була. Большевиклар әлеге биналар комплексын тартып алганнар. Бөек Ватан сугышы елларында аларның госпиталь итеп файдаланылуын аңларга була. Әмма хәзер бит ул биналар МИД балансында калып... стенография курслары өчен хезмәт итә. Мондый хәлне мин Мәскәү татарлары истәлеген мыскыл итү дип саныйм. Әсәдуллаев йорты кайчан үзенең чын хуҗаларына, ягъни Мәскәү милли-мәдәни автономиясенә кире кайтарылыр?**

— Мин сезнең фикерегезгә кушылам. Эш шунда, әлеге комплекс Россия Федерациясе Президенты администрациясе эшләре идарәсенә карый, ягъни федераль милек булып хисаплана. Без бу мәсьәлә белән шөгыльләнәбез. Аны юридик яктан Мәскәү хөкүмәте милке итеп күчерсәк, нинди дә булса формада татар милли-мәдәни автономиясенә тапшыру ягын карар идек.

**— Сезнең командада, округ, префектура җитәкчеләре арасында татарлар күпме?**

— Милли билгеләнеш буенча статистикабыз юк. Барлык хезмәткәрләрне дә эшлеклелек сыйфатына, профессиональ әзерлегенә карап сайлыйбыз. Әмма шуны да әйтә алам: хөкүмәтнең үзендә дә, түбәнрәк

баскычларда да татарлар күп. Байтак вакыт минем урынбасарым булып та сезнең милләтнең бик әйбәт бер вәкиле эшләде. Татарлар эшкә җаваплы карый торган төгәл һәм намуслы кешеләр дияр идем. Алар белән эшләве җиңел. Мин аларга ышанам. Дусларым арасында да татарлар күп. Гомумән алганда, мин үзем начар халыклар булмый, начар кешеләр генә очрый, дигән принципта торам.

**— Юрий Михайлович, 1941 елга кадәр Мәскәүдә берничә татар мәктәбе эшләгән. Әле бу Мәскәү татарларының чагыштырмача аз булган чагында. Бүген исә бер генә милли мәктәп тә юк.**

— Әйе, чынбарлык шундыйрак. Соңгы елларда вазгыять бераз үзгәрде. Башкалада тулысынча татарча тәрбияләүгә корылган балалар бакчасы бар. Ике урта мәктәптә татар теленнән факультатив дәресләр кертелде. Мәскәү хөкүмәте киләчәктә дә балаларны туган телләрендә укытуга зур игътибар бирәчәк. Монда күбесе әти-әниләрнең ментальлегеннән һәм активлыгыннан тора, билгеле. Балаларын алар кайсы мәктәптә нинди телдә укытырга тели. Телләр турындагы законда да укыту телен ата-аналар сайлый диелгән бит.

Бу урында Татарстанның безгә һәрвакыт методик әсбаблар, дәреслекләр белән ярдәм итүен һәм киләчәктә дә ярдәм итәргә әзер булуын әйтеп узарга кирәктер. Монысы инде яхшы фал.

**— Юрий Михайлович, Мәскәү күптән түгел үзенең 850 еллыгын билгеләп үтте. Озакламый Казан да үзенең бөек юбилеен — меңьеллыгын бәйрәм итәчәк. Казан Мәскәүдән өлкәнрәк яшьтә булып чыга.**

— Бик шәп! Казанның юбилее, Мәскәү юбилее кебек үк, бөтен Россия бәйрәме. Мондый бәйрәмнәр бик кирәк. Беренчедән, хакыйкатьне билгеләп, ачыклап үтү өчен. Икенчедән, мондый юбилейлар үзеңне бөтен ил белән бергә итеп тоярга булыша. Без Казан, Татарстан кешеләре өчен сөенәбез. Мәскәүлеләр дә бәйрәм чараларында катнашыр, юбилейга әзерләнергә булышыр.

**— Сез беләсез инде, Татарстанда күптән түгел Президент сайлаулары булып узды...**

— Мин чын күңелдән күптәнге ышанычлы дустым Минтимер Шәрипович Шәймиевне өченче срокка сайлануы белән котлыйм. Ул — булдыклы җитәкче, аның потенциалы Россиядә тулысынча файдаланылмаган әле. М.Ш.Шәймиев җитәкчелегендә Татарстанда барган үзгәрешләр миндә хәтта көнләшү тойгылары уята. Ак көнләшү тойгылары. Мин һәрвакыт аңардан өйрәнергә тырышам.

**— Ниһаять, соңгы сорау, Юрий Михайлович. Әңгәмәбез башында Мәскәү үсә дигән идегез. Әйтегез әле, Мәскәү бай шәһәрме?**

— Бик бай. Әгәр дә Мәскәү бай булмаса, ярлы булса, Россиянең берләштерелгән бюджетына барлык акчаларның кырык процентын кертә алмас иде. Булдыра алмас иде! Ә бит булдыра. Мәскәү байлыкны читтән туплау белән шөгыльләнми, ул аны эшләп ала. Мәскәү эшли, хезмәт итә. Бездә эшсезлек юк диярлек. Мәскәү бүген, бөтен икътисадын үзгәртеп корып, үз хезмәтенең нәтиҗәсен күрә. Әңгәмәбез үзәген тәшкил иткән теманы төгәлләп, шуны да белдерәм: башкала байлыгына Мәскәү татарлары үзләренең лаеклы өлешен кертә.

# Явызлык империясе яки империянең явызлыгы

## Нәрсә ул «ислам фундаментализмы»? Россиядә «ислам фанатизмы» күзәтеләме?

### ФУНДАМЕНТ ҺӘРНӘРСӘГӘ НИГЕЗ...

Соңгы унъеллыкта элеккеге Советлар Союзы территориясендә «ислам фундаментализмы», «ислам фанатизмы» дигән яңа терминнар барлыкка килде, ә Россиянең үзәк гаммәви мәгълүмат чаралары бу хакта бер-берсеннән уздырып сөйләп, илнең мөселман булмаган халкын төрлечә куркыта башладылар, янәсе Россиягә яңа «афәт» килә.

Чынлап та, бу терминнар нәрсәне аңлата һәм алар артында нәрсә булса да яшеренеп ятамы соң? Бу хакта миңа еш кына борчылып сораулар бирәләр, аңлатуымны сорыйлар.

Әлеге терминнар чагыштырмача күптән түгел генә, Россиядә большевиклар идеологиясе белән бергә барлыкка килделәр. Ә исламда бу терминнар, гомумән, юк. Чөнки Мөхәммәт пәйгамбәр болай дигән: «Ислам — һәртөрле вакытка, урынга һәм җәмгыятькә туры килә». Ниндидер өченче җенес кешеләре була алмаган кебек үк, бер раса башка расалардан өстен була алмый. Мөселман фанатикларча бер расаны яклап, икенчесен кимсетергә яки бер милләтне күтәреп, икенчесен кимсетергә тиеш түгел.

Хәзер мәсьәләне кабыргасы белән куеп, җентекләп тикшерергә тырышып карыйк.

### БЕРЕНЧЕДӘН, НӘРСӘ СОҢ УЛ — ФУНДАМЕНТАЛИЗМ?

Бу сорауга гадәти халәттә караган очракта, биредә бер дә гаҗәпләнерлек урын юк. Фундамент — һәр дингә хас нәрсәнең нигезе. Фундаментализм — һәр идеология, һәр дингә хас нәрсә. Ачыктан-ачык әйтсәк, аның элементларын ислам, христиан, иудаизм, буддизм һ.б. диннәрдә дә очратырга мөмкин.

Безнең карашка, диндә фундаментализм билгеләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1. Мөмкин кадәр күбрәк халыкның күңелен яулап алу.
2. Тирән теологик нигез булу.
3. Дәүләт, йә булмаса, янәшәдәге конфессияләрдән өстенлеккә ирешү.
4. Дини кануннарны төгәл үтәү.
5. Башка динне тотучыларны да бу эшкә этәрү.
6. Икенче бер конфессияләр эшчәнлеген (әгәр алар халык арасында ихтирам казанганнар икән) ничек булса да чикләү.

Дини фундаментализм бернинди җәмгыятькә дә куркыныч тудырмый. Шул исәптән, ислам фундаментализмы да. Бу бары тик большевиклар тарафыннан гына уйлап чыгарылган чираттагы ялган гына, аны исә хәзер төрле необольшевиклар, неонацистлар, державачылар һ.б. бик оста файдаланалар. Элек рус авылларында кечкенә балаларны: «әнә татар килә», — дип куркытканнар бит әле (бу очракта шагыйрә Марина Цветаева барыннан да уздырып җибәрә, мәгълүм шигырендә ул: «Псу татарину отдам...» — ди), шуның шикелле мәгънәсез, урынсыз, хаксыз бер нәрсә генә.

Күргәнебезчә, фундамент — яхшы нәрсә, әгәр ул ныклы нигез игелекле, көчле куллар тарафыннан куелса, әлбәттә. Әгәр инде нигезең нык түгел икән, көл-туфракка әйләнүең дә бар.

Хәзер мәсьәләнең икенче яртысын — ислам фанатизмын карыйк. Ул җәмгыятькә куркыныч микән?

## ҺӘРТӨРЛЕ ФАНАТИЗМ ДА КУРКЫНЫЧ

Тарихтан белгәнебезчә, диндә генә түгел, һәртөрле идеологиядәге фанатизм зур җимергеч көчкә ия. Фундаментализмның фанатизмга әверелүе аеруча куркыныч. Хәзерге вакытта «фанатизм» түбәндәгечә аңлатыла.

1. Халыкка динне догма итеп көчләп тагу.
2. Җәмәгать тормышына тәэсир итү өчен көч кулланып көрәшү.
3. Башка конфессияләрне көч кулланып читкә этәрү.
4. Дини кануннарга сукырларча табыну.
5. Дини кануннарны халык арасында тарату өчен яшерен яки ярым яшерен структуралар булдыру.

Кызганычка каршы, һәр диндә дә агрессив агымнар бар. Бу ямьсез күренешне исламга гына ябыштырып калдыру бик зур гаделсезлек, әлбәттә. Хәер, бу Россия җәмгыятенең дин нигезләрен (шул исәптән ислам динен дә) тиешле дәрәҗәдә белмәвеннән килеп чыга.

## АЛЛАСЫЗЛЫККА ЮЛ

Танылган рус галимнәре, Шәрык, ислам дине белгечләре — профессор Г.С.Саблуков, академик И.Ю.Крачковский, Коръән тәрҗемәчеләре М.И.Веревкин, Д.Н.Богуславский ислам фанатизмы хакында беркайчан да язганнары да, сөйләгәннәре дә булмады. Коръәнне русчага тәрҗемә иткән замандашыбыз Валерия Михайловна Порохова белән дә шул хәл.

Гомумән, исламда фанатикларга урын юк. Мөхәммәт пәйгамбәр болай дигән: «Безнең арадан берәү дә фанатизмга чакырмый, фанатизм өчен көрәшми, фанатизм өчен үлми».

Мөхәммәт пәйгамбәрдән берәү: «Фанатизм нәрсә ул?» — дип сораган, ди. Пәйгамбәр: «Халкыңны гаделсезлеккә вә залимлек-тиранлыкка китергән нәрсә ул»,— дигән. Коръәндә болай диелгән: «Әгәр мөселман дини вә милли фанатизмга чакыра икән, бу наданлыкка вә Аллаһысызлыкка илтә, ә ислам, Аллаһ илчесе һәм аның китабы моннан котылырга чакыра».

## ЯҢАРЫШНЫҢ ДА ТӨРЛЕСЕ БУЛА

Россиядә җимерелгән, таланган чиркәүләрне, мәчетләрне төзекләндерү, яңарту эшләре киң колач белән бара. Яңалары да салына.

Мәсәлән, Казан, Уфа тирәсендәге мөселман авыллары барысы да яңа мәчетле булып беттеләр бугай инде.

Әмма эш никадәр генә игелекле булмасын, анда чама хисе булырга тиеш. Мәскәүдә христиан (православие) диненең иң зур храмы — Коткаручы Христос храмы корылды, моңа барыбыз да шаһит. Хуш, шәп, игелекле эш! Әмма... мөселманнар мәчет корырга уйласалар, төзелешне иганә акчасына кергән тиеннәрдән башлап җибәрәләр. Ә бу храмны Россиянең салым түләүчеләреннән кергән акчага (ягъни мөселманнардан да) кордылар. Менә шул. Бер яктан игелекле, икенче яктан гөнаһын җыеп бетергесез. Бу инде исламның түгел, ә православиенең кычкырып торган фанатизмы.

1996 елның 28 мартында әлеге храмның иң зур тәресен беркеттеләр. Тәренең биеклеге — 10, киңлеге — 6, авырлыгы — 3100 килограмм. Ул иң чиста бронзадан коелган. Тәрене тышлау өчен югары сыйфатлы 5 килограмм алтын сарыф ителгән.

Ярар, илнең иң зур храмы булгач, зиннәтле дә булсын, ди. Әмма безне, мөселманнарны иң хурландырганы, кимсеткәне шул — әлеге тәре астындагы ярымай. Имеш, Россиядә исламны бар дип тә белмиләр, имеш ислам руслар тарафыннан буйсындырылган дин. Кабатлап әйтәм, менә бу, чын мәгънәсендә, фанатизм инде.

## ЧУКЫНДЫРЫП БЕТЕРЕРЛӘР ИДЕ. ӘГӘР ХӘЛЛӘРЕННӘН КИЛСӘ...

Хәзер гомумбелем мәктәпләрендә яңа предмет — «Урок Божий» дигән бер нәрсә кертә башладылар. Армиягә, төрмәләргә христиан руханилары штатларын кертү, анда чиркәүләр, гыйбадәт кылу урыннары булдыру хакында да сүзләр куера. Әйе, бер караганда искитәрлек нәрсә дә юк кебек. Тик сорау туа: башка диндәгеләр ни эшләргә тиешләр? Христиан диненә күчсеннәрме? Ә Россия Федерациясе полиэтник, поликонфессиональ дәүләт бит.

Париж, Лондон, Нью-Йорк, Дейтрот кебек дөньяның зур калаларында төрле агымдагы христиан гыйбадәтханәләре белән берлектә, мәчетләр дә эшли. Бу илләрдәге мәктәпләрдә дә балалар үзләре теләгән телдә белем алалар. Хәтта ерак Австралиянең Аделаида шәһәрендә яшәүче аз санлы татарлар да ана телләрендә мәктәп ачып, шунда балаларын укыталар.

Ә бездә... Телевизор кабыздың — чукындыралар, балалар бакчасына барсаң — чукындыралар, мәктәптә — чукындыралар, армиядә — чукындыралар, хәтта төрмәгә эләксәң дә (Аллам сакласын) чукындыралар.

Шуның өчен дә безгә, ислам дине тарафдарларына, аеруча Татарстаннан читтә яшәүче татарларга, балаларга милли тәрбияне алар үзүзләрен аңлый башлагач ук бирергә кирәк. Татарлар яшәгән һәр

төбәктә туган телне, ислам дине нигезләрен өйрәтү буенча һәр төрле группалар, курсларның эшләве зарур.

Россиядә православиедән башка диннәрне дәүләт сәясәте дә санга сукмый. Дәүләт бүләкләрен генә алыйк. Илдәге орден-медальләрнең барысы да дип әйтерлек тәре рәвешендә. Кыскасы, яхшылык, батырлык эшләгән мөселман — хөкүмәт тарафыннан тәре ала. Мин моны кешенең намусыннан көлү, мәсхәрәләү, дип аңлыйм. Андый бүләк тәрене түшемә тагып та йөрмәс идем. Ә сез?

Россия Федерациясе армиясе сафларында хезмәт итүче хәрбиләрнең киемнәренә игътибар итегез әле: аларның мундирлары җиңенә «Россия» дип чигелгән. Бу ил Конституциясенә каршы килә түгелме соң? Төп закон буенча Россия дигән ил юк. Әгәр бар икән — ул Татарстан, Башкортстан кебек Россия Федерациясенең субъекты булырга тиеш. Кабатлап әйтәм, ә андый субъект юк. Хәер, без икенче темага кереп барабыз бугай...

Кыскасы, Россиядә ислам беркайчан да агрессив булмады, һәм бу илдә беркайчан да ислам фанатизмы күзәтелмәде. Ил тарихында ислам дине әһелләренең башка дин тотучыларны мәҗбүриләп үз диннәренә күчерү очрагы да булмады. Ә менә православие руханиларның татар халкын мәҗбүриләп чукындырып йөрүләре халкымның йөрәген һаман да әрнетеп тора әле. Чөнки бу ерткычлыкны, залимлыкны, вәхшилекне һич тә онытырга мөмкин түгел. Ә Россиядә исә дәүләт күләмендә халыкны ислам фанатизмы белән куркыталар. Кызык та, кызганыч та...

## МИЛЛИ ИДЕЯ ХАКЫНДА

Шахрай, Солженицын, Шафаревич кебек державачылар «яңа» Россиягә яңа милли идеяләр кирәклеге хакында берөзлексез тәкрарлыйлар. Бу аңлашыла да. Чөнки демократик үзгәртеп корулар чорында чит җирләрне басып алу нигезендә корылган Россиянең элекке милли идеясе халыкара җәмәгатьчелек алдында үзенең асылын югалтты. Шуның өчен дә хәзер илнең «демократия» аталары яңа, үзләренә кулай идея чыгару белән мәшгуль. Ә бу идея иске күлмәкне ямаулыклар белән ямап яңартылган шикелле булачак инде. Һаман шул «бөек рус халкы», аның мәнфәгате, ә Россиядә яшәүче дистәләрчә башка халыклар интересын яклап кыл да кыймылдатмаячак. Үрнәккә АКШны, йә булмаса Швейцарияне алсалар иде дә бит, юк шул, «өлкән туганыбызның» иреге «кысылачак».

Күптән түгел Президент ярдәмчеләре Президентның барлык россиялеләрне берләштерүче «яңа рус идеясе» төзергә исәбе барлыгын белдерделәр. Ә ни өчен «рус идеясе»? Ә нигә, әйтик, чукча, мари, удмурт «идеясе» түгел?

Моннан утыз еллар элек академик Александр Павлович Виноградов: «Һәр милләттә дә хөрмәт ителә торган кешеләр булырга тиеш», — дигән иде. Әлеге очракта, синең каның нинди, нинди дин тотканың исәпкә алынмый. Сәләтең, талантың ничек — кешенең кеше булуын менә нәрсә хәл итә.

## СЛАВЯННАР ТУГАНЛЫГЫ НӘРСӘ УЛ?

Бөек Карл Рим империясе төзегәч тә, аның гражданнары христиан-католиклар булырга тиеш, дип боера. Чукынырга теләмәүчеләрне юк итәләр. Россия тарихында мондый хәлләр бихисап: татарларны чукындыру конторалары, илдәге барлык халыкларны да совет халкына әйләндерү...

Хәзер исә «Славян халыклары Берлекләрен» төзү модага кереп китте. Барлык галәмәви мәгълүмат чаралары да «славяннар туганлыгын» ниндидер мифик дошманга каршы торырга өнди. Сүз Россия, Белоруссия һәм Украинаның бер Союзга берләшергә кирәклеге турында бара. Имеш, бу славян халыклары тарихи яктан бер-берсенә шулкадәр беректәннәр икән, аларны төрле бәла-казалардан берләшү генә коткарып калачак. Тагын гаҗәп хәл. Әйткәнемчә, Россия Федерациясендә руслардан тыш тагын дистәләгән милләтләр яши. Россия җитәкчелегенең моны күрергә теләмәве, аларның башка халыкларга карата шовинистик караштa торуларыннан килеп чыга. Ярар, славяннар берләшсеннәр, ди. Ә безгә, әйтик, татарларга, башкортларга Пакистан, йә Төркия, ә калмыкларга, бурятларга Монголия белән берләшергәме?

Хәзер элеккеге СССРның Көнчыгыш Европадагы союзниклары, Балтыйк буендагы элеккеге союздаш республикалар тешләре-тырнаклары белән НАТОга керергә омтылалар. Юкка түгел, авызлары бик каты пеште шул аларның. Яңадан рус аюы тырнагына эләгәсе килми шул.

## ТАРИХ ДӘРЕСЛӘРЕ

Совет заманында тарих дәреслекләре «татар-монгол» басып алучыларының кылган «явызлыклары» белән тулган иде, хәер, моны һәркайсыбыз хәтерли торгандыр. Шул уңайдан минем дә искә алтмышынчы елларда булган бер вакыйга килеп төште. Ул чагында мин, яшь эшче, Сарапулдагы кичке мәктәпләрнең берсендә 8 нче класста укый идем. Тарих дәресе бара. Тема — «Рус җирләрендә монгол-татарларның ерткычлыклары». Класстагы 30 укучының өчесе генә татар. Шулчак укытучыбыз Николай Николаевич дәресне миннән сорамасынмы:

— Шәфыйков хәзер безгә татарларның ничек итеп рус гыйбадәтханәләрен җимереп-ватып йөрүләре хакында сөйләр.

Укытучы «монгол» сүзен ни өчендер төшереп калдырды. Теманы яхшы белә идем мин, ә менә сөйләргә телем әйләнми, башым әллә нишләп китте, күз алларым караңгыланды. Тарихчы тагын сорауны кабатлады, мин исә һаман да дәшмим.

Укытучым аптырагач:

— Шәфыйков, син материалны яхшы беләсең бит, әйдә сөйлә,— дип тә карый. Шулчак, кискен карарга килеп, класстан ук йөгереп чыгып киттем...

Бу мәктәпкә мин башка килмәдем инде, озак та үтмәстән армиягә дә китеп бардым.

Урта мәктәпне мин армиядән кайткач кына, 26 яшьтә яхшы билгеләренә тәмамладым. Тарихтан аттестатта «бишле» билгесе иде.

Мин укытучыма шактый вакыт рәнҗеп йөрсәм дә, соңыннан аның гаепсез икәнлеген аңладым. Төп гаеп совет дәреслегендә икән ләбаса.

Россия халкы дөнья күләмендә иң күп укучы халык булса да, наданлыгы, чикләнгәнлеге ягыннан дөньяда мөгаен иң алдынгы урыннарның берсендәдер. Иң мөһиме, без үзебезне, үз тарихыбызны, шәҗәрәбезне белмибез. Н.Карамзинның «История Государства Российского», Л.Гумилевның «Древняя Русь и Великая степь», М.Каратеевның «Русь и Орда», Г.Федоров-Давыдовның «Общественный строй Золотой Орды» кебек акыллы китапларын, кызганыч, күбебезнең кулына да тотып караганы юк. Әле мин рус авторларын гына санап чыктым, руста да төрле кешеләр булуын искәртү өчен.

Кайчандыр Идел тамагында Алтын Урданың башкаласы — данлы Сарай булган. Биредә мөселман мәчет-мәдрәсәләре янына ук башка дин гыйбадәтханәләре дә салынган һәм моңа берәү дә гаҗәпләнмәгән. Бабаларыбызның күңелләре киң булган анысы, Аллага шөкер! Башкаларның да шулай булсачы...

## СОЛДАТ БУЛЫП ТУМЫЙЛАР

Большевиклар Рус-Кавказ сугышы 400 ел дәвамында түгел, ә «нибары 100 генә ел» дәвам итте дип безне һәрчак алдап килделәр.

Кавказда тагын кан коела. Чираттагы рус-чәчән сугышы Россиядәге барлык халыклар өчен дә афәт булды. Күпләр бу низагны ике дин — христиан һәм ислам сугышы дип атыйлар. Кыскасы, бу үтә дә четерекле, катлаулы мәсьәлә.

Соңгы вакытларда Үзәк телевидениедән әлеге сугышта һәлак булучыларның исемлеген игълан итәләр. Кайгы исемлегендә мөселман фамилияләре дә очрый. Бу бик коточкыч хәл. Димәк, ислам динен тотучы чәчән егете диндәше татар яки башкорт егетен үтерәчәк.Ниләр генә булмый бу дөньяда.

Соңгы елларда Төньяк Кавказда бик еш булганлыктан, мин чәчән сугышы корбаннары төялгән махсус составларны күп күрдем. Шул уңайдан бер коточкыч хәл турында сөйләмичә булдыра алмыйм. Ростов-Доннан 60 километрлап көньяктарак Кушевская дигән бик матур станица бар. Сугыш башлангач та, әлеге станицадан ерак түгел, җимерелгән сугыш техникасын төзекләндерү цехы ачылды. Башта халык бик куанды, эшсез йөреп булмый бит, гаилә бар, ашыйсы килә. Димәк, яңа эш урыннары булачак. Әмма шатлык озакка бармады. Чәчәнстаннан җимерелгән, яндырылган техника белән солдатларның өзелгән куллары, аяклары, йә булмаса янган гәүдәләре дә кайта башлады. Цех тирәсе үлек белән тулды. Акча эшләргә теләгән ир-егетләр бу хәлгә түзә алмыйча цехтан берәм-берәм качып беттеләр...

Хәзер икенче вакыйга. Ростов өлкәсенең Волгодонск шәһәрендә мин бер укытучы гаиләсен беләм. Шуларның бердәнбер уллары чәчән сугышында хәбәрсез югалды.

Егетнең әнисе, бу хәбәргә ышанырга теләмичә, улын үзе эзләргә булды. Ростовка килеп, сугыш корбаннары төялгән поезд составларындагы һәр вагонны җентекләп карап чыкты. Әмма улының гәүдәсен тапмады. Кайткач, бер хәл исенә төшә. Егеткә армиягә китәр алдыннан дәү әнисе арка җылыткыч бәйләп биргән була. Җылыткычка җеп җитеп бетми, әби аптырап тормый, икенче төрле җеп белән бәйләп бетерә.

Ана кеше яңадан Ростовка китә һәм шушы арка җылыткыч ярдәмендә улының ярым әчелгән гәүдәсен туган җирләренә алып кайтып җирли. Яңа гына 40 яшьләрен тутырган ата белән ана хәзер дөньяга битараф, чәчләре чалланган карт-карчык кыяфәтенә керделәр. Беркемгә кирәкмәгән сугышның нәтиҗәләре менә шундый.

Хәзер хәрби училищеларда курсантларны ниндидер билгесез мөселман дәүләтен дошман күрү рәвешендә тәрбиялиләр икән. Бу хакта миңа чәчән сугышы утыннан чыккан офицерлар сөйләгәннәр иде. Хәер, каян да булса, дошман образын эзләп табу һәр империягә хас нәрсә инде, аеруча империянең таркалу чорында. Әлеге мисал моны бик ачык раслый.

## И АЛЛАМ! ҖҮЛӘР ПАТША ҖИБӘРӘ КҮРМӘ...

Мәскәү, Ростов өлкәсе, Краснодар крае, Адыгей, Удмуртиядә һәм Татарстанда яшәүче милләттәшләрем миңа еш кына үзләрен борчыган сорауны, руслар белән татарлар арасында низаг булмас микән, дип сорыйлар да, аннары үзләре үк, булмаска тиеш, дип җавап бирәләр. Хәер, мин үзем дә шулай уйлыйм.

Россия — Азия һәм Европа киңлекләренә урнашкан һәм ике дин — христиан (православие) һәм ислам таралган ил. Әгәр дә инде телевизордан нинди дә булса мәгълүм сәясәтче, язучы: «Россия — православие иле. Безне бары тик христиан дине генә коткара»,— дип нотык сыман граммофон тәлинкәсе кебек һаман бер сүзне тәкрарлый икән, бу инде ахмаклык.

Гасырлар буе бергә яшәгән рус һәм татар халыкларын бер-берсенә каршы кую инде мөмкин булмаган нәрсәдер, аларның тормыш, яшәү рәвешләре шулкадәр үрелгән ки, аларны һич аерып булмастыр. Моны белә торып русның танылган кешеләре А.Солженицын, И.Шафаревич һаман да Россияне исламлаштыру куркынычы яный, дип армый-талмый кабатлыйлар. Шулай итеп, православныйларны мөселманнарга каршы астыртын гына котырталар.

Кабатлап әйтәм, ислам фанатизмы Россия Федерациясендә яшәүче татарларга хас нәрсә түгел. Агрессивлыкны, гомумән, татарлар үзләре дә яратмыйлар. Кыскасы, Россиядә ислам фанатизмын мин караңгы бүлмәдә кара мәчене эзләү белән чагыштырыр идем.

«Каракның бүреге яна» дигән бик тапкыр әйтем бар. Дөньяны бутаучыларның үз бүрекләре төтенләми микән?

# Соңгы сүз урынына

## БЕР МОГҖИЗА БЕЛӘМ МИН...

*(Автор белән әңгәмә)*

Минем фикеремчә, язучы һәм публицист Ягъсуф Шәфыйков әдәбият сөючеләр белән махсус таныштыруга мохтаҗ түгел. Аның исемен күпләр белә. Ягъсуф Шәфыйковның җәмгыятебезнең үткәнен һәм бүгенгесен анализлап язган документаль очерклары, хикәяләре, публицистик мәкаләләре, повестьлары матбугатта еш чыга. Китаплары даими рәвештә республика нәшриятларында бастырыла. Ул «Татарстан» журналының иң актив авторларының берсе, редколлегия әгъзасы.

Ягъсуф Шәфыйков милләт тарихы, аның рухи һәм мәдәни тормышы белән күптән кызыксына. Аның рус телендә язылган «Я знаю одно чудо...» исемле китабы республика җәмәгатьчелек тормышында зур яңалык булды. Мөселманнарның изге китабы Коръән турындагы бу китапта автор Коръәннең борынгы Болгарга, соңрак Россия территориясенә үтеп керүе, аның русчага тәрҗемәләре һәм тәрҗемәчеләре турында яза. Бу — Коръән Россиягә килеп кергән чордан алып, бүгенге көнгә кадәр булган вакыйга-хәлләр турында фәнни тикшеренүгә нигезләнеп язылган беренче публицистик хезмәт. Бу китапны Коръәнгә үзенә күрә бер юл күрсәткеч дип атарга да мөмкин.

Шушы көннәрдә «Я знаю одно чудо...» китабының татарчасы «Идел-Пресс» нәшриятында дөнья күрде. Ул «Бер могҗиза беләм мин...» дип атала.

Бу китап турында тулырак мәгълүмат алу максатыннан без Ягъсуф әфәнде Шәфыйковның үзенә мөрәҗәгать иттек.

**— Китапның исеме бик тә нәфис, матур яңгырый — «Я знаю одно чудо...», үземчә тәрҗемә итеп тә карадым әле мин аны.— «Бер могҗиза беләм мин...» Ни өчен җыентыкны шулай атадыгыз?**

— Бу «могҗизалы» исемнең «тудыручысы» мин түгел. Кайчандыр Мөхәммәт Пәйгамбәрдән үзе кылган могҗизалы эшләрне аңлатуын сорагач, ул болай дип җавап биргән: «Мин могҗизалар ясамыйм. Дөньяда мин белгән бары тик бер генә могҗиза бар. Ул — Коръән». Чынлап та, Коръән китабы — безгә күктән иңдерелгән зур һәм кабатланмас гаҗәеп могҗиза бит ул!

**— Ягъсуф әфәнде, ни өчен шундый китап нәшер итәргә уйладыгыз?**

— Катлаулы сорау бу: авыр да, җиңел дә. Изге Китап һәрбер мөселманның күңелендә яши инде ул. Тик эш башкада: безнең һәркайсыбыз Коръәнне белем дәрәҗәсенә, теләк-омтылышына карап үзләштерә.

Безнең өйдә (Актаныш районы, түбән Карач авылы) Коръән һәрвакыт лаеклы урында — түрдәге киштәдә сакланды. Авылдашларым барысы да диярлек бу Изге Китапны кадерләп тоттылар. Ул вакытларда безнең әниләр өйдә генә бәби тапканлыктан, барлык балалар да Коръәннең яклаучы «канаты» астында туган булып чыгалар.

Соңрак, авылда тормыш авырлашкач (әтине «халык дошманы» ясап, төрмәгә ябалар), безнең гаилә Удмуртия шәһәре Сарапулга күчеп китә. Ул вакытта да әни Изге Китапны онытмый: Коръәнне, иң кыйммәтле байлыгы буларак, үзе белән ала. Кызганычка каршы, большевиклар идарә иткән заманда, без телебезне, тарихыбызны югалттык, алфавитыбызны гына да ничә мәртәбә алыштырдылар. Коръәнне төп нөсхәсендә укый алмавыбыз — шулар нәтиҗәсе. Ләкин күпме генә динебездән, телебездән яздырырга тырышып карасалар да, Коръәннең күп кенә сүзләрен без яттан белә идек. Әбекәйләр, әниләр артыннан кабатлап, җанга сеңдереп үстек.

80 нче еллар азагында Коръәннең русча, соңрак татарча басмалары күренә башлагач, мин шифалы суга сусаган кеше шикелле, Изге Китапка кагылышлы бик күп авторларның тәрҗемәләрен, аңлатмаларын йотлыгып укырга керештем. Хәзерге вакытта шәхси китапханәмдә Коръәннең ярты йөз басмасы һәм русча тәрҗемәләре саклана. Дөрес, татарчалары әлегә күп түгел, шулай да миндә үзенчәлекле басмалар җитәрлек.

Ни өчен Коръән турында язарга уйладыммы? Мөгаен, бу уйга мине аның тәрҗемә авторлары этәргәндер. Аларның бик күпләре белән мин очрашып таныштым, сөйләштем, аралаштым һәм шул фикер алышулардан соң күңелем әйтеп бетергесез зур шатлык белән тулды. Хисләремне башкаларга да белдерәсем килде. Көнетөне, кәгазьдән аерылмыйча диярлек, яздым, иҗат иттем. Кемдер миңа «өстән» әйтеп, өйрәтеп торган шикелле тоелды. Әйтерсең Аллаһы Тәгалә үзе шулай кушкан.

**— Кайсы авторларның тәрҗемәләрен иң уңышлы хезмәт дип саныйсыз?**

— Беренче чиратта шуны әйтергә кирәк: Коръәннең төп нөсхәсе —Мөхәммәд Пәйгамбәргә Аллаһ тарафыннан күктән иңдерелгән, гарәп хәрефләре белән язылганы, хәзерге вакытта Мәккәдә нәшер ителә торган Коръән китаплары төп нөсхәдән күчереп басыла. Аларны «Тәҗвид»нең аерым кагыйдәләре буенча укырга кирәк. Ә башкаларын исә, мин ясалма, ягъни — тәрҗемәләре, тәфсирләре дип кенә кабул итәм. Дөрес, алары да зур игътибарга лаек. Чөнки күп кеше Коръәнне тәрҗемәләр аша танып-белә, нәкъ шул тәрҗемә-тәфсирләрдән. Соңыннан исә, чын мөселман кешесендә Изге Китапны төп нөсхәсендә өйрәнү теләге туа. Шулай итеп, Коръәннең тәрҗемәләренә ничек кенә бәя бирсәк тә, аларның дөньяны танып-белүдә әһәмиятләре чиксез һәм Бөек Иҗатчыга —Аллаһы Тәгаләгә якынаюда юл күрсәтүче якты маякка хаклы рәвештә тиңләргә мөмкин.

Башта мин Коръәннең русчага тәрҗемәсен танылган галим Игнатий Юлианович Крачковскийдан укып белдем. Соңрак Гордий Семенович Саблуков һәм Дмитрий Николаевич Богуславский хезмәтләре белән танышырга туры килде. Ә Коръәнне бүгенге көндә тәрҗемә кылган Валерия Михайловна Порохова һәм аның ире Мөхәммәт Сәит Әл Рошд белән якын дусларга әвереелдек. Валерия Порохова тәрҗемәсе шигъри телдә язылуы белән киң җәмәгатьчелекне үзенә җәлеп итте. Аллаһ тарафыннан җир йөзенә иңдерелгән Изге Китабыбыз Коръән дә ак шигырь рәвешендә иҗат ителгән бит...

**— Сез ничек уйлыйсыз, Библия (Тәурат) белән Коръән арасында берәр уртаклык бармы, яисә, аларның аермалары нидә?**

— Коръән ул — мөстәкыйль яши. Изге Китап. Ул Библия шикелле үк, Аллаһ тарафыннан иңдерелеп, рухландырылып кына калмаган, ә бәлки мөселманнар өчен Аның туры сөйләме һәм Ул әйткән олуг сүзләр дә булып тора! Аллаһы Тәгаләнең Мөхәммәд Пәйгамбәр белән бәйләнеше гаять катлаулы, ул исламда бик әһәмиятле күренеш. Мөхәммәд Коръәнне үзе уйлап чыгармаган, әмма җаны-тәне белән андагы уй-ниятләрне, фикерләрне, хисләрне тойган. Шуңа күрә дә Пәйгамбәр бүгенге көнгәчә исламның бөек рухи кыйммәте, мирасы булып санала.

Библия белән Коръәннең охшашлыгы шунда, алар икесе дә тарихи вакыйгаларны чагылдыра. Бу — Кешенең, Галәмнең барлыкка килүе, Адәм белән Һаваның беренче кылган гөнаһы, Ибраһимның миссиясе (Авраам), Мисыр фиргавеннәре династиясе, яһүдләрнең Мисырдагы Ханаан җиренә килеп урнашулары һәм башка күренешләр. Болар барысы да Тәуратта һәм Инҗилдә, шулай ук Коръәндә дә бик төгәл сурәтләнгән. Ә аермалы якларга килсәк, мөгаен, шуны әйтеп китәргә кирәктер: Коръән язмалары тулырак та, төгәлрәк тә. Мисаллар кирәкме? Рәхим итегез. Библия буенча, имеш, Галәм алты көн эчендә яралган, ә җиденче көнне иҗатчы ял иткән. Уйлап карыйк әле, ничек, нинди системага нигезләнеп исәпләнелә икән әлеге «эш көннәре»?

Коръәндә исә болай диелә: «Ару-талуны белмичә, без Галәмне илле мең ел озынлыгына тиң булган алты көн эчендә яраттык».

Мондый аңлатмалар Коръәндә бик еш китерелә.

**— Гафу итегез, турыдан-туры сорау: Сез ничек уйлыйсыз, Алла бармы һәм Ул берме?**

— Без мөселманбыз. Динебез исламдыр. Ислам диненең нигезе, беренче шарты — Аллаһның барлыгына вә берлегенә инану. Аллаһы Тәгалә ул — катлаулы дөнья программасының инженеры. Галәмнең гамәли механизмын тудырган олуг Зат ул.

Әйләнә-тирәбездә күзгә күренгән, күренмәгән йөз-меңнәрчә нәрсәләр бар. Мәсәлән, ике күзәнәкнең бергә кушылуыннан яңа шәхес тууы, ми эшчәнлеге, кеше фикерләренең һәм тойгыларының ерактан сизелүе (телепатия), биокыр (биополе). «Алладан башка Тәңре юк, Мөхәммәд — Алланың илчесе».

**— Дарвин тәгълиматларына ничек карыйсыз?**

— Тамырдан каршы мин. Комьютерны инструкция буенча өйрәнгәндә аның инженер тарафыннан уйлап табылып төзелүенә һич тә шикләнмисез. Ә нигә сез Галәмне тудыручы инженерның бар икәнлегенә ишанмыйсыз?

Галәмдә төрле-төрле кешеләр, хайваннар, үсемлекләр, Кояш, Ай вә хисапсыз йолдызлар бар. Болар берсе дә үзлегеннән бар булмаганнарын, боларның бөтенесен яраткан, юктан бар иткән бер яратучының барлыгын аңлыйбыз. Ләкин кем? Тәүлектә 24 сәгать, елда 12 ай, ел фасыллары, йолдызлар системасы, планеталар... Ышаныгыз, бу гигант механизмны тик бер даһи Инженер гына төзи ала.

**— Коръәнне кайбер «яхшы белүчеләр», имеш, анда «гаделсезне үтер!» дип язылган, дип тәкрарлыйлар. Дөресме?**

— Тик бер нәрсәне һич кенә дә истән чыгарырга ярамый: теләсә кайсы текстны укыганда да, Коръәнме ул, йә башка язмамы, бер юлны контексттан аерып алып укырга кирәкми. Сезнең сорауга җавап итеп Коръәннең 47 нче сүрәсен китерәм: «Әгәр алар сезнең яныгыздан китмәсәләр, сезгә тынычлык тәкъдим итмәсәләр, сезгә каршы башлап кул күтәрсәләр, тотыгыз да юк итегез сез аларны».

Аңлашыла ки, монда үтерү факты алдында һөҗүм итү акты тора. Димәк, дошман сезгә башлап кул күтәрә, дигән сүз.

**— Коръән дөньяның ничә телендә тәрҗемә ителгән?**

— Алтмыштан артыграк булыр, минемчә.

**— Сезнеңчә кайсы автор-тәрҗемәченең тормыш юлы кызыклырак?**

Мин аларның берсенеке дә башкаларныкына охшамаган, дип әйтер идем. Мәсәлән, Коръәнне инглиз теленә тәрҗемә итүчеләрнең берсе — Абдулла Юсыф Али. Үзе үлгәннән соң 45 ел узгач кына аның хезмәтен бастырып чыгаралар. Аның тәрҗемәсе төп нөсхәгә мәгънәсе ягыннан да, поэтик яктан да бик якын. Юсыф Али чыгышы буенча Һинд мөселманы. Оксфорд университетын тәмамлый, бик күп мөселман илләрен йөреп чыга. Озак вакытлар Лондонда яши. Гарәпчәдән тыш, инглиз телен дә бик яхшы үзләштерә. Юсыф тәрҗемәсенең үзенчәлеге шунда — ул, ислам традицияләре белән беррәттән, Коръәндә югары фәнни дәлилләр дә китерә.

Яисә икенче бер автор биографиясенә күз салыйк. Ул — Гордий Семенович Саблуков. 1804 — 1880 елларда яшәгән. Вафатына ике ел кала Коръәннең рус теленә тәрҗемәсен төгәлли. Бу шәхеснең тормыш юлы заманына күрә бик кызыклы булган. Ул Сарытау руханилар семинариясендә укыткан, татар телен бик яхшы белгән, танылган рус язучысы Н.Г.Чернышевскийны да татарча укырга-язарга өйрәткән. 1849 елда Г.С.Саблуков Казанга күчеп килә һәм андагы Руханилар Академиясендә профессорлык дәрәҗәсенә ирешә. Мөстәкыйль рәвештә берничә көнчыгыш телен өйрәнеп, көнчыгыш телләре белгече булып китә. Бөтен гомерен Коръәнне тәрҗемә итүгә багышлый.

Изге Китапны рус теленә тәрҗемә итүче тагын бер шәхес — Д.Н.Богуславский. Тормышы да игътибардан читтә калырлык түгел.

Кавказлыларның патша колонизаторларына каршы азатлык хәрәкәте җитәкчесе имам Шамил Калугада сөргендә булган чакта, аңа күзәтүче итеп рус армиясе генералы Дмитрий Николаевич Богуславский билгеләнә. Тоткын янында үткәргән көннәрен генерал файдалы якка юнәлдереп җибәрә: Шамил имамнан ул гарәпчә укырга-язарга өйрәнә, Коръәнне тирәнтен үзләштерә һәм гомеренең соңгы елларында аны русчага тәрҗемә итә. Менә шулай.

**— Без моңынчы гел рус тәрҗемәчеләре хакында гына сүз алып бардык...**

— Әйе, әйе. Коръәнне татарчага тәрҗемә итүче авторлар да шактый. Коръән китабын яттан белүчеләрне халык Коръән-Хафиз дип атап йөрткән. Шунысын да әйтеп үтү кирәктер. Коръәнне иң беренче славян теленә, төгәлрәге, белорусчага тәрҗемә итүчеләр XV-XVII гасырларда поляк-литва җирләренә килеп утыручы татарлар булган. Дөрес, алар инде әкренләп үз туган телләрен онытканнар. Әмма тәрҗемә үзе гарәп хәрефләре белән язылган.

Узган гасырның 80 нче елларында Казанда аталы-уллы исламчылар Хөсәен һәм Мөхәммәдзариф Әмирхановлар тәрҗемәсендә Коръәннең ике томлыгы нәшер ителә. Шул ук елларны Истанбулда да төрек галиме Пинтаби Мәхмүдинең дүрт томлыгы дөнья күрә. Безнең бабайлар һәм әтиләр дә әлеге хезмәттән бик теләп файдаланганнар.

Татарстанның хәзерге матбугатында Коръәннең татарча сүрәләре һәм аятьләре исламчы галим Шәйхелислам Әсадулла улы Хәмиди аңлатмаларына таянып бирелә. Ул 1869 елны Буа өязендә туа, озак вакытлар Сарман волосте Яхшыбай авылында мөселман мәхәлләсенең имамхатибы вазифаларын башкара.

1907 елда Оренбургта Ризаэтдин Фәхретдин, Уфадагы «Галия» мәдрәсәсе ректоры, профессор Зыя Камали (елы билгесез) тәрҗемәләрендә дә дөнья күрә Коръән китабы.

**— Сүз уңаеннан сорап китик әле, сезнең китап укучыларга татар телендә дә барып ирешәчәкме?**

— Кызганычка каршы, мин бу хезмәтемне бик үк куандырырлык булмаган дәлилләрне күздә тотып яздым. Татарстаннан читтә яшәүче күп кенә милләттәшләребез туган телләрендә укый-яза белмиләр. Бик аяныч хәл бу. Алар өчен дә, һәм шулай ук рус халкын да Коръән белән якыннанрак таныштыру максатыннан әлеге җыентыкны нәшер иттем дә инде мин.

Шушы көннәрдә китабымның татарча варианты дөньяга чыкты.

**— Химаячелек турында сүз чыккач, әйтеп үтсәгез иде: хезмәтегезне бастыруда кем ярдәм итте?**

— Бу эштә миңа тулысы белән «Лукойл» нефть компаниясе булышлык күрсәтте. Анда минем фикердәшләрем, тарафдарларым шактый булып чыкты...

Әңгәмә соңында укучыларга замандашыбыз, профессор Мөхәммәд Нури Османов сүзләрен җиткерәсем килә (ул Коръәнне даргин һәм рус телләренә тәрҗемә иткән): « Коръәнне танып-белү өчен бер кеше гомере генә җитми, аны дөньяның барча телләренә дә тәрҗемә итеп чыгу зарур. Шуңа күрә мин Русиядә Коръән институты булдыруны мөһим гамәл дип саныйм».

Әгәр кодрәтемнән килсә, мин мондый институтны Татарстан Фәннәр Академиясе каршында оештырыр идем. Бездә бит Коръән тәрҗемәләрен барлау һәм тикшерү зур тарихи әһәмияткә ия һәм моның буенча шактый хезмәтләр тупланган. Коръән институты халкымны рухи пакьлеккә, яңарышка китерер иде...

Шәхсән мин үзем Ягъсуф әфәнде Шәфыйковның әлеге кызыклы һәм тарихи фактларга бик бай җыентыгын гомуми белем бирү мәктәпләрендә өйрәнергә тәкъдим итәр идем. Факультатив дәрес кысаларында булса да, аның файдасы укучыларга тими калмастыр, минемчә.

Ә инде өлкән яшьтәге кешеләр өчен бу китап — Коръәнгә якынаюның иң кыска юлы.

*Тәнзилә Хуҗәхмәтова*

# Эчтәлек

Кереш сүз . . . 3
М.Ш.Шәймиев: «Җиребез барчабызга бер генә...» . . . 5
Мортаза Рәхимов: «Без бергә һәм дус яшибез...» . . . 26
Ф.Ә.Табеев: «Үткән елларым — байлыгым минем» . . . 38
Чишмәләр һәм урманнар дөньясы . . . 51
Мансур Хәсәнов: «Без янарыш чорында яшибез» . . . 56
Альберт Бикмуллин, Халыкара мәгълүматлаштыру академиясе президенты: «Мәгълүмат кем кулында — дөньяга шул хуҗа» . . . 80
Язмыш йөртә татарны . . . 86
Кемнәр алар татар морзалары? . . . 94
Абыйлы-энеле Акчуриннар . . . 107
Тинчуриннар Ростов-Донда . . . 127
Кавказлы әсир . . . 134
Ренат Ибраһимов: «Мин «Газпром»да да җырлыйм» . . . 145
Сугышлар шулай бетә... . . . 149
Ике язмышның тантанасы һәм фаҗигасе . . . 171
Казак тамыры качактан . . . 177
Татар Мәскәве . . . 185
Явызлык империясе яки империянең явызлыгы . . . 195
«Бер могҗиза беләм мин...» . . . 202

*Шәфыйков Ягъсуф Долмаганович*

**БЕР ОЧРАШУ — БЕР ГОМЕР**

(Мәшһүр татарларның гыйбрәтле язмышлары турында 17 әңгәмә)

Мөхәррире *Р.У.Әмирханов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Рәссамы *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *Н.Н.Мусина*
Корректоры *М.Ш.Хәйруллина*

Нәшриятка 04184 нче номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 28.11.2002.
Форматы $60\times90^{1}/_{16}$. Офсет кәгазе. «Антиква» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 13,0+рәс.3,0+фор.0,25. Шартлы буяу-оттиск 26,5.
Нәшер-хисап табагы 14,09+рәс.3,19+фор.0,39. Тиражы 2000экз. Заказ Б-600.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул.Баумана, 19.

**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.